www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әхтәм ЗАРИПОВ. Әманәт. *Бәян.* ....................3
Гәрәй РӘХИМ. Язмышлар ул — безнең ялгышлар. *Шигырьләр.* ....................48
Әмирҗан МОТАЛЛАПОВ. Йөзә торган арба. *Бәян.* ....................50
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Бу заман нинди заман соң? *Шигырьләр.* ....................65
Ләлә САБИРОВА. Бер уч борчак. *Бәян.* ....................69
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Җир шарына әйләнүләр телә. *Шигырьләр.* ....................86
Наилә ХАРИСОВА. Эссе җәйнең ун көне. *Бәян.* ....................90
Ленизa ВӘЛИЕВА. Мәңгелек бәхеткә ышанам. *Шигырьләр.* ....................126
Рүзәл МӨХӘММӘТША. *Хикәяләр.* ....................129
Гөлгенә КӘРИМОВА. Кайгылыга кулым суздыммы? *Шигырьләр.* ....................138
*100нче бит:* Рүзәл МӨХӘММӘТША. Татарлыкта татар улы... кем? ....................100

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Нурфия ЮСУПОВА. «Йөрәкләр турында язасы бар әле...» ....................141
Алия МӨБАРӘКШИНА. Тукай турында «Кардәш каләмнәр». ....................145

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Тукай очырган карлыгачлар: Оркыя Ибраһимова. ....................150

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Яшәү матурлыгы — саулыкта *(Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы Рөстәм БАКИРОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе).* ....................153

ТАРИХ

Дамир ИСХАКОВ. Татар халкының этник тарихын яңадан барлау. ....................159
*Юбилейга барышлый:* Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ: Журналыбыз турында. ....................176
IX Халыкара Мәхмүд Кашгари исемендәге хикәяләр конкурсы. ....................177
Татарстан Язучылар берлегенең XVIII корылтаеннан күренешләр. ....................178

АК ҖИЛКӘН

Хикәя яза аласызмы? *(Гөлзадә САФИНА, Гөлшат ДӘҮЛӘТБАЕВА хикәяләре).* ....................180

ТАБИГАТЬ ҺӘМ МИН

Рәфикъ ЮНЫС. Хатирәләр. ....................185
*Шаян сәхифә.* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....................187

«Казан утлары» архивыннан. ....................148
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....................190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер)**.**

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.1268).*
: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612)*.

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.06.2016, график буенча 30.06.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-1627. Тираж 4016.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2016 ел



Әхтәм
Зарипов

# ӘМАНӘТ

БӘЯН

**1 БҮЛЕК**

## Маҗаралар башланганчы...

...Узган гасырның соңгы бер елында миңа Согуд Гарәбстанына бару насыйп булды. Әткәй мәрхүм васыятьләреннән берсе – Бөек Ватан сугышында һәлак булган абыйларымның каберләрен табып, зиярәт кылу булса, икенчесе – барыбыз өчен дә дип Хаҗ кылу иде.

Олы абыйның үлем хәбәренә кадәр килгән хаты: «Мадьярларның «Тарпа» дигән авылы өчен сугышка керәбез», – дигәне соңгысы булса, кече абыйныкы: «...Сугыш бетәргә күп калмаганга охшый, чәчүгә чыкканчы кайтарырлардыр, баянны сораучы булса – сатыгыз, монда хуҗалары ташлап качкан хуторларда нимес гармуннарының төрлесе очрый, «аккордеон» дигәннәренең ак телләренә басып уйнап караган идем – татар көйләре тальяндагы кебек яңгырый. Командирлар рөхсәт итсә – үземә биш рәтлесен, энекәшкә өч рәтле, сөяк тышлы, ефәк эчлесен алып кайтырмын, парлап уйнарбыз... (бер-ике юл боздырылган).

...Гродноны алгач, званиемне үстерделәр, мин хәзер сержант булдым, («младший» дигәне әйтелми). Медале дә озак көттермәстер... (боздырылган юллар).

...Кичә сакта торганда, сыерчык сайравын тыңладым. Нәкъ бездәгечә сайрый. Әллә безнең өянкедәге ояда үсеп очкан сыерчык идеме икән ул?..»

...Хат шушы урында өзелә. Барыбызны да гаҗәпкә калдырып, ничә еллар буена елаткан бу хат «хәбәрсез югалды» хәбәреннән соң өч ай узгач, таныш түгел кул белән язылган конвертта килде. Әллә инде шуннан чыгып, әнкәй үзе үлгәнче кече абыйны – исәндер, гарипләнгәндер, шуңа гына үз кулы белән яза алмыйдыр, бер кайтмаса – бер кайтыр, дип көтеп яшәде. Соңгы хатта язылганнарны көйгә салып «укый» иде. Аның соңгы хат булуына ышанырга теләмәде, мәрхүмә...

...Абыйларның кайда җирләнүен белергә әткәй республика органнары аша юллату сорап караса да, «хәбәрсез югалган солдатларны эзләү дәвам итә» дигәннән артык җавапка ирешә алмады.

---

Әхтәм ЗАРИПОВ (1935) – *режиссёр, актёр, сценарист, прозаик һәм публицист. Татарстанның атказанган эшлеклесе. Казанда яши.*

...Институтта укыганда, кече абыйның өзелгән соңгы хатын конвертка салып җибәргән лейтенантны үзлегемнән эзләп тапсам да, аның җавабы шатландырырлык түгел иде: «Үлем хәбәре кумү взводына тапшыргач җибәрелә, ә кумү взводының маршрутын да, язмышын да хәрәкәттәге армия частьлары контрольдә тота алмый, аларның да, бомба яки снаряд төшеп, һәлак булуы ихтимал. Сугыш кагыйдәләргә буйсынмый. Аның үз кагыйдәләре, үз кануннары, үз законсызлыклары...» «Бәлки» һәм «ихтимал»ларга өметләнеп, 60 яшем тулганда Хаҗ сәфәренә юллама табуга ирештем. Күңелнең бер почмагында абыйларны күргән-белгәннәрнең берәрсе белән очрашу өмете дә пыскый иде...

...Әгәр дә 30 нчы елларда «кулак» дип әткәй-әнкәйнең йорт-җирен, каралты-курасын, мал-туарларын сатмаган булсалар, әткәй васыятьләренең берсен булса да үтәү мөмкинлегем булыр идеме?! «Раскулачивание» дигән мәхшәрне үз күзләре белән күргән авылдашларым мине очраткан саен: «Атаңны талап саткан Юзбашев оныклары хөкүмәттән компенсация акчасы ала, ә син йоклап йөрисең», – дип тукый торгач, ниһаять, сорап карарга тәвәккәлләдем һәм тиешле оешмаларга гаризалар җибәрдем. Җавап артыннан ике ел чабарга туры килсә дә, тырышу бушка китмәде: ике катлы нарат йорт, бозаулары белән ике сыер, колынлы бия, алты баш сарык, икешәр оя каз-үрдәк, кием-салым, савыт-саба өчен ун мең сум компенсация акчасы бирделәр. Ягъни, бер бозау кайтты! Аварияда ватылган «Москвич-12» машинасын «запчастька» саткан акчаны да өстәгәч, Хаҗ кылу юлламасына җитәрлек сумма тупланды.

...Шатлык белән әзерләнеп һәм әсәрләнеп юлга чыктык.

Юл газабы – гүр газабы, дисәләр дә, җәфа күрмичә генә, Мәккә каласына килеп төштек. Кунакханәләрнең шәп дигәненә урнаштырдылар. Ашханәсе этаж саен, ашау-эчү бушка. Гыйбадәтеңне генә калдырма! Шулай итеп, без Согуд Гарәбстаны короленең кунаклары статусындагы хаҗилар булдык.

«Хаҗи булдык» сүзе җиңел язылса да, чын хаҗи булу өчен күп көч сарыф итәргә кирәклеген мин анда баргач кына тойдым.

Ислам дине йолаларын шәригатьчә үтәү өчен сәламәтлек тә, ихласлык та, җаваплылык та кирәклеген белә идем.

...Ихрамнан башлап, Корбан гаетендәге таш атуга тиклем гыйбадәт-йола төрләренең барысын да, мөмкин кадәр Коръән кушканча, үтәргә тырыштым.

Кыймылдарлык хәлем калмаганда да, фарыз гамәлләрне генә түгел, сөннәтләрен дә калдырмадым. Кая да булса бара алмаганда, утырган, яки яткан килеш үтәдем. Бу минем мактануым да, аклануым да түгел. Язмама ялган керүдән саклануымны күрсәтү дип кабул итәрсез.

...Хаҗ вакытында гыйбадәт гамәлләрен җиренә җиткезеп кылуда «хызырның» ярдәмен сүзләр ярдәмендә генә аңлатып булмас. Аларны үлчәү ихтималы да, җае да юк. Аның ярдәмен чиксезлек белән генә күрсәтеп булыр иде. Чиксезлекнең үзен нинди тамгаларда күрсәтергә? Шуңа күрә... шулардан чыгып, язган сүземә ышануыгызга өметләнеп, тагын бер серемне ачам: «хызыр» «маҗараларын» исәпкә алмаганда, минем Хаҗда күргән, белгән, кылганнарым башка хаҗиларныкыннан аерылмый.

Атың барда – җир таны, атаң барда – ир таны, дигәннәр. Бу заманда атай да, ат та түгел – эшне үзеңнең атың популяр булу хәл итә икән. Бер канатым театрга, икенчесе телевидениегә тоташып көч алган атым аркасында, бүлмәдәге тугыз танышның һәркайсы, күреп булмаса ишетеп, мине беләләр булып чыкты. Күрше бүлмәдәге якташлар арасында да танучылар табылгач, мине монда шөһрәтле кешедән саныйлар. Мин, әлбәттә, моңа каршы түгел идем...

Очрашкан чакларда: «Бә, ...син дә мондамыни?!» – дип, юк сүзне бар итәргә тырышып, намазга да, Мәккә урамнарын тамаша кылырга да, ашханәгә дә бергә барабыз.

...Барыбызның да өстендә, гомум мунчадагы кебек, ак чүпрәк бөркәнчек кенә булса да, минем кулдагы видеокамера үз ролен үтәгәндер – кая барсам да, таныш хаҗилар миңа иярергә, «киногa төшәргә» тырыша, абруемны шул ныгыта иде.

Кемнедер ишәккә атландырып, кемнедер дөя сыртында видеотасмага, кайберләрен ишәк хуҗасы белән кочаклаштырып фотога төшерәм.

Ни өчен ишәк хуҗасы белән, дигәндә, ул үзебезнең Питрәч керәшене Сергей булып чыкты. Кайчандыр хоккейчы булган икән. Кредит түләүдән качып, Гарәп Әмирлеге командасына күчкән. Үз капкасына алка керткән өчен гаепләнеп, куылгач, монда килгән. Җиденче ел инде илгә кайтканы юк икән, Мәккәдә боз сарае төзелгәч, кабат уйный башларга өметләнә. Җилән, чалмага өстәмә исемен алыштырган – Сөләйманга әверелгән, тормышыннан канәгать, «ниһаять, үземне таптым», ди. Килүебезнең икенче көнендә иртән иртүк булды бу очрашу. Бездән акча алмады. Киңәшләрен дә кызганмады. Өстәвенә, күп хатынлы гарәпнең адресын бирде, өйләдән соң унҗиде хаҗи шул гаиләне тамаша кылырга киттек. Тик... гаиләнең ашау вакытына туры килдек. 30 метрлар чамасы ара калдырып, дүрт хатынның бер ирне ничек бүлгәләүләрен күрәсебез килеп көтсәк тә, кызыклы тамаша урынына, каяндыр кинәт пәйда булган полицейскийның ачулы йөзен күрү генә насыйп булды. Коръән тыйган гамәлләр белән шөгыльләнәбез икән!..

Бәхетебезгә, арабызда инглизчә сөйләшүче бер абзый бар – шул коткарды. Аңлавыбызча, ул гарәп хатыннарына беребезнең дә дәгъвабыз юклыкка ышандырырга тырышса да, полицейский, беләзекләрдәге язуларны укыгач, группаларга аерып тезде дә көткән машиналарына таба алып китте, төялергә ымлады. ...Чирек сәгать узмагандыр – кунакханәбезгә китереп тә «аударды». Җаваплы кешеләрне чакыртып, ниндидер язуларга кул куйдылар, фотоаппаратларны алдылар. Миңа шундагы тылмач аша видеокамерамның саклау бүлмәсенә бикләнәчәген, рөхсәтсез камера тотып урамга чыккан өчен штраф түләргә кирәклеген төшендерделәр. Мин, үзебезчә, акчам юклыкны аңлатырга тырышсам да, ишетүче булмады. Инглизчә сөйләшә белгән теге хаҗи гына полицейскийдан нидер сорады да миңа карап тынычланырга ымлады.

Ашыбызга төшкән «тараканнан» котылып, бүлмәбезгә кайтып керүгә ирешкәч, озакка сузылган фикер уртаклашуларның нәтиҗәсендә: ислам дине туган бу җирдә тәртипләр кирәгеннән тыш кырыс икән, дингә ислах – реформа кирәк икән, дигән карарга килдек. Протоколларсыз, сүздә генә, әлбәттә. Төрле карарлар кабул итеп, аларны үтәмәскә өйрәнгәнлектән, реформа сүзен кабат искә төшерүче булмады. Үзебезне җиңүчегә санап тынычландык. Видеокамерамны тартып алулары кәефемне бозса да, бүлмәдәшләремнең берләшә белүе аны тиздән йолып алачагыбызга өметләндерде.

...Инде бу бердәм төркемнең һәркайсы белән аерым-аерым таныштырып үтү кирәктер. Мине таныгансыздыр: авылда туып, шәһәрдә гомер уздырган бер «даһимын». Калган тугыз «даһиның» өчесе «Казан ятиме», икесе Мәскәү астыннан – табиблар. Түбән Новгород белән Чувашиядән ике бизнесмен – итчеләр.

Казан ятимнәреннән Мәхмүт абый кайчандыр судья булган. Хәзер адвокатлар коллегиясендә юрист-консультант вазифасында икән. Рәшит Нуриевич – хәрби очучы булып эшләгәндә чукраклангач, таможня хезмәтенә күчкән, монда күз кирәк, колак безгә нипочём, дип көлә. Орден-медальләре өстенә «Очучы бәхете»

дигән китап яздырып, Язучылар оешмасында «член» булуына таныклыгы бар, кирәксә дә, кирәкмәсә дә шуны күрсәтеп, үзен «әдип» дип таныта. Хәйдәр Кыямович исә Иске Бистәнең яңа мәчетендә «запасной» мулла икән, пенсиягә «куылганчы» төрле органнарда «числился», соңгы эш урынын «контролёр за исполнением наказания» дип горурлана. (Куштырнаклар эчендәге сүзләр аның үз авызыннан чыкканга, үзгәртүне кирәк санамадым.) Подполковниктан уздырмадылар, аерган хатыннар өстән яздылар, ди. Түбән Новгородныкыларның кәсебе кышын кыяр, җәен каз үстерү булса, Чувашстанныкылар ат итеннән казы ясап сата икән. Ниятебез – татар яшәгән һәр төбәктә «хәләл» кибетләре ачу, диләр. Бу Шыгырдан мөселманнарының шыгырдавы гына түгел, кыскасы, бүлмәдәшләрем хәллеләр, телләрендә – Алла, ниятләре – малда...

...Хаҗ сәфәренә кадәр күзгә-күз очрашкан булмасак та, кайбер ниятләр, фикер уртаклыгы безне бер бүлмәгә урнаштырды. Уныбызны да «яңа ислахчылар» дияргә булыр иде, тик беребез дә аны нәрсәдән башларга, нәрсәгә омтылырга икәнен күз алдына китерми.

– Ниндидер агымда яшәү мәҗбүриме?

– Әйе! – диләр алар, шуның өчен генә үзләрен «ислахчы»га саныйлар. Мин дә шул төркемнең бер әгъзасы буламдыр инде. Минем дә күңелем әллә кайларда оча, мин дә үзгәреш телим.

Безне, барыннан да элек, дин өлкәсендә күпне белү түгел, күп нәрсәне белмәү берләштергәндер дигән фикер дөрес булыр иде. Тик без нәрсәне белмәвебезне дә белә алмыйбыз. Әмма сүздә, бәхәстә һәркайсыбыз үзенең күп нәрсәдән хәбәрдар булуын, башкалар белмәгәнне белүен күрсәтергә тырыша.

– Мәче башлы ябалакның холкын-табигатен өйрәнү өчен, аны төнлә күзәтергә кирәк. Мин чын-чынлап дин юлына бастым. Тәүбәгә килдем. Юлымда калу өчен – Ислам диненең асылына төшенү, серләрен чишү өчен, иң элек аның туган илен күреп белү мөһим булганга, мин бүген монда – ислам динен биргән илдә... – диде Хәйдәр Кыямович бер әңгәмәбезнең кызган вакытында.

– Аллаһы Тәгалә җирне илләргә бүлгәләп карамый. Бөтен галәм Аныкы. Динне «ил бирде» дигән фикер... наданлыктан. Аны ил түгел – Алла бирә, Алла иңдерә. Без Рәсүлуллабызга илаһи вәхиләр иңә башлаган Мәккә каласында гөнаһка кереп утырабыз, – дип төзәтмә кертә Мәхмүт абый Хәйдәр хәзрәт сүзенә.

Шулай, сиздерми генә, бәхәс кузгалды. Һәркем үзенең белгәнлеген күрсәтергә тырышып, наданлыгын раслый башлады.

– Пәйгамбәребезнең вафатыннан соң византиялеләр белән булган сугышларда Коръән хафизлар шәһит киткәч, хәзрәте Гомәр ибне Әл-Хәттаб, хафага төшеп: «...Әгәр дә без тиз арада Коръән аятьләрен җыймасак, аның күп өлеше юкка чыгуы ихтимал. Ничек тә Коръәннең язма нөсхәсен булдырырга кирәк...» – дип сүзен дәвам итә Мәхмүт абый. Сагаябыз... Мәхмүт абыйның сөйләвен бүлдерүче юк. «Республиканың атказанган юристы» дигән дәрәҗәле пенсионер бит! «Рәсүлебез башкармаган эшне ничек инде без башкарыйк?» – дип Гомәргә каршы чыкты Әбүбәкер.

Тынлык урнаша. Хәйдәр хәзрәт ятарга дип урын әзерли. Янәсе, аңа болар күптән билгеле!

– Бу бит каршы чыгу түгел, ә куркып калу, шик белдерү, – дим мин, бәхәс сүнмәсен өчен. Мәхмүт абыйга, күрәсең, шул гына кирәк:

– Дөрес әйтәсең: куркып калу, шик белдерү – каршы бару түгел. Хәйдәр хәзрәт, мәсәлән, минем әйткән һәр фикеремне шик астына ала икән, бу аның

миңа каршы чыгуы түгел, ә мәсьәләне тирәнрәк төшенергә теләве, бәхәссез кабул ителердәй җавап эзләве. Эзләнү гаеп түгел...

Хәйдәр хәзрәтне «йомшак тотып катыга утыртуы» белән Мәхмүт абый бүлмәбезнең лидеры булып танылды.

Барыбыз да «йотылып» аны тыңлыйбыз. Күптәннән таныш легенданы беренче тапкыр ишеткәндәй күрсәтергә тырышабыз.

– ...Хәзрәте Гомәр әйтә: «Үзебездән булмаса, булдыручыны табып, бу изге гамәлне кылдырырга һәммәбез бурычлыбыз», – ди. Табалар кешесен! Ул Зәед ибне Сабит-пәйгамбәребезнең сәркатибе булган Сәхабә икән.

– Зәед! – диләр аңа. – Син сәламәт акыллы, зирәк фикер йөртүче, тапкыр телле, хәтерле кеше. Без сиңа ышанабыз. Син Коръәнне өйрәнү һәм туплау эше белән шөгыльләнергә тиешсең!

– Әгәр Арафат тавын бер урыннан икенче урынга күчереп куярга булса, җиңелрәк булыр иде, – дип, Зәед ибне Сабит эшнең үтә дә җаваплы булуын искәртә.

Әгәр дә ул шулчак карышкан булса, безнең кулда бүген шушы Коръән булмас иде.

...Яфракларга, дөя-куй хайваннарының калак сөякләренә язылганнардан, аерым сәхабәләрнең хәтерләрендә сакланган фикерләрдән беренче нөсхә Коръәнне туплый бу изге җан.

– Икенчел нөсхә Коръән дә бармы әллә? – ди Мәскәү асты хаҗие, учакка утын өстәп. – Гаҗәп икән, бик гаҗәп... «икенчел Коръән»...

– Гаҗәпләндерерлеге шул: туплау эшләрен төгәлләгәч, Коръәннең төп нөсхәсен ул Гомәргә түгел, ә шик белдергән Әбүбәкергә тапшыра! – ди Хәйдәр хәзрәт, сүзгә кыю катнашып.

– Кемгә тапшырса да, шул нөсхәдән күчерелә-күчерелә үрчеп, Коръән барып җитмәгән ил калмый. Тәңречелек белән яшәгән безнең бабаларыбыз да аңа табына. ...Мөстәкыйльлегебезне югалтуга беренче адым шул чакта ясалмадымы икән? – ди Мәхмүт абзый, провокацион фикер өстәп.

Әллә аңламаудан, әллә куркудан бу сорауга җавап бирергә ашыгучы юк. Тынлык урнаша.

– Коръән – ислам диненең мәйданнар яулап, халыкларны буйсындыруда иң отышлы коралы булган.

– Мәхмүт абый! Син судья булган кеше. Хөкем процессы барган вакытта кодексларның статьяларын тикшермиләр. Мин әйткәннәрне үз карашыңны яклауга таба борма. Коръәнне тикшерүнең нәрсәгә алып баруы сиңа сер булырга тиеш түгел. «Хакыйкать хакына» дигән булып, күңелләргә коткы салып утырма. Яшәүнең Алла хөкеме икәнен, гөнаһларыбызны ярлыкатыр өчен Хаҗга килүебезне онытмыйк. Коръәнгә ышанычыбызны югалтмыйк!

...Мондый патетик чыгышлардан соң «яшәсен!» дип кычкырырга яисә «көчле алкышларга күмәргә» гадәтләнгән булсак та, сөйләшүнең юнәлешен үзгәртү кирәклеген тоеп: «Амин!» – дидем мин. Барысы да миңа таба борылдылар. Шуннан файдаланып сүземне дәвам иттем:

– Ничек уйлыйсыз: Коръәнне Конституциягә тиңләү дөресме? Әллә үз чорының универсаль кодекслар җыентыгымы ул?

– Ә нигә үз чорының гына?

– Уголовный кодекс бар иде – үзгәрде, гражданский башка. Коръән һаман шул килеш яши бирә!

– Яшәсен! – диде Хәйдәр хәзрәт, ни белән чагыштырырга маташсак та. – Коръән чагыштыргысыз, бердәнбер ул, ягъни, кояш кебек...

Бәхәснең кызып барган чагында, биргән сорауларга җаваплар бугаздан чыга башлагач, бүлмә ишеге ачылып, агарынган йөзле, күгәргән борынлы – Рәсәй хаҗиларының җитәкчесе килеп керде.

– Нинди мал бүлешәсез сез? «Сезнекеләр сугыша», – дип, кизү торучы кереп уятты. Ятыгыз, зинһар.

– Сугышмыйбыз, хакыйкать эзлибез.

– Хакыйкать табылган – Коръәндә ул, – диде җитәкче.

– Әгәр сорауларыбыз булса?

– Сорауларыгызны иртәгә Мәккә каласының иң мәртәбәле имамына бирерсез. Рәсәй таралгач барлыкка килгән мәмләкәт хаҗилары белән очрашу үткәрергә киләчәк, ди. Сынатасыгыз килмәсә, сорауларыгызны язып барыгыз. Түлке, җәмәгать, Коръәнгә тел тидерүдән сакланыгыз.

– Без Коръәнгә тел тигезмәбез, хаҗи. Тик андагы кайбер аңлашылмаган аятьләр буенча соравыбыз гына ихтимал.

– Зинһар, фетнәчелеккә тартмагыз. Болай да гөнаһлар баштан ашкан. Пенсиягә чыгарга да күп калмады...

Җитәкче китте.

Без, ясигъ намазына бармыйча, сораулар әзерләргә керештек.

Миңа аларны теркәп бару эшен йөкләделәр. Иң беренче сорау итеп Мәскәү врачыныкын куйдык: «Әгәр, Зәед әфәнде исән булып, аңа Коръәнне заманга яраклаштырып язу эшен йөкләсәләр, алыныр идеме икән? Алынса, күпме гонорар билгеләнер иде икән?.. Әллә инде Нобель премиясенә тәкъдим ителер идеме икән?..»

Бу сорау «провокационный» дип табылды, мәсьәләгә җитдирәк килергә куштылар.

– ...4 нче сүрә, 81 аять: «Нинди дә булса яхшылыкка ирешсәң – Алладан, ә начарлыкка юлыксаң – ул үзеңнән», – диелгән. Язмыштан узмыш юк, дигәнне фаш итмиме бу? Ягъни, начарлыкка юлыкканда, Алла читтә калып, ләүхелмәхфүз юкка чыкмыймы?

– Чыга! – дидем мин, ашыгып.

– Чыкса – яз шуны сорау итеп, шомартып!..

Тагы 16 нчы сүрәгә күчеп, 95 нче аятькә карыйк: «Алла, теләсә, һәммәбезне бертөрле итә ала. Теләгәнен аздыра, теләгәнен туры юлга юнәлдерә ала. Әмма сездән барлык кылган гамәлләрегез өчен үзегездән генә җаваплар соралыр...» Инде, шуңардан чыгып, сорауны яз: «Димәк, Алла кешеләрне үзе теләп аздыра, туздыра да шуның өчен кешене җавапка тарттырамы? Бу аятькә таянганда, «гадел», «иң шәфкатьле» дигән зат кем була соң?..

Гомәр Хәйям болай дип язган:

«Яраттың да, Ходай, минем җисемне син.
Язып куйдың эшләнәчәк эшемне син.
Үзең язган гөнаһларны кылган өчен,
«Җәһәннәмгә, кеше, син кер, дисең!»

– Гомәр Хәйям сүзләрен язаргамы, юкмы? – дидем мин, тукталып.

– Сорауны яз, ә җавапны миннән түгел, шәехтән сорарсың...

...Мөмкин кадәр ишетелмәгән, яңа сораулар гына бирергә дип килештек тә, көймәбез комга терәлеп, туктап калдык.

– Ә кем боларны барыбыз исеменнән шәехкә җиткезергә алына? – диде Мәхмүт ага.

Барыбыз да атказанган юристның үзенә карадык. Ә ул исә катгый баш тартты:

– Киләсе сайлауларда, исән-сау булсак, мин үземне мөфтилеккә кандидат итәргә ниятлим. Мөфтиенә узалмасам – казыйлыкка казык кагарга да риза. Шул ноктадан караганда, үземне Коръәннән хата эзләүче итеп күрсәтү яраган эш булмас. Сорауларның мәхәллә мулласы авызыннан әйтелүе дөрес булыр.

– Әйе шул, – диде Хәйдәр хәзрәт, кабынып, – мәхәлләбездә беренче хәзрәт булу-булмау мәсьәләсе чишелергә торганда, Коръәнгә ревизия ясаучы булып күренергәме? Ярый ла Муса Бигиевтан Тукай гына көлгән. Хәзер һәр рифмачы үзен Тукайдан өстен саный... Көлеп кенә калмаслар... Әнә... кем... Чувашстан батырлары сорасын!

– Без батырлар түгел – ә Батыр районы сугымчылары!

– Шуңа күрә әйтәм дә... Сезгә бит «хәләл» супермаркеты ачарга фатиханың хаҗлысы кирәк... Җайлаштырып шуңа бәйлисез дә...

– Бәйлисе юк! Суперлар белән ил тулы, итен генә китер...

– Алайса, әнә – Мәскәү дантистлары сорасын! Алар дин гыйлемендә наданлыкларын яшермиләр...

– Беренчедән, без дантист түгел, ә терапевт высшей категории; икенчедән, стоматолог дипломыбыз да бар безнең; өченчегә, «ислам дине докторы» дигән диплом обещали... Так что, пускай теледиктор и спрашивает... ему терять нечего...

Минем бакчага ыргытылган таш иде бу. Җавапсыз калу бизәмәс:

– Йә бетәсең, йә сүтәсең очрагы бу, әфәнделәр, – дидем мин. – «Коръән серләре» авторының язмышын беләсездер: аны, үлгәнче үк «Аллаһы Тәгаләнең каһәре сукты», диделәр.

Сораулар язылган кәгазь минем алда калды.

...Күмәкләшеп җомга намазына киттек. Мәчеттә Урта Азиядән, Рәсәй төбәкләреннән һәм башка мөселман илләреннән килгән хаҗилар белән гыйбадәт залы тулган иде...

...Шәех дигәннәре көче ташып торган, тук чырайлы, кап-кара сакал-мыеклы ир уртасы кеше икән. Иярченнәре дә гайрәтле күренә. Араларыннан кыска юаны, тенор тавыш белән, Коръән аятьләре укыды. Безнең мәчетләрдә догаларны, кабатлый-кабатлый, мөмкин кадәр озаграк-озынрак итеп укырга тырышсалар, боларның вакыты кадерле, ахры, аятьләр укуны бик тиз тоттылар. Бит сыйпауга, «сорау-җавап» мәйданына күчтеләр. Рәсәйдән килеп укучы шәкертләр тылмачлык итте.

...Әүвәл Кавказ мөселманнары кыюлык күрсәтте. Шәһит китүчеләрнең ятим гаиләләренә ярдәмне кем һәм ничек оештырырга тиешлек буенча төпчینделәр. Аннары сәдакаларның күләменә тәңгәл савабы булуны раслаган дога таптырдылар.

Урта Азия хаҗиларын никах, калым йолаларын үтәгәндәге «тышаусызлыклар» борчый. Калымның керемгә чутланырга тиеш түгеллегенә кагылышлы сүрә юклыгы законсызлыклар тудыра икән. Налог агентларының авызын томаларлык аять таптырдылар.

– «Аять түгел, оят кирәк!» – диде Мәхмүт абзый, безгә генә ишеттереп.

...Алгы сафтагы хаҗи инглизчә нидер сорап маташты. Тылмач, аңа соравын язып, мәҗлес соңында имамнар бүлмәсенә керергә кушты. «Инглиз хаҗие» ризалашты.

...Имзаларын куйган безнең бүлмә хаҗилары, кул күтәрүемне көтеп, еш-еш миңа карыйлар, ашыктыралар.

Себер мөселманнары вәкиленнән соң, минем дә күтәрелгән кулны күрделәр...

...Килешү буенча, кереш сүземне шома гына әйттем. Аның шәехкә тәрҗемә

ителүен көткән арада, хаҗиларның күз карашлары, ни өчендер, мине гаепли иде. Тылмач та миңа карап: «Үзеңнән акыллы булып күренергә тырышма, күп сүз – чүп сүз, сорауларыңны кыскарак тот!» – диде.

– Алар кәгазьгә язылган, – дидем дә язуны (кулдан-кулга) шәехкә таба җибәрдем. Тылмач аны башта үзалдына гына укыды да Шәехкә аңлатырга кереште. Минем өчен бер сәгать булып тоелган шул дәкыйкадә безнең бүлмә «даһилары», сабырсызланып, миңа ачу белән карыйлар, эчтән сүгенәләр дә кебек тоелды.

...Тылмач, миңа карап:

– Бу сорауларны раслап кул куйган хаҗилар мондамы? Басыгыз!

...Басучы юк. Тынлык...

Тылмач соравын кабатларга мәҗбүр.

Беркем селкенми дә, дәшми дә. Тиз арада киңәшләшү, пышылдашу булып ала. Шуннан соң тылмач:

– Бу сорауларга җавапны, илегезгә кайткач, Диния нәзарәтеннән алырсыз.

...Минем өчен бәйрәм үтте, «сынау килде сындырып».

...Күпмедер вакыт узгач, ушыма килеп, күзләремне ачсам... ялгыз утырып калганмын. Ташлап киткәннәр...

Моңа кадәр бер дә игътибар иткәнем юк иде – йөрәк «дөп-дөп» тибә икән. «Язмышлардан узмыш юк» дип тибүедер инде...

Бүлмәдәшләр кунакханәгә кайткач, минем белән сөйләшүдән генә түгел, күзләребез очрашудан да качалар; намазга йөрүләре ешайды, ашханәгә бергәләп баралар, туңдырма тотып бергә кайталар. Миңа дәшүче юк...

Бүлмәдәшләрдә генә түгел, үземдә дә үзгәреш: өзлексез йөткерәм, температурам күтәрелде, баш сызлый, тел тотлыга, күз чагыла, колак чатный, аяк атламый...

...Кич белән коридорга чәй алырга дип чыксам, күрше бүлмәдәге таныш казанлы хаҗи очрап: «Сине һаман кайтарып җибәрмәделәрмени? – дип сорагач, тәмам хастага әверелеп, түшәккә егылдым.

Тегеләр... ясигъ намазыннан кайтып, ятарга җыенганда, Мәхмүт абыйдан сорарга җөрьәт иттем:

– Ни булды бу?

– Ни язсаң – шул булды.

– Сез әйткән сорауларны гына яздым бит, үзегез укып, кул куйдыгыз...

– Сиңа ышанып, укымадык шул...

– Инде ышанычыгыз калмадымы?

– Ни чәчсәң – шуны урырсың, энем. Ярамасны язгансың, димәк. Алланың каһәре төшмәсен дип тәүбәгә килеп ят...

– Нинди гөнаһым өчен тәүбәгә?

...Бу соравым җавапсыз калды. Бүлмәдәшләр харам мәчетенә барырга тәһарәт яңартканда, бүлмәбез докторы, каяндыр кайтып керде дә, рус телендә сәер тәкъдим белән мөрәҗәгать итте. Мин ул сөйләшүнең эчтәлеген татарчага тәрҗемәдә язам:

– Температурам югары дип врач чакыртма. Бүлмәбезне карантинга ябулары ихтимал. Миндә төрле-төрле рецепт бланклары бар. Шуларны күрсәтеп, дарулар барып алсаң, үзем дәваламын. Терелгәч, исәп-хисап ясарбыз. Үзебезнекеләрдән күп алмыйм мин...

– Миндә нинди авыру икән соң?

– Стресс! Аннары тирләгән килеш туңдырма ашагансың. Шуңа өстәмә кондиционер салкыны, нервлар...

– Туңдырманы башкалар да ашый, алар авырмый...

– Алар Коръән белән булышмый.

– Мин дә булышмадым.

– Тереләсең килсә, мә сиңа рецептлар.

– Миндә бу кадәр дарулык акча юк.

– Рецептың булса, монда акча сорамыйлар. Шикләнмәсеннәр өчен барган саен бер генә рецептыңа ал. Бу дарулар бездә дефицит.

– Шулкадәр дару эчәргә тиеш буламмы мин?

– Урын табылыр, алуың хак булсын.

– Афёра ич бу...

– «Балабыз юк» дип төтен җибәр... сорасалар...

– Бу яшьтә бала турында сүз алып баруга миңа кем ышаныр икән?..

– Баласызлык – ирләр гаебеннән генә түгел... Иптәшләргә ярдәмләшүнең бер төре булыр. Минем Хаҗга килүем дә шул бала хыялын тормышка ашыру максатыннан гына.

– Хатыныңны җибәрергә иде.

– Ул узган ел булды. Хаҗга килү өчен ислам диненә күчте хәтта...

...Төштә күргән, саташу сыман бу сөйләшү турында мин әлегә кадәр уйлансам да, җавап таба алмыйм: уен идеме, чын идеме, әллә бер сынау идеме?

Бүлмәдәшләр каядыр, мин медсанчастька юнәлдем.

...Кеше юктыр дип барсам, чират Казан клиникаларыннан ким түгел иде.

– Кем ахыргы?

– Кайсы ишеккә?

– Ишек түгел – доктор кирәк миңа.

– Тешнекеме, эчнекеме?

– Даруныкы...

– Алайса, әнә Сәлим баба артыннан бас.

Сәлим баба дигәннәре янына утырдым. Сөйләшәбез. Ул Бохара мәдрәсәсендә укыган 27 яшьлек татар егете булып чыкты. Үзбәкстанның Карши шәһәреннән килгән. Бер сорау бирмәсәм дә, үзе турында үзе сөйләп, баш авыртуын көчәйтте. Үз акчасына килүен кат-кат әйткәч, авызында калган өч тешенең дә селкенеп торуына зарланды.

– Ясалма теш куйдыр, – дидем.

– Таныш табибың булып, тиз эшләсәләр – хакыннан тормас идем, – диде ул.

– Сөйләшеп карармын, – дидем мин, абруемны төшерәсем килмичә.

– Коръән укуы авырлашты. Селкенүләренә түзәр идем дә, сызлап җәфалыйлар. Суыртырга чиратым җитүне көтеп утырам. Миңа кадәр әле тугыз кеше...

– Теш сызлауга түзеп була, җаның сызласа нишләрсең...

– Түзмим – өчесен дә суыртам... Монда акча сорамыйлар. Бушлай булганда, син дә суырт, сызлавын көтмә...

– Тешләрем түгел – җаным сызлый минем, энем...

– Җан сызлавы пүчтәк, теш сызлавы үтерә, суыртуың хәерле... – дип әйтүе булды – ишек ачылып, тешләреннән котылырга чиратлары җитүне көткән тугыз хаҗины эчкә уздырдылар. Авызларына мамык капкан ун хаҗи, учларындагы тешләрен табышка тиңләп, бүлмәләренә тайды.

...Коридор бушап калды дип уйларга өлгермәдем, башына Батулланыкы сыман бүрек кигән, йөзен чадра, гәүдәсен кара ефәк белән каплаган хатынын җитәкләп бер ир керде дә, чират торучыларның һәммәсе белән кул биреп

күрешкәч, минем каршыма килеп басты. «Әссәламегаләйкем!» дигәненә җавап алса да, күзләремә багып тора бу. Иреннәре кыймылдавын авыз эчендә дога укыганга охшата. Күңелгә нindiдер шом керде. Сыңар кулы белән битен сыйпагач, бөркәнчегенә кулларын сөртә-сөртә:

– Син шул татар бит? – диде бу миңа татарча.

– Шул, – дидем мин, шомлануымны сиздермәс өчен генә.

– Сине кайтарып җибәрергә тиешләр иде бит. Ничек син монда? Кичерделәрме, чикерделәрме?

– Хаста алды. Чирләдем. Дәваланам. Даруга килдем.

– Ай-һай, терелерсеңме икән? Һәр авыру Аллага тел тидерүдән килә.

– Мин Аллага тел тидермәдем.

– Коръәндә әйтә...

– Шул әйтелгәннәрне төшенәсе килеп язган сорауларны гына биргән кеше мин.

– Коръәндә төшенмәслек фикер юк. Кирәген таба, тапкач – укый, укыгач аңлый белү кирәк.

– Әгәр аңлашылмаса?

– Ышану тиеш!

– Ышандырмаса?

– Андый бәндә белән сөйләшеп тору да зур гөнаһ. Дәһри ул, – диде дә, хатыны янына китеп, аңа нидер сөйли башлады бүрекле.

...Чират торучылар арасында миңа карап «пышылдашулар»дан соң, барысы да каршы як эскәмиягә күчеп утырдылар. Хатынын җитәкләгән бүрекле генә утырмады.

Ярый әле шулчак ишек ачылып, ак халатлы кара доктор миңа: «Come on», – диде. Бүрекленең хатынына нәрсәдер аңлатырга тырышуыннан файдаланып, ачык ишектән җәһәт кенә ыргылдым да, ике негр егете каршына килеп, рецептларымның һәммәсен бергә өстәлләренә салдым. «Кайсына бирсәгез дә кирәкле, авыруларым күп», – дигәнне аңлатырга тиеш иде бу гамәлем.

Импортный рецептлар аларга кызык иде ахры. Үземә карамыйча, берни сорамый укыйлар да – көлешәләр. Больницаларда еш булсам да, авыру алдында көлгән врач очратканым юк иде. Түзмәдем – өстәлдә яткан градусникка төртеп күрсәттем. Докторларның утырганы русчалап:

– Жена молодая, да? – диде көтмәгәндә.

– Нет, старше меня на семь лет, – дидем.

– Тогда понятно, – диде врач, иптәшенә күз кысып. Аннары кабат рецептларны тикшерергә тотынды. «Яндым» дигән фикергә килеп, җавап әзерләгәндә, бу миңа:

– На что жалуемся? – димәсенме!..

Мин тамак авыртуны аңлатырдай ымлыклар ясадым. Докторлар, минем селтәнүләргә дә, чырайга да игътибар итми, үзләренчә сөйләшеп, көлештеләр дә, авызымны ачтырып тамагымны карагач, рецептлардагы даруларны җыя башладылар. Үзләре һаман көлешәләр иде. Дарулар табылып, катыргы тартма кулыма тоттырылуга, ишек ачылып, хатынын җитәкләгән «бүрекле» килеп керде дә:

– Почему так долго? – диде миңа.

– В чём дело? – диде доктор, мине коткарып.

«По женским вопросам мужиков не принимаем», – дигәч, хатынымның үзен алып килдем.

– Мы не гинекологи.

– Нам не гинеколог, а таблетка надо! Лекарство для беременности!

– Рецепт есть?

– Сколько долларов надо?

– У нас ничего не продаётся.

– Буду жаловаться...

...Бу пар чыгып китүгә, шәех белән очрашуда күреп калган хаҗи килеп керде дә, докторларга тиз-тиз нидер әйтеп (инглизчә!), ак җәймә япкан эскәмиягә сузылып ятты. Докторларның сүзгә катышмаганы, ашыгып, укол әсбапларын әзерли башлады. Күрәсең, бу хаҗиның монда беренче керүе түгел, сөйләшүләре дә күптәнге танышларча иде. Ә мин чыгып та китә алмыйм, сүз катарга да кыенсынып торам. Ни өченме? Чөнки бу кеше минем сораулар язылган кәгаземне тылмачлар алганны күрде бит! Аңа калырга, каядыр керергә куштылар... Безгә билгесезне белергә тиеш иде ул.

Сорарга өлгермәдем – ул үзе эндәште:

– Гафу ит, энем, бүлдердем, ахры... Уколсыз тора алмыйм. Ашыгуым шуннан гына, – диде ул татарча.

– Зыян юк, – дигән булдым.

Бу абзыйны тагы кайларда очратуымны хәтерләргә тырышкан вакыт арасында, аңа инъекция ясалып, утырырга рөхсәт ителүгә: «Нигә иптәшләреңнән калдың?» – диде ул миңа.

– Авырыйм. Даруга килдем.

– Хаҗның һәр йоласын үтәү тиеш. Берсен генә үтәмәү дә Хаҗ кылганыңны юкка чыгара.

– Хәлемнән килмәсә?

– Теләгең сүнмәсә – хәл үзе килә ул.

...Шуннан соң ул, докторлар белән сөйләшеп, сорауларына җавап алгач, миңа карап көлә башлауга, китү ягын карадым.

...Лифтта күтәрелгәндә «Хызыр»ны кайларда күргәнем искә төште: гарәп гаиләсе белән күрешергә баргач, ул мине полицейскийдан коткарырга маташты ич! ...Бусы беренчесе. ...Аннары шәех белән очрашуда инглизчә сораулар бирүче дә ул иде. Аңа имамнар бүлмәсенә керергә куштылар... Минем уемча – бу чын хаҗи түгел, ә КГБ кешесе иде.

...Артымнан күзәтеп барса – югалтсынга, лифтка утыргач, җиденче катта чыкмыйча, тугызынчыга күтәрелеп, аннан җәяүләп төштем. Эзләсен!

...Туганнарга, оныкларыма бүләк алу өчен дип, туңдырма кургашына төреп яшергән 50 долларым бар иде. Шуны алырмын да, кайтарып җибәрсәләр, эшем бетә торсынга, кибетләрдә сайланырмын, дип, бүлмәгә керсәм – матрасларыбыз идән уртасына өелгән, швабра тоткан ике хәбәш (эфиопияле) көлешеп тора. Телләрен белмәгәч, үзебезчә: «Ник көләсез, ни булды?» – дидем. Аңламасалар да, плинтуслар буйлап сузылган сөт инешләренә күрсәттеләр.

– Күрмисеңмени? – янәсе. Ашаганнан соң һәркем туңдырма алып кайтып, күршесенә тәкъдим итү белән юмартлык күрсәтә иде. Алучы булмагач, кая куйсын?! Матрас астына тыга да – оныта... Кич алып кайтып кыстырган туңдырманың иртәнгә кургашын кәгазе генә кала.. Эремәс туңдырма да катыра белмиләр икән бу гарәп феодаллары, дип сүгенәбез әчтән...

Ә хәбәшләр «русь-русь» диләр, миңа карыйлар.

Мин: «Но – татарин», – дип аларны төзәтсәм дә, һаман «русь» диләр.

Алар көлә дип, көлеп булмый – күзем белән дә, күңелем белән дә матрас астындагы 50 долларымны эзлим. Юк. Чүп өемнәре арасында да, кәрҗиндә дә юк. Димәк, тапканнар, шуңа көлешәләр. Администраторга шикаять бирә

алмыйм. Долларың декларировать ителгәнме дип бәйләнүләре бар... Дарулар белән тулы тартманы бүлмәдәге докторның тумбасына куярга дип узсам – кургашлы бөтием шунда! Табышны азсынганнармы, әллә инде соңыннан бүлешергә дип калдырганнармы?!

Ни уйласалар да уйласыннар хәбәшләр – 50 доллар капиталымны алып, «свой» дидем дә кибеткә киттем.

...Кибет дигәннәре безнең «Колхоз базары» кадәр биш зурлыктагы мәйданны биләгән «конгломерат» икән. Бер ишегеннән кереп, аккумулятор белән йөри торган канәфигә утырасың да бүләк җыясың. Мин җәяүләп кенә караштырырга булдым. Нәрсәгә тотынсаң да, хакы күрсәтелмәгән. «Скидка» дигән ялган да очратмадым. Нәрсә сайларга белми йөреп ялыккач, оныгыма дип бер курчакка орынган идем, ул дөнья бетереп еларга тотынды. Авызын томаларга кнопкасын эзләп әйләндерсәм, күләргә кереште. Тере баланы юаткандагыча, тибрәтеп тә карыйм – аның саен үҗәтләнеп, йә елый, йә көлә, каһәрең, туктамый.

...Куярга да кайтырга дип торганда, кинәт: «Һоп!» – артымнан килеп, култыклап алмасыннармы! Пәһлевандай ике полицейский!..

– Я ничего не сделал противозаконного, хотел купить вот эту ерунду! – дип, курчакны ыргыттым. Кибет тынып калды. Пәһлеваннар сүзсез генә мине каядыр алып баралар. Карышу да юк, дәшмим дә.

...Намазлыклар түшәлгән иркен бүлмәгә алып керделәр дә намазга утырдылар. Күрәсең, мине кулга алганда тәһарәтләре бозылмаган, ә минеке бала елаганда ук бозылган иде – сиздермәдем. Алар чүккәндә чүктем, бассалар бастым. Бүлмәдә намаз авазлары гына хуҗа иде.

...Өйлә намазы вакытларында бу илдә, эш тукталып, һәркемнең гыйбадәттә булуын махсус полиция күзәтә, дигәнне ишеткәнем бар иде. Мине эләктерүчеләр әнә шул йола сакчылары булган икән.

Намаз тәмамлануга, пәһлеваннар мине үз машиналарында кунакханәбезгә илтеп куйдылар. Кургашка төргән байлыгым чишелмәде.

Пәһлеваннарга мине «эләктерү» зур җиңү булса, минем өчен бу «ЧП» кайтарып җибәрелүемне тизләтүгә тагы бер саллы сылтау иде. Ни кылып карарга да, кем белән киңәшләшергә дә белмим. Мине тотып китергән полицейскийлар вестибюльдәге погонлы кизүгә нидер аңлаталар, кизү тыңламаса да, аңлаган кебек башын селкетә, ә мин, кузгалырга базмый, кереп баскан урынымда торам, ялт-йолт каранам.

Авыру икәнемне сиздерергә ярамый – карантинга ябылу яный. Бүлмәбезгә менәргә рөхсәтне кемнән сорарга икәнен белмим. Нәрсәдер булуын көтәм. Ун-унбиш минуттан йола сакчылары, мине онытып, кизүдән язу кисәге алдылар да, чыгуга таба атладылар. Шак-шок! Мавзолей сагына баручы солдатларны да, космостан төшкән космонавтларның доклад белән Хрущёвка баруын да хәтерләтә иде бу күренеш...

...Кулга алынудан котылуыма шатланырга тиеш булсам да, тиражы узган лотерея билетына игътибар булмагандай, чыгышлый мине полицейскийларның күрми узуларына ачуым кайнаудан, артларыннан сүгеп калырга дип, пыяла ишеккә капландым... Капландым да, тапландым да: Батулла бүрекле хаҗи белән йөзен чадра каплаган ханым ишекне эчке якка этәләр иде. Ишек ачылмый, чөнки мин чыгарга дип эчтән этәм. Озак этешерлек көчем дә, теләгем дә булмагач, «кичерегез!» дидем дә лифтка таба чаптым.

Бүрекле, артымнан:

– Әй, син, – диюгә, хатыны аның авызын кулы белән каплады, сүзләре

йотылды. Лифтның ишеге ачык иде, керү белән «7»ле цифрлы кнопкага бастым, ә менеп җитүгә «2»лесенә басып, кирегә төшеп киттем. Тегеләр белән очрашмас өчен шулай эшләсәм – алар икенче кат хаҗилары икән, җәяүләп кенә менеп киләләр иде. Тагы очрашылды.

– Син? – диде бүрекле.

– Сез! – дидем мин, үземне үзем ишетмәс тавыш белән.

Нәрсәдән һәм нигә куркуымны аңламасам да, минем өчен бер хакыйкать ачык иде: очраклы бернәрсә дә юк, барысы да миннән котылу өчен «тегеләр» тарафыннан оештырыла. «Тегеләр» дигәнемнең кемнәр булуына җавабым булмаса да, мине озатырга, сәбәпләр ярылып ята.

«Беткән баш – беткән» дидем дә, бүлмәгә күтәрелеп тормыйча, асылташлар, энҗе-мәрҗәннәр кибетенә киттем.

...Кибет дигәннәре кунакханәдән ерак түгел иде. Тышкы яктан да, эчендәге товарлар төрлелеге белән дә бер-берләренә, игезәкләрдәй охшашлар, сатучылары һәм әйберләренең хаклары белән генә аерылалар иде. Кирәкле нәрсәмне очрата алмый озак эзләнеп йөрдем. Чөнки нәрсә кирәген тәгаен белмим. Шунда казылыкчы хаҗи очрады, нәрсә эзләвем белән кызыксынды. Сер бирәсем килмәүдән генә: «Хатын-кыз өчен энҗе-мәрҗән, алкадыр, төймәдер, – дидем. – Эшемдәге ярдәмче кызларга», – дип тә өстәдем.

Ышанмаса да, ышанганга охшатып аңлатты шыгырданлы хаҗи:

– Андый кыйммәтле нәрсәләрне «Зәкәрия» кибетеннән алу отышлы. Ә боларда барысы да фальшивка. «Зәкәрия»нең хуҗасы үзебезнең кеше – Австралия татары.

...Ышанмасам да, рәхмәт әйтеп, «Зәкәрия» кибетен эзләп киттем.

Юлда, нигә без кешеләргә, кешеләр безгә ышанмый икән, дигән сорауга җавап эзләп бардым. Җавап таба алмасам да, кибетне тиз таптым.

...Ниятем очсызрак хакка муенса, алка, төймә кебек нәрсәләр алуда. Кайда эшләгән кеше булуымны сиздерә алсам, реклама максатында, бәлки бүләк итеп тә «тамызырлар».

...Таш-тауны чокып ясалган кибеттә өч хаҗия «товар» сайлый иде. Берсе теге чадралы – ике озатучы хатын белән! Сөйләшүләре татарча. Киенүләре – озатучыларның чадралары юк, өсләрендә халат; ә чадралыда исә бу юлы үтә күренмәле бөркәнчек. Үтәли әлләни күрсәтмәсә дә, тән байлыгын яшерә алмаган. «Мин монда» дип кычкырып торган мул күкрәкле чадралыга алка-төймә сайлыйлар, беләзекләр үлчәтеп карыйлар...

Түгәрәк сәхнәчектәге читлегендә, һәр хәрәкәтне күреп, пышылдап сөйләшүне дә ишетеп, кибетче егет утыра.

– Сәнең толымың да, кашың да күмер кара, кызылдан алу тиеш, чәһрәң тагы да гүзәлрәк балкыр, яшьрәккә чыгарсың, – ди бер озатучы.

Шушы сүзләрдән соң чадралы миңа таба карады; киңәшчесенең сүзләрен минем ишетү-ишетмәвемне тикшерүе бугай – кычкырыбрак җавап кайтарды:

– Амин, абыстай, исән-имин монысыннан котылып, насыйбым очраса кире какмам...

...Ишетмәгәнгә сабыштым. Киңәшче хаҗияләр дә тавыш яшерми сөйләнүгә күчтеләр.

– Шундый гүзәлгә насыйбын очратмаса... җир тетрәр...

– Чәч агарып, гүзәллек шиңсә?

– Сарыдан ал! Караны да ача, зәңгәргә дә бата...

– Зәңгәрләрне женем сөйми...

– Кибетче ни әйтер?..

– Хакыннан тормабыз!

– Бәхетегезгә, бүген хуҗа үзе сугылырга тиеш. Бик үтенсәгез, сөйләшеп карарга булыр...

Озатучы хаҗияләр чадралыны култыклап, симертелгән үрдәкләрдәй алпан-тилпән, сайлаган нәрсәләрен тотып, пыяла читлектәге кибетче янына күтәрелгәч, сөйләшүләре ишетелмәс булды. Мин исә түргәрәк уздым... Чадралының һаман миңа карап сөйләшүе җилкендердеме, чынга ашмаячак хыяллар диңгезендә йөзүемне тойдым...

...Йөзен дә күрмәгән ханымның миңа нинди тылсымы күчкәндер, Казанга озатмасыннар өчен, чадралыны ерактан гына булса да күрергә әллә ниләр бирергә дә әзер булуымны тойдым. Нәфесемә боерык биреп тыела торган гадәтем коткарды... «Чү, егет, дип читкәрәк киттем, йөземнәр әле пешмәгән!»

...Зиннәтле муенса, алка, брошка, беләзекләр төрлелегеннән күзләр камаша, берсен алсаң – икенчесе әрәм калыр кебек. Ярты сәгать чамасы сайлана торгач, үземнең гаиләгә, апа белән сеңелкәшләрнең һәркайсына муенса, алка, беләзекләрнең төрлесен җыйдым да ике кирпеч биеклегендәге сәхнәгә – кассага юнәлдем. Күрсеннәр, акчалы хаҗияләр егетнең зәвыклысын! Тик хаҗияләр инде киткән, кибетче үзе генә утыра иде.

– Бик шәп, – дидем эчемнән, милли хисләр дулкынында ачыктан-ачык сөйләшергә уңай булыр... Кыяфәте саранга охшамаган сатучының...

...Бер баскычлы мәрмәр баскычтан сәхнәгә күтәрелеп, сайлаганнарымны алдына салдым моның.

– Чутлагыз, дустым!

– Һәммәсен аласызмы? – диде кибетче, йөзендә нәрсәдәндер шикләнү чагылдырып.

– Алмасам сайламас идем... Казан татарлары саран түгел.

– Сүз татарлар турында түгел – ташлар турында. Монда бик күп бит, абзый.

– Ташларыгыз бар ич, үзебез таш булмыйк, Казаннан килгән сәнгать әһелен рәнҗетмәслек итеп кенә исәпләгез, дигәндәй, хәер, сезне өйрәтәсе юк – аңлыйсыз: «реклама» дисәгез – мин телевидениедә эшләүче режиссёр булам...

– Хуш, мәйле, боларны нәрсәгә сөйләвегез аңлашылмаса да, санап карыйбыз, әйе... шулай... Менә бу муенсаның сезгә нәрсәдән эшләнгәне кирәк? Гәрәбәдәнме, яшма яки якуттанмы, әллә инде рутилдан, фенакиттан, кохинурданмы? Алар күп төрле бит. Нindиен сайлыйсыз?

– Соң, әфәндем, бу сайлаганнарның һәммәсе нәрсәдән дә булса эшләнгән ич инде?

– Эшләнүен эшләнгән. Тик боларның барысы да муляж. Сез нindиен сайласагыз, шуның буенча остаханәдәге осталарга заказ җибәреләә, өч көннән, калган 40% акчагызны түләп, товарның үзен аласыз. Аванс 60% хәзер үк түләнә.

– Өч көн көтә алмасам? Мине бүген үк самолётка утыртып озатулары ихтимал.

– Муляжларны алам дисезмени? ...Алар сатылмый шул, инвентарь.

– Сатыла торганнары күпмелек була?

– Әгәр ашыгычлык өчен дә түли алсагыз...

– Түлим!..

– Нинди таштан эшләү кирәген шартнамәдә үз кулыгыз белән күрсәтергә тиешсез. Монда кануннар каты, әмма төгәл үтәлә: язгыгыз... Рутилмы, фенокитмы...

– Миннән алдагы хаҗияләр нindине алдылар?

– Коммерция сере булса да, иҗат кешесе булуыгызны хөрмәт итеп, сезгә генә әйтәм: алар яраттыру тылсымына ия александритны сайладылар. Хатын-кызга мәхәббәтнең дәвамлырак булуы кирәк бит.

– Безнеңчәрәк исемлесе юкмыни?

– Гәрәбәнең төрлесе бар. Рутил дигәннәре, мәсәлән, салават күперенең бар төсен үзенә җыйган минерал. Һәр ташның үз легендасы.

– Яртысын рутилдан, калган яртысын александрит белән кохинурдан.

– Хуп... исәпләп карыйбыз.

...Электрон санагычын төрткәләп озак маташты Алматы татары. Казаныбызныкылар, чырайга карап, күптән үзләренә кирәк хакны чыгарып әйткән булырлар иде. Ә бу исәпли дә уйлана, чутлый да күзгә карап тора...

– Сез банк аша күчереп эш итәсезме, хәзер үк кулдан кулга түлисезме? Долларда?

– Җәмгысы ничә сумлык булды?

– Ике мең җиде йөз туксан дүрт долларлык.

– Суммы?

– Доллар дим ич!

– Үз татарыңамы?! Сәнгать вәкиленәме?

– Казан магнаты өчен ике «Тойота» хакы күпмени ул? Ике мең җиде йөз туксан дүрт!

– Магнат өчен күп түгелдер. Ә 50 долларын ничек кирәк, алай саклаган хаҗи өчен... күбрәк. Төшерә төшегез.

– 50 долларыгызга, әнә – биш бөртек мәрҗән сезгә! ...Австралия суларында үрчетелгән «Зәкәрия» фирмасы продукциясе! Бу фирманың һәр мөселман илендә үзенең асылташлар кибете, эшкәртү остаханәсе бар. Репутация! Яңа ысул белән үрчетелгән мәрҗәннәре чыннан аерылгысыз. Олы хаҗ алдыннан гына сатуга куелды. Күрсәтимме?

– Күрсәттегез ич инде... Мин дә күрсәтимме?

– Сез мине мыскыллауга, хурлауга кучтегез түгелме?

– Ә сезгә мыскылласагыз да ярыймы? Үз татарыңнан көләргә телисеңме?

– Полиция чакыртмыйча бу мәсхәрәне туктатып булмас ахры.

– Бернәрсәгез дә кирәкми. Үзегезгә булсын! 50 долларымны да калдырам... Шалтыратмагыз!

– Безгә кеше малы кирәкми, без аңа калмаган. «Зәкәрия» кибете бу!

...Кибетче шулай дип сөйләнә-сөйләнә телефон номерлары җыйганда, ишек ачылды һәм... минем бер тартма дарулар алуымның шаһиты булган, үзен «Хызыр» дигән хаҗи килеп керде.

...Ул күренүгә, мин, әйтерсең, биек кыядан төпсез коега «чумдым». Кибетченең полиция чакыруыннан куркудан түгел, ә «Хызыр» мине күрмәсен, танымасын дип артка чигенгәндә, бер аягым бушлыкка туры килеп... Әйе, «бәла – аяк астында» дигән очрак иде бу. Инде менә ятам сөйләшүләрен тыңлап, йөземне күрсәтүдән куркып.

– Әссәламегаләйкем, – диде «Хызыр» кибетчегә.

– Вәгаләйкемәссәлам, Зәкәрия абзый... Бик вакытлы килдегез, көтә идек, ягъни көтә идем...

– Кемең ул баскыч төбендә аунап ята?

– Бу... Казаннан килгән хаҗи, режиссёр, ди.

– Бума чирлеме әллә?

– Психопат. Әрсезлеге чамадан тыш.

– Әрсезлеген нәрсәдә күрсәтте?

– 50 долларына 3 мең долларлык товар... таләп итә!

– Таләп итмәдем, «хакын төшереп булмасмы», дидем, – яткан урынымда сүзгә катышып, – ә ул биш бөртек энҗе алырга куша, 50 долларга...

– Кушарга хакыбыз юк, тәкъдим итүем хак.

– Сиңа ул 3 мең долларлык товар бик тә кирәк идеме?

– Кирәкмәсә, сайламас идем. Гаилә әгъзаларыннан тыш, ассистент кызларым, редакция машинисткалары «бүләк» дип калдылар...

– Хакын белмичә сайладыңмы?

– Анда хакы күрсәтелмәгән ич...

– Мостафа, тутыр тәзкирәсен аванссыз.

– Анлык рәтем юк минем.

– Хызыр галәйһиәссәламнән бүләк булыр. Фирмабыз исәбенә дип үзем кул куярмын, яз – аптырама, исәплә!

– Саналган, язылган, – диде кибетче.

– Кайткач, мине «Черек күлгә» чакыртып, иманымны суырсыннар өчен юмартлык уены уйнавыгызмы? Кирәкми миңа ваххабистлар бүләге!

– Үз сүзлегең мактауга лаек булса да, ятып сөйләшүең татарларга хас түгел. Басып сөйләш, хаҗи.

– Басып баш июемне көтсәгез, ялгышасыз.

– Урынында иелә дә белергә кирәк. Сыгылган сынмас. Тор, якыннанрак танышыйк...

...Шунда мин, кыюланып, басмакчы идем, уң аягымның чәкән сөягенә нидер булганлыгын тойдым: киселгән дә, кысылган да кебек авырта. Басарга бирми.

– Әллә сынган? – диде «Хызыр».

– Авыртуын гына тоям.

– Чакыр, Мостафа, үзебезнең табибны, карасын. Әнә бит күгәргән сыман күренә.

– Сынган-тайганны мин үзем дә күп күргән, өч ел мал врачы булып казакъ даласында күрмәгән калмады... кая, күрсәт авырткан төшен!

– Якын килмә! Куй сарыгы түгел мин сиңа!

...Шулай дигәндә йөзем-битем ачылып, «Хызыр» белән күзләребез очрашты.

– Менә сиңа «мә»! Син түгелме бу?! Ирлек дарулары ярдәм итмәгән, ахры, тор, ятып сөйләшү ирләрне бизәми. Әллә мин очраткан хаҗи түгелме син?

– Түмгәккә абынып, имгәккә әверелдем.

– Абынып егылгач, түмгәкне сүкмиләр, хаҗи. Кая басканыңны карап басарга кирәк иде. Чыга алмас чокырга төшсәң нишләрсең? Дәвалауны мин үз өстемә алам!

– Миннән рөхсәтсезме?

– Син миңа кирәкле инсан булырга охшыйсың. Ишетәсеңме? Син – миңа, мин сиңа кирәк!

– Әлегә һич тә сезне аңларга теләгем юк.

– Мостафа, күр – нәрсә ди бит!

– Татарлык! «Ыспай туңмас – калтырар».

– Аягын күр, дим мин сиңа. Тел һәммәбездә – пычак.

– Уколдан шешенә. Сыныгы чәкәндә, гипска катырмый төзәлмәс...

...Бу сөйләшүләрне мин уколдан соң, йокы аралаш ишетеп, аңлап яттым. Сүзгә катнашасым килсә дә, дәшә алмадым. ...«Ашыгыч ярдәм» машинасында докторлар килүен, алып китәргә «Хызыр»ның рөхсәт итмәвен, травматологны

кибеткә китертеп, аякны гипска катыруларын да, «Зәкәрия» фирмасы исәбенә мин сайлаган нәрсәләрнең һәммәсен остаханәдә эшләтергә шартнамә төзелүен дә, «бүләккә» дип «Хызыр»ның аңа кул куюын да, кунакханәгә кайтарылуымны да аңлап яттым, сүзгә генә катыша алмадым. Ни булыр бу? Ник? Ни өчен шундый кыйммәтле бүләк бирә ул? Уйларымның чиге юк...

Ә менә кайчан йокыга китүемне, күпме вакыт йоклавымны хәтерли алмыйм...

50 данә мәрҗән белән 50 долларым янымда. «Хызыр» бүләк итәргә дигән нәрсәләре юк. Димәк, заказ үтәлерлек әч көн узмаган. Кемнән сорарга? Чын эшме бу? Сораргамы? Бәлки, болар барсы да безнең КГБ диктовкасы белән эшләнәдер? Уендыр? Алай дисәң... мин кем инде алар өчен? Үз эшемнән башканы белмәгән бер һөнәрман!.. Бәлки, шул һөнәрманлыгымнан тегеләр файдаланырга планлаштыралардыр? «Тегеләр» дигәне кемнәр? «Хызыр» группасымы? Бушлай вәгъдә ителгән бүләкләр җәтмәнең бер төре булса? Мең сорауга бер җавабым юк.

Тәбедәге сырга алданган тычкан хәлендә каласы килми. «Хызыр»га миннән ни кирәк? Ни бирә алам икән мин аңа? Киңәшләшер кешем юк, дисәм, коридордан тавышлар ишетелде. Ишек янында ук сөйләшәләр. Бүлмәдәшләр арасында «Хызыр» тавышы да таныла...

– Бер-береңне гафу итә белү мөһим. Көлдермик милләтебездән. Бердәмлек кирәк.

– Ул көлдерде! Ул! Ул хур итте...

...Диалогларда кемнәр катнашуын аерып таный башладым:

Мәхмүт: ...Безнең татарлыктан башка уртаклык юк... Аның белән дә, сезнең белән дә.

«Хызыр»: Телебез, моңыбыз, йолаларыбыз бер, нәзарәтебез уртак. Сайлаган мөфтиебез уртак.

Хәйдәр: Юлламаны башка мөфтияттән алган ул. Җавап шул мөфтияткә җибәрелергә тиеш.

Мәхмүт: Җавапка лаек дип табылса.

* * *

...Алты кеше күтәргән носилкада кара ташны әйләнгәнемне дә, күргәннәремне дә хәтерләмим. Кеше диңгезеннән һәм кулымдагы догалыктан башка күземә берни чалынмады. Һәр аять үз урынында укылса гына кабул ителгәнлектән, шактый тырышырга туры килде.

Носильщикларга кем утырса да, аны тиз-тиз кара таш тирәли әйләндереп, чираттагы хаҗины утыртып чабу мөһим.

Носилкада утырган кеше йолаларны дөрес үтиме-юкмы – аларга барыбер. Акчасы түләнгән, сатулашып торасы юк. Тиз дә – тиз, түз дә – түз! Ә менә хаҗиның хәле хәл: кайсы әйләнештә кайсы доганы укуны бутамаска кирәк...

...Әйләнешләренә тәңгәл килгәндерме, юкмы, язылганнарның һәммәсен укырга тырыштым. Носилкадан төшкәндә, өч догам артып калган иде әле, аларын сәгыйгә күчкәндә юлда укыдым.

....Җан тынычлыгымны, кунакханәгә кайтарылгач, Хәйдәр хәзрәт белән Мәхмүт абый бозды.

– Күрдек, күрдек! – диде Мәхмүт абый. – Шулайдыр дигән идек, шулай булып чыкты.

– «Шулай»ны аңламадым.

– Күп гөнаһларыбыз әнә шул аңламый кылган гамәлләребездән килә, – дип сүзгә катышты Хәйдәр хәзрәт.
– Нинди гөнаһ?
– Күрдек без синең сиртмәле бишеккә утырып кәгъбә әйләнүеңне. Ваххабист дусларыңны да күрдек... Әллә ни кәттәләр түгелләр икән үзләре... янып торса да күзләре. ...Әйе.
– Озатучы шәкертләрне әйтәсезме?
– Шәкерт кыяфәтенә кереп station аздыручы иблисләрне әйтү.
– Хата җибәрелгән булса, кабат ялгышмас өчен минем хәзер үк беләсем килә...
– Таваф кылучы буларак ридаэның уртасы уң кул астында, очларын сул җилкәңә салып, тавафтан соң элеккечә кияргә тиеш идең – берсен дә эшләмәдең... Карап тордык... Бинокль аша. Беренче өч әйләнүдән соң раммүл кылмадың...
– Анысы ни тагы?
– Тиз адымнар белән әйләнү...
– Носильщиклар болай да гел йөгереп әйләнделәр...
– Тышаулары телеңдә бит, тыярга иде!..
– Алар кайда кызу, кайда акрын баруны үзебез беләбез, диделәр.
– Кара ташка якынаюга, аңа кулыңны тигезеп, сәлам бирергә тиеш булсаң да, тидермәдең, сәламләмәдең.
– Буем җитмәде!
– Уең җитмәде...
– Үзебезнең республикада мәгълүм кеше буларак, сине кисәтми дә кала алмыйбыз: иганә-спонсорлык вәгъдә итепме, бүләк бирепме – сиңа монда елышырга теләүчеләр табылыр. Начармы, яхшымы, каләмең бар. Йомшак агачны корт басар, ди... Имәнне дә корт төшеп корыта. Шәкертләр хезмәте дә, носильщиклар да корт төшү ул. Хәйлә! Тозак!
– Мине сакларга тырышуыгызга рәхмәт. Тик... юкка борчыласыз.
– Илгә кайтасыны онытмыйк...

**2 БҮЛЕК**

## Васыять

Маҗаралар-могҗизалар күп очраган Зәкәрия атлы татарның үзенә дә.
Ачтан үлми калуын иң мөһим могҗизалардан дип саный ул һәм... сөйли:
– Мин 1925 елның 22 апрелендә (Ленин һәм Чарли Чаплин да шул көнне туган, имеш) Татарстанның Красный Бор районы Бүләк авылындагы землянкада туганмын, – дип ерактан башлый ул. Мин бүлдермәскә тырышам. – Олы Баржыдан яңа җирләр «әрчер» өчен күчеп килгән халык, колхозлашу кыямәте башлангач, кабат урын алыштыра; бу юлы Иж елгасына коя торган Кәтмәс елгасы буена – Югары Баржы дигән яңа оешып килүче авылга күченәләр...
...Безнең әткәй монда кузнец Сашка абзыйның ярдәмчесе булып эшли башлый. Агач эшенә осталыгы аны шәһәргә этәрә. Казанда ачылачак танкистлар мәктәбенә элеккеге драгун полкары биләгән казармаларны сипләп биналар корырга балта осталары җыялар, акчасын немесләр бирә, хакны әйбәт түләячәкләр икән, дигән хәбәр әткәйләрне тагын кубарга җилкендерә, дядя Саша белән китәләр болар. Кар яугач, безне дә кайтып алдылар. Күпмедер вакыт гаиләләребез белән, калай мич ягып, такта сарайда яшәдек, Яңа елга кирпеч баракларга күчерделәр...
...Әткәйнең эш урынына ашау илтергә барганда, миңа, чын немесләрне

күреп, сөйләшүләрен дә ишетергә туры килде. Алар анда, эткәй әйтүенчә, укыйлар да, укыталар да икән...

...Соңыннан үзебезгә каршы сугышачак танкистларны үзебез үк әзерләгәнбез булып чыга. Төзелештә дә эшлиләр иде алар, ял көннәрендә танышларына чәйгә дә баргалыйлар иде. Үзем шаһит.

Якшәмбе кичләрендә бакыр чәчле немец егете эткәйгә ияреп безгә дә кайткалады. Сарымсаклы колбасаның тәмен шул немец кулыннан алып татыдым. Исе һаман борынымда. Ничәнче килүендә булгандыр – шул бакыр чәчле немец эткәйгә, сер итеп, Гудериан килүенме, әллә киләчәгенме әйткән. Яңа «телогрейка» дигән сырма алуын эткәйнең шуңа бәйләп сөйләгәне хәтердә.

Курсантның, безгә килеп, бараккагы кер кайнату бүлмәсендә дядя Сашаның кызы тётя Люда белән кунып калуын үзем күрдем. Күргән саен бер папирос биреп, «тсс» ди иде ул миңа. Миннән сүз чыкмаса да, 43нче елны Сослангер лагеренда ятканда, Казан танк школасында немецләрнең утыз танкисты укып чыкканлыгын, кайберләреннән бала калганлыгын солдатлар сүгенеп сөйлиләр иде.

Берсенең, хәтта үз-үзенә ачу белән: «Мин аны саклап, күзенә карарга да оялып йөрсәм, аңа немец курсанты чүпрә салырга өлгергән; озатырга баласын күтәреп килгән, каһәр. Көтәрмен дип калды. Ышанмасам да, яратам бит шул кәнтәйне», – дип елый-елый хат язып утыруы хәтердә. Исән-сау әйләнеп кайтып күрешә алдылар микән?

...Шулай, немецләр хакында сүз күп булды. Бездә генә түгел – башка шәһәрләрдә дә укытканнар аларны.

Версаль договоры буенча Германиягә кораллану да, хәрби һөнәр ияләре әзерләү дә тыелганлыктан, немецләр урау юлны такырайткан.

Мәсьәләнең ул якларына кереп тормыйм, керсәң, чыгып булмас...

Ничәнче елның кайсы аенда булгандыр, немец курсантлары кинәт кенә Казаннан китеп, күпмедер ара вакыт узгач, тётя Люда нәкъ папирос бирүчегә охшаган бакыр чәчле малай таба. Аны Иж буендагы Балтач больницасында тудырып, Петропавел авылындагы әбиләрендә өч ай буе беркемгә хәбәр итми ятканлыгын соңыннан белдек.

«Никахсыз туган бала» диптер инде, тётя Лида малайга таныклык яздыру артыннан йөрми. Немесеннән хат көтеп яши. Ә хат юк та юк... тётя Люданың кулында Балтач больницасы биргән белешмә язуы белән немец биреп калдырган фотокарточка да алтын балдак кына. Ул балдак кайсы бармагына кисә дә, шуып төшкәнен үзем күрдем.

Никахсыз туган булса да, исемсез яшәп булмый, малайга, атасы әйткән буенча, Генрих дип исем кушалар. Ә без аны «Гәрәй» дип йөри идек. Малайга өч яшь булганда, авылдагы әбисе килеп, чиркәүгә алып барганын хәтерлим; немецтән туган бала икәнен әйткәч, поп курыккан; чукындырырга католиклар чиркәвенә алып барырга кушкан. Әбисе киткәч йөрүче булмады, «Гәрәй» булып калды «Рыжик» кушаматлы малай.

Атасы бу вакытларда, мөгаен, танкка утырып, Польша җирләрен үзләштерү белән мәшгуль булгандыр... Белеп әйтүем түгел. Килгән бердәнбер хаты Польшадан иде. Соңыннан аны милиция килеп алган.

...1937 елда эткәйләр Яңа заводка кузнец эшенә күчә. Дядя Саша белән аның кызы тётя Люда да шул ук заводның бер үк цехында эшлиләр. Эше авыр булса да, ашау әйбәт, дип сөйләнүләре исемдә.

...38 нче елга күчкәч, завод складларында янгын чыгып, чит илдән кайтартылган җиһазлар яна.

...Ут чыгуның сәбәбен ачыклыйсы урында, «Кем гаепле?» дигән сорауга җавап эзләп, безнең әткәйләр эшләгән цех эшчеләрен гаеплиләр. Янгын, имеш, «кузнечныйдан» башланган. Алар, «кулга алынып, хөкем ителергә тиешле!» Аларга «нимес шпионнары» дигән тамга салына. Тикшерү эшләре 41нче елның июленә кадәр бара... Ничәдер эшчене мәҗбүри эшкә, җиде кешене төрмәгә утыртырга, өч кешене атарга дигән хөкем чыгарыла.

Кызы белән дядя Саша һәм безнең әткәй кайсы төркемгә кертелгәнен әйтмәгәннәр...

...Баштарак аларны янгын сүндергәндә янганнар, больницада дәваланып, хәлләнгәч, хөкем итәчәкләр, диделәр. Хәбәр ялган булды. Хөкем карарын алардан башка гына чыгарганнар, күрәсең.

...Рөхсәт ителеп, соңгы очрашуга баргач, тётя Люда безнең әнкәйгә алтын балдагы белән, Гәрәй тугач, Балтачта бирелгән язуны кайда яшергәнен әйтә; «эшнең» ни булып бетәсен белмәгәч, алтын балдакны сатып, азык-төлек алырга, малаена өс киеме тектерергә куша. Әнкәй балдакны сатмый, саклый. Кием-салымны миннән калганнарны ямаштырып бирә.

Мине сугышка алганчы, ягъни, 43 нче елның 5 августына кадәр Гәрәй бездә яшәде. Мин китеп, кыш җиткәч, әнкәй аны анасыннан калган нәрсәләре белән бергә Шаршада балалар йортына илтеп тапшыра. «Нәрсәләрен» тәрбияче кул куеп ала. Малайны, бабасының исеме Александр булудан, «Искәндәров», атасы Роммельдән чыгып, «Рамилевич» дип яздыра әнкәй. Исеме «Гәрәй» кала...

...Шушы хәбәрләр язылган хат миңа әнкәйдән килгән соңгы хат булды.

...Сослангерда, фронтка җибәрелүемне көтеп, ачлыкка чыныгып ятканда, әнкәем мәрхүмә булган. «Старшина» дигән явыз шуны миңа поездга төялгәндә генә әйтте; имеш, кызганган, әйтмәгән, борчыйсы килмәгән.

...«Фронтка» дип җибәрсәләр дә, чын сугышны күрмәдем мин: ФЗОда тимерчелек һөнәрен үзләштереп, заводта эшли генә башлавымны әйттемме икән – беренче эш хакымны да алмаган идем. Безне ватык коралларны төзәтү заводына җибәрделәр, мылтык урынына чүкеч тоттырдылар. Озак барылды. Бер поезддан икенчесенә күчерәләр. Күбрәк төнлә барылды. Әледән-әле бомбага тоталар. Хәтәрнең хәтәре нәрсә дисәләр – безнең юл булгандыр.

Озак барылса да, һәр юлның ахыры була. Килеп җитүебезне әйттеләр. Кайда җитүебезне белмәдек. Ниндидер вагон эченә көйләнгән душта суык су белән юындырып, «комбинезон» дигән чалбар бирделәр, кулга тимер кисү кайчысы тоттырдылар, тимер юл буена утыртылган баганаларга киртә сузып, каяндыр куптарылган иске калай белән түбә ябарга куштылар...

Сугыш техникасын төзәтү заводы шушы булыр, диделәр. Ышанып бетмәсәк тә, шат идек. Ут эченә керүгә караганда, түбә астында тынычрак булыр дип уйладык. Теләсә ни булсын – эше белән ашы гына булсын, янәсе.

Тик бу тормыш озакка сузылмады. Белоруссия азат, Польшада хакимият башка, дигән хәбәр таралды. Күченергә тиешбез, диделәр. Командировкага әзерләнергә куштылар. Без – һәрчак, һәрнәрсәгә әзер пионердан азган солдатлар – Белоруссиянең көнбатыш чигендәме, Польша җирендәме бер узловая станциягә килеп төштек. Төн булса да, күреп була – ватык танкларны җыеп вагоннарга төягәннәр, озатырга өлгермәгәннәр. Кемнәрнеке булуын сорар кеше юк. Сораганда да җавап булмаячак. Күп белүче бер ефрейтор сөйләвенчә, командование ватык техниканы СССР юлларыннан узарлык вагоннарга күчереп, Уралга озату бурычын куйган икән. Без шул бурычны үтәр өчен монда ятабыз икән. Юлларның күбесе җимерек, төзәтелүе вакытлыча.

Пулялар сызгыруы ишетелмәгәч, шыңшымый түзәбез, краннар килүен көтәбез. Бер вагоннан икенчесенә күчеп утырулары белән санаганда, айдан артык яттык, исләндек, бетләдек. «Подножный корм» белән, ягъни сорашып туенабыз.

Беркөн кемдер ашханә «табып» кайткан. Чүплегенә бәрәңге кабыклары, черегән кишер, кәбестә яфраклары чыгарып ташлаганнар, ди. Кайнар суда шуларны пешекләп, атна буе ашказанын алдадык.

Бер төнне күктә бихисап күп самолётлар очып тормышыбызга үзгәреш кертте, гражданский киемле берәү килде дә, русчалатып:

– Среди вас есть татары? – диде.

Үзем җавап бирмәдем. Башкалар миңа таба карагач, гражданский: «Пошли», диде. Теләсәм дә, теләмәсәм дә, ни буласын белмичә иярдем. Ун-унбиш минуттан иң кырый юлда торган составның сакчылар вагонына кертте дә бу: «Тут будешь ожидать», – дип чыгып китте.

Вагонда миннән тыш тагы алты кеше утыра иде. Буш консерва банкалары аунап ятудан монда ашау бирәләр икән дигән уй хәл кертеп җибәрде. «Исәнмесез, саумысез!» – дидем үзебезчә.

...Җавап бирү урынына алтының берсе миңа урын күрсәтте дә: «Сядь!» – диде.

Бер-беребезгә ияләшә төшкәч, шуны аңладым: көнгә бер мәртәбә ашау бирелә икән, аны тәүлеккә җиткезергә кирәк икән. «Кем бирә, кайчан төяп, Уралга җибәрәләр, кебек сорауларга җавап юк. Бер-беребезне сыныйбыз, көтәбез.

Кай көннәрдә эт өргән, немесчә кычкырган тавышлар ишетелгәч, әллә фронт шулай якында гынамы икән, дигән уй килеп, әсир төшү ихтималыннан куркып куям.

Атна тула дигәндә, безне тагы аердылар да, китәсе вагонга дип, күчереп утырттылар. Ашык-пошык, шым гына, төнлә.

Бу юлы юлдашларымның берсе урысча белгән поляк, икенчесе полякча белгән белорус иде. Киемнәре безнекечә түгел. Ничек сорарга белми аптырап утырдым-утырдым да тәвәккәлләдем:

– Сез солдатлармы, әллә тимер юл хезмәткәрләреме?

– Икесе дә, – диде берсе русча. Сөйләшү русча барды.

Икенчесе:

– Сиңа кайсы кирәк? – диде, бераз тын утыргач.

– Миңа иптәш кирәк! – дигән булдым, битараф күренергә тырышып. Шул җавабымнан соң, кыюланып, снаряд кыйпылчыклары тишкәләгән «тәрәзәчекләрнең» берсеннән тышка карасам, параллель юлдагы вагоннарның кайбер язулары акбур белән немесчә язылган; юлның теге ягында кранлы вагон узып-узып киткәли. Төяү-күчерү эше бара, димәк. Тик ни өчен немесчә язулы вагоннарга төйиләр?

Әллә әсир ителдекме, дигән сорау-шик туса да, коралсыз кешене әсир итмәсләр дип, тынычланырга тырышам. Вагоннар арасында бәйләнеш юк, ишекләр тыштан бикле.

Юлдашларымның өс киемнәре погонсыз. Димәк, әсирмен дип борчылыр нигез юк. Ә кем соң без?

– Где мы находимся? – дигән булдым.

– В плацкартном вагоне польского поезда.

– Куда едем?

– По-моему, в Гданьск.

– Не на завод разве?

– На завод, только Польский завод.

– А почему нас так мало?

– Мы обменные, – диде берсе.

Ишек йозагын ачкан тавышка сөйләшүебез бүленде.

Моңа кадәр күрмәгән формалы офицер керде. Сакчысы тышта калды.

– Как вы попали в этот броньвагон?

– По приказу майора, – диде белорус.

– Какие у вас имеются документы?

– Он забрал себе.

– Вы перебежчики или пленные?

– Да, мы перебежчики! – диде Польша татары, белорус та ризалашып баш какты.

– А я не перебежчик, я солдат, – дидем мин.

– Пленный, значит, оттуда, ихний...

– Я совсем не воевал, я – кузнец!

– Значит, перебежчик!

– Как то есть, перебежчик? Я никуда не бежал... Меня украли, потому что я не знаю... как я попал сюда и где я?

– Разберёмся... разберутся...

Платформага төшкәч, офицер мине этле сакчысына тапшырды да паровоз машинистына таба юнәлде. Бераздан кемнедер ияртеп, составны саклаучылар вагонына керде. Анда сүзнең безнең турыда барганлыгы бәхәссез булса да, бәхәснең ни турыда баруы минем өчен әле һаман да сер иде. Ничә ел бергә эшләп, бергә яшәп, бер максатка омтылсак та, Ян Роммель бу серне чишмәде. Кемнедер сатасы килмәдеме, антын бозудан курыктымы – минем аның карамагына ничек килеп эләгүем турында сүз чыгарудан качты. Сүзне мин чыгарсам, бик тиз үзгәрттерә иде. Соңрак чын әсирләр белән очрашып, сөйләшкәнем булды. Аларның кайсы үзе теләп бирелгән, кайсын урлаганнар, кайсы җиңелүдән эләккән. Мин андыйларның берсенә дә кермим.

...Сакчылар вагонында озак сөйләштеләр. Мине саклап торучының эте, иялэшеп, миңа койрыгын болгый башласа да, светофорда сары ут кабынганчы, офицер чыкмады. Сары ут кабынгач, башта машинист күренде. Аннары офицер, мине тәрәзәсез вагонга кайтарып, кулыма номерлы калай тоттырды да тыштан ишекне бикләде...

...Хәзер аңлавымча, бу миннән «ирекле перебежчик» ясау процедурасы булгандыр, дип уйлыйм.

Иске танышларым янында яңа сыйфатта калгач, алар миннән сагаялар иде.

Совет җиреннән төялгән техника калдыклары Польша җирендә! Кем кемне кемгә саткан? Кем алган – шайтан белсен...

Ничә көн барылгандыр – самолётлар гөрелтесе аралаш бомбалар шартлавы – вакыт узуны да, көн исәбен алып баруны да оныттырды, көн белән төнне бутарлык хәлгә китерде.

Тынлык урнашкан араларда бер-беребезнең исәнме, түгелме икәнлеген генә тикшергәлибез.

Бердәнбер көнне, өчебезне дә таң калдырып, тукталганны... тойдык.

Польша татары «тәрәзәгә» капланды. Кайдан танып әйткәндер: «Гданьск!» – диде дә урынына ауды... Ул шат иде. ...Тишектән карау чираты белорус перебежчигына җитте. Ул диңгез портына тукталуыбызны аңлатырга тырышты.

Минем өчен кайда тукталсак та барыбер иде. Чөнки мин ни булса да, кайчан булса да качарга тиеш! Уемда шул гына.

...Өч ай чамасы порт мастерскойларында эшләткәч, 1945 елга чыгуга, безне төрле марка ватык танк моторлары төялгән үзйөрешле баржаларның берсенә кертеп бикләделәр дә аерым әмер көтәргә куштылар.

...Белорус егетен рулевой рубкасына, Польша татары белән мине трюмга яптылар.

...Безне «самоходкага» озатучы капрал «поляк-татарның» «рус-татарга» командир булачагын аңлатырга маташты. Шунда гына мин ерак милләттәшнең исемен белдем: Самуэль Конапацкий икән.

Мин: «Сәмигулламы»? – дигәч: «Может быть, – диде дә, – инженер-строитель!» – дип куйды. Ягъни, монда төялгән моторларга да, самоходкага да катнашы юк. Капрал чыгып китүгә, баржабыз нык селкенә башлады. Димәк, кузгалабыз. Баржаның баруыннан туктаганлыгын аеруы кыен: тибрәтә дә селкенә, чөя дә коега ташлаган кебек итә.

Баштарак күңел болганып җәфаландык. «Качкага» күнә төшкәч, «Proviz-ia» дигән язулы мичкәләргә күз төште. Алар җидәү иде. Икесендә тозланган дуңгыз мае – сало, өчесендә кукуруз, он, томат пастасы. Алтынчысында тоз, җиденчесендә селёдка иде. Эшләнү урыннары белән еллары язылган: «1914». «Киль», «Росток».

Сәмигулла портта торганда, тутыгып беткән ватык кораблар трюмыннан мичкәләр тәгәрәтеп чыгарганнарын шәйләгән икән. Ашханә кухнясында да шундый ук әллә кайчангы сугыш «трофейлары» барлыгын белгән. Күрәсең, корабльләре төзәтә алмаслык сафтан чыккандыр да, эчендә калган нәрсәләре безне көткәндер. Бозылганга охшамаганнар, нимесләр һәрнәрсәне сыйфатлы ясыйлар, диде Самуэль-Сәмигулла, күзгә чалынган нәрсәләрне карап йөри-йөри. Зур су мичкәсе янындагы тимер өстәлдә ике котелок, ике кашык күреп безне озак яткызачакларын аңладык. Күтәртү чыгырлары, домкратлар, төрле чүкеч-сандаллар, игәү, пычкы, ачкычларның аунап ятуы – бу дәлилләрне раслый иде. Димәк, эш урыныбыз да, йокы да, ашау да шушында булачак. Озаккамы? Кемгә буйсынабыз? Фаразлауларны бүлдереп, түшәмгә эленгән электр лампасы кабынды, бортка беркетелгән репродуктор телгә килде. Өзек-өзек ишетелгән әмердән аңлаганын Самуэль-Сәмигулла тәрҗемә итте: трюмдагы ватык моторларның төзек запчастьларын сүтеп, яшел әрҗәләргә, ватыкларын сарыларына тутырырга тиешбез икән. Экипаж белән бәйләнеш һәр көн иртәнге алтыда, кичен – тугызда. Ачлыктан организмнар какшаганлыктан бик аз ашарга кирәк икән... Йокы ирекле.

...Кинәт кабынган ут кинәт сүнде дә. Ни өчен? Кем сүндерде? Тынлык. Трюмның без бикләнгән бүлемендә бер генә тәрәзәсе бар. Алай-болай «ЧП» булса, ватып чыгарга кеше сыярлык шул яктылык чыганагын вакыт-вакыт су каплый, дөм караңгы булып кала. Башка яктылык чыганагы юк. Шундый шартларда ничек эшләргә дә, ничек яшәргә? Шунысын да әйтеп узу кирәктер: кеше күзе, караңгыга ияләшеп, бәрелешмәслек микъдарда күрә икән! Фән ничек аңлатадыр моны – безнең шартларда бу могҗизаны диңгез суы аша үткән яктылыктан булгандыр дип уйладык.

Азмы-күпме кукуруз капкалап, кушканны тыңлап, сүтү-җимерү эшләре белән дә шөгыльләндек.

Янгыннан саклану өченме, әллә суык чакта радиаторларны каплар өченме куелган киез кисәкләре табып, ятар урын әзерләдек. Сәгатьне йокыга карап

билгелибез. Көн белән төн кушылды. Утсыз яшәү – яшәү түгел, дуңгыз маеннан шәм ясау фикеренә килдек.

Тик аны ничек кабызырга? Шырпыбыз юк.

Вахта кнопкасына басабыз – җавап сигналы эшләми. Тимергә тимер бәреп чаң сугабыз – тынлык.

Ә диңгездә дә, һавада да сугыш. Әле тегендә, әле монда шартлау, ухылдау, самолёт гөрелтеләре.

Үлем безнең белән «уйнаган» шундый бер мизгелдә мин, шырпысы юкта, әткәйнең Югары Баржы тимерчелегендә эшләгәндә, ничек итеп учак кабызуын күзалладым: кадак кебек очлы тырма тешен алыр иде дә, сандалга салып, уттай кызарганчы чүкер иде, кызган тимерне әзерләп куйган чүбек өеменә төртер иде. Чүбектәге ут күмергә, күмердән чырага күчеп, учак кабыныр иде.

...Чүбек таба алмый зиңкедек. Ахырда гимнастёрка җиңен ертып, аны мамык иткәнче тишкәләп, озын бер болтны чүкергә керештек. Мин дә сугам, Самуэль да суга. Коткарды гимнастёрка җиңе! Кабынды учагыбыз. Тик өскә кигән гимнастёрканың бер җиңе юк иде инде.

Үз утыбыз булу минем абруемны Самуэль каршында бермә-бер күтәрде.

Күбрәк очракта, русча сүзләрне белүебез җитмәгәндә, ымлыклар белән аңлашсак та, бер көнне, әллә төн идеме, мин аның ниндидер татар көен «шыңшып» утыруын ишеттем. Ашаудан соң битен сыйпап куюыннан ислам динен тотучы булуына да ышандым. Телне белми, ә йолаларны белә.

Көнне төннән аеру мөмкинлегебез булмагач, тәрәзәдән яктылык күренүне яңа көн туугa тиңлибез. Тәүлектә егерме дүрт сәгать булса, безнең тәүлек ике яисә дүрт сәгать кенә булуы да, кырык ике сәгатькә сузылуы да ихтимал. Вакыт узуны ашыйсы килүдән чыгып санар идек тә – ашыйсы килмәгән чак юк.

Бермәл тәрәзәдә яктылык чагылуны яңа көн туугa санап: «Бүген минем кызымның туган көне – бәйрәм итәбез!» – ди командирым Самуэль.

Шунда ук ул муенына таккан күн бөтүен ачып, кечкенә фотосурәт чыгара... Аның гаиләсе белән төшкән фото иде ул.

– Син бүген кайсы көн икәнен каян беләсең? – дим мин моңа.

– Җаным белән тоям, биологик сәгатемне тыңлыйм. Вакыты җитте: бәйрәм булгач, бәйрәм. Ниһаять, мул итеп сало салып кукуруз боткасы пешерәбез!

– Безнең организмнар ачлыктан нык какшаган. Рационны акрынлап кына арттыру тиешлекне беләбез... ярармы?

– Бүген бәйрәм көн булуын да беләбез... Аннары: без организмга буйсынырга тиешме, организм безгәме? Бәйрәмне бозма! Ниһаять, мин үз илемдә! Аны да бәйрәм итәрбез.

– Без әле диңгездәге йомычка хәлендә: кая йөзүебезне дә белмибез!

– Киләчәккә йөзәбез!

– Күрәчәккә булмасын, – дидем мин, Самуэльне тынычландыру өчен генә. Әмма ул, хыяллары белән рухланып – комарланып сало мичкәсен дә, селёдканы да каерып ачып, мул итеп ризыклар чыгарды; томат пастасын сыеклап, эчемлек ясады, котелокларның берсен үзенә, икенчесен миңа куйды. Аннары, күкрәгендәге бөтүен тотып үзенчә нидер әйтте дә, котелоктагы сыекчаны эчеп тә җибәрде, комсызланып селёдка ашады, селёдкадан соң зур кисәк салога тотынды.

Барсын да яхшыга гына юрап, карап торуымны күргәч:

– Нигә эчмисең? – диде ул миңа.

– Мөселманнарга эчү гөнаһ, – дидем мин, котелогымны этеп.

Ул бераз уйланып торгач, анысын да эчә башлады, чәчәде, әмма түкмәде, тагы салога тотынды. Эчә дә сало ашый, ашый да укшыган кебек итенә. Боларны күреп тору бик авыр булгач, мин кукуруз куырырга калай кисәге эзлим дип, табыннан читләштем. Җирәнүем дә булгандыр.

...Агызып алу җаен тапсаң, кайбер моторларда машина мае калган иде. Җае да, мич ясарлык торба кисәге дә, калай да табылды. Күпме вакыт узгандыр – табын янына килсәм, Самуэль, балык мичкәсенә сөялеп, коса алмый интегә. Нидер ярамаган ахры, тамагына бармагын да тыгып карый – «ах-ух» итә, укшый, берни чыкмый...

– Ни булды? – дидем. Ярдәм итә алмасам да, ярдәмгә әзерлегемне күрсәтәм. Ул башын күтәрми генә, үзенчә нидер мыгырдап, котелокка күрсәтте. Артыкка киткән дип әйтүе булгандыр. Ә минем уемны «агуланмадымы икән?» дигән шик кистереп узды. Самуэль кинәт калтырана, дерелди башлады, җыерылып, пружинадай кысылды шикелле... Нишләргә белми карап торуымны күреп: «Яткыр!» – диде. Коса-нитә калса, чәчәп буылмасынга, капландырып яткыздым да өстенә ябарга брезент кисәген алырга киттем. Аны табып килсәм, Самуэлем чалкан яткан, нидер сөйли, күзләре йомык.

Русчасы, полякчасы катнаш телдә сөйләнеп ятканының хәтеремдә сакланган эчтәлеге васыяткә тиң иде. Ул Белосток воеводасының Сокульск янындагы татар авылыннан икән. Балачактан кулы гарип булганлыктан, хәрби хезмәткә соң алынуын, мобилизацияләнеп, частька килеп урнашкач та әсирлеккә эләгүен, анда поляк корпусына язылып, күп хурлыклар кичергәннән соң, әйбәт кешеләр тырышлыгында качуга ирешкәч, монда килеп эләгүен вак-төягенә чаклы төшереп калдырмыйча сөйләде дә тынып калды. Арып йокыга китте дип уйлап, брезент кисәге белән өстен ябып, кукурузымны карарга киттем. Ул янып күмергә әйләнгән иде. Төтеннән котылырга төннек эзләп карыйм – таба алмыйм; аннары калайга яңа порция кукуруз салып куырдым да Самуэльне сыйларга янына килдем: күзләре йомык. Йоклый икән дип, тагы капландырып яткызмакчы булдым. Бу юлы, гәүдәсе, ничектер, авыр тоелды. Күз кабагын ачып карасам – күзенә кан сауган. Тәне җылы. Икенче күзен дә карадым. Битенә суккаладым – уянмый. Авызын ачып карыйм – телен тешләгән, сулышы юк. Үлгән дияргә – күзләре йомык. Үлгән кешенең күзләре ачык калуы турында ишеткәнем бар иде. Селкетеп, уяныргa кушып кычкырам – мәгънә юк.

Вахта кнопкасына басып карыйм – тынлык; кулга, күзгә эләккәннәргә суккалап, чаң сугам – тынлык. Әллә рубкадагылар үлгәнме? Самолётлар очкан, шартлаган тавышларның якында ишетелгән берсендә самоходкабыз сикереп куйгандай булды булуын, әмма без аны сизмәгән, белмәгәнгә сабышып, үз эшебездә булдык. Тагы Самуэль янына килдем. Күз кабакларын ничек ачкан булсам, шулай ята. Үлгәндер дип уйларга куркып утырам янында... Тыны юк...

...Күпме утырылгандыр, кинәт: аны нишләтергә, дигән сорау туды. Шул сорауга җавап табалмыйча күпме вакыт узгандыр, сары ящикның зурысына салып, брезент белән каплау дөрес булыр дигән фикер туды. Шулай эшләдем дә, «табутны» «тигр» моторы артына шудырып, брезент белән каплап та куйдым. Командирым «җирләнде». Мин, үземә-үзем командир булып калгач, әллә нервлар какшаудан, әллә ашамаудан – үз үлчәмем белән өч көн, өч төн рәттән йоклаганмын...

...Көн исәбен югалтканлыктан, мәет янында күпме вакыт, ничек яшәвемне хәтерлисем дә, сөйлисем дә килми. Минеке белән чагыштырганда, Робинзон Крузо күргән-кичергәннәр – курчак уены.

...Шунысын әйтеп узу кирәктер: мине чамасын белеп кенә кукуруз боткасы ашау коткарды. Беренче бөтендөнья сугышы чорында тозланган шпикны кайнатып, шулпасын түгә идем дә, аны тагы бер кат пешергәч кенә, турап, боткага сала идем. Томат пастасын да озак кайнаткач кына файдаландым. Мөгаен, шуңадыр, агуланмадым, ачыгу чиреннән дә тереләдем.

Машина маен күп яндыру баш сызлауга сәбәп булган. Трюмга тулган сөремнән котылыр өчен, домкрат белән түшәмне, ягъни палуба идәнен тишүгә ирештем.

Трюм һавасы күзгә күренеп сафлангач, тән хәрәкәтләнү сорый башлады. Трюмнардан трюмнарга күчеп, эзләнәм дә уйланам, уйланам да качу планнары корам.

Монда төрле двигатель моторлары белән бергә кайбер танкларның кабиналарын бөтен килеш төягәннәр иде. Приборлары өчендер инде, минем хәлдәге кыргыйга әверелгән кешене кызыксындырырлык нәрсәләр очрамаса да, төзегрәк сакланган нимес танкының әсбаплары «оясында» кырыну станогы, язу белән тулы блокнот, баласын кочкан хатын сурәте белән карандаш кисәге таптым. Шикләнсәм дә, алдым аларны. Кырыну станогын, көзгем булмаса да, шунда ук эшкә җиктем. Блокноттагы буш калган битләрнең дә кирәге чыкты: шул тапкан көннән алып, булганнарны «теркәп» бара башладым. Әгәр мине тере килеш тапсалар, табылу көненнән кирегә таба санап, чама белән күпме гомер бу зинданда яшәүне исәпләп чыгарырга булыр, дип уйладым...

...Һәм бик дөрес уйлаганмын: табышлы булуыма утыз өч көн дигәндә, трюм тәрәзәсеннән корабль күреп, гудок тавышы ишеттем. Гаваньга керергә рөхсәт соравыдыр, дип фаразладым...

Бу, чынлап та, безнең баржаларның каядыр килеп җитүе иде. Кайда? Ник килдек? Бу сорауларга җавап тукталуыбызның өченче иртәсендә булды: «Засниц» дигән порт-шәһәрдә икәнбез. Германиядә. Кемнән белдемме?

...Синең белән танышлыкны ныгытуым да, ерактан башлап бәйнә-бәйнә сөйләвем дә шул кешегә рәхмәтле булудан. Аның васыятен үтәргә тырышудан... Люк ачылып, палубага чакырган әмер бирүче – Казан танк училищесы курсанты Ян Роммаль – тётя Люданың никахсыз ире – Гәрәйнең әтисе иде.

– Кая икенчегез? – диде ул русча. Ә мин көтелмәгән бу очрашудан тораташтай катып калдым.

Мин һаман сүз таба алмыйм.

– Син мине таныйсыңдыр бит.

– Мине әсир итүче нимес офицеры син.

– Шуннан?

– Әсир төшмәс өчен Совет солдаты йә үзе үләргә, йә әсир итүчене үтерергә тиеш...

– Ник үтермисең?

– Башта беләсе иде: мин ничек монда? Ник монда?

– Син минем улым белән аның анасы хакындагы дөреслекне белүче. Ягъни, миңа бик кыйммәткә төшкән шаһит син.

– Трофей диген...

– Сугыш әле бетмәгән. Әмма Германиянең җиңеләчәге бәхәссез. Һәммәбез трофей. Минем белән ни булса да, кайда гына булсам да, мин сине ташламаячакмын.

...Сөйләшү-аңлашу бик озакка сузылмаса да, күп сорауларга ачыклык кертте: ул, танкта янып, әсир төшкәч, Казанда укыгандагы танышы ярдәмендә кача алган; абруйлы фамилиясе каршылыкларсыз яңа хезмәткә урнаштырган; ничә хат язса да, Казаннан хәбәргә ирешә алмаган, интендант хезмәтенә күчкән; таныш дипломатлар ярдәмендә Казаннан 43 нче елда хезмәткә алынган

солдатны эзләтә-эзләтә, ниһаять, миңа килеп юлыккан... Әкияттәге кебек. ...Калганының әһәмияте юк. Аның хәзерге эше шушы баржаларга төялгән яшерен стратегик йөкне адресатына тапшыру икән.

– Мине кем, ничек сатты? – дигән сорауга:

– Сугыш булган җирдә сатуы да, алуы да була. Тыелган мәсьәләгә кермик – аңа җавап юк, – диде. – Сине сакларга куелган Польша татарының хәле ничек? Нигә ул трюмнан чыкмый?

...Бер гаебем булмаса да, җавап бирә алмадым. Соравын Роммель башкача кабатлады:

– Әллә сезнең блокка да бомба төштеме? Күрәсеңдер: матрослар кубригы снаряд эләгеп җимерелгән, радист та, электрик та үлгән...

– Самуэль агуланып үлде! – дип әйткәнемне сизми дә калдым.

Аннары ничек булганын бәйнә-бәйнә сөйләргә туры килде.

– Өч көннән кырыгы тула, ә ул әле җирләнмәгән дә, – дидем, үпкә белдергәндәй.

– Сезнең конвой җыенысы егерме ике генә көн килде. Каян алып «кырыгы» дисең?

– Үз исәбем буенча шулай чыга.

– Кайда аның мәете?

– Сары ящикта, каплаулы. Бөтүен салдырып алдым, номеры миндә.

– Бу турыда башка беркемгә дә әйтмә...

– Кем бар монда, кем белән сөйләшә алам?

– Ни турыда сөйләшер идең?

– Аны җирләргә кирәктер ич?

– Корабльдә үлгәннәрне диңгезгә ташлыйлар...

– Ул – мөселман. Безнең диндә андый йола юк. Күмү тиеш.

Кинәт кенә ул, сакчы чакыртып, мине трюмга бикләтте дә, үзе, ашыгып каядыр китеп барды. Икенче көнне иртән сакчы мине, бомбоубежище кебек бинага кертеп, Роммельгә калдырды. Шунда мин аның да кемгәдер буйсынуын, аның да хуҗасы барлыкны аңладым.

– Менә нәрсә, Захарчик, – диде Роммель, сакчы чыгып китүгә күземә карап, – радист, электрик белән бер кабергә сине дә күмәргә туры килер...

Бу хәбәрне ничек кабул итүне чәчем кинәт агаруны күрсәтеп сөйләр идем – чәчем коелып беткәнгә дә ун еллап бардыр, – Роммельгә биргән сорау хәтердә:

– Алар да мөселманмыни?

– Сугыш барганда традицион йолалар онытыла. Сине туганнар каберенә күмәбез.

– Корабльдә үлгәннәрне диңгезгә ташлыйлар, дип үзегез әйттегез. Мин бит баржада үлмәдем. Нинди туганлык?

– «Зәкәрия» дип Конапацкийны җирлибез дә, аның исеме белән син яшәп каласың. Шулай кирәк.

– Иленнән урланган, исемен югалткан сатлык кемгә кирәк икән?

– Миңа кирәк! Улымны тапканчы, син минем белән булачаксың.

– Ул чакта Германия зоналарга бүленгән идеме әле? – дип сорыйм Зәкәрия-Конапацкийны бүлдереп, тарихны белгән кешедәй.

– Үземнең статусымны да белмәгәндә, каян ул чакта зоналар, союзниклар турында белим? – диде ул.

– Хуҗаң, ягъни сине урлап, әсир итүчең белгәндер.

– Ул чакта һәркемдә ничек тә исән калу уе гына иде...

* * *

...Иксез-чиксез диңгезгә ташланган «йомычка» өстеннән бомба төягән самолётлар оча, җил, давыл, дулкыннар. Әле алда, әле артта бомбалар шартлый. Көткәнебез – үлем. «Кайчан?» «Ничек?»

– Исән калуыгыз очраклылыкмы, планлы «эш» нәтиҗәсеме?

– Плансыз бер эш тә эшләнми. Үлем дә, яшәү дә очраклылыклар конгламираты.

– Исән калу – яшәүнең төп күрсәткече.

– «Яшәдек» дип әйтерлек булмаса да, Засницта үлми калу могҗизага тиң. Ә могҗиза тереләргә генә очрый.

...Бер ай чамасы интегүләрдән соң, «ирекле ялланган Польша татары Конопацкий» исеменә документлар эшләтеп, суднолар төзәтү остаханәсенә Роммель мине тимерче итеп урнаштыра. «Ирекле» кол булып анда бер айлап яшәгәч, безнең «конвойны» көчле буксирга тагып, Хейлигенхафен портына җибәрәләр. Роммель, корыдан барып, «конвой»ны каршы алырга тиешлегенә, теләсә нинди очракта мине эзләп табачагына ышандыра.

...Германиянең җиңелүен, сугыш бетү хәбәрен мин Хейлигенхафен портында якорь ташлагач белдем...

...Соңыннан белүемчә, 1945 елның июль ахырларында, Ян Роммель Потсдам конференциясе барган вакытта американнарга бирелә. Американнар исә аны Төньяк Африкадагы инглизләр корпусын тар-мар иткән фельдмаршал Роммельнең туганыдыр дип, англичаннар хөкеменә тапшыра. Ныклы тикшерүләрдән соң, гаепле туганлык расланмагач, Ян Роммельгә яңа оешкан ООН мандаты биреп, булган мөлкәте белән, Австралия Союзына кергән Науру утравына сөрергә хөкем итәләр. Мондый хөкем чыгарылуда кем кулы уйнагандыр, әмма Роммель үзе дә дипломат, тумыштан юрист иде. Кирәк урында фельдмаршалның туганы, кирәге юкта «адашы» дип ышандыруларына үзем шаһит.

...Без барасы Науру Яңа Зеландия кануннары буенча яшәсә дә, бик ярлы хәлдәге утрау булып, Ян Роммель экспедициясе аны җанландырырга, каучук плантацияләрен үрчетергә тиеш булган икән.

Бу экспедициягә тагын нинди бурычлар йөкләнүе, кемгә-ничек буйсынуы, составы, бюджет чыганаклары, сәяси һәм административ каршылыклардан ничек котылуы турында Джордж Сельдесвер дигән журналистның «Дөньяны тоткан мең дә бер хуҗа» китабында Ян Роммельгә багышланган бүлегендә бәйнә-бәйнә языла. Фильмы да бар.

...Китапка кертелгән байлар исемлегендә 363 нче урынга куелса да, минем өчен хуҗам һәрчак беренче булды. Гадилеге, кешелеклелеге өчен, эшчәнлек үрнәге булуы өчен.

...Безне Көнбатыш Австралиянең Фримантл портына китереп, ниһаять, дүрт айдан соң якорь ташлаталар. (Науру атавына судноларыбызны кабул итә алмау сәбәпле, маршрутыбыз үзгәрде дип сөйләнделәр.)

«Ян Роммель ничек баеды?» – дигән сорауның иң өстә яткан җавабы шул – баржаларга төялгән ватык техниканың төзек «әгъзаларын» буяп, хуҗалыкта файдалануга яраклаштырып сату. Малайзиягә кергән бер утрау губернаторы гына да җиде танк моторы алды. Андый утрауларның мин белгәннәре генә дә йөздән арта. Кайсыберләренә мотор сазлык киптерү насосларын эшләтү өчен кирәк, кайберләренә электр тогы алу өчен...

Карбюратор, динамо, аккумуляторларның нindiләре генә юк иде бездә! Төп белгеч мин булгач, йөзебезгә кызыллык китермәдек, дип мактана алам. Безнең марка белән сатылган техниканы әле дә булса эшли дип ишетәбез.

Бу безнең фирманың башлангыч капиталын туплауда төп мая булды, аннары чын бизнеска юл ачылды. Каучук плантацияләрен киңәйтү, сыер, сарык фермалары булдыру, тире эшкәртү заводлары төзетү, сату-сәүдә урыннары ачу өчен күп көч һәм акча китте. Барысына да иреште Роммель. Дөресе – ирештек. Бер генә нәрсәгә ирешә алмадык – гаилә бәхетебез булмады.

...Соң өйләнде ул... өч-дүрт ел балалары булмады. Ата-бабалары немец дип балеринага өйләнгән иде. Таиландтан иде. ...Никахларының сигезенче елында гына, дәваланулары нәтиҗәсендә, малайлары туды. Әмма гомерсез булды ул бала. Өч яше тулыр-тулмас үлеп, ата-анасына хәсрәт кенә калдырды. Башка балалары юк... ...Монда килгәнче тикшерүләр барышында Германиядә якын туганнары калмавы раслангач, аңа туганнарның «ераkларын» эзләтүдән мәгънә юк иде. Хатынының да ышанычлы туганнары булмаганлыктан, ул мине өйләндереп, уртак бала үстерү уе белән яши башлады. Ә мин кемгә өйләним?

«Зәкәрия» исеме белән күмелгән Самуэль Конапацкий рухы каршында үзебезне бурычлы саный идек. Миңа Польшадан мәрхүм Самуэльнең хатыны белән кызын алып килеп, гаилә кору бурычы йөкләнде. Бардым. Күрдем. Самуэльнең хатыны тәкъдим турында ишетергә дә теләмәде, кызы кияүдә иде инде... Җан тынычлыгы өчен тәкъдим иткән долларны да алмадылар. Күңелсез очрашу булды ул. Засниц шәһәрендәге каберлектә «Зәкәрия» исемендә ятучы Самуэльгә чәчәк салып, Рәсәйгә чыгарга виза алыр өчен Берлинга юл тоттым. ...Тик, консуллыкта ашыгычлык белән кайтуымны таләп иткән телеграмма бөтен планнарымны челпәрәмә китерде...

...Ашыгып кайтуым унңиде көнгә сузылды. Мин кайтканда, Ян Роммель Аделаида шифаханәсендә яшәү белән үлем арасында ята, хатыны Ава якты дөньяны калдырырга ашыккан иде...

...Мине Европага озатканчы, хатыны теләге буенча, Роммель яхта алдырта. Аңа «Яманлыкны оныт» дигән исем куйдырта. Мәрхүм сабыйларының туган көнен аның истәлегенә «Зигфрид» дип аталган каучук үстерү утравында уздырмак булалар. «Әҗәлең җитсә, суда янып үләрсең», – диләр. Плантациядә янгын чыгып, ут яхтага да күчә – ир белән хатын төзәлмәслек яраланалар. Сәер янгын була ул... ...Роммель аны гөнаһларым өчендер дип тикшертми, эш кузгаттырмый...

...Өч көннән балеринаны зурлап күмәләр, ә Роммельне янгыннан дәвалау үзәгенә – Аделаида шәһәренә илтәләр. Шунда, фирма исеменә «ут кабып», олы «янгын» башлана. Кем хуҗа булыр? Кем? Кем? Тәне яртылаш янган Роммельнең бу «янгынны» сүндерергә көче юк, әмма акылы саф: ул мине чакыртып телеграмма җибәртүгә ирешә.

...Фирмада төрле һөнәр ияләреннән ике дистәдән артык белгеч ялланып эшли. Аларның, үз киләчәкләре өчен борчылудан, китү-күчү турында, фирманың таралачагы турында сүз куертулары докторлар аша Роммельгә ишетелә.

Ни хикмәттер, шул хәбәрләр аны авырудан терелергә мәҗбүр итә. Беренчедән, ул үзе табып үстергән белгечләрнең фирмадан китүен теләми, икенчедән, аңа фирманың яшәве кирәк. Әнә шул кискен көннәрендә мин кайттым. Күрешү рөхсәт ителмәсә дә, кайтуымны аңа белдерүгә ирештем.

...Икенче көндә үк ул Фримантл шәһәренә кайтаруны оештырды; кул астындагы һәммә белгечне, нотариус-юристларны офиска китертеп, фирма белән җитәкчелек

итүне миңа, ягъни Самуэль Конапацкийга тапшыруы турындагы тәзкирәләргә кул куйды. ...Барысы да «ах» итте, версияләр тишелде, «чыш-пыш» китте.

...Офистагы белгечләрнең һәммәсе диярлек фирмадан китәргә теләүләре турында минем исемгә гариза бирделәр. Бу – Роммельгә каршы махсус оештырылган акция сыманрак килеп чыкты...

...Калдырылган гаризаларны тотып, Роммельгә килсәм – сулышы юк, күзләре ачык. Пульсын да тикшереп тормыйча, үзебезнең докторга шалтыратам. Ул, чакыруны гына көткәндәй, бик тиз керде; карады, күрде дә, соң инде, диде. Тәүбә! Тәүбә! ...Үземне-үзем белештермичә: «Терелт!» – дип акырдым.

...Арсеналындагы һәр мөмкинлеген кулланып, утыз-кырык минутлар тырышуы бушка китмәде – «пульсы бар!» диде доктор, пышылдап кына. Роммельнең бер тәүлек йоклап уянганнан соң миңа әйткән беренче сүзе: «Син – Зәкәрия-Самуэль – минем коткаручым!» – булды.

Шушы хәлләрдән соң тагын унике ел яшәде ул... Мин эшләдем, ул идарә итте. Керем – уртак, сагышлар – аерым. Минем тәкъдимемне кабул итеп, башкарган уртак эшебез каучук – гевия (Хевея) плантацияләреннән котылып, энҗе молюскалары үрчетү фермасы булдыру иде. Ул безнең төп кәсебебезгә әверелде. Роммель тәкъдиме белән минем исемдә йөртелгән бу тармак безгә каучук плантацияләре ясаган чыгымнарны оныттырып кына калмады, ә яңа тармак – сарык үрчетү мәйданнарыбызны арттырды, фабрикалар төзетте.

Натураль каучукның кадере китеп, синтетик каучук заманы килгәч, безнең плантацияләребез чыгымнар чыганагы булып калган иде. Ялланган хезмәткәрләребезнең үзләре теләп күпләп китүе дә безнең файдага булды. Судлашып йөрмәделәр. Шулай аякка бастык, канатландык, үз кораблебезне булдырдык, вертолёт алдык...

Барысы да бар – бәхет кенә юк. ...Шул хәсрәт аны гүр иясе итте.

«Дөньяны тоткан 1001 хуҗа» каталогының икенче санында бүген Роммель урынында «Конапацкий-Зәкәрия» дигән исем. Бу исем миңа Роммельнең бурычларын да йөкли.

Аларның иң җаваплысы – теләсә нинди юллар белән Генрих-Гәрәйне табу һәм атасыннан калган капитал белән идарә итүне аңа, ул исән булмаса, аның нәселенә тапшыру иде.

## 3 БҮЛЕК

### Әманәт

Язмамның төп исемен шулай кую дөрес. Чөнки һаман сүз шул әманәт турында барды, барачак...

Сюжет кора белмәү – язу тәҗрибәм юклык галәмәте.

Ян Роммельнең васыяте турында язылса да, Самуэль Конапацкийның – Зәкәриянең сүзе бетмәгән иде әле:

– Син коммерция-финанс махинацияләре белән тапланмаган гадел хезмәткәрсең, – дип дәвам итте ул сүзен, – телевидение экраннары аша «кеше эзлим» дигән циклың белән республикада яхшы абруй казанган журналистсың икән. Атасыз үскән балалар, баласыз картайган өлкәннәр проблемасы һәр илдә бар. Эзләнүләр дә, табышлар да өзлексез дәвам итә. Адвокатларым, киңәшчеләрем белән сөйләшкәч, мин шундый карарга килдем: Ян Роммель васыятен үтәүне син үз кулыңа алырга тиешсең.

Радиотапшырулар циклы оештырасыңмы, телевидение буенча барган үз

тапшыруларыңда урын табасыңмы, китап язасыңмы, фильм төшерәсеңме – анысы синең ихтыярда.

Тик нәрсә генә эшләсәң дә, аның нәтиҗәсе җәмгыятьнең температурасын сүрелдерергә түгел, ә күтәрергә тиеш. Сер итеп кенә әйтәм: температураны төшергән дарудан файда юк. Бу эшләр өчен мин синең счётка биш миллион доллар күчертүгә хәзер үк ышаныч язуы – гарантия бирәм.

– Минем банкта да, сберкассада да счетым юк, – дидем, үземне үзем ишетерлек кенә тавыш белән.

– Ачарбыз.

– Проблема счётта гына булмаса?

– Төп проблема – бу эшкә мин исән чакта өлгерүдә. Шаһитлар көннән-көн кими. Алар үлеме белән хакыйкать тә югала.

– Эш шаһитлардан гына торса икән...

– Мин дару белән генә яшим. Үзең күрдең – каным тиз куера. Операцияне күтәрә алмассың, диләр. Ян Роммельнең васыяте үтәлгәнне белмичә, миңа үләргә ярамый.

Фильм төшерергә дисәң, аның үз кулы белән язган истәлекләре, көндәлекләре бар. Мин аларны сиңа бирермен. ДНК анализлары, төрле белешмәләрнең копияләре, Союз буенча эзләтү гаризаларына җаваплар – барысы да сакланган.

– Кирәкме икән алар?

– Кирәге чыкмаса да, югалту ярамас.

...Ян Роммельнең әнисе ягыннан бабасы Адольф фон Байер – галим-химик, 1905 елда аңа буяу һәм хушбуйлар буенча ачышлары өчен Нобель премиясе бирелгән.

– Зәкәрия абзый! Сез сөйләгәннәр кызыклы да, гыйбрәтле дә. «Шуларга таянып, ни дә булса иҗат итү мөмкинме?» – дигәндә, мин: «Мөмкин түгел!» – дияр идем. Чөнки бу оригиналлар үзләре теләсә нинди күчермәдән көчлерәк. Кино – копиянең үтемле бер төре генә ул. Мин үзем, мәсәлән, бу эшкә алына алмыйм. Иҗади әүхәтем дә, тәҗрибәм дә сез һәм Ян Роммель ирешкәннәр тирәнлегендә «йөзәрлек» түгел.

...Без – коммунизм идеяләре корбаннары. Алардан тиз генә котылып булмый. Русларда: «Лучше ужасный конец, чем ужас без конца», – дигән әйтем бар. Эзләп-эзләп тә бернәрсәгә дә ирешмәү хурлыгына юлыкканчы, эш башлаганчы ук аннан баш тарту дөрестер. Ышанычың өчен рәхмәт... Үпкәләшмик. Бетерик бу турыдагы сүзне.

– Син инде кырыктан артык фильм төшергәнсең, акча булса, тагы да төшерер идем, дип, газеталарга интервьюлар биргәнсең, миңа аларны таптылар, укыдым, таныштырдылар... Мин сиңа илегездәге хакимнәргә дә, законнарыгызга да каршы эшләр тәкъдим итмим... Аңлыйм.

...Законнар бит алар – хатын-кыз кебек, кайда да мактау гына көтә. Һәр илдә шулай. Түз, җайлаш! ...Син бит югалган кешене эзлисең! Кеше эзләү! Үз темаң бит! Бер югалган кешене табу – мең кешене шатландыру, дөньяга шатлык өләшү ул!

– Абзый, мин бер-берләрен югалтып, сәясәт токтынлыгында яшәүчеләрне эзләүдән баш тартам, димим. Бу темага нәфис фильм төшерергә алынмас идем, – дидем. Чөнки бүген сәясәт токтыны булмаган кешене табу ихтималы юк! Барыбыз да сәясәт токтыннары без. ...Әйе... Минем иҗаттагы максатым кешеләр арасыннан кеше эзләү. Шул юлда миңа берәр Генрих очрый икән – мин табышлы. ...Әгәр дә аларның берәрсе дуңгыз булып чыкса йә алкаш булса?

– Шулай да тыңла: сиңа минем үз йомышым, ягъни шәхси үтенечем дә бар. Әманәтем. Шулай ук – кеше эзләүгә бәйле. ...Ул инде менә нәкъ син эзләгән чын кеше иде...

– Кем ул?

– Мин үземнең җәсәдемнең әткәй белән янәшә күмелүен теләр идем.

– Моңа кем каршы? Законмы? Бездәгеме, сездәгесеме?

– Бу мәсьәләдә әлегә кадәр сүз кузгатканым булмады.

– Күмелми калган мәет юк. Зинһар, бу турыда сүз алып бармыйк.

– Үлгәч сөйләшеп булмый. Әткәй кабере белән янәшә урын алып куярга кирәк. Сездә хәзер ничектер, бездә урын алу проблема...

– Казанның кайсы зиратында күмелгән әтиең?

– Бу соравың белән син мин сөйләгәннәргә игътибарлы булмавыңны күрсәтәсең. Мин атамның үлеме-тереме икәнен дә, кайдалыгын да белми алындым, ярты елга якын Сослангерда «сосладылар». Лагерьда шулай озак тотылган башка солдат бармы икән? Менә сиңа «кеше эзләргә» тагы бер язмыш! Мин сиңа бистәдә яшәгән эшчеләрнең нәселләре аша эзләү өчен өч-дүрт фамилияне бирермен. Әткәй белән бер чорда заводта эшләүчеләрне.

– Илдәгесе – иңдә булыр, эзләргә калгач эзләрбез.

– Сиңа анда «Хызыр» ярдәм итмәс бит...

– Ярдәм күрсәтүче һәркемне «Хызыр» дип ышанам мин.

– Ышанычыңа ышанып, бер миллион долларга сертификат бирәм сиңа.

...Менә ул... Кайсы банктан ничек алырга? – җаваплары конвертта. Тоткарлык килеп чыкса, безнең фирма юристларының телефон номерлары да шунда. Кабул итеп ал! Русча беләләр – сөйләшерсез.

– Сөйләшү булмаячак. Чөнки мин сезнең бу «сертификат» дигән нәрсәне дә алмыйм.

– Бусы минем үземнең шәхси фондымнан. Атам-анам зиратын табып таш куйдыру өчен. Урын өчен дә түләү кирәк булыр...

– Эшләнмәгән эш өчен гонорар алу бездә хилаф гамәл санала.

– Аванс бу!

– Мин сезгә болай да бурычлы.

– Бурычын таныган – бөлмәс, аңа ышаныч сүнмәс.

– Ышаныч терәге – гамәл. Башта гамәл кирәк.

– Моннан дүрт ел элек бер нәзарәткә вакыф малы күчердем. Фәкыйрь мөселман кардәшләрне туйдырып, кундырып чыгару өчен хәйрия йортын төзү максатында, дип сөйләштек. Ишетүемчә, йортны салганнар, ашханәсен ачканнар. Тик бай эшмәкәрләргә очрашу урыны буларак кулланалар икән.

...Йортның кереме нәзарәткә булмаса да, бинаны тоту чыгымнарын нәзарәт түли икән. Тикшерү башлана. Эшләре судка куела... ...Нәтиҗәдә вакыф малына салынган бинаны «банкрот ясап» саталар. Алучысы – шул йорт ашханәсен тотучының улы! Зур отыш аның кесәсендә. ...Бу гыйбрәтле тарих син әйткән гамәлдән генә тора түгелме? Гамәл төрле була.

– Минем белән шартнамә төзү булмаячак. Кыстамагыз.

– Бу карарың сиңа булган ышанычымны тагы да ныгыта гына төшә. Нишләмәк кирәк – һәркем үзенә ышанучыга мохтаҗ шул... ...Син, заказларны кабул итәм, алдан акча гына алмыйм, дидең. Мин хәзер адвокатыма барып шартнамә яздырам. Сиңа, барыбер, үзең әйткән шартларга ризалашып, имза саласы гына кала. Шул уңайдан видеокамераңны да алып килермен, паспортыңны бир... Вакыт бетеп бара.

– Паспорт бирелә торган нәрсә түгел. Шикләнәм.

– Шикләнү – белемнең башы.

– Ышануым белән янәшә шигем дә яши, абзый, нишлим, үпкәләшмик. Холкым шундыйдыр...

– Гомере буе гел ялганда яшәгән кеше шуңа яраклаша, дөреслеккә ышанмый башлый. Шул синдром бу.

– Ышанасы бик килә дә...

– Һәркемнең икенче кеше күңелендә үзенә кулай урын белергә омтылуы, хәтерләрдә озаграк сакланырга тырышуы табигый...

– Алары шик тудырмый. Ә менә туган нигездә миннән башка ышанычлы кешегез булмау табигыйлекне боза, шикләндерә.

– Сиңа булган ышанычым, милләтемә ышанычымнан киләдер, энем. Бәхеткә – син шул милләтемнең бер вәкилесең. Аннары... Һөнәрең – миңа кирәкле һөнәр. Шунлыктан ниятем ният булып кала. Үзгәрми. Мин чигенү яшеннән узган.

...Китте абзый. Паспортымны алды. Егерме кешелек брезент палатканың алгы бүлемендә, ниндидер йөктән котылгандай, җиңеләеп калдым. Утырам ялгызым уйларыма күмелеп. Ялгышларымны санап. Ышаныч өчен генә миллион доллар! Ышанмау шулай ук кыйммәт бәяләнергә тиеш түгелме?..

...Казанга кайтуга, бу сәер бай абзыйның «серләрен» ачыклау өчен «Черек күл» буенда көтеп торсалар, ни дип акланырмын? Гәрчә мин аннан берни сорамадым, тәкъдим ясамадым. Үз эшемне дәвам итәрмен, дидем. Бары шул бит!

...Әгәр яшерен микрофоны булып, әңгәмәбез язып барылса – диктофонда гел аның монологы!..

...Хәзерге техника күргән-ишеткәнне генә түгел, уйлаган уйларыңны да белә, диләр. Шунысы куркыныч... Ул сөйләгәндә, тәкъдим ителгән миллионнар кулга кергәч, аны нишләтергә белми бүлгәләп утырдым. Бүлгәли алмагач, баш тарттым. Алай түгелме? Хәтерләмим. Баш тарту факты булдымы? Булмады шикелле... Ә нәрсә булды соң?

...Сикереп чыгармын дип упкынга чумдым, ахры... Ничек чыгарга? Бүлмәдәшләр белән киңәшләшми булмас. Читләшсәләр дә, алар миңа ят түгел. Якынаюга сылтау табылуга шатланып, палатканың эчке бүлеменә керсәм, барысы да утырганнар, миңа, башка планета кешесен күргәндәй, гаҗәпләнеп карыйлар.

– Ни булды сезгә? – дип сораудан башка сүз тапмадым. Алар хор белән: «Ә сиңа ни булды?» – диделәр һәм шул бер кәлимә белән без сөйләшкәнне ишетеп утыруларын саттылар.

– Беләсез – «Хызыр галәйһиссәлам» миңа күп ярдәм күрсәтте.

– Инде шуның бәрабәренә хак соравын аңладык шикелле.

– Хакны ул үзе куеп, үзе бирмәкче.

– Фашист офицеры турында фильм төшерү шарты белән.

– Кеше турында, баласын эзләүче ата турында...

– Геббельс күп бала атасы булган. Кемдер сиңа килеп аның турында фильм төшерергә дисә?

– Сез дөрес аңламагансыз.

– Һәр сүзегез ачык ишетелмәсә дә, әңгәмәнең ни турында баруы аңлашылды.

– Нинди киңәш бирәсез?

– Тәкъдим үтәлгән очракта күпме түләячәген әйттеме?

– Аванс суммасын гына әйтте.

– Әнә шунысын без ишетмәдек, чөнки ул анысын, пышылдаган кебек, акрын гына әйтте.

– Ә минем колагымда шул сан һаман яңгырый шикелле...

– Күпме?

– Биш миллионга өстәп тагы бер миллион.

– Суммы?

– Доллар?

...Бу җавапны ишеткәч, Хәйдәр хәзрәтне очкылык тота башлады, Мәхмүт абзый күзләре дә, авызы да ачык килеш катып калды. Бераздан, чи арыш тутырылган капчыктай, гөрселдәп, урынында ауды.

– Человек умирает, где доктор? – дип кычкырдым.

– Кычкырма! Монда чукрак урыслар юк! – диде таможник Рәшит, үзе дә акырып.

– Ху-хуже! – диде Хәйдәр хәзрәт.

Кемдер: «Наивный булып кылана!» – дисә, икенчесе: «Уйный!» – диде. Миңа юнәлгән идеме, Мәхмүт абыйгамы – аклану максатында бүлмәдәшләргә Зәкәрия-Самуэль-Роммель тарихын сөйли башладым. Докторыбыз, шприцын чыгарып, аңа яңа энә эзли иде.

– Бу кадәресен... без инде... белү түгел – киптереп элгән... Син әйт: нигә дип... очып кергән... бәхет кошыннан... баш тарттың? – диде Хәйдәр хәзрәт, көч-хәл белән.

– Мин бернидән дә баш тартмадым, ә аталарын югалткан балаларны, балаларын җуйган аналарны эзләүне дәвам итәчәкмен, дидем. Ул шуңа ризалашты.

– Ә миллионнар белән ни булачак? Болгар җилләредәй Ташкент-Ашхабад якларына исәчәкме?

– Татарстанның җилгә очкан миллионнарын саный башласаң – үзең җилгә очарсың...

...Ниһаять, энәсен табып, бүлмәдәш докторыбыз Мәхмүт абыйның беләген мамык белән сөртмәк булды. Әллә спирт исеннән, әллә ушына килүеннән, атказанган судья кулын тартып алды да:

– Йогынма! Мин әле синең даруга калмаган! Әнә – режиссёр кадады инде: башта биш миллион дип, аннары аңа тагы бер миллион өстәп.

– Долларда! – диде кемдер.

...Умарта күчедәй «гөрләү» башланды. Аны Мәхмүт абыйның «ыс-сс»лавы туктатты:

– Счеты юк, имеш. Синеке булмаса, мондагы һәркайсыбызныкы берничә. ...Ни өчен дип уйлыйсыз? Әгәр берәребезнең счётына күчертсә – бер проценты счёт хуҗасына китә, статьясы бар.

– Аны белмәгәндер ул. Белсә эшләмәс иде.

– Белепме, белмиме – кайсыбызныңдыр йөз меңе янды, очты...

– Җәмәгать! Бу легенда тоташ ялганнан ялганып ясалган. Имеш, ул Сослангерда ярты елга якын какланган. Анда өч айдан артык тотмаганнар.

– Лагерь өчен кирәкле һөнәр иясе булса тотканнар.

– Аннары, имеш, Совет поезды Польшада булып чыга. Анда Европа стандарты! Вагоннарның рельска сыю-сыймавын белми алдый... Аннары... безнең тягач моторлары нимескә ник кирәк?

– Ул мәсьәләдә эш болайрак тора, – дип мәсьәләгә Рәшит ачыклык кертергә алынды, – мәсәлән, безнең «И-2» самолёты РКК заказы белән эшләнгән, нимес

конструкторы Эрнс Хейнкел истребителенең игезәге. Ике шөребен алыштыру җитә – кайда эшләнгән булуын аера да алмыйсың...

– Монда самолёт моторының ни катнашы? Сүз алты миллион доллар турында бит...

– Шуны әйтәм шул! Ә танк моторлары нәрсә ул? Тимер-томыр! – диде таможник Рәшит, үз сүзендә калып.

...Шунда Хәйдәр хәзрәт тә хәрби белемен сиздереп куюны кирәк тапты:

– «Коммунар» немесләрнең «пономагы» ул. Аермасы – чабатасында, ягъни чылбырында гына.

– Танкларның орлыгы неместә генә түгел. Сормовода төзелгән беренче танк «Рено»дан күчермә. Мине гаҗәпләндергәне – аларның барысы бер составка төялгәнлегендә, – диде Мәхмүт абый, шок хәленнән чыга алмыйча, – кем төяткән, ничек ычкына алганнар? Кем кемгә түләгән?

– Ә ни өчен немесләр Липецк шәһәрен бомбага тотмаганнарын ишеткәнегез бармы? – диде Рәшит, күп белгәнен күрсәтергә тагы җай чыкканга җанланып, – чөнки аларның лётчиклары Липецк аэромәктәбендә Геринг белән бергә укыганнар. Герингның сөяркәсе Липецкта калган...

– Монда сөяркәләрнең ни катнашы бар? Сүз вагоннарның ничек Польшага эләгүе турында...

– Сүз алты миллион долларның бездән очуы турында бара, эзне югалтмыйк.

– Очырга әле аларга канат чыкмаган.

– Имеш, Польша татары шпиг ашап үлә, Казан татары исән кала. Агуны пешереп кенә бетереп булса икән... Ялган!

– Роммельнең, имештер, исән калган бер туганы да юк. Немесләр алар тугыз буынны туган итә торган милләт. Бу, имеш, кузнец малаена – татарга калдыра. Ышандырмый торган ялган. Ялган!

– Ялган булса, вакыф малы күчермәс иде ул! Күчерүе хак бит! – дидем мин, боларның шаулашуыннан арып. ...Ниһаять, тынлык урнашты.

...Бәхәстә катнашучы һәркем үзенә килгән зыян турында уйлап, ялгышны ничек төзәтүгә вариант-җаваплар эзли иде, ахры. Сүзне Мәхмүт абый яңартты:

– Хаҗилар! – диде ул, лотереясы оту ихтималын сизенгән кешедәй сак кына. – Чокырдан бер сикерү белән чыгу әмәлен таптым шикелле.

– Ничек? – диде Хәйдәр хәзрәт, – кумәкләп эзләгәндә табылган нәрсәнең шатлыгы уртак булырга тиеш: шатландыр безне дә.

– «Вакыф малы» дигәннән хәтерләдем... Бу эшнең казанында кайнаган юрист буларак, серемне әйтәм: Зәкәрия, чыннан да, зур мөлкәткә ия Самуэль исеме астындагы татар булуы бик ихтимал...

– Ха! Анысына безнең шигебез юк. Яңа материк ачкандай кыланмыйк.

– Табылган материкның файдасын күрергә кирәк!

– Ничек? – дидем мин. – Әйтегез!

– Аягыңның гипсын алдыргансың. Бераз аксасаң да, үзеңне-үзең йөртә аласың.

– Шуннан? Йөресә ни?

– Барсын, гафу үтенсен, бүлмәдәш хаҗиларның һәркайсы ярдәм вәгъдә иттеләр, дисен, коллектив исеменнән, шартнамә төзесен!.. Вәссәлам!

– Шушымы бер сикерү белән чокырдан чыгу ысулы?

– Начармыни?

– Дөресен әйткәндә, бу безнең һәммәбезне чокырга этеп төшерү, – диде Хәйдәр хәзрәт, очкылык тотуыннан котылып, – мин аңа бернинди киносыз,

кинәсез атасының каберен табып бирә алыр идем. Хикмәт башкада. Ни тели ул? Чынлап та, атасы белән янәшә күмелүдән мәзхәбкә юл эзләүче агентмы ул? Бу – без белгән уен уенчысы түгел.

– Ә нинди уеннар уйнала соң хәзер бездә? – дидем мин.

– Зиратлар мәсьәләсендәге мәхшәр – уен түгелмени?! Олы уен. Отучысы алдан билгеле. Керсәң – чыгарлык, чыксаң – керерлек түгел. Җитмеш-сиксән ел элек җирләнгәннәрнекен түгел, җиде-сигез ел элек күмелгәннәрнең урынын табу да катлаулы мәсьәлә. Мәет өстендә мәет, таш өстендә таш.

– Бик авырга китсә, сиңа килербез, хәзрәт. Хаҗда бергә булу истәлегенә урын табышырсың, шәт...

– Анысы четерекле булмас. Менә хәзер син тудырган ситуациядән чыгу өчен нишләргә безгә? Шул проблема.

– Бүренең дә тук, сарыкның да исән калу юлын табарга кирәк, – диде Мәхмүт абый.

– Каян эзләп?

– Аның юлы бер генә: үзебезгә сарык булмаска.

– Рәхмәт, – дидем мин. Ниһаять, үз юлымны таптым шикелле.

Беркем бер сүз әйтми, барысы да миңа карадылар. Ә мин үзем белән аласы нәрсәләремнең һәммәсен алып, такси тотарга дип палаткадан чыгып киттем.

...Бүлмәдәшләрем «сарыкны исән калдырып, бүрене ничек туйдыру» юлын эзләп калды. Ә мин үзебезнең консульствога элдерттем. Таксист, беләзектәге язудан «король кунагы» булуны аңлап, консуллык урнашкан зәвыклы йорт каршына тиз китерде. Будкада утырган сакчыга тиз-тиз аңлатып, телефон аша хәбәр җибәрелгәч, таксист миңа кулын сузды. Мәгълүм илле долларымны биреп, сдача көткән арада консул килеп җитте. Сакал-мыегы мөселманча, башында түбәтәй булгач: «Әссәламегаләйкем», – дисәм, җавабы: «Здравствуйте!» – булды. Гаҗәпләндергән бу сөйләшүнең тәрҗемәсе:

– Тыңлыйм сезне.

– Эчкә кермибезмени?

– Язылган идегезме?

– Мин хаҗи.

– Күрәм. Сезгә кем кирәк, нигә кирәк?

– Мин бик четерекле хәлдә калдым. Консул белән киңәшләшергә иде.

– Бүген консул булмаячак. Илчелеккә киттеләр. Гариза язып калдыра аласыз. Өч-дүрт көндә, каралып, хәл ителәчәк.

– Ашыгыч эш буенча булганда күпме көтәсе?

– Визагызны озайту буенчамы?

– Кыскартмасалар – булганы җитә.

– Алайса – хушыгыз.

– Йомышымны әйтмәдем ич әле...

– Аны мин хәл итмим. Язып калдырыгыз. Паспортыгыз үзегез беләндер бит?

– Түгел иде шул.

– Гаҗәп...

– Тиешсез урында төшерүдә гаепләп, видеокамерамны арестовать иткәннәр иде. Шуны саклау камерасыннан алу өчен, паспортымны Австралиядән килгән хаҗига биргән идем. Ул инглизчә сөйләшә белә.

– Зәкәрия абзыйгамы?

– Сез дә аны беләсезмени?

– Аны белмәгән татар юктыр.

– Бик сәер кеше. Миңа алты миллион доллар тәкъдим итте. Тиктомалдан.

– Беләбез...

– Бу нәрсә? Мине сынаумы? Шантажмы?

– Сез ялгышасыз.

– Әгәр бу тәкъдим астында хәйлә – мәкер ятса?

– Сөйләмәгез юкны. Хөрмәткә лаек шәхес ул. Туган җир туфрагы тарта картны. Сезнең турыда ул безнең каналлар аша белеште. Булдыра алсагыз, ярдәм итегез. Сезгә биргән бүләкләрен таможнядан үткәрсеннәр өчен, тиешле документлар эшләтеп алды. Шикләнмәгез. Үзе шикле кеше генә башкалардан шик эзли.

* * *

Мин бу очрашудан үзем өчен үземне ачтым: шикле кеше икәнмен бит!..

Күземне күрсәтмәскә кара күзлек киеп, Мәккә каласын бераз тамаша кылып йөргәч, тагы такси яллап, Минага кайттым.

Ахшам узган, ясигъ җитмәгән иде әле. Беркемнән дә шикләнмичә генә кереп яту ниятендә палата янына килсәм, эчтә Зәкәрия абзыйны «кысалар»:

...Мәдинәгә күчәр көн якынлашкач, король исеменнән биреләчәк бүләк турында фаразлар төрләнгәннән төрләнеп, ахыр чиктә, ирләргә – видеокамера, хатыннарга ноутбук бирелә икән, дигәнгә ышаналар. Шуның дөресме-түгелме булуын Зәкәрия абзыйдан ишетәселәре килә.

– Мине бу мәсьәлә кызыксындырмый. Кирәк дисәгез, мин һәркайсыгызга шуларны үзем бүләк итәргә әзер, тик сез миңа да, якташ режиссёрга да теләктәш булып, ярдәм итегез.

– Шул сумманы корбан итәргә ниятләгәнсез икән, без сезгә бу эшләрнең чын осталарын тәкъдим итә алабыз. Израильдән, Төркиядән яисә Мәскәүнекеләрне!

– ...Нинди осталарны? Зират эшләре буенчамы? Кабер казыргамы?

– Зират эшләре вак мәсьәлә. Анысын ничек кирәк, шулай эшләтергә була. Сүзем кино – фильм турында.

– Мин үзем эзләгән профессионалны таптым. Кирәк сумманы күчертү өчен реквизитлары алынды. Ниятем – ният, карарым үзгәрешсез.

...Кызыксынуым җиңде, палаткага кердем...

Бүлмәдәшләрнең йөзендә төнге кояш балкыды.

– Вон, үзе кайтты, – диде Мәскәү асты хаҗие, Зәкәрия абзыйга карап.

Ә Мәхмүт абый мине тиргәргә кереште:

– Иртәгә Мәдинәгә алып китәләр. Кешегә йомыш кушасың да югаласың... Әнә – видеокамераңны китергән! Әйберләреңне җыештырырга кирәк. Һәй, бу иҗат әһелләрен әйтер идем...

– Минем һәрнәрсәм җыйналган.

– «Зәмзәм» суы тутырган шешәләрне ничәне аласың? Рөхсәт ителгәне ун литр, ди.

– Нигә аны моннан алырга? Аэропортта шул ук су. Анда да бушлай.

– Ә компановка мәсьәләсе? Әгәр биргән бүләкләренең күләме артып китсә, аэропортта чемодан актарып утырырга җай булырмы? «Зәмзәм»гә урын калырмы?

– Калмаса? – дип сүзгә катышты таможнячы Рәшит. – Су – кайда да $H_2O$ түгелмени? Бросьте, зинһар... Режиссёр әфәнде хаклы: исем өчен аэродромда бер шешә алдың – шул җитә. Кайткач, кызыксынган кешегә шуннан бушаган шешәгә Әлдермеш суын салдың – эчерден.

– Иҗат кешесен гөнаһлы гамәл кылырга котыртасың, Рәшит әфәнде. Әлдермеш суын «Зәмзәм» дип сыйлауның гөнаһы үзеңә булуны онытма.

– Ярый, сезнеңчә булсын, биш литрлы бутыльны аның өчен дип үзем алып кайтырмын. Киносын төшергәндә массовкага чакыру шарты белән...

– Җитди эшне уенга борасыз. Массовка үз урынында, без үз урыныбызда кирәк. Исән-имин илгә кайтып җитәргә язсын, – дип, Мәхмүт абый «Зәмзәм» темасына нокта куймакчы булган иде дә, барып чыкмады. Су тутырылган шешәләрне мөмкин кадәр күбрәк сыйдыру буенча ярыш башланды.

Барыбыз да социализм тәрбиясе күргән: һәр эш – ярыш белән, алга барышыбыз – карыш белән...

...Полиэтилен шешәләре тыгызлауга чыдамыйча, бөкеләре ычкынудан ярыш алдынгылары чыланып беттеләр, әмма җиңгәнче тырыштылар.

...Намаздан соң Зәкәрия абзый Роммельгә кагылышлы документларның һәркайсын аңлатма белән миңа тапшырды да берсен кул куярга дип сузды.

– Гаеп итмә, төрле хәлләргә юлыгуың ихтимал. Монда нинди документлар барлыгы гына күрсәтелгән, сине бернәрсәгә дә мәҗбүр итми. Гомумән дә, син һәрнәрсәдә ирекле иҗатчы.

...Мәдинәгә илтүче автобуска төялгән хаҗиларның йөзләре генә түгел,үзләре дә күренмәслек итеп өелгән төргәкләр аша атлап узарлык җае калмаган. Зәкәрия абзый, озатырга аэропортка гына киләчәген әйтеп, офисына китте.

– Әзерләткән бүләкләрем дә анда калган, – диде.

Аның бу хәбәре дә табышмак булып яңгырады.

Ике тәүлектән артык Мәдинәдә фарыз гамәлләрнең барысын үтәп, кибетләрендә нәфесләрне тынычландыргач, аэропортка китү вакытын әйттеләр. Кабат мәхшәр башланды: тегесе алынмаган, монысы табылмаган. Безнекеләрнең багажлары башка мәмләкәтләрдән килгән хаҗиларныкы белән чагыштырганда, күпкә зуррак күренүе аларның саруларын кайната иде, ахры, безгә күрсәтеп «казанские сироты» дип узалар.

Арбалы чемодан тартып барган бабай, үзенә ияргән ирле-хатынлы парга мине күрсәтеп, нидер әйтә дә көлә. Тегеләр миңа карый. Чадра бөркәнгән хатын нидер сорамакчы иде, ире соратмады. Лифтка керделәр. Мин дә кердем.

– Нигә көләсең? – дидем, актык тешен суырткан егерме җиде яшьлек «картны» танып.

– Шиннән түгел, – диде тешсез...

– Кешедән көлү – гөнаһ бит...

– Ул бит кыйбланың кайшы якта булуын белми намазга утырды.

– Ә син беләсеңме соң?

– Белмәшәм әйтмәш идем.

– Минем дә беләсем килә.

– Пәйгамбәребез кабере ягында.

– Гыйлем иясе өчен ярлыканмас гөнаһлы булгансың: «Кәгъбәтулла ягында!» – дияргә иде.

Шушы сүзне генә көткәндәй, чадралы ачык тавыш белән көлеп куйды: аны култыклаган чалмалы хаҗи, лифтны туктатып, чыкмак булды. Кнопкага ничек кенә басса да, лифт туктамады. Үз этажыма җитеп, чыгышлый таныдым: бу теге Батулла бүрекле хаҗи, хаҗия – аның ханымы иде.

...Ниһаять, без аэропортта. Корольнең безгә бүләк өләшеп, озатып калырга килүен көтәбез. ...Кемдер аның илендә юклыгын, мондый чараларга ярдәмчеләренең хезмәтчеләре генә киләчәген әйткән иде, бу белдеклене «ник дәштем?» хәленә төшереп, күздән югалырга мәҗбүр иттеләр.

Кемнәрдер аны халыкара этикет кагыйдәләрен аңламауда гаепләде.

Кемдер берсе «провокатор», диде. Шуңа кушылып тынычландылар кебек. Бүлмәдәшләрем исә, Зәкәрия абзыйның «шөребен – шөрепчә, кадагын – кадакча» сүтеп тикшергәч, шул әгъзалардан үзләренә кирәкле юмарт кеше «модулен» җыю белән мәшгульләр иде. Дөресен генә әйткәндә, король бүләге белән Зәкәрия абзый бүләген чагыштыра алмаудан гаҗиз иде алар. Чөнки кемнән нинди бүләк буласы билгесез.

Шулчак кемдер: «Киләләр!» – диде. Кул сәгатенең «келтләве» трактор моторы эшләүне хәтерләтә: келт-келт...

«Ялт» итеп «Мерседес» килеп туктый. Корольне көтәбез бит. Машина ишеге ачылып, Зәкәрия абзый пәйда була.

– Бәхетем булгач, өлгердем бит... – диде ул, һәммәбез белән кул биреп күрешә-күрешә. Минем яныма килеп туктагач, дипломатыннан пластмасса тартма чыгарды.

– Монда мин яшәгән утрау туфрагы. Үземнең көлемне кайтарып җирләгәнче, урын биләп көтсен. Якташларың алдында кабул итеп ал.

...Нindидер сүз әйтүне артык санап, тын гына алдым. Көтәм. Барыбыз өчен сүзне Мәхмүт абый әйтте:

– Ышан, Зәкәрия абзый, ислам дине йолалары кушканча булмаса да, туфрагыңны җирләрбез. Безнең бурыч – атаң-анаң каберен табу. Анысын башкару авыр булмастыр.

...Зәкәрия абзый нindидер бер дога укыды. Барыбыз да аңа кушылып бит сыйпагач:

– Инде, хөрмәтле хаҗилар, әманәтемне барыгызга да ишеттерәсем килә, – диде ул якынрак килергә чакырып, – минем атам Әхмәтситдыйк Хәбибрахман улы Шәрифҗановның 1896 елда туганлыгы билгеле. Кайчан, кайда, ничек үлүе дә, кайда һәм ничек дәфен ителүе дә гаип...

...Аның кабере табылгач, зиратында җеназа намазы укып, һәркайсыгыз берәр уч туфрак алып сипсә, минем җаным тынычланыр иде.

Анамныкын җиңелрәк табарсыз, дип өметләнеп, фирмабыз исеменнән һәркайсыгызга медальон тапшырырга рөхсәт итегез. Кашлы балдак ясатырга размерларыгызны белү кирәк иде. Медальон эчендәге дога сезне һәр ихтимал бәла-казадан сакласын.

– Алла сакласа, – диде Хәйдәр хәзрәт, ниһаять, сүз кыстырырга ашыгып, медальонга шатланмаганын сиздерергә теләгән кыяфәттә, – һәрнәрсә Алла хөкемендә.

Битләр сыйпалгач, визит карточкалары тарату, кунакка чакыру йоласы үтәлде.

– Исәнлектә очрашырга язсын, бердәм булыйк, бергә булыйк! – дип китте «хызыр галәйһеәссәлам».

...Зәкәрия абзыйны озату ыгы-зыгысында абайламыйчарак калганбыз – килеп туктаган фургонлы машиналар катына ялтыравык погонлы өч офицер өч урында үзләренә таба чакыра.

Алар әйтеп өлгергәнче халык агымы, дәррәү кузгалып, чиратка баса. Шул арада бүләк салынган катыргы тартмалар таратылып, багажларны үлчәү башлана. Кеше күңеле шундый бит ул: бүләкне һәркем чиратсыз, күршесеннән алдарак алып үлчәтәсе килә. Ләкин тормыш теләк белән түгел, чират белән алга бара. Рәсәйлеләр булган җирдә чиратсыз берни дә юк. Бүләкне алган хаҗига аны карау мөмкинлеге дә юк – ашыктыралар, кеше кабаланырга мәҗбүр.

...Нindидер кысан аранда этенә-төртенә чират җитүне көтәбез.

...Аэропорт «иләгеннән» уза алмый ун кило урынына йөз кило «зәмзәм» алганнарның «бер ноль өстәгәннән ни була» дип шаяртуларына карамастан, канистралар бушаттырыла. Шул моментлардагы хаҗиларның турсайган йөзләрен сурәтләргә Суриков – Репин осталыгы кирәктер.

...Яһүд кешесе, күршесенә каза килсә, кайгыруын, татарның шатлануын ничек аңларга да, ничек аңлатырга? Күңел тарлыгымы бу?

Алай дисәң, Ватан сугышында иптәшен үлемнән саклап, амбразурага капланган татарларның процент-саны күпчелек тәшкил итүне ничек аңлатырга?

...Бу шул: «татар барда – хәтәр бар» әйтеме дә, «хәтәр барда – татар бар» дигәне дә хак-дөрес.

Тормыш, яшәү шартлары, биш гасырдан артык коллыкта яшәү шулай үзгәрткән татарны.

Күршесенә шатлык килсә, кушылып шатланмавы да, ике татар очрашканда өченчесенең гайбәтен сатуны да шуның белән генә аңлатып буладыр.

– Рәхмәт корольгә! Бер бүләген биреп, икесен ташлатты, – диде Мәскәү асты хаҗие – доктор.

– Безнең королебез Зәкәрия абзый булуны исебездән чыгармыйк, – диде Хәйдәр хәзрәт, миңа карап.

– Корольлеген кемгә тапшырачагын да онытмыйк... Инде тапшырмаган булса, – диде Мәхмүт абый, шулай ук миңа карап.

...Һәр хаҗи төргәк-тартмаларын тотып үлчәгечкә баса. Үлчәүче негр, хаҗиларның багажындагы икедән арткан шешәләрне ташлатып, кулларына авырлык цифрлары язылган «кәпитәнсәнең» бер нөсхәсен тоттыра да трапка күрсәтә.

– Хуш, Гарәбстан!

...Самолётка килеп керүгә күзгә ташланган монитордагы: «Перегрузка. Бер урыннан икенче урынга күченмәскә, селкенмәскә, сөйләшмәскә, радиохәбәрләргә игътибарлы булырга», – дигән кисәтү һәркемне телсез итте, йөзеп чыга алмас уйлар диңгезенә чумдырды, белгән догаларын кабатлаттырды.

Күпчелек хаҗи егерме кило урынына, кимендә биш килога артыграк багаж белән утырганлыктан, һәркем гаепне күршесеннән эзли; үзенең касыгына бәйләнгән «грелкага» тутырылган «зәм-зәм»не металл эзләү капкасын узганда, электрон күзләр күрмәсә дә, Аллаһы Тәгаләнең белеп, күреп торуын уйламый.

...Шул рәвешле, тәүлек булып тоелган җиде сәгать очып, телсезлектән һәм кече йомыш кыставыннан «җан тәслим» хәленә җиткәндә, аэропортка якынлашуны әйттеләр. Күзләр күрми, колак ишетми. Күршем – таможнячы Рәшит, кабыргама төртеп: «Уян, төшәбез, Мәскәү!» – диде. (Шуннан бирле, «Мәскәү» сүзе миңа «оҗмах» сүзе булып яңгырый.)

Аэродром асфальтына аяк басканда, сәгать төнге уникеләр узган булгандыр. Хәйдәр хәзрәт, багажларны көткәндә, исән-аман илебезгә кайтып төшүгә багышлап намаз укылырга тиешлекне әйткән иде дә, беравыздан, «тәһарәт бозылды» дигәч, тәкъдим кабатланмады, һәркем аулаграк урын сайлап, багажын кочаклаган килеш үзе генә калырга ашыкты. Вәгъдә ителгән бүләкне карап рәхәтлек дәкыйкасы кичерүдә иде өметләр. Авырлыгына һәм күләменә караганда, футлярда видеокамера түгел, ноутбук булырга тиеш кебек иде. Шулай дип фараз итеп футлярны ачсам, анда ноутбук та, планшет та түгел, ә бәрхет тышлы фолиант иде! (Икенче бүлегендә йөз данә аудиокассета.) Фолиантны кат-кат әйләндерә-тулгандыра карый торгач, мин аның изге Коръәнебез икәнлеген аңладым!..

* * *

...Талгын гына җил исте. Борынга таныш җир исе, кар исе, яз исе керде. (Әллә инде бу очракта «Туган ил исе аңкыды» дип язу дөресрәкме?!) Шул мизгелдә мин, үзебезнең Рәсәй җиреннән дә ямьле, иркен, бай җир юклыгын, шул илдә яшәүнең бәхет булуын җаным-тәнем белән тоеп, «Илкәем» көенә җырладым... Күңелем шатлык белән тулудан, эреп бетмәгән кар өстенә чалкан ятып, миңа көнләшеп күзәткән айга карап, ике йөз сиксән кеше сыйдырышлы самолётта өч йөз кешенең исән-имин кайтып төшүенә шатланудан күз яшьләре белән еладым... Җырлыйм да елыйм, елыйм да җырлыйм. Бермәл тоям – җырлавым да, елавым да күңелемдә генә, тавыш-тынсыз гына икән... Бары тик күз яшьләрем генә чын икән...

...Шулай күпме вакыт ятканмындыр, исемемне ишетүгә башымны күтәрсәм – каршымда Мәхмүт абый басып тора.

– Кая югалдың син?

– Югалмадым, киресенчә, мин үземне-үзем таптым бүген...

– Эзләмәгән җир калмады... сәгатеңә кара...

– Сөйләшәсен сөйләштек, килешәсен килештек, адрес-телефоннарны алыштык, нәрсә онытылган, миннән кемгә ни кирәк тагы?

– Анда сине «Диннәр дөньясында» журналының корреспонденты көтә.

– Андый журнал бармыни?

– Бәлки башкачарак аталадыр. Миңа шулай ишетелде. Мөһим сораулары булганга охшый.

– Мөһим сорауларга сездән узып җавап бирә аламмы?

– Бездән сорыйсын сорады, әйтәсен әйттек.

– Җавап бирә алмасам, сезне хур итү булмасмы?

– Үзең әйтмешли, «җавап бирә алмау – үзе җавап».

...Мәхмүт абыйның «корреспондент» дигәне «Религии мира» журналының махсус хәбәрчесе булып чыкты. Гарәпчә дә, төрекчә дә сөйләшә белүче яһүдә икән.

Күрешеп танышуга, яктыруны көтеп утырган юлдашларымнан гафу үтенде дә мине аулак бүлмәгә чакырды. Шуның белән үк күңелемә шом салды. Чөнки мин – шаһитлар алдында, ачыктан-ачык сөйләшүне мәгъкуль күрүче журналист. Әйдә – хәерле булсын.

– Исән-имин туган ил туфрагына кайтып төшүегез белән котлыйм, – диде ул, сүз башлау өчен.

– Әйе, һәркайсыбыздагы Коръән-Кәрим исән-сау очуыбызга гарантия булып, Алла саклады.

– Шулай дип уйлыйсызмы?

– Ышанам.

– Үзегез хата тапкан Коръәнгәме?

– Сезгә ялгыш җиткергәннәр: мин хата табучы түгел, ә аның кайбер аятьләрен аңлатуны көткән надан бер мөселманмын.

– Кайсы аятьләрен?

– Хәзер инде барысын да аңладым. Гөнаһка керүемне ярлыкау көтеп гыйбадәт кылам.

– Нинди гөнаһларыгыз бар дип уйлыйсыз?

– Белеп кылганнары юк.

– Сезгә юллама биргән Диния нәзарәтенә хыянәт иттем дип уйламыйсызмы? Хыянәт итмәсәгез – тап төшерү...

– Юллама өчен анда эшләгән сабакташыма рәхмәтлемен.

– Ә менә безгә җибәргән хатында сабакташыгыз сезне «ашаган табынына төкерүче» дип атый.

– Димәк, ул ихластан Алла юлында йөрүче түгел, ә көтүгә иягән юлдаш – попутчик.

– Сезнең өчен мөфти абруймы?

– Аллага ышану – мәхәббәткә тиң хис бит ул. Бер шагыйрь бик дөрес яза: мәхәббәт ир-хатын арасында була, аларга арадашчы өченче зат кирәк түгел, ди. Аллага ышану-ышанмауда да өченче зат артык. Мөфти дә, мулла да өченче зат ул.

– Алайса, сезнең өчен абруйлы дин әһеле юк?

– Алар артыкка китте.

– Сезнеңчә, кемнәр үз урынында түгел? Ә кемнәр шул урынга лаек?

– Сәяси яктан сизгер, башка диннәргә түземле гыйлем иясе хөрмәткә каршы хөрмәткә лаек, ислам кануннарына хас киңәш белән эш итүче, иман ныклыгын илне ярату хисе белән бәйләп алып баручы, заман проблемаларына ачык караучы ихлас мөселман мөфти була алыр иде.

– Исемләп әйтә аласызмы?

– Андый егетләр бар һәм аларны Рәсәй мөфтиләр советы берләштерә.

– Үзәк Диния нәзарәте түгелмени?

– Сезнең миннән шулай дип әйттерергә теләвегез сизелә. Ә мин: абруй – хакимлектә түгел, шәхси камиллектә, хикмәтле булуда, белемдә, дияр идем.

– Нәзарәтләрнең диннәр арасындагы аерманы бетерү сәясәте алып баруын танный сызмы?

– «Сәясәт» дип мәчет манарасына Даут йолдызы куйдыруны яки «Русия мөселманнарының рухи атасы» дип патриарх кулын үбүне әйтсәгез – танымыйм.

– Җавапларыгыздан сезнең өчен абруйлы шәхес әлегә юклык исе аңкый. Ялгышаммы?

– Коръәнне таныган, аның аятьләренә ышанып, ислам дине әһелләренә хөрмәт белән караган һәр мөселман минем өчен иң абруйлы шәхес!

...Мин бу махсус хәбәрчене җиңдем дип тә, үземне аннан җиңелгән, сынаткан бәндә дип тә санамыйм. Ул үз эшен белеп, үзенчә башкарды. Мин дә үкенерлек җаваплар бирмәдем шикелле. Хәерлегә булсын! Һәркемнең яшисе килә. Ә минем алда, беләсез – таудай эшләр, бурычлар, васыять-әманәтләр...

...Казанга билетлар юк, диделәр. Шунда ук проводникка түләп кайту мөмкинлеген әйттеләр.

Тагын ютәлем буа башлады. Хәлем юклыктан якындагы поездны көтәргә дип эскәмиягә утырган идем, йокымсырап киткәнмен.

...Милиция уяткач, сәгатькә карасам, ул тәүлеккә ике тапкыр гына дөрес күрсәтүче булып чыкты. Сәгать йөрми дип поездлар йөрүдән туктамый – халык агымына кушылып, кырый платформага килсәм, Барнаул поездына төялү бара икән. Бәхетлеләр билетларын күрсәтәләр дә керәләр, ә миңа – Хаждан кайтучыга – игътибар итүче дә юк – этәләр дә төртәләр, төртәләр дә кереп күздән югалалар.

...Поезд кузгалганда, тамбурга басмакчы идем – проводник, вагон ишеген япмак булып, тотынгычтан кулымны ычкындырырга боерды. Шунда ук артымда «ычкындырма!» дигән әмер яңгырады. Бу, әлбәттә, хызыр галәйһиссәлам иде! Аның йөзен күрергә өлгермәдем, аркасына баян биштәре аскан мыеклы вагонга сикереп менде дә, күптән көткән танышын очраткандай, кондукторның кулын

эләктереп, көрешү йоласы үтәргә кереште. Голланд мичедәй олы гәүдәле ханым кулын ычкындырырга тарткалашканда, мосафирның икенчесе тамбурда кунаклауга, «ялт» итеп, мине дә тартып кертте дә, «шылт» итеп вагон ишеген бикләп тә куйды. Җәмгысына бер минут вакыт уздымы икән – бу эшләр, яшь солдатның «Калашников» автоматын сүтеп җыйганы кебек, бик тиз эшләнде.

Күнегүләр уздырган булулары һәр хәрәкәтләрендә күренә иде.

...Күп тапкырлар сыналган «сценарий планы» буенча, сатулашу башлансынга, кондукторның «теш күрсәтеп алуы» кирәк иде һәм ул аны көттермәде – «стоп-кран»га таба атлады. Мыеклының берсе, аның юлына каршы басып бүлдерсә, икенчесе «күчтәнәч»нең кайда бирелергә тиешлеген ачыклап, сәясәтчеләр телендә: «Такса үзгәрмәгәндер, шәт?» – диде. Профессиональлеген формалы китель кигән түтәебез бер җөмләдә аңлатты: «Ике урын Муромда бушый, өченчегезгә Сергачны узгач люкс хакы белән боковой», – диде. Ниһаять, җаныма җылы үтеп, миңа ярдәм иткән бу «хызыр»ларыма күзлегем киеп карасам, тамбур караңгылыгын балкыткан мыеклыларның берсе виртуоз музыкантыбыз Рөстәм Вәлиев, икенчесе мәшһүр язучыбыз, конферансье-сатирик Камил Кәримов җәнаплары иде. Депутатлык дәгъва итүче әрсез бер эшмәкәрнең сайлаучылар белән очрашу мәҗлесеннән кайтып килешләре икән. Бераз гонорар эшләп алганнар, карыннары ач булса да, кесәләре буш түгел, күңелләре түгәрәк иде. Хәзер инде (өчәү булгач!) безгә салкын тамбур ресторан да, люкс та иде...

...Билет юк дисәләр дә, яртылаш буш барган вагонда, билет тикшерүне көтеп, ат кебек аягүрә йоклап кайтабыз. Ревизор күренми. Әллә, өлешен алып, күренмәүне кулай күрдеме?

...Ярты юлны узуга, кондуктор белән исәп-хисапны өзеп, коридорга узарга рөхсәт алынды. Егетләргә рәхмәтлемен – минем өчен дә түләделәр. Корбан итәргә әзерләнгән зөбәрҗәт кашлы беләзекне алмадылар, «җиңгәчәйгә калсын, безне, Сабан туенда квас белән сыйлап, «бәхилләтерсең», дип сүзне уенга бордылар. «Хызырларым» кәефемне күтәрергә никадәр генә тырышсалар да, температурам гына күтәрелде: 38.7°. «Стресслардан» дисәләр дә, сәбәпләре күп булгандыр... Булганнарына өстәмәгә аэропортта көтеп торган хәбәрче яһүдәнең сораулары... Ни көтә мине өйдә?囓Эштә?

...Хәер, мин – гаделсезлекләр белән күзгә-күз очрашуларга күнеккән кеше, һәртөрле киртә, тышау, богауларга иммунитетым бар; көрәшергә дә, көтәргә дә, сынауларга да әзермен...

* * *

Әйе, шулай: «әзермен!» дип йөри идем. Әмма, кайткач, каршылыкларның мондыйлары очравына әзерлегем булмаганлыгы беленде.

...Безнең эштә, кая да булса барып кайткач, гадәттә, иң элек олы хуҗага түгел, аның ярдәмчесенә, ягъни «сам»га түгел, «зам»га күренәсең.

Без – хезмәткәрләр өчен, ул арадашчы гына түгел – киңәшче дә, иптәш тә, хуҗаны алыштыра алучы дәрәҗәле чиновник та. Аның мактанырлык бер генә нәрсәсе бар – баш түрәләрне еш алыштырганда да аңа тиюче юк. Ул һаман «зам». Ничәдер ел «сам» булып та эшләп алды. Чыгарып атмадылар – берничә «сам»га күз-колак булып утырсын өчен, аерым бина төзеп, сәркатип биреп «сам»нарга «сам» ясадылар. Бу вазифадан үзе туйдымы, бишенче тәгәрмәч булумы туйдырды – ул кабат «зам» булып утыруны кулай күрде. Бөкрегә күнгәндәй, зыяны тимәгәч, аның барына-югына игътибар булмагач, утыра. Биш

елдан биш елга «Иң яхшы журналист» дигән исеменә өстәп, җиңел машина бүләк ителүгә дә күнекте. Алу ихтималы булган дәрәҗәләрне алып бетергәч, сиксән биш яшенә яңа дәрәҗә уйлап чыгарылуны көтеп яши, имеш, диләр. Булса да булыр. Алырга күнеккәннең капчыгы зур була, диләр.

Кайтуымның җиденче көнендә, ютәлем йомшарып, температурам төшүгә, отпускитан калган көннәремдә эшкә чыгарга теләвемне әйтергә «зам»га керергә язылдым. Чиратым төшке аштан соңга булса да, ул мине сәгать унбергә үк чакыртып алды. «Әллә сагынганмы?» – дигән уй йөгереп узды баштан.

...Килдем. Кердем. Гадәттәгечә сәлам бирдем. Гадәтенчә, ул аны алмады, ә кулына тоткан хатка текәлеп, башын калкытмый гына:

– Эшкәме? Эшләргәме? – диде.

– Эшкә эшләр өчен чыгасың бит инде ул...

– Шулай булса икән... Һай, шулай булса...

– Башлап киткән эшләрем бар иде...

– Нинди эшләр? Әгәр сер булмаса...

– Алар күп инде ул... Саный китсәк...

– Санамыйк. Эш һәммәбезнеке дә бар. Эшләнеше генә юк...

– Үз адресыма андый гаепләү булганы юк иде шикелле!..

– Бу мәсьәләдә хуҗаның үзе белән сөйләшү кирәк булыр. Хат бик җитди, ышандырырлык фактлар белән нигезләп язылган.

– Нинди хат?

– Менә ул хат... Заказной. Мин сине шул мәсьәләдә аңлатма бирергә очрашу сорагандырсың дип уйлаган идем. Синең гафу үтенә белмәвең исемнән чыккан.

– Хат белән танышырга мөмкинме?

– Сиңа таныш эшләр буенча ул.

– Миңа таныш булмаган эш юк. Тагы нинди афёра икән? Күрәсе иде.

– Зинһар, агрессиясез генә аңлашыйк. Әйтергә тиешлесен хуҗа үзе әйтер. Кирәк тапса, хатны да укытыр. Миңа мәгълүм кадәресе шул: оешма исеменнән сатлыкҗаннар белән шартнамә төзеп, фашист офицеры токымнарын барлау идеологиясен пропагандалау юлына баскан журналист безгә юлдаш түгел.

– Бу нәрсә: «кит» дигән сүзме әллә?

– Ә нигә киткән кешегә «кит» диярргә?

– ?

...Бу сүзләрен әйткәндә, ул без белгән «вечный зам» түгел, ә «сам»нарга «сам» иде. Шомлануымны сиздермәскә тырышып:

– Үзенә хәзер керергәме? – дидем.

– Чакырса. Бу көннәрдә реорганизация эшләре белән мәшгуль. Вакыт тапса чакырыр.

– Чакырмаса?

– Мондый хәлдә мин сиңа киңәшче түгел. Ихтыярың...

...«Ихтыярың» дигән җаваптан соң тәмам ихтыярым сынды. «Автопилот» хәрәкәте белән операторлар бүлмәсенә төшеп, «разведка» ясарга булдым. Үзсүзле операторлар аз булса да, әңгәмә кызык булды. Алар аңлавынча, мин, җирне күчәреннән ычкындырмакчы булып, яшеренеп әзерләгән шартлаткычыма ток үткәргәнмен икән дә сигнал көтәм икән. Хатның шуны сизгән патриотлардан булуын «биш минутлык» киңәшмәдә хуҗа үзе әйткән. «Ышанмасак та, тикшерми ярамый», дигән. Берсенең соравына икенчесе өчне өстәп, сорау арты сораулар яуды:

– Сизгер патриотлар кем булуны үзең сизенәсеңме?

– Беләсем килмәсә?

– Андыйлар белдерерләр дә, бөлдерерләр дә.

– «А воз и ныне там», дигән шагыйрь.

– Шигырьне шига алыштырды. Заманы шул.

– «Җаныңның ваклыгын заманга сылтама!» диме замана шагыйре?

– Синең вакланмавыңны да хатка язганнар. Имеш, яңа мәзһәп оештыру максатында фильм төшерү өчен кулыңа бирелгән ничәдер миллионнан баш тарткансың... Доллардан!

– Бирелгән түгел тәкъдим ителгән!

– Димәк, дөрес?

– Белерсез әле. Сезнең белән эшлисе эш. Эшләрбез дә. Тешләрбез дә, тиешлесен алырбыз да. Насыйп булса.

Оператор егетләр белән, ачыктан-ачык сөйләшеп, фикер уртаклашкач, алар тәкъдиме белән Зәкәрия абзыйга «эш башланды» дигән телеграмма сугарга үзәк почтага киттем. Оныттылар дип хафаланмасын, тыныч булсын картлач. Телеграмманы алып тынычланырмы-юкмы, ә менә үземнең тынычлыгым югалды. Хатынга хәлне сөйләүдән файда юк. Аның җавабы мине гаепләүдән узмаячак.

Хатны үзем укымагач, эчтәлеген белмәгәч, «сам» белән очрашуга нинди җавап әзерләргә белмим. Бәлки әле шуның белән узар, чакырмас. Ә менә «зам»ның «юлдаш түгел» дигәне узгынчы сүз булмаса? Реорганизация дигәне нәрсә?

Киңәшләшергә таныш юристларым булса да, Мәхмүт абыйга барырга булдым.

Атказанган юрист тиз генә җавап бирмәде. Көттергән җавабы да тынычландырырлык түгел иде:

– Да, проблема, – диде ул, ухылдап-ахылдап сүземне тыңлагач. – Беләсеңме нәрсә, коллега, – дип, сүзен дәвам итмәкче булган иде, тукталып калды.

– Белмәгәнгә күрә өегезгә килдем, Мәхмүт абый, киңәш ит: нәрсә булыр икән?

– Мондый сорауга җавап бирү өчен, хуҗагызның сиңа конкрет тәкъдимен белү кирәк...

– Соң булса? Әгәр аның карары әзер булса? Мин пенсия яшенә чыккан... Нет человека – нет проблемы. Мәсьәләнең бик гади генә чишелеп куюы бар.

– Гади күренсә дә, ситуациядән төрлечә чыгу ихтималы бар.


– Кодекста ничек каралган?

– Ничек, ни өчен, кем өчен дигәндә, кодексның кирәклесен табу да хикмәт... Давай, син миңа рәсми приёмга языл. Именно мине сора, мин хәзер элеккеге штатта түгел. Үтенечең кабул ителсә, мин бер-ике көнгә эшкә чыгармын. Үзең беләсең – сайлаулар якынлаша. Эшем муеннан булса да, синең өчен чыгармын – сора. Именно мине!

– Чыкмагыз! Таныш юристларым бар.

– Бу ситуациядә теләсә кайсы юрист киңәш бирә алмый. Син по крупному эләккәнгә охшыйсың, хаҗи.

*Ахыры киләсе санда.*



Гәрәй
Рәхим

# ЯЗМЫШЛАР УЛ – БЕЗНЕҢ ЯЛГЫШЛАР

## Йолдыз атыла

«Синең кайгың – минем кайгы», – диде
Каләмдәшем шагыйрь Ркаил[1] ...
Көтелмәгән үлем-китемнәрдән,
Ачы фаҗигадән курка ил.

Компьютерлар, телевизор, урам
Әҗәл кебек йота безләрне.
Көтмәгәндә генә китереп тыга
Кабыргага тимер безләрне.

Ә күңелләр шундый нечкә безнең...
Тик замана тупас, бик юан.
Әй, күңелем, бүген Тукайларың,
Пушкиннарың белән син юан...

Сәгать саный диләр гомерләрне –
(Вакыт җиткәч ул да ватыла).
Сине эзләп, Ходам, замандашлар
Йолдыз булып күккә атыла...

...Язам... елыйм... өзгәләнәм... түзмим...
Каләм калтырана кулымда.
И Тәңрекәй, синең хозурыңа
Атылды бит минем улым да...

...«Синең кайгы – безнең кайгы», диде
Дус-туганнар һәм дә Ркаил...
...Көтмәгәндә генә күк йөзенә
Йолдыз атылудан курка ил.

[1] Улым Родионов Кубрат Григорьевич (13.08.1997 – 09.12.2015) фаҗигале рәвештә вафат булгач, «Мәдәни җомга» газетасында (2015 елның 26 декабрь саны) шагыйрь Ркаил Зәйдулланың кайгымны уртаклашкан шигыре басылды.

Гәрәй РӘХИМ (Родионов Григорий Васильевич – 1941) – *Татарстанның халык язучысы, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, «Татар поэзиясе антологиясе»нең ике томлык академик басмасын төзүче. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, татар телендә утыздан артык китап һәм дөньяның дистәләрчә телләрендә басылган әдәби әсәрләр авторы. Казанда яши.*

## Күрәчәк

*Улым Кубратка*

Матди авырлыклар күрмәдең син,
Рухи авырлыкны күп күрдең...
Япь-яшь көе мондый яшәешнең
Катлаулыгын татып өлгердең.

Алга таба кирәк тапмадың син
Ялган тулы Монда яшәүне...
Җирдә калды синең истәлегең
Япь-яшь көе... Ул гел яшь әле...

Ә без калдык... Сөйрәп барабыз без
Картлык дигән язмыш арбасын.
Без дөньяны аңлап бетермибез –
Шулай булгач, әй, сез, җирдәшләрем,
Дөнья безне ничек аңласын?..

Абыең[2] да калды... Ул тормышның
Бөтен катлаулыгын күрәчәк...
Нишләдек без?..
Ни булды соң безгә?..
Бу – күрәчәк булды...
Күрәчәк...

## Тургай җыры

*Сайрый тургай, сайрый тургай –*
*Баласын җуйган бугай.*
Татар халык җырыннан

Елый-елый шигырь язам,
Миңа кушыла тургай.
Тургай да минем шикелле
Баласын җуйган бугай.

Без – шагыйрьләр һәм тургайлар
Күккә менеп сайрыйбыз.
Җирнең бөтен манзарасын
Күк йөзеннән карыйбыз.

Талларга кунып сайрамый –
Күкләрдә сайрый тургай.
Син дә, улым, шул тургай күк
Күккә омтылдың бугай.

Тургай җырын тыңлый-тыңлый
Җылыйм да җылыйм шулай.
Сайрар тургай йөрәгемә
Оясын корды бугай.


Сайрый тургай, җылый тургай –
Баласын җуйган бугай.
Баласын җуйган тургай күк
Сайрап җылыйм мин шулай.

## Язмыш һәм ялгыш

Әйтте берәү: «Безнең гомеркәйләр
Бары язмышлардан тора», – дип.
Гомер үткәч белдем – әй, язмышлар
Безнең ялгышлардан тора бит...

---

[2] Кубратның абыйсы Даут.



Әмирҗан
Моталлапов

# ЙӨЗӘ ТОРГАН АРБА

БӘЯН

1

Галиәкбәр атын тугарды да, йөгән тезгенен үрәчәгә бәйләп, бахбаен арбадагы курпы печәнне ашарга кушты. Печән утлашырга утардагы ике баш сарыгын чыгару өчен кузгалмакчы иде, урам капканың дөбер-шатыр килү тавышын ишетеп, артына борылды. Карады да гаҗәпкә калды: якын– тирәнең танылган карагы, Ары киртә урамында гомер кичерүче Искәндәр абзыйсы, озак утырудан кагаеп череп, тактасы челтәрләнеп беткән урам капкасын, баганасы-ние белән төртеп аударып, ишегалдына керде. Бер мизгел өнсез торганнан соң, Галиәкбәр телгә килде:

– Кече капкадан ипләп кенә кереп булмый идемени, Искәндәр абзыкай? Олы капканы нигә җимерергә иде?

– Яңарта белмәдең, югыйсә. Бу очта урамны ямьсезләп торучы әрхәрәй капка синеке генә. Оят кирәк сиңа, егет башың белән шушы өтәш капкаларны көн саен ачып-ябып йөрергә. Бичә ярәшкәч тә шушы капкадан алып керерсеңме? – дип, Искәндәр, сукрана-сукрана, егет янына якынлашты.

– Яңартырга кирәген бик беләм дә, рәт-чират юк шул әле. Чамадан килсә, әллә кайчан урыс капка утыртып куйган булыр идем, – диде Галиәкбәр, фәкыйрьлегенә зарланасы килеп.

– Көтеп ятсаң, байлыкны кем китереп бирер дип уйлыйсың? Үзеннән-үзе ишелеп керә торган хәзинә түгел ул.

– Андый могҗизага өметләнгән юк-югын. Хәзер байлык җимерек капкадан өркеп бөтенләй якын йөрмәс, фәкыйрьлек кенә өерелеп тулыр инде, – диде егет, гәпне шаяртуга борасы килеп.

Искәндәр белән телләшү-тарткалашуның мәгънәсезлеген аңлый ул. Авылны гына түгел, якын-тирәне дер селкетеп торган ата бур һәм куәт иясе белән бәхәскә керүнең файдасызлыгы сабый бала өчен дә яңалык түгел.

– Атаң мәрхүмне җирләгәннән бирле бу ихатага каккан берәр казыгың бармы? Булса, күрсәт шуны миңа, – дип төпченә бирде абзыкасы, погонлы тикшерүчеләрдәй таләпчәнлек белән.

Галиәкбәр ык-мык килде, уңай җавап бирү өчен сүз тапмады. Каян тапсын! Атасы үлгәннән соң каккан ярты казыгы да юк аның. Түбән карап, иңсәләрен генә җыерып куйды егет.

---

Әмирҗан МОТАЛЛАПОВ (1934) — *прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Яшьлегем кайтавазы», «Бал сатучы Төлке», «Абыну», «Шобага» һ.б. китаплар авторы. Актанышта яши.*

– Как сөяккә калган алашаңнан кала, тагын нинди малың бар?

Белеп тора, юри сорый. Бу сөальне җавапсыз калдырмады хуҗа, булганын әйтте:

– Ике баш сарык...

– Тфү, – дип җиргә төкерде Искәндәр. – Оятыңнан җир ярыгына керерсең. Туган-тумача бит әле, югыйсә. Адәм көлкесе!.. Синең өчен мин оялам... Тирә-юнеңә күз сал: авылда синнән дә фәкыйрь хуҗалык күренәме? Бу хакта уйланыштырасыңмы?

– Белмим, белмим, – дип кабатлавын дәвам итте Галиәкбәр, кулын баш түбәсеннән һаман төшермичә.

– Туганкаем, синең менә мондый җырны ишеткәнең бармы?

– Кайсы ул?

– Әчтерханның чикләвеген, ватып булмый теш белән. Әзрәк-мәзрәк урлашмасаң, баеп булмый эш белән, – дигән җыру.

– Ник булмасын! Үзем дә җырлаштырам.

– Җырлавын җырлыйсың да, тик мәгънәсенә төшенмисең. Чын хакыйкатьне үз башыннан кичергәннәр чыгарган бу җыруны. Җыру гына түгел, рәтле яшәү өчен лазем алым турында искәртү дә ул.

«Үзең урлашып баегач, хикмәтнең нидә икәнлеген беләсең инде, – дип уйлады Галиәкбәр, күңеленнән абзыкасы белән бәхәскә керәсе килеп. Хәлбуки, Искәндәр сүзләрендә күпмедер хаклык барлыгын инкарь итмәде. Җае килгәндә аз-маз чәлдергәләү авыл өчен артык хилафлы гамәл саналмый. Рөхсәтсез агач кисеп, теләсә каян печән чабып алып кайтуны бурлыкка санаучы юк. Тик тотылма гына...

– Шулаен-шулай, – дип телдән килеште егет.

– Бу чаклысы аңлашылгач, эшкә кереш. Ике сөйләшергә яратмаганлыгымны үзең беләсең. Тузаныңны кагарга күп сорамам, – дип ничек ажгырып килеп кергән булса, шул ук җәһәтлек белән чыгып китте Искәндәр.

Ауган капка янына басып, Галиәкбәр абзыкасын озатып калды...

**2**

Көтүдән кайткан маллар керүдән ишегалдын саклап, караңгы төшкәнче вакыт үткәрде Галиәкбәр. Хәерчелектә көн күрсә дә, күңелгә якын, кадерле ихата бит. Маллардан таптатасы килмәде.

Икенче көнне иртүк килде Галиәкбәр Ары киртә урамына. Абзыйсының ихата тирәсендә дә, ишегалдында да җан-тын күренми. Капка баганасына кадакланган тимер боҗрага атын бәйләп, өйгә кермәкче иде, тышкы баскычта Искәндәрнең өен җыештырып торучы карчык күренде.

– Җиңгәчәй, абзыкай өйдәме? – дип сорады Галиәкбәр, карчык белән исәнләшкәч.

– Түгел шул, – дип җавaплады карчык.

– Ерак киттеме?

– Әйе. Минзәләгә үк. Бүген таң тишеге белән кузгалдылар. Никрутлар итеп чакырганнар аларны.

– Кемнәр белән китте?

– Дүртәү бугай. Кашшафетдин Билалыннан башкасын белмәдем. Сорашмадым да.

– Искәндәр абзыкай миңа, такта алып китәрсең, дигән иде.

– Миңа сөйләнде ул аны. Алыр, диде. – Карчык өйгә керергә ашыкты. Кабалануының сәбәбен аңлатты – кабартырга сөт куйган икән, кайнап түгелүе бар.

Төгәл ун буй такта сөйрәтеп алып китте Галиәкбәр. Кайтып җиткәч кенә исенә төште: пычкы, өтерге сорарга оныткан икән бит. Кире барып, теләнергә кыенсынды егет, тимерче Шәмсегалигә кагылуны хуп күрде. Өтерге ясатып алырга ниятләде.

Шәмсегалинең үз ихатасындагы, ата-бабасыннан калган алачыкка кереп, йомышын җиткергәч, тимерче, кем әйтмешли, бот чабып көлде:

– Әллә Галиәкбәргә дә дөнья куу хәстәре кергәнме?

«Ата ялкау» кушаматы белән яман даны таралган Галиәкбәрнең эш коралы тергезү артыннан йөрүе Шәмсегалигә сәер тоелды шул.

– Мыскыл итмә әле, кордаш, бәлки, мин дә берәр хикмәт майтара алырмын, – диде Галиәкбәр, замандашының шаяртуына каршы.

– Күптән тәвәккәлләргә иде. Әлбәттә, булдырасың: теләк кирәк тә, ялкауланмаска гына.

– Ихатаң авып төшсә, тәвәккәлләргә туры килә икән шул.

– Җил җимермәгәндер бит?

– Юк ла! Искәндәр абзыкай тибеп аударды, – диде, дөресен әйтеп. Авыл хәлнең чынын барыбер беләчәк, яшереп торуда файда юк.

– Рәхмәт Искәндәр абзыйга. Күптән аударасы калган икән. Эш кайгысы салган бит әле ул синең башка, – диде Шәмсегали, кет-кет көлеп.

**3**

Минзәләгә ике тарантас белән бармакчылар иде егетләр, яңадан, ат мичәүләп бер арбада юл чыгуны мәслихәт санадылар. Такталачыктан таң беленер-беленмәстә кузгалганнар иде, Сөн елгасындагы Боҗырлы тегермәне буасын чыккач, яр читендә туктап, тамак ялгап алдылар. Эш сәгате башлануга Минзәләгә килеп кергәннәр иде алар.

Иртә булуга карамастан, хәрби комиссариат ишегалды авыл җыены төсен хәтерләтә иде. Атлар койма буена тезеп тугарылган, арбага бәйләп, печәнгә кушылганнар. Уртада, ачык калган урында, комиссиягә килгән некрутлар төркем-төркем булып түгәрәкләнгән. Кызып-кызып гәп саталар, кайберләре тәмәке көйрәтә. Ике кулын чалбар кесәсенә тыгып, киләп сарып, әрле-бирле йөрүчеләр дә бар. Күренеп тора: мондыйлары – шәһәрнеке. Киемнәре дә үзгә, кыланмышлары да башка. Кыяфәтләренә ясалма тәкәбберлек чыгарып, үзләренең өстенлекләрен күрсәтергә тырышулары бер караштан сизелеп тора.

Сабантуйга баргандагыдай бөтенлек белән җиккәннәр иде Такталачык егетләре атларны. Дугага җиз кыңгырау гына такмадылар. Дирбияләр тоташ каештан иде. Йөгәннәрнең һәр атламасына ялтыравыклы җиз тәңкәләр тезелгән. Кояш нуры астында алар кыйммәтле талир тәңкәләр шикелле, күз камаштырып ялтырый. Авылдан килгәннәр генә түгел, шәһәрнекеләр дә Такталачык егетләренең атларына басымлап күз салалар иде.

– Безнең атлар тынгылык бирми малайларга, күзләре белән йотардай кыланып текәләләр. Йоклап калмыйк, атларны чишендереп китмәсеннәр, җәяүләп кайтырга калыр, – дип кисәтте Искәндәр иптәшләрен.

– Күрәләтә талатмабыз инде. Өерелеп кенә килеп ябышмасалар. Ул чакта каршы тору икеле – эт оясында көчле бит, – диде Билал, үз карашын белдереп.

– Алар этләнсәләр, без бүредәй кыланырбыз. Сүкәлеп карасыннар, күрмәгәннәрен күрерләр. Үзләреннән яман кылансак, чабалана алмаслар, – дип, Искәндәр авылдашлары күңелендәге шикне киметергә теләде.

– Ышаныч синдә, – диде чепи Исхак. – Минем ише капка тәләкәсенең барын-югын белмәсләр, бөтереп кенә ыргытырлар.

– Курыкма, күрәләтә бирәүне дә кыйнатмабыз. Үзеннән яман кылансаң, теләсә нинди бандитны шөлләтергә мөмкин. Үзебезгә бердәм булырга, бирешүдә исәп юклыкны сиздерергә генә кирәк, – дип Искәндәр соңгы киңәшен җиткерде...

Комиссиягә егетләрне чиратлап керттеләр. Тикшерү барганда ишегалдында бернинди болганыш килеп чыкмады. Шик тудырып, атлар янында йөрүчеләр дә күзгә чалынмады. Такталачык егетләре арасыннан иң соңгы булып Искәндәр чыкты.

– Атларны җигә башлагыз, кузгалабыз, егетләр, – дип эндәште ул, ишектән тышка аяк басу белән.

Исхак белән Малик, җиргә коелган сандыкларны җыештырып арбага салдылар да, атларны тәртә арасына керттеләр. Аларның хәрәкәткә килүен генә көткәндәй, тетер кебек өч егет шулара арба янына килеп басты.

– Кая кайтасыз? – дип сорады тәбәнәк юаны.

– Безнең кайтасы җир ерак, – дип кул гына селтәде Билал.

– Ерак булса да исемле төбәктер бит? – диде шул ук егет.

– Исемле. Такталачык дигән авыл, – диде Билал, сорау бирүчеләргә күз дә ташламыйча.

– Башкорттан штули? – диде арадан иң озыны. Ни житте Искәндәрдән дә хәтсезгә калку иде ул.

– Сезгә каян булсак та барыбер түгелмени? Нигә ул чаклы төпченәсез? – дип сүзгә кушылды моңарчы тын торган Искәндәр.

– Төпченәбез икән, кирәк, димәк, – диде беренче сүз башлаганы.

– Җәһәт кыланыгыз, егетләр. Сүз боламыгы болгатып вакыт үткәрмик. Кайтасы ара озын, – дип ашыктырды егетләрне Искәндәр.

– Тигезлек түгел бу! Сезнең атлар гел каешка төренгән, ә безнең сбруйлар юкәдән генә... Хет йөгәннәрне алыштырыйк, – дип, озын егет мичәүдәге ат башына килеп ябышты. Искәндәр күз ачып-йомганчы аның каршында иде инде.

– Яхшылап әйтәм: кулыңны ал. Югыйсә, начар булачак, – дип буйчанның беләгеннән кысып тотты. Үзеннән бер башка кыска күренгән Искәндәрнең көч-куәтен чамалады егет. Кысуга чыдый алмыйча, бөгелеп төште. Бу хәлне күреп торган икесе, шыпан-шыпан гына, арба тирәсеннән читләштеләр. Искәндәр озынның беләген ычкындырды да иңсәсеннән күтәреп, аягына бастырды.

– Бар, ияр куркак куяннарыңа, – дип аркасыннан этеп җибәрде...

Атларга утырып урамга чыккач, әлеге вакыйганы искә төшереп, егетләр рәхәтләнеп бер көлделәр.

– Юарга кирәк бу вакыйганы. Кесәләрегезне капшаштырыгыз – кемдә күпме сәмән бар? Кибеткә үзем керермен, – диде Билал, уч төпләрен угалап.

– Әлбәттә, «юабыз». Шәһәргә килеп тамак төбе чылатмый кайтып китү гөнаһ булыр, – диде Исхак, Билал фикерен куәтләп.

Искәндәрнең тәкъдимнән читтә калырын берәү дә башына китермәде. Коткыны беренче булып ул кузгатыр дип көткәннәр иде әле, никтер башлап сүз катмады. Ниндидер уйларга уралып утыра иде егет.

– Әллә безнең ширкәткә керергә исәбең юк? – дип сорамый кала алмады Билал, аның битараф утыруына гаҗәпсенеп. Искәндәрнең аракы затын читкә ташламавын якын-тирә белә, югыйсә.

– Юк ла! Мәгез! – дип, кесәсеннән кәгазь акчалар чыгарып, чутлап тормастан, Билалга тоттырды. Энесе Галиәкбәрне искә төшереп, аның язмышы өчен борчылып утыруы иде Искәндәрнең.

– Тирән уйга чумгансың әле, – дип беренче булып кызыксынды сүзсез барган Исхак.

– Энекәшне искә төшердем...

– Галиәкбәргә ни булган? – дип беравыздан сорау бирделәр.

– Булмаган. Яңа капка ясап, утыртып кую өчен ике көн вакыт биргән идем, җитешә алды микән, дим.

Билал җәһәт кыланды. Кибеткә кереп, ике шешә алып чыкты.

– Кемгәдер кереп, кыстырып килгән ризыкларны ашап-эчкәндә, шәп булыр иде, – дигән тәкъдим җиткерде саран сүзле Малик.

Аның белән килештеләр. Шәһәр читендәге рәтлерәк күренгән өйгә кагылдылар. Атны капка баганасындагы боҗрага бәйләп, эчкә уздылар. Өйдә хатын-кыз шөгыле белән мәш килеп йөрүче ирдән башка җан иясе күренмәде.

– Чәйдән башка сыем юк, оланнар. Ялгыз кешенең хәлен чамалыйсыздыр... Ә үзегезнекен ашап-эчүегезгә ничек каршы килим инде? – диде хуҗа.

– Бер ялгызың яшисеңмени? – дип кызыксынды егетләр.

– Алай дияргә дә ярыйдыр... Көне-төне айнымый торган улым бар. Эчүе өстенә, тыйгысыз хулиган. Ул кайтып буза куптара башлаганчы кузгалсагыз тынычрак булыр, оланнар. Якалашырга күп сорамый, дуамаллыгы чамадан ашкан, – дип кисәтте хуҗа. Сизелеп тора: улының юньсезлеге тәкатен корыткан атаның. Таныш түгел кешеләр алдында шул тиклем ачылып китеп зарланыр идемени, югыйсә.

– Хафаланма, агай. Безгә зыян сала алмас. Без җәһәт кыланырбыз. Китәргә өлгермәсәк, бәлки, аның белән уртак тел табарбыз? – дип, атаның борчылуын киметергә теләде Искәндәр.

Егетләр сәкегә түгәрәкләнделәр. Түргә Искәндәр белән Билал утырды. Малик белән Исхак як-яктан урын алды. Билалның шешәне ачып, аракыны стаканнарга бүлүе булды, дөбер-шатыр килеп, артыннан ишекне дә япмыйча, үзе кебек бер сәрхушне ияртеп, хуҗа малае кайтып керде.

– Чакырылмаган нинди кунаклар болар? Хуҗаны да көтмичә сыйланып утыралар, – дип сөрән салды хуҗа малае.

– Сыйлана башларга өлгермәдек әле. Әйдә, утырыгыз, бергәләп авыз итәрбез, – диде Искәндәр, үзен тыныч тотып.

– Кемнең түр башында утыруыңны чамаламыйча, хуҗа булып кыланмакчымыни? – дип, Искәндәргә күрәләтә бәйләнәсе килә иде егетнең.

– Синекендә түгел, атаң түр башында утырам. Үз түр башыңны булдыру өчен сиңа башта селәгәеңне сөртергә өйрәнергә кирәк, – диде Искәндәр, тегенең кызуына куз өстәп.

– Әле минем белән телләшәсеңме? Анаңны сатам бит, – дип, йодрык төйнәп, егет Искәндәргә ташланмакчы иде, Такталачык батыры аннан өлгеррәк кыланды – кистәндәй йодрыгы белән тегенең ияк астына утыртты. Көчле орудан тынсыз булып каткан егет, эчтә генә туктап калмыйча, ишегалдына кадәр очып чыгып китте.

Өй эче тынып калды. Сәфәрче егетләргә озаклап утыру хасияте юк иде. Җәһәт арада ашап-эчтеләр дә китәргә кузгалдылар.

– Улым, рәхмәт, кулыңнан куан. Минзәләдә ул тукмамаган кеше калмагандыр, үзенә сабак бирүче юк иде әле, дип ата Искәндәрнең аркасыннан сөйде.

– Таяк ике башлы бит, агай. Иртәме-соңмы аның икенче башы барыбер үзеңә эләгә, – диде Искәндәр, батырларның да батыры барлыгын искәртеп.

– Әйбәт эләктерден. Акыл булыр, бәлки, – дип, рәхмәт сүзләрен кабатлап, юлчыларны озатып калды хуҗа...

**4**

Искәндәр дуамаллыгы, ат карагы, шул ук вакытта фәкыйрьләрнең яклаучысы буларак, якын-тирәгә танылды. Искәндәрнең каршылыклы гореф-гадәте хакында хәзергә кадәр төрле истәлекләр саклана. Аның тормышы белән бәйле, риваятькә

якын вакыйгаларны өлкән яшьтәге авылдашлары тәмләп сөйләргә ярата. Шунысы игътибарга лаек: атаклы бурны берәүнең дә этеп, гаепләп искә алганы юк.

Искәндәргә «ат карагы» кушаматы береккән берегүен. Әмма ул ат урлау белән генә чикләнмичә, сыер-сарык «чәлдерергә» дә күп сорамый. Шул ягы гыйбрәтле: ул авыл халкының, күрше-тирәнең мал-мөлкәтенә сүкәлми, табышны ерактан «юллый». Искәндәр фәкыйрьләргә ярдәм итүне төп бурыч санаган. Хөлҗүгә калган гаиләләргә ит, он биреп ярдәм күрсәткән. Урамда уйнап йөргән ач гаилә малайларын өенә алып кереп, тамакларын туйдыра торган булган. Ашаткан малайларга «тәрбия» бирү ягын да онытмаган.

Бу җәһәттән, халык хәтерендә калган кечкенә бер гыйбарәне искә төшерик...

Искәндәр беркөнне сәләмә киемле ике малайны өенә алып керә. Алар алдына табак белән ит һәм ипи куя.

– Рәхәтләнеп туеныгыз. Булдыра аласыз икән, ашап бетерегез, – дип, үзе чыгып китә.

Ике әйтергә яратмаган кырыс холыклы агаларының кемлеген белгән малайлар хәлләреннән килгәнчә тырышалар. Әмма табак төбенә кадәр төшә алмыйлар. «Бетергәнче ашагыз», – дип әйтте бит, калдырган өчен «өшкерүе» ихтимал, исән чакта ычкыныйк», – дип, малайлар шыпан-шыпан гына чыгып китәргә телиләр. Котылырсың Искәндәр кулыннан! Эләктереп ала тегеләрне.

– Нишләп ашап бетермәдегез? – ди малайларга.

– Нишлик соң, Искәндәр абзый? Йота алмый башладык бит.

– Чама белергә кирәк... Менә монысы корсак ярылганчы ашаганыгыз өчен, ә менә монысы рәхмәт әйтмичә табын артыннан кузгалганыгыз өчен, – дип, сыек чыбык белән «кунаклар»ның арт ягына икешәрне чыжлатып ала.

Үзенчә кирәк санаган тәрбия алымнарын еш кулланган Искәндәр карак. Холкын белгәнгә күрә, халык аның мондый гадәтен гаепкә алмаган. Киресенчә, хуплаган гына.

**5**

Кара көзгә кергәнче Агыйделнең теге ягыннан урап кайтырга теләде Искәндәр. Куш көймәне берләштереп көйләнгән паромның бер көймәсе тишелгән икән. Искәндәр кичүгә килгәндә, паромчылар тишекләрне ямау белән мәшгульләр иде. Бераз көтеп торганнан соң, түземлеге бетеп, сорарга мәҗбүр булды Искәндәр:

– Эшегез озакка сузылырмы?

– Төгәлен генә ничек әйтик инде? Бер тотынгач, башка житешсезлекләрен дә төзәтергә туры килер. Өйлә соңсыз кузгала алмабыз, мөгаен, – дигән җавапны ишетте ул.

Юл кешесенә кабалану хас. Биредә кагаеп көтеп торуны урынсызга санап, Искәндәр янәшәдәге Бурсык авылы астындагы кичүгә юл тотты. Ул килеп җиткәндә, кичүдә атлылар гел юк иде. Агыйделнең теге ярына шомырт җыярга чыгучы бер төркем хатын-кыз, берничә ирдән башка җан иясе паром кузгалуын көтеп тора иде. Ике тәгәрмәчле җиңел арбага җигелгән күк айгырын эчкә кертеп бәйләүгә, паром кузгалды. Башка юлчылар килүен көтеп тормадылар, чөнки каршы якта паром көтеп торучылар шактыйга җыйналган иде.

Агыйдел ярына чыгу белән, Кабан авылына юнәлде Искәндәр. Бу саланы биш бармагы шикелле белә егет. Такталачыкның күп кенә гаиләсе, Мерәс авылының хәтсез кешесе, җир җитмәгәнлектән, шушында күченеп утырган. Башта килмешәк саналып йөртелсәләр дә, күпләре тора-бара тернәкләнеп, төбәкнең күренекле байларына әйләнгән. Шундыйларның берсе – Әхмәтҗан, Искәндәргә чыбык очы карендәш. Аңа кагылу исәбе белән килде Искәндәр Кабанга.

Әхмәтҗанның нәселле биясе бар. Юыртуда тирә-якта аннан өстен чыгучы ат юк. Шушы бахбайның нәселен тергезергә хыяллана Искәндәр. Биянең колынын үстереп, җигеп йөрергә ниятли карак. Әүвәл юртакның үзен сатып бирүен теләгән иде егет. Әмма Әхмәтҗан бу тәкъдимне кабул итмәде. Биясеннән аерыласы килмәде аның.

– Сатып бирмәсәң, урлап алып китәм, – дип шөлләтмәкче булып та караган иде Искәндәр, әмма бай куркаклардан түгел иде.

– Бәйрәм ашы – кара-каршы, Искәндәр туган. Әгәр бияне урлыйсың икән, ат түгел, кәҗә тәкәсе ябып асрарлык ихатаң калмаячак. Минем егетләр синең мөлкәтең өстенә «кызыл этәч» җибәрәчәк, – дип үзеннән саллырак итеп әйтте Әхмәтҗан.

Шушы сөйләшүдән соң аларның сүзгә килешкәннәре юк. Хәтәр дустанә кыланып, аралашып йөргән булалар.

Искәндәр атын бәйләп капкадан кергәндә, Әхмәтҗан ишегалдында йөри иде.

– Юньсез булсаң да, бәхетең бар синең. Гомерең дә озын булыр шикелле. Синең хакта уйланып кына тора идем, – дип каршылады аны Әхмәтҗан. Алар ике куллап күрештеләр.

– Миңа тәтергә тиешле бәхет нидән гыйбарәт инде, ягъни мәсәлән? – дип кызыксынды Искәндәр.

– Әле генә бия колынлады. Исән-имин туса, монысын сиңа бирермен, дип нәзер әйткән идем. Иншалла, көткәннән әйбәт килеп чыкты: бия дә җиңел котылды, колын да сау-сәламәт, – диде Әхмәтҗан, елмая төшеп.

– Һай рәхмәт, кордаш, шатландырдың бит әле син мине. Аягым тартып, күңелем нидер сизенеп килгән идем. Шатлыклы хәбәр ишетергә булган икән, – диде Искәндәр, канәгатьлек белән кулларын уып.

– Колынны кыш буе ашатып яткырмам, Агыйдел бозы туңу белән алып китү чарасын күрерсең. Үзең теләгәнчә карап, өйрәтеп үстерерсең, – дип, кулдан китәсе малга печән әрәм итәсе килми, дигән мәгънә аңлатып, хәйләкәр елмаеп куйды бай. Искәндәр аның тел төбен чамалады:

– Илла саран да инде үзең!.. Бөртек саламыңны да чутка кертәсең... Хәер, саранланмаса, кеше шушы тиклем байыймыни? – диде ул, ихатаны колачларга теләгәндәй, кулларын җәеп. Чыннан да, Әхмәтҗанның бөтен ихата-курасы, шыңгырдап торган нарат бүрәнәдән салынган кара-каршы йорт кемнең кемлеге турында ачык сөйли иде.

– Дөрес сукалыйсың, туган. Берәүләр – саранлашып, икенчеләр урлашып байый...

– Йә, йә, төрттермә. Шырпыңа да кул салганым юк, – диде Искәндәр, хәтәр төз кешедәй, хәтере калып.

– Кәкре эчәкләнеп, үзеңә кабул итмә, синнән генә чыгып әйтмим, – диде хуҗа, аклана төшеп. – Йә ярар, телгә бетмик, өйгә кереп чәйләп алыйк...

Табын янында озак юанмадылар. Такталачык паромының йөрү– йөрмәвенә ышаныч тәгаен түгеллекне сылтау итеп, Искәндәр иртәрәк кузгалу ягын карады. Көзге көннең озынлыгы да чамалы бит...

– Такталачык базарына чыгу исәбендә торам, җае килсә, сиңа кагылырмын, – диде Әхмәтҗан, кунакны озатканда.

– Һичшиксез кагыл, көтәм, – дип, Искәндәр, ике тәгәрмәчле арбага җигелгән айгырын Агыйдел ягына каерды.

...Халык телендә шундый гыйбарә йөри: бур кеше ихатасына буш кул белән кайтып керүне түбәнчелеккә саный, имеш. Чәлдерергә җай килмәгән чакта, башындагы бүреген култык астына кыстырып капкадан керә икән, дип әйтәләр. Бу фикер хакыйкатьтән ерак түгелдер. Искәндәрнең дә как арба төбенә утырып капкасыннан кергән чагы сирәк.

Авыл көтүе йөри торган әрәмәлек аланына кагылу исәбендә Искәндәр. Көндезләрен көтүчеләр малларны шунда туплаучан. Сарык көтүе бүген дә шунда йөри иде. Атын куе куак артына яшереп, әсир алырга җибәрелгән гаскәри шикелле, шыпан-шыпан гына мал йөри торган җиргә якынлашты. Ау коралын әзерләп, күңелгә ятыш кайсыдыр бер сарыкның үз тирәсенә килүен көтә башлады.

Озак көтәргә туры килмәде, хәтәр калку гәүдәле көр бәрән ике аяклы «бүре» каршына килеп чыкты. Балык җәтмәсеннән көйләнгән тозагын тегенең өстенә ыргытты Искәндәр. Нәрсәгә таруын абайламаган бәрән секундлар эчендә тоткынга әйләнде. Берничә кат бәэлдәп алырга гына өлгерде. Төреп арбага салгач та ни булганын чамалый алмый иде әле мәхлук.

Өлгерлек яраткан Искәндәр шундук Агыйделгә карап томырылды. Ә ат менгән ике көтүче, сарыкларның өркеп, шомыраеп калуыннан шикләнеп, бәрән тавышы ишетелгән тарафка килделәр. Сарыкны бүре эләктерде, дигән исәптә иде алар. Тик, арба эзләренә тап булгач кына, бүренең ике аяклы икәнлегенә төшенделәр.

Әрәмәлекне чыгуга, Агыйделгә таба чабучы җигүле атны күргәч, артыннан куа киттеләр.

Угрының алда барыр юлы юклыгын чамалап, көтүчеләр атларын кабыктырырлык дәрәҗәдә кумадылар. Комлык башлангач, бахбайларга чабуы авыр иде. Арба сөйрәгән алдагы ат ничек бара торгандыр әле?

Искәндәр куа килүчеләрнең ниятен чамалады. Агыйдел ярының сөзәк урыныннан төшеп, атны корсагына хәтле суга кертkәч, туктап тын алдырды. Бу хәлне күреп торган көтүчеләрнең берсе:

– Капты карак. Суга батырып ишәбез, – диде.

– Нигә ишеп кенә калырга! Бәреп үтерәбез дә Агыйделгә агызабыз, – диде икенчесе.

Куучылар суга килеп терәлгәндә, Искәндәр айгырын эчкә әйдәкләде. Күндәм бахбай, һич карышмыйча, йөзеп, Агыйделгә кереп китте. Өнсез калган көтүчеләр авыз ачып әйтергә сүз тапмыйча аптырап тордылар.

– Әҗәле судан икән. Әйдә, батып үлүен үз күзләребез белән күреп калыйк, – дип, нидер килеп чыгарын көтеп калдылар.

Искәндәрнең батып үләргә исәбе юк иде – җигүле ат белән Агыйделне кичүе беренче тапкыр гына түгел. Бу юлы да толпарының сынатмавына ышанды һәм алданмады: айгыр хуҗасын ярга исән-имин алып чыкты.

– Йөзә торган арба да була микәнни? – дип аптыраешта калды көтүчеләр.

– Ат карагы Искәндәр булды бу. Мондый хикмәт кылырга ул гына маһир, – дип кул селтәп, яр буеннан китүдән башка чара калмады көтүчеләргә.

Чыннан да, хикмәте бар иде арбаның. Суда батмаслык итеп, махсус эшләтте аны Искәндәр. Су өстендә көймә шикелле йөзә торган итеп... Җиңел итеп...

**6**

Искәндәр белән сөйләшү Галиәкбәрне уйга батырды. «Чыннан да, хәллерәк бәндәләр шәенә омтылып яшәү өчен ныклап тотыныр вакыт җиткәндер. Мин кемнән ким? Тәнем сәламәт, көч-куәтем бар. Искәндәр абзыкай әйтмешли, йокыдан айнырга гына кирәк....» – дип үз-үзе белән фикерләште егет.

Абзыкасыннан шөлләүдән генә түгел, оятына көч килүдән дә кыенсынды ул – ихатаның урам як өлешен хәтәр күркәм кыяфәткә китереп, бөтәйтеп куйды. Капкалар да кәефкә ятыш килеп чыкты. Дәрт итү генә кирәк икән. Моңа чаклы балта белән нидер чапкалаганы булмаган Галиәкбәрдән дә хикмәт чыкты түгелме соң? Корал эшләр – ир мактаныр, дигәннәр, эш кораллары тергезергә кирәк. Хәер эстәп, кешеләрдән теләнеп йөрү егетлек түгел.

Минзәләдән кайтуының икенче көнендә үк килеп карады Искәндәр энесе үтәгән эшне. Ошатмыенча бәйләнергә керешер микән, дигән шиккә калган иде егет, абзыйсында андый исәп сизелмәде.

– Кем белән эшләдең?

– Үзем генә...

– Хак әйтәсеңме?

– Сине ничек алдыйм инде, абзыкай?

– Алдарга тиеш түгелсең, билгеле... Мин сиңа шуны әйтәм: кулыңнан хикмәт килә икән бит, энем. Дөнья корырга күптәннән керешәсең калган, әллә кайчан авыл баена әйләнә идең, – дип канат куйды Галиәкбәргә абзыйсы, астыртын елмаеп.

– Алдагы өмет. Мин дә синең фамилияне йөртәм бит, мантып булмасмы әле? – диде егет, җитди генә.

Бу җавап Искәндәр күңеленә хуш килде.

– Дөрес сукалыйсың, энем. Мохтарныкылар адәм актыгында сөйрәлеп яшәү өчен килмәгән дөньяга. Нәсел-ыруга сүз китереп, ата-баба рухын рәнҗетеп яшәргә ярамый. Син лаеклы вәкилебез булырга тиеш, – диде Искәндәр, әлеге темага сүзне йомгаклап.

– Аңлыйм, – дип килеште энесе.

– Иртәгә ни кылмак буласың? – дип сорады Искәндәр, уклы карашын текәп. Аның карашын күтәрү авыр иде, Галиәкбәр күзләрен читкә борды.

– Иртүк курпы чабарга китәм.

– Дөрес эшлисең. Кар ашатып мал кышлатып булмый, печән кирәк. Печән икенче елга калса да зыян итми, – дип хуплады Искәндәр, энесенең ниятен. – Печән мәсьәләсен хәл иткәч, сине икенче олы шөгыль көтә.

– Нинди ул? – дип аптырап калды егет.

– Ике ихатада эшләргә туры килмәгәе, дим...

– Ничек? – дип сорады Галиәкбәр, абзыйсының тел төбен аңышмыйча.

– Минекендә һәм үзеңнекендә, – дип ачыклык кертте Искәндәр.

– Җитешә алсам ярый ла?!

– Җитешерсең. Бушка эшләтмәм. Тиярен түләрмен, – дип файда ягын да искәртте Искәндәр.

– Эшкә кайчаннан керешергә инде? – дип кызыксынды Галиәкбәр. Хак түләү хакында сүз кузгалгач, кесәгә акча керәчәк икән, дигән өмет уянды анда. Абзыкасы әйткән сүзеннән тайпылмый торган кеше, түләмичә калмас.

– Курпы эшен төгәлләгәч кул сугышырбыз, – дип, Искәндәр ихатадан чыгып китте...

Галиәкбәр печән мәшәкатен атна эчендә түгәрәкләде. Алып кайткан курпысы лапас түбәсенә генә сыеп бетмәде, җиргә өйгәне дә олы бер чүмәлә хасил итте. Кылган гамәлен күздән кичергәч, аптырап куйды Галиәкбәр, бу тиклем печән аңа нигә кирәк инде?! Күңел тынычландырырлык җавабын да үзе тапты: «Яз көне печәнгә мохтаҗ хуҗалыклар табылыр, шуларга сатармын, акчасы булыр...»

Икенче көнне, абзыкасы янына килеп кергәндә, Искәндәр, баш астына ике кулын куеп, озын сәкегә сузылган килеш нидер уйланып ята иде.

– Килдеңме, энекәш?

– Килдем, абзыкай, – диде Галиәкбәр, ишек катыннан ары узмыйча.

– Гомерең озын икән, синең хакта уйланып ята идем, – дип урыныннан күтәрелде Искәндәр.

– Әйбәт фикер белән булса ярый ла!..

– Туган хакында начар фикер йөртәләрмени?

– Кем белә инде...

– Мин беләм, – дип, хуҗа егетне тышка алып чыкты. Абзарга ияртеп керде. Эчкә узгач, аклы-каралы ала бозауга күрсәтеп:

– Мүкләк сыерның мүкләк бозавы бу. Әнкәсе куе сөтле. Алып кайтып кит, үстер, сыер ит, файдасын күр, – дип, Искәндәр бозау муенына муенчак кидерде.

– Ничек бәхилләтермен? – дип аптырашта калды Галиәкбәр. Җил уйнап торган кесәң белән олы малга ничек килеп йогынсын инде ул?!

– Кайгырма, җае чыгар. Бергә яшисе бит, – дип, Искәндәр муенчак бавын егетнең кулына тоттырды...

**7**

Искәндәр кулыннан ит алырга җиксенүчеләр авылда бар иде. Нәзберекләнүнең сәбәбен белә ул. Урланган түгел, үземнең малны суйдым, шуның итен бирәм, дип акланган чаклары еш була иде. Ышанганы ышанды, ышанмаганы – юк. Шулай да Искәндәр биргәндә, кыенсынып, барыбер алдылар.

Ат карагының алдаша торган гадәте юк иде. Урланган мал итен үзе дә ашамады, кешеләргә дә өләшмәде. Хайванның күбесе Искәндәрнең ихатасына кайтып кермәде. Алдан сөйләшеп куйган кешесенә туры китереп бирүне кулай санады. Мондый җай чыкмаган очракларда, арадашчы табып, урланган эре малны кулдан-кулга йөртеп, ераккарак озату ягын карады.

...Авыл халкы өчен кыш айлары – ятим-җилпегә, фәкыйрьләргә мәрхәмәтсез чак. Салкын килгән кышлар тәкатьне аеруча корыта. Алдагы кыш та кырыс килергә тартып тора. Ноябрь керү белән чана юлы төште. Елга-күл өсте боз белән капланды. Ай уртасында җәяүлеләр Агыйдел аркылы чыгып йөри башлады.

Бу көннәрдә Искәндәр өй тирәсендә генә хәрәкәтләнә. Кыш ныклап торып башланмыйча, «табыш» юллап кузгалу исәбе юк. Көн саен өйләдән соң Галиәкбәр килә. Көн саен лапасны тазарта, тиресне олы бакчага чыгарып өя. Төнгелеккә мал астына салам түши, утлыкка печән сала...

Чираттагы килүендә Галиәкбәр байтактан әйтәсе килеп йөргән сүзен ирештерде...

– Абзыкай, ишеткәнең юкмы, вак маллар, ишегалдындагы эш кораллары югала икән. Шуларны Искәндәр урлый, дип сүз тараткannар.

– Һы, – диде Искәндәр, авыр ыңгырашкандай сузып. – Соң мин Такталачыкта түгел, волость халкына да зыян салганым юк бит. Киресенчә, авылдашларга ярдәм итәргә тырышкан булам.

– Синең исем астына яшеренеп явызлык кылалар, димәк.

– Кемнәр икәнен чамалыйсыңмы?

– Хафиз белән Шәйхи түгел микән, дигән сүз йөри.

– Инәләрен өшкерәм мин аларның! – дип, йодрыгын төйнәп, урыныннан сикереп торды Искәндәр. Болай да калку гәүдәсе тагын да озынаеп киткәндәй булды. Ярсый төште.

– Сугып имгәтә күрмә тагын үзләрен. Зурга китеп, бәлагә таруың ихтимал, – дип абзыкасын сүрелдерергә теләде егет.

– Бер тондырсаң җан тәслим кылырдай ул бәндәләргә артыгын кыланмам, шулай да акылга утыртырлык итәрмен, – диде Искәндәр, тынычлана төшкәч, ахыргы чутта.

Галиәкбәр җиткергән яңалыкны башкалардан да ишетте Искәндәр. Вак бурлар белән очрашу җаен көтеп яши башлады. Икесен бергә туры китерүдә иде нияте. Бу көн озакка сузылмады, икесен берьюлы урамда очратты. Бераз төшергәннәр, кәефләре хәтәр күтәренке.

– Исәнме, Искәндәр абзый? – дип әллә каян сәлам бирделәр үзләре.

– Мин исән дә, сезнең хәлләр артык шәптән түгел икән бит. Бөтенләй хикмәтсезгә әйләнгәнсез, – диде ул, аларның сәламенә каршы.

– Ни-нәмә булган? – Егетләр бераз аптыраштa калды.

– Авыл халкы сезне урманга алып барып, ыштаныгызны салдырып, кырмыска оясына утыртырга җыена икән бит.

– Нәрсә өчен инде?!

– Якын килегез, хәзер әйтәм.

Егетләр аның янына якынлашты. Искәндәр тегеләрнең җилкәләреннән каптырып алды да, маңгайга-маңгай чәкештерде.

– Күзегездән ут күрендеме?

– Күренде, күренде, абзыкай... Берүк җибәрә күр. Сиңа бернинди зыян салганыбыз юк бит...

– Миңа салмасагыз, авыл халкын рәнҗетәсез. Шуны аңлагыз: авыл янына өн казып бала чыгарган бүре дә шушы авылга афәт китерми. Ризыкны еракатан алып кайтып балаларын туйдыра. Сез бүредән дә мәнсез кыланасыз. Әгәр авыл кешеләренең әйберләренә кагылуыгызны тагын ишетсәм, маңгаегыздан очкын гына чыгарып калмам, ут кабынырлык итәрмен, – дип кисәтте Искәндәр вак бурларны.

Егетләр акланып тормадылар, аның файдасызлыгын беләләр, җәһәт кенә ычкыну ягын карадылар.

Шушы «аңлашу»дан соң авылда урлашу хикмәте бетте, халык тынып калды...

## 8

Искәндәрнең тапкырлыгы, кыен хәлләрдән котылу җаен таба алу осталыгы турында байтак истәлекләр сакланган. Хәтта кайберләре әкияти маҗарага тартым. Аларны Искәндәрнең туган авылы Такталачыкта гына түгел, якынтирә төбәкләрдә дә беләләр, искә алып сөйлиләр.

Искәндәр турындагы хикәятләргә әкият итеп карау дөреслеккә туры килмәс. Ул яшәгән чор тарих катламына күмелмәгән әле. Аны күреп белгән агайлар күптән түгел генә арабыздан китте. Искәндәр турындагы истәлекләрне алар безнең буынга сөйләп калдырды. Шулардан калган хатирәләр йөри хәзер халык арасында.

Искәндәр бакыйлыкка яшьли күчә. Күмәк хуҗалыклар оештыру елларына кадәр яшәми. Тик революциянең нәрсә икәнлеген ишетә, авылларда барган үзгәрешләрне күрә, тормышның кай якка агуын күпмедер сизенә. Әмма яңа власть кубызына биергә ашыкмый, канына сеңгән кәсебен дәвам итә.

Ат урлаганда туган хикмәтләр турында Искәндәр үзе дә сүз сыярдай якыннарына «тәмләп» сөйли торган булган. Бүген безнең арада йөргән кайбер истәлекләрне ат карагының үз авызыннан ишетелгән вакыйга дип кабул итәргә мөмкин.

Иң гаҗәбе шул: ничәмә-ничә сыер һәм ат урлап Искәндәр тотылмаган. Ул урлаганны белә торсалар да, аны гаепләрлек дәлил таба алмаганнар. Судан коры чыгу өчен җае да килеп торган – җирле халык аны «сатмаган». Авылга зыян салмавы, ярлы-япанга ярдәм иткәне өчен хилаф эшләрен яшергәннәр. Аның белән бәйләнешкә керүдән шөлләүчеләр дә булгандыр, бәлки. Маллары урланган хуҗаларның кырыс холыклы, чорсыз бәндә белән низагка керәселәре килмәгәндер. Ахыргы чиктә, ни күрсәтмәс ул?!

Күп очракта Искәндәрнең тапкырлыгы, хәйләкәрлеге, зирәклеге дә катлаулы хәлләрдән шома чыгу өчен ярдәм иткән.

...Искәндәр Агыйдел аръягындагы мари авылыннан ат урлап алып кайта. Төбәктә ат карагының кемлеген чамалаганга күрә, хуҗалар, Такталачыкка юл тотып,

Искәндәрнең артыннан куа китәләр. Килүчеләрнең кемлеген сизенеп, Искәндәр җәһәт кенә намазлыкка баса. Чит милләттән булуларына карамастан, өйгә керүчеләр, гыйбадәтне бозарга базмыйча хуҗаның укып бетерүен көтәләр. Ә Искәндәр энесе Галиәкбәрнең килеп җитүен көтә, ул менә-менә бирedә булырга тиеш.

Ат карагының бәхетенә күрә, шулара Галиәкбәр килеп керә. Искәндәр намазлыкка баскан килеш:

– Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, арт аранда ат бар, арт капкадан аткар, Галиәкбәр! – дип энесенә хәбәр сала.

Абыйсының фикерен ярты сүздән төшенергә күнеккән Галиәкбәр шыпырт кына күздән югала. Атны арт капкадан алып чыгып, тирән яр эченә кертеп яшерә.

Намазлык өстендә көне буе утыра алмый, билгеле, Искәндәр. Күпмедер вакыттан соң, гамәлен түгәрәкләп, битен сыпыра да чакырылмаган «кунак»ларга сәлам бирә:

– Әссәламегаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ике «кунак»ның берсе: «Исәнмесез», икенчесе: «Привет», – дип җавап кайтара. Килүчеләр тартып-сузып тормыйлар, мәсьәләне кабыргасы белән куялар:

– Без атны алып китәргә килдек. Әгәр карышасың икән, жаның белән хушлашырга туры килер, – ди калын гәүдәлесе, чапан эченнән билбауга кыстырылган алтатарның сабына тотынып.

– Нинди ат турында әйтәсез? – ди Искәндәр, кыяфәтенә гаҗәпләнгән төсмер чыгарып.

– Нинди булсын, син урлаганы!

– Андый хәлнең булганы юк, туганнар. Ышанмасагыз, ихатаның астын-өскә китереп тентегез. Әгәр ат бу ихатада икән, шәт, тапмый калмассыз, – дип, килүчеләрне ияртеп, ишегалдына чыга.

Барлык каралты-кура эчен актарта, хәтта кар базына тиклем карыйлар, әмма юллаганын таба алмыйлар. Аптыраудан гаҗәпсенеп, кул селтәп чыгып китәләр куа килүчеләр. Каян тапсыннар, атның ихатага кергән эзе дә юк бит! Искәндәр ул чаклысын да искә алган – атны керткәндә, аның аякларына чабата кидергән булган шул.

Шул ук төнне Искәндәр урланган атны Сарман якларына илтеп, кулдашына тапшыра. Таң беленгәнче Такталачыкка әйләнеп кайтып та җитә. Әлбәттә, кайтышлый сарык «кыстырып»...

Икенче тапкырында да шуңа тартым вакыйга кабатлана...

Аты югалган берәү туп-туры Искәндәргә килә.

– Минем бияне кая куйдың? – дип «үгезне» мөгезеннән эләктерергә тели.

– Нинди бия ул? Миңа ат бирмәдең түгелме соң? – дип сорау белән җавап бирә Искәндәр.

– Бирмәдем, әмма син сораусыз алгансың, ягъни урлагансың... Күреп калганнар, – дип, дәлил китереп, ат хуҗасы шөлләтмәкче була Искәндәрне.

– Күргәч, нигә урында ук тотмаганнар? «Күрдем» дигән кеше үзе бияңне урлап суйгандыр яисә икенче якка олактыргандыр... Миңа ышанмыйсың икән, әйдә, тикшер ихатаны, – дип, Искәндәр каралтысын актарта. Биясен юллап килүче бернинди шикле нәрсәгә тап булмый. «Алып кайту белән атны суйган», – дип әйтергә дә урын күренми, сугымлык тирәсендә кан эсәре юк.

Ат хуҗасы, аптырап, Искәндәрнең кәефен бозуына кыенсынып, ихатадан чыгып китә.

Чынлыкта бия ихатада кала. Искәндәр аны махсус ясалган трап буйлап иске өй түбәсенә менгереп, алдына солы салып куйган була.

...Искәндәр ихатасына кайтып кергән мал сәгате-минуты белән юкка чыга, кая куюын һич белә торган түгел, – дип сөйли торган булганнар. Ничек юкка чыгуын белмәгәннәр. Аның ихатасына керү-чыгу өчен җир астыннан юл бар икән, урланган малны шуннан алып кайта, шуннан алып чыгып китә, дип тә күрәзәчелек иткәннәр.

Искәндәргә җир асты казуның кирәге чыкмаган. Урлап алып кайткан малны озак тотмаган, үзенә мәгълүм юллар аша читкә озату ягын караган. Алынган табышның күп өлешеннән хәерчеләргә өлеш чыгарган. Авылда Искәндәрне хәлле кешеләрдән санаганнар. Дөрес, аның кесәсеннән бервакытта да акча өзелмәгән. Әмма аның күп өлеше аракыга китеп барган. Үзе эчү өстенә, таныш-белешне сыйлау өчен дә күп тоткан...

**9**

Искәндәр кунакка йөрүдән баш тартмаган. Кая килеп чыкса да, аны дәрәҗәле түрә шәенә кабул иткәннәр. Олпат гәүдәле, куәт иясе булуы белән генә игътибар җәлеп итеп калмаган, «тәмле» теллелеге белән дә бәндәләрнең игътибарын үзенә тарткан, ихтирам уяткан.

Уйнап-көлеп, кешеләр күңеленә ятышлы сүзләр генә сөйләп йөрмәгән ул, аракы сөреме белән зиһене томаланган чакларда үз-үзен онытып, холыксызланып алышынган. Кәефенә ятыш килмәгән бер сүз аны чыгырыннан чыгарган. Мондый чакта ул ике сорап тормаган, кем икәнлегенә карамастан, тәпәләп ташлаган. Рәнҗеш төшүнең барын-югын белмәгән. Гафу үтенмәгән. Шулай да күңеленнән үз-үзен битәрләгәндер, чөнки гаепсезгә кимсеткән кешеләрен, төрлечә җай табып, бәхилләтергә тырышкан...

Яшәү рәвешен үзгәртәсе килепме, Искәндәр гомеренең соңгы көннәрендә янәшәдәге Бурсык авылына күченә. Урлашу гадәтен киметсә дә, дуамаллыктан арына алмый ул.

Беркөнне туган авылына килеп, шактый сыйланып кайта. Бурсыкта да байтак «төшерә». Үзенең аруын, атының ак күбеккә батуын күреп, бер агай аңа киңәш бирмәкче була:

– Искәндәр туган, кайтып ял итү ягын карарга кирәк сиңа, – ди.

– Син миннән ялыктыңмыни? Куасыңмы? – дип Искәндәр тегеңә бәйләнергә керешә. Арба төбендәге кечкенә балтасын алып, акыл өйрәтүчегә ыргыта. Ярый, балта йөзе белән туры килми, түтәсе белән агайның җилкәсенә эләгә.

Бу хикмәтне күреп торган берничә ир Искәндәрнең өстенә ташлана. Исерек ирне дөмбәсләү артык көч таләп итми. Йодрыклары кинәнгәнче кыйныйлар Искәндәрне. Арадан берәү каяндыр корык эләктереп, тегенең башына тондыра. Искәндәр бөгәрләнеп төшә...

– Җитте, егетләр! Үтердегез бит... Ат карагы булса да, кеше бит ул. Нәрсәгә тарыячагыгызны чамалыйсызмы? Җыеп алып китәчәкләр бит, – дип, кыйнаучыларның күңеленә шом сала, орышка катнашмыйча, читтән карап торган өлкән агай.

– Ни кылырга соң хәзер? – дип, чыннан да, шөлли кала Искәндәргә ябырылучылар.

– Уйламыйча тотынган эш соңыннан уйланырга мәҗбүр итә шул. Баш ватыгыз инде хәзер, – дип, акыл бирүче бу тирәдән китеп бара.

– Әйдә, үз ягына озатабыз, – дип, ике егет, Искәндәр гәүдәсе янына утырып, атны авылдан алып чыгып китәләр...

* * *

Айгыр күбенеп, су өстенә калыккач кына, Искәндәрнең батып үлү хәбәре якын-тирәгә таралды. Бу фаҗиганең килеп чыгуы күпләрне аптырашта калдырды. Җигүле атта Агыйделне аркылы йөзә торган Искәндәр Шәбез

елгасы тамагында ничек батып үләргә тиеш, дигән сорау икеләндерде танышбелешне.

Искәндәрнең үлем сәбәбен һәркем үзенчә юрады. Искәндәр нык исергән, дилбегә арба тәгәрмәченә уралгач, ат йөзеп чыга алмаган, диючеләр булды. Тик сугып үтереп, аты белән суга кертеп җибәрелгән, дигәнгә ышанучылар күбрәк иде. Арба төбенең тишкәләнүе шулай уйларга урын калдыра иде.

Искәндәр фаҗигасе турында хәзергә кадәр ике төрле караш яши. Әмма авылдашлары: «Искәндәр үз үлемен үзе тапкан», – дигән карашны кире кага. Халыкның күпчелеге аның үтерелүенә икеләнми.

**10**

Чана юлы төшү белән, Гыймазетдин атлы егетне, Такталачык сельпосына аракы алып кайту өчен, Сарман районындагы Петровски спирт заводына җибәрәләр. Кайтышлый, караңгыга калгач, юл өстендәге бер авылга кунарга туктый. Урыс капкалы, биек коймалы, шыңгырдап торган нарат бүрәнәдән салынган өй ихатасына керә. Ныклы ихата эчендә аракыга сүкәлмәсләр, дигән караштa тора егет.

Өй эчендә аны буе ике метр булган, киң иңсәле, мыегы Чапаевныкы шикелле тырпаеп өскә күтәрелгән, алтмыш яшьләр тирәсендәге ир каршылый. Кунарга туктау өчен рөхсәт сорауга, хуҗа:

– Кер, туган, урын җитәрлек, – дип шундук риза була.

Гыймазетдин атын тугарып, чанадагы печәнгә кушкач, өйгә керә. Чишенеп юынгач, хуҗабикә аны кайнар чәй белән сыйлый. Ризыкларны да үзләренекен куя. Гыймазетдиннең юлга төйнәгән төенчеген ачтырмый да хәтта.

Гыймазетдин табын артыннан кузгалгач, хуҗа аннан сорый:

– Энем, нәрсә алып кайтасың?

– Сельпо аракыга җибәргән иде, шуны алып кайтам, – дип, егет турысын әйтә.

– Кая кайтасың?

– Такталачыкка.

– Энем, бик кыен булса да, бер ярты алып кер әле, – дип сорый хуҗа. Кунган өчен, бер ярты калдыру исәбе үзендә дә булгач, Гыймазетдин бер шешәне җәһәт кенә алып керә. Хуҗа шешәне зур көрешкәгә салып, тын алмыйча гына эчеп куя. Күпмедер вакыттан соң хуҗа тагын бер ярты сорый. Бирә инде Гыймазетдин, тик куркуга кала: хуҗа төнлә чанага зыян салмаса ярар иде... Төнне йокылы-уяулы үткәрә.

Иртән торгач та, хуҗа тагын бер ярты алып, баш төзәтә. Шундук эчеп бетерә. Исерми дә, селкенми дә ичмасам. Гыймазетдиннең ис-акылы китә.

Хуҗа Гыймазетдинне кунак шәенә сыйлый, эчкән аракысы өчен тулысынча акча түли, атына юллык печән сала, үзенә күчтәнәч төйнәтә.

– Миңа ни өчен бу тиклем сый-хөрмәт күрсәттең? – ди Гыймазетдин.

– Такталачыкныкы булган өчен. Син Искәндәрнең авылдашы бит, – дип җавап кайтара хуҗа.

– Анысы хак...

– Минем җан дустым иде мәрхүм. Ул китергән атларның байтагы минем кул аша үтте, – дип аңлата хуҗа дуслык нигезен. Балыкчы балыкчыны ерактан күрә, диләр, табышу-аралашу өчен бурларга да ара ераклыгы комачаулык итми икән, дип уйлап куя Гыймазетдин, хуҗа белән хушлашып, юлга кузгалгач.

...Гыймазетдин озын гомер юлы үтә. Хәтере дә ташламый аны. Авылдашлар арасында Искәндәр хакында сүз чыга икән, ул шушы вакыйганы тәмләп сөйли торган була.

* * *

Ат карагы саналуына карамастан, халык хәтере аны авылдан чыккан бер каһарман сыйфатында саклый. Яман ягы белән искә алучы юк Искәндәрне. Аның ярлы халык өчен кылган гамәлләре Робин Гуд батырлыгына охшатып искә алына...

Тарих явыз Иваннарга да урын бирде. Искәндәр Такталачык тарихына кереп калса, артык хилаф эш булмый торгандыр.

Һәр дәвергә геройны тарих үзе сайлый. Кемнең кемлеген еллар исбатлар дигән ышанычта калыйк. Чөнки тарих битеннән мәҗбүриләп урын алып булмый...

## Йомгак

Узган гасырның илленче ел башында, мин Актаныш урта мәктәбендә укыганда, шундый бер истәлекле очрашу булды...

Кыш башланып, чабата эченә кар тулырлык төшкәнче, көн саен диярлек авылга кайтып йөри идем. Яшь вакыт булса да унике чакрым араны барып-кайту җиңелдән түгел иде. Юл уңай ат яки машина туры килсә, ул зур бәхет чутлана иде.

1950 елның көзе. Без, укучылар, урта мәктәп өчен Агыйдел ярына кайтартылган агачларны салдан чыгардык. Арылды. Шулай да авылга кайтырга кирәк. Үзебезнең якка кайтучы юлаучылар туры килмәсме дип, Әҗәкүл ашлык кабул итү пункты янына киттем. Бәхеткә, Такталачыкка кайтучы машинага тап булдым. Йөкләрен бушатканнар, китәргә җыенып кына торалар иде ашлык китерүчеләр. Алардан калу юк инде, тизрәк яннарына елыштым. Уразай белән Такталачык уртасындагы күпергә чаклы утырып кайтырга исәп тотам. Анда төшсәм, безнең Мерәскә дүрт чакрым гына кала...

Исемнәрен белмәсәм дә, йөкчеләрнең күбесе таныш иде. Мине дә беләләр. Такталачык базарында чабата сатып, Сабан туенда бил тотышып үскән малай бит.

Янәшәдә утырган өлкән яшьтәге агай иңсәгә кулын салды һәм:

– Улым, син дә Искәндәр буйлы, шуның кебек куәт иясе булырсың, мөгаен, – диде. Искәндәрнең ат карагы икәнлеген ишетсәм дә, көч чамасын белми идем.

– Гайрәтле идемени? – дип сорадым.


– Ничек кенә әле! – дип шушы агай, Минзәләгә каралырга баргач, фатирда килеп туган хәл турында сөйләде. Дүрт егетнең берсе ул булган икән.

Искәндәр хакында башкача төпченмәдем. Бик күп мәгълүмат алырга булыр иде, югыйсә. Язучылык белән шөгыльләнермен, ярты гасырдан артык вакыт үткәч, Искәндәр турында язарга алынырмын дип кем уйлаган?

Төпченәсе килмәүнең икенче сәбәбе дә булгандыр. Совет чорында ат карагы турында искә алу сәяси кире коткы тарату кебек исәпләнә иде. Шуңа күрәдер, халык Искәндәрне сирәк кенә искә алды, аның хикмәтләре турында ачыктан-ачык сөйләмәделәр. Мондый күрәләтә «оныту» истәлекнең күп өлешен югалтуга китерде. Яшьләрнең күбесе Искәндәрнең кемлеген дә белми хәзер. Аларның ата-аналары да белә микән әле?

Рәхмәт Хәләф ага Шәмсиевкә. Тугызынчы дистәне ваклауга карамастан, хәтере саф икән, байтак истәлекләрне аннан ишеттем.

Бу язманы Искәндәрне искә төшерүдә беренче омтылыш дип саныйм. Киләчәктә киңәйтелгән вариантлар да барлыкка килер һәм аңа хәзерге буын теләп алыныр, дигән өметтә калам...



Рим
Идиятуллин

# БУ ЗАМАН НИНДИ ЗАМАН СОҢ?

## Күпме гомер кирәк икән?

Бу каләмем  Пушкин язган алтын
Каурый түгеллеген белсәм дә,
Акай ябалактай, төн катында
Илаһи сүз аулыйм бүлмәмдә.

Мин хаким дә һәм хәким дә түгел,
Акыл саткан кебек сөйләмәм;
Көн итмешем – әзерләргә бәзер,
Кошлар телен аңламыйм да хәзер,
Их,
Җитмештән соң бар да Сөләйман[1].

Балкый кояш, калка ай да, мәгәр
Фикер кысыр, хисләр тоткында;
Ә язмасам, мин янмасам әгәр,
Мәтәлер күк дөнья упкынга.

Без арбадан төшкәннеме көткән? –
Әйләнде дә куйды дөньялар;
Бакмыйча да әнә тамырына,
Тоткан җирдән өзә яңалар.

Гыйбрәт хәл: кер кундырмас җанны
Туя белмәс нәфес сарганда,
Картка яшьне димләр яучы сыман,
Ярәштерә хакны ялганга.

[1] Сөләйман (Соломон) пәйгамбәр – җирдәге барча киек-җанвар телен белгән, картлыгында исә зирәклеген югалткан мәлик-падишаһ.

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) – *шагыйрь; «Хәерле иртә», «Хәерле көн», «Хәерле кич» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Уфада яши.*

Шыр шарлатан алдый мут Шомбайны
(Шашкын ирек бүген безләрдә!):
Төштә төшем күреп, өндә тычкан
Тизәген дә сала бизмәнгә.

Аһ, җуела җанның бизәкләре;
Әйләнербез кемгә, рух сынса?
«Бушка елмаймас бу», – диеп, күңел
Шәфкатьлене хәтта ятсына.

Адәм заты – залим хатынга тиң,
Туя белми ызгыш-сугыштан;
Сабый – чиксез Җир шарында качак…
Шардай күзендәге каргыштан
Яначакбыз, валлаһ, тәмугта.

Таш гасырдан безнең Туң дәвергә
Башын иеп килә мең сорау;
Кайчан табарбыз соң җавап? Тып-тын. –
Гавам сырхау, Галәм саңгырау.

…Белмим, белмим, утларгамы башны,
Суларгамы әллә салырга?
Күпме гомер кичү кирәк икән
Җирдә Кеше булып калырга?!

## И Алла!

*(Ана монологы)*

Күкнең төбе тишелгәндер,
Яңгыры ярсып бәрә;
И Алла,
Саргаерга язды микән
Сыланып тәрәзәгә?

Күрсәм, чат ябышыр идем
Хет өмет сыныгына;
Йа Хода,
Буш өемдә кача-поса
Шом йөри шымып кына.

Онытты улым, онытты
Дөньяга ник туганын;
Илаһым,
Талап акча, чапты эзләп
«Тилебәрән орлыгы»н.

Ниләр генә уйласам да
Батам гел ачысына;
Ярабби,
Әллә Күк тә битарафмы
Чал Ана кайгысына?

Көфер хисләргә юлыксам,
Син яктысына ялга!
И Алла,
Нигә яманын калдырып,
Газизен иртә ала?!

Җәй көнендә җылы йокмый,
Төренсәм дә шәлемә;
Илаһым,
Екты язмыш: калдым ирсез
Пешкән җиләк мәлемдә.

Бу заман нинди заман соң,
Болгана да тулгана?
Йа Хода,
Тормыш гөрли, кала гүли,
Бала кала далада…

Ташларга бәрми бу яңгыр,
Башкайларыма бәрә;
Яраббым,
Бәхетсез итәр ил-көнне
«Наркоман» дигән бәла.

Дөнья чукрак, ишетми ул,
Кычкырсаң да каравыл;
Йә Хода,
Үлем сатып байый әнә
Адәм йөзле газраил.

Шом йөри шымып өемдә,
Сизәм, йөри бик якын;
И Алла,
Ничек аңлатыйм балама
Яшәүләрнең чын хакын?

Шәүләсеннән таныр идем,
Бер карачкы күренсә;
Илаһым,
Никләр үлем эзли улым,
Мин үлгәнне көтмичә?!.

## Серем чиштем сезгә

Әнкәм миңа җырлар көйләмәде,
Сөйләмәде серле әкият;
Җаным никтән моңга төренгәнне
Төшендем мин бүген ниһаять.

…Иртә таңда, шомлы көй чыгарып,
Ертык тәрәзәдән җил өрә;
Тамагына Әнкәм ризык табар! –
Ул келәттә ашлык җилгәрә.

Нәрсә эзли анда шәрә базда? –
Һич чыелдап туймый ач тычкан.
Күтәрелгәч кояш, мин җылыга чыгып,
Әвәләдем ипи балчыктан.

Өзелепләр сайрый, бу кошларның
Бу дөньяга юкмы катнашы?
Дөмекмәгән сугыш – ал офыкта
Җуелмаган һаман кан төсе.

Салкын уйга батып йомылганда,
«Балам!» диеп, Әнкәм эндәшә:
Күзендә – нур, керфек очларында
Энә күзе кадәр күз яше.

Мичтән генә чыккан ипимени, –
Капылт кояш сихәт бөркеде,
Әнкәм
ат башыдай алтын тапкан:
Сузды бер уч бодай бөртеге…

Бозлык, соңра йотлык дәверләрен
Исән кичтек ләса, ни хикмәт?!
Безнең гомер «Мең дә бер кичә»дән
Хәтәррәк чып-чын хикәят,
Әйе,
Адәм ышанмастай әкият.

Әнкәемнең куян күчтәнәче
Зурлап сөйләр нәрсә түгел дә,
Тик ни кылыйм, ул бөртекләр җанда
Сагыш булып шыта бүген дә.

Ертык еллар җырны өнәмәде,
Елыйм дисәң, ай-һай күп сәбәп;
Нидән моңсу шагыйрь булуымның
Чиштем серен сезгә ниһаять.

## Бүләк

Бу сандугач моңы һич туйдырмый,
Сайраса да көн дә бер көйгә;
Валлаһым да, манып чык суына,
Иртән иртүк сөенечле хәбәр
Җиткерәсе килә һәркемгә.

Чылтыратып көмеш кыңгыраулар,
Туй аты күк чапкан чишмәләрнең
Уч тутырып суын бер капсаң,
Валлаһ, терек суын уртлагандай,
Кочар яшьлек сине кабаттан.

Ә чәчәкләр һаман сылу ласа,
Һаман һуш китмәле исләре;
Күзләреңә баккан бу матурны
Өзәрләргә, валлаһ, беркем кыймас,
Юк, табылмас андый исәре.

…Сандугачым, чәчкәм, чишмәм, – Ходам
Бүләк иткән җанлы җәүһәрләр;
Мәнсез бәндә тик берсенә шуның
Карасамы әгәр йөз чытып,
ул,
Җирне түгел, үзен җәберләр.



Ләлә
Сабирова

# БЕР УЧ БОРЧАК

БӘЯН

**Үзе белә!..**

– Әтиең төрмәдә, әниең авыру, ә син оялмыйча трай тибеп йөрисең!

Зариф чыдап торды-торды да, түзмәде, мышкылдап елап җибәрде. Әллә авыртудан, әллә гарьләнүдән, әллә куркудан... «Сталин» (малай аның мәктәп директоры икәнен байтактан гына белде, беренчеләр коридор стенасындагы портретны аныкы дип йөри иде) малайның колагын бик шәп борып тоткан иде шул, сүзен әйтеп бетермичә җибәрмәде.

Әти төрмәдә булгач, ник чабып йөрергә ярамый икән соң? Ә авыру әнисе янында шыпырт кына йөри Зариф. Ул ни әйтә, йөгереп кенә эшли дә ата. Әнисе аны еш кына югары очтагы Хөббениса түтиләргә җибәрә. Малай аннан нәни кәстрүл белән кайнар аш алып төшә. Аш суынмасын дип кызу-кызу атлый, шул арада, тукталып, кәстрүлдән килгән хуш искә хозурланып ала. Тәмле-е! Кайткач, әнисе аңа бераз өлеш чыгара үзе. Тик аның белән генә тамак туймый шул.

Әтисе сугыштан исән-имин кайткан аның. Ул чактагы шатлыкны Зариф бик аз гына хәтерли. Ә тамагы туйганчы ашый башлаганы исеннән бер дә чыкмый. Әтисе кайтканга бит инде ул! Тик ул рәхәт вакытлар күпкә бармады. Әтисен тагын алып киттеләр. Әнисе, кергән бер кешегә: «Бер уч бодай өчен», дип елый-елый сөйли иде. Үзе озакламый түшәккә егылды. Күршеләр «кайгыдан», диде. Хөббениса түтиләре әллә нинди үләннәр белән дәвалап карады, өшкерде дә, төчкерде дә...

Әтисе кайтканчы бер рәхәт күрмәде инде Зариф. Алай дисәң... Булды рәхәт вакытлары. Җырларга яратты ул. Тик мәктәптә түгел – анда аны берәү дә кирәксенмәде. Әнисе авыл кырыендагы әрәмәлеккә чыбык-чабык җыярга җибәргәч җырлый иде. Бөтен әрәмәлек яңгырап тора иде инде, малай үз тавышына үзе шакката иде. Өй стеналарында кара төстәге радиоалгыч эленгән, шул көне буе сөйләп тора. Ара-тирә җырлар яңгырый, һушы китеп тыңлый шуларны Зариф. Сүзләрен дә шуннан отты, онытса, үзеннән чыгарып та җырлады.

Бервакыт әрәмәлек кырыеннан узып баручы бер атлы кеше ишетеп алган моны. Зариф үзе сизмәде, тырышып-тырышып «Рамай»ны суза иде. Үзе күңеле

---

Ләлә САБИРОВА (Гыймадиева) — *язучы, журналист. «Кызарган алмалар», «Чуфут-Кале малайлары», «Мин аңа бәхет телим», «Ике әни һәм бер математика» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

белән әллә кайларга китте. Кош булып очып йөрде, шаулы урманнар, зу-ур сулы күлләр өстеннән узгандай булды...

– Әй, малай! – дип дәшкән тавышка сискәнеп китте Зариф. Әтисен төрмәгә утыртканнан бирле шулай һәрнәрсәдән куркып китә ул. Тагын нindидер хәтәр эш булыр дип шикләнә.

– Курыкма, апаем, Шәйдулла абзыең мин! Кил әле бире!

Зариф чыбыкларын ташлады, әүвәл сәерсенеп карап торды.

Абзый арбасыннан сикереп төште дә аңа таба турылап китте.

– Бик матур җырлыйсың, кем өйрәтте?

Малай җилкәләрен генә сикертте. Кем өйрәтсен инде, үзе белә!

– Җырчыларны яратам мин. Әй, үзәкләрем өзелеп тә китә инде!.. Тамагың ачтымы? Мә, капкалап ал!

Анысына сәерсенеп тормады малай, тоз сибелгән ипи телеменә ике куллап ябышты. Нишләп шулай гел ашыйсы киләдер инде аның...

Икенче тапкырында колхозның ындыр табагы кырыеннан узып барганда күрде ул Шәйдулла абзыйны. Киребеткән кәҗәләрен басу ягыннан алып кайтып килеше иде. Малайны күргәч, абзый кем беләндер сөйләшеп торган җиреннән тукталып калды.

– Әй, апаем, син икәнсең! Кил әле, кил, апаларыңны дәртләндер әле эшкә! Аларның да тыңлыйсы килә сине!

Зариф «ә» дә, «җә» дә димәде, туктап, аңа аптырап карап тора башлады. Кәҗәсе тартылды, ычкынмакчы булып бәргәләнде.

– Менә болай итәбез... – диде Шәйдулла абзый, кәҗәнең бавын Зариф кулыннан алып, баганага бәйләп куйды. – Әйдә, ялындырма! Хезмәт хакың – бер уч борчак!

Бер уч борчак... Малай абзыйга күтәрелеп карады. Аның әтисен дә шул бер уч... бер уч бодай өчен алып киткәннәр түгелме соң? Күзләре яшь белән тула башлады...

– Кит әле, сиңа тигән кеше юк бит! Нәрсә сытылып торасың? Җырламасаң җырлама, ярар! Йә, ач әле кесәңне! Авансом! Икенче вакыт җырларсың, яме!

Шәйдулла абзый Зарифның зур авызлы кесәсенә чыштырдатып бер уч борчак койды.

Һәрберсен озаклап чәйни-чәйни кайтты малай. Моннан да тәмле нәрсәне күптән ашаганы булмаган икән. Кайтып җиткәнче кесә бушады. Борчак турында әнисенә әйтеп тормады. Йә куркып калыр тагы...

Бер-ике көн үтте, «бер уч борчак» артыннан килүче булмады. Зариф аның тәмен авызында кабат тойгандай булды. Беркөнне кәҗәсен тагын ындыр табагы кырыеннан алып кайтты. Дәшүче булмаса да, шунда кайнашучы апалар янына үзе килде.

– Миңа Шәйдулла абзый кирәк иде!

– Ә-ә, җырчы егет килгән! Абзаң юк шул! Безгә генә җырлап бирмисеңме соң?

– Ник җырламаска! – диде Зариф, үзе күз кырые белән генә борчак өеменә күз ташлады.

Хатыннар көлешә-көлешә аның ертык кесәсенә ярты гына уч (малайга шулай күренде) борчак салып куйдылар да аңа карап тора башладылар. Зариф та кыюланып китте, кәҗәсен кочаклап утырып, «Сарман» көен сузып җибәрде. Башта тып-тын калып тыңладылар. Аннары кайсыларыдыр мышык-мышык борын тарта башлады. Әллә малайны җәлләделәр, әллә үзләрен уйладылар. Бик матур иде шул Зарифның тавышы. Киткәндә:

– Апаем, тагын кил яме, бер дә оялма! – дип калдылар.

Малайның даны авылга тиз таралды. Бервакыт кибет тирәсендә җыелып торган апалар үзләре дәшеп туктатты.

– Син җырласаң, бернинди радио да кирәкми, әйдә, сузып җибәр әле! – диделәр. Зариф ялындырмады. Җырлаганнан соң кесәсендә ни дә булса кайтачагын яхшы белә бит ул.

Бервакыт мәктәптә аны «Сталин» янына алып керделәр. Коты очты малайның. Тагын колакны бора инде, дип уйлады. Әмма аныңча булып чыкмады.

– Сине, энекәш, бик матур җырлый, диләр. Ник бездән качып йөрисең? Ник мәктәптә җырламыйсың?

Кайчан качканы бар әле аның? Мәктәптә кем әйткәне бар аңа җырла дип?

– Иртәгә матур киенеп кил. Мәктәп сәхнәсендә җырларсың.

Матур киенеп дип... Ние бар, шул инде...

Киемең ямьсез дип тормадылар әле, котыра-котыра кул чаптылар. Балалар да, укытучылар да. Бөтен кеше сиңа шаккатып карап торганда, бик күңелле була икән ул.

Кесәсенә әйбер салмасалар да...

## Гармун уйный да уйный...

Сталин (бу вакытта Зариф аның кем икәнен яхшы белә иде инде) вафатыннан соң амнистия чыкты – этиләре котылып өйгә кайтты. Аның белән күрешү шатлыгыннан күрше-күләнне кунакка җыйдылар. Унике яшьлек Зариф, хәзерге заман теле белән әйтсәк, авылда «йолдыз»га әйләнгән иде инде – аларга чын-чынлап концерт күрсәтте. Әтисе шаккатып тыңлап утырды. Соңыннан улын кочаклап, күз яшьләрен түкте.

– Иртәгә үк гармун алып бирәм мин сиңа, – диде.

Болай гына әйткәндер дип уйлаган иде Зариф, әтисе сүзендә торды. Үзен генә түгел, исенә хәтле яратты малай ул гармунның. Башка бер нәрсәдә гаме булмады, әнисе әйткән йомышны чаба-чаба эшләп куя да тизрәк шуңа ябыша.

– Бар, мунча алачыгына кереп кычкырт! – диде беркөнне әнисе, аптырагач. – Башым тубал булды бит инде тавышына!

Зариф карышмады, гармунын күтәреп, шунда чапты. Әтисенең: «Каты дәшмә, уйнасын, тулык чыгачак бу малайдан», – дигәнен ишетеп калды.

Мунча алачыгында рәхәтрәк тә әле, тегене әйтеп, монысын кушып бүлдерүче юк. Бер атна дигәндә рәхәтләнеп көй чыга башлады гармуннан. Бер көнне авыл эшчәннәренә багышланган концертта «Дим-дим»не үзе уйнап, үзе җырлады. Халык кул чапканда авыл клубы урыныннан купкандай булды.

Улының мондый уңышларына этисе бик куанса да, әнисенең әлләни исе китмәде.

– Тамак туйдыра торган үнәр түгел, син аны үзең белән урман кисәргә йөрт! – ди торган иде. Андый чакта әтисе аңа каршы төшә:

– Син алай дияргә ашыкма әле! Белмәссең! Ә утынны... аннан башка да кисеп була. Бармакларына зыян килмәсен. Йорт тирәсендә кайнашканы җиткән.

Беркөнне аларга теге чакта танышкан Шәйдулла абзый кереп утырды.

– Малайны өйләндерәм, туй мәшәкатьләре белән йөрим әле, – диде. – Менә Зарифны җибәрсәгез иде, уйнап-җырлап утырса, ну шәп булыр иде!

Моны ишеткәч, әнисе күтәрелеп бәрелде:

– Ни сөйлисең, Шәйдулла! Бала гына бит әле ул! Әнә, Мөтәвәли малаена әйт! Түбән оч Рәкыйп та шәп тарта. Тапкансың чакырыр кеше!

Шәйдулла кулын гына селтәде.

– Рәкыйп та булдымы гармунчы?! Ә Мөтәвәли малаена әйтсәң, бер ярты сәгатькә түзсә түзәр, аннан эчеп егыла бит ул! Алкаш... Аннары, мин бит бушка димим, тиярен биреп кайтарырмын...

Әнисе тагын нәрсәдер әйтергә талпынган иде, әтисе туктатты.

– Туктале, хатын, чәбәләнмә... Тиярен бирәм ди бит. Шулай өйрәнә инде ул тамак туйдырырга. Үзең шуны теләгән идең түгелме?

Бик күңеле булып кайтты ул көнне Зарифның. Шулкадәр дәртләнеп уйнады, кунаклар аяк тибә-тибә кул чапты. Тамагы да туйды, «тиярен» дә алды. Анысын шунда ук әнисенә кайтарып бирде. Алуын-алды әнисе ул акчаны, тик никтер авыр сулап, озак итеп улына карап торды...

Тугызынчыны бетереп йөргәндә, колхоз бригадирының юбилей кичәсенә дәштеләр Зарифны. Өйрәнгән эше, андый мәҗлесләргә бик яратып йөри ул. Әнисе дә күнгән иде инде:

– Ярар, үз кирәк-ярагыңа булыр, менә шушында җыя барам, – дип, улы алып кайтып биргән акчаны комод тартмасына салып куя башлаган иде.

Бригадирның табыны мулдан булды. Уйнап-җырлап арыгач, Зарифны да бер почмакка утыртып ашаттылар.

– Әйдә, сыйлан, әле таралышырга иртә, бераз ял ит тә... – дип, бригадир абзый малай янына үзе килеп утырды. – Бусын да кабып куй. Курыкма, әче бал гына ул. Башыңны ачып җибәрер, – дип, болганчык суга охшаш сыеклык салынган кырлы стаканны шапылдатып алдына китереп утыртты.

Шуннан соңгысын юньләп хәтерләми Зариф. Уйнаган шикелле дә була, нәрсәдер җырлады да бугай. Аннары... Үзләренең капка төпләрендәге эскәмиядә гармунын кочаклап йоклап яткан җиреннән таң алдыннан уятып алдылар. Уятып дип... Әтисенең чалтыратып яңагына сугуыннан айнып китте ул. Әнисе ярсып-ярсып елый иде.

– Тагын бер генә дәшсәләрме... – дип тәкрарлый-тәкрарлый, Зарифның кулыннан гармунын йолкып алды. Аны кая яшергәндер, соңыннан күпме актарынып караса да, эзенә төшә алмады малай. Шуның белән мәҗлесләргә юл ябылды.

Ябылса ябылды, әмма ул мәҗлесләрдә зур абзыйларның бер-берсен бүлдерә-бүлдерә акырышып җырлап утырулары исеннән бер дә чыкмады.

Дөресрәге, алар җырлаган такмакларның сүзләре.

Беркөнне әнисе аны күрше авылга йомыш белән җибәргән иде, юлда «Авыл» көенә шуларны кычкырып җырлап барды:

> Бакчабызны үлән баскан,
> Йөгерә-йөгерә утадым...

Әй, рәхәтләнгән иде шунда, тавышы карлыгып беткәнен дә сизмәгән иде. Тик менә «концерт»ның икенче өлеше өйгә кайткач дәвам итте шул. Аны артыннан күзәтеп килгән башлангыч класс укытучысы тыңлап барган, әтиләренә: «Санап бардым, йөз дә ике куплет оятсыз җыр җырлады», – дип кереп әйткән. Тел белән дә өйрәтте әтисе, йодрык белән дә...

Мәктәпне бетергәндә Зариф «музыкальный...» дип сөйләнә башлаган иде, әнисе авызын да ачтырмады.

– Укытучы тормышына кызыгып гомерем үтте, авылдан чыгып китәргә булсаң, беркая түгел, түлке педагогическийга барасың! – диде. Укытучы булса, тәртипле яшәр дип өметләнгәндер инде. Әтисе кысылмады. Теге вакыйгадан соң улының киләчәге турындагы фикерен ул да үзгәртә төште булса кирәк.

## Мин – мин микән?..

– Малай, тор! Имтихан бирәсеңне оныттың мәллә, ай-яй, соң кайттың!

Зариф бүлмәдәшенең сукрануын колагына да элмәде. Иярләнгән инде. Башын бәрә-бәрә укый торган егет ул, «биш»ле эләкмәсә, кабат-кабат барып тапшыра. Ничек туймый, диген! Ә Зарифка «өч»ле дә җитә. Анысын болай да куялар. Куймый карасыннар! Армый-талмый факультет данын яклап йөри бит ул. Деканатта күтәреп кенә йөртмиләр, бәйрәм-фәлән җитә башласа, олысы-кечесе бер артына, бер алдына төшеп мәш килә. «Троечник» дип тормыйлар, стипендиясен дә юллап бирәләр.

Әнисенең «тамак туйдыра торган үнәр түгел» дигәне вакыт-вакыт исенә төшеп куя аның. И, әни, ничек кенә туйдыра әле! Шул булмаса, ул стипендия акчасына ничек яшәмәк кирәк! Сездән бер тиен дә таммый бит! Гармунны яшергән булган иде, монда кулына елкылдап торган өр-яңа баян тоттырдылар. Анысына да тиз өйрәнде Зариф. Шәйдулла абзый әйтмешли, талантны күмеп куеп булмый, әллә каян тишеп чыга ул!

Кичә группадашы Рәсим туганнарының гаилә бәйрәменә чакырган иде. Рәхәтләнеп сыйландылар. Зариф баянын кулыннан төшермәде. Кем әйтмешли, «от души» уйнады. Яхшы кешеләр өчен хезмәтен кызганмый ул. Җитмәсә, хуҗабикәнең үсмер сеңлесе – авылдан кунакка килгән Җәмилә бер дә күзен алмады үзеннән. Зариф кашларын сикертә-сикертә аның каршысына килеп җырлаганда, комач кебек кызарынды, бик оялчан нәрсә икән. Кунаклар көлеште, кызый, үпкәләп, табын яныннан торып ук китте.

Юри генә үпкәләгән булган ул, Рәсим әйтә, «сине бик сораша, гашыйк булып куймагае», ди. Булмагае! Аның ишеләр Зариф тирәсендә буа буарлык, теләгәнең сайлап ал! Бөтенесе аңа ошарга тели. Егет берсенә дә караңгы чырай күрсәтми. «Гармунчының буыннары саен мәхәббәт аның...» дип юкка җырламыйлардыр инде. Тулай торакның кайсы бүлмәсенә барып кермә, колач җәеп каршылыйлар. Кем авылдан күчтәнәч төяп килгән, кемнең кайсыдыр туганы ит-бәрәңге кертеп чыккан, кемнең ниндидер бәйрәм уңаеннан кечкенә мәҗлес уздырасы килә – сыйланырга Зарифны да дәшәләр. Ялындырмаячагын да, баянын үзеннән калдырмаячагын да беләләр. Йөри-йөри сүзгә дә остарып бетте, ул авызын ачса, сөйли башлаганчы ук кызык көтеп гөрләшергә тотыналар.

Бүген «Фәнни коммунизм»ны бирәсе. Имтихан алучы – деканатның профком рәисе Хәниф Хатыйпович. «Җырлап» тапшырачак ул аны. Кеше янында рәис аңа «Зариф Закирович» дип кенә дәшә. Шулай булмый ни! Күп эше шул Зариф аркасында гөрләп бара да инде аның...

...Август ахыры. Зарифның, авылда ял итеп килгәч, тулай торакка урнашып йөргән мәле иде. Вакыт уза – быел дүртенче курсны башларга җыена. Әнисе җай чыккан саен: «Улым, вакытыңны килде-киттегә әрәм итмә», – дип тукып тора. И, әни, нинди килде-китте инде! Үз вакытында бар да кирәк. Ә уку болай да бара ул. Узган ел бер мәктәпкә практикага йөрттеләр. Беркем дә Зариф кадәр булдырмады. Аерылышыр алдыннан мәктәп директоры үзе килеп Зарифның кулын кысты. «Диплом алгач, туры үзебезгә кайт!» – дип чакырды. Шулай булмый ни, балалар бик яратты үзен, өлкән класс кызлары – бигрәк тә. Авызын ачып сөйли башлауга, тып-тын булалар. Сүз осталыгына үзе дә сокланып куя кайчак. Мин – мин микән, мин кем икән, дигәндәй... Әйе, талант гармун түгел, аны яшереп куя алмыйлар...

Тулай торак ишегеннән уйланып кына чыгып бара иде, үзеннән зур чемодан сөйрәгән кызый белән чак маңгайга-маңгай бәрелешмәде. Күзе чыккан

диярсең! Зариф, күтәрелеп, усал сүз әйтмәкче иде... Бәрәч, бу теге чакны кунакта танышкан Җәмилә түгелме соң? Егет киң итеп елмаеп җибәрде.

– Китер, матурым, булышыйм. Инде син дә үсеп җиттеңмени? Студент булдыңмыни?

– Ә-ә! Зариф... абый! Булдым шул! Сез дә шушында яшисез, иеме?

Зариф гөрелдәп көлеп җибәрде.

– Кемгә – абый, кемгә – җаный... Монда яшибез инде, матурым. Йә, сине кайсы бүлмәгә озатасы? Карап калыйм әле. Кунакка дәшәсең булса, юлны буташтырмыйм тагын.

Җәмилә дә көлде. Зариф аңа текәлебрәк карады. Әлләни чибәрләрдән булмаса да, хәйран сөйкемле. Шактый кыюланган тагын үзе. Теге вакыттагы сүз саен кызара торган сабый түгел инде...

## «Монда килгән кеше китми...»

...Сәгать чылтыраган тавышка чәчрәп уянып китте Зариф. Ул да булмады, ишек дөбердәтергә тотындылар. Егетнең җен ачуы чыкты. Тапканнар вакыт! Җилфердәп килеп ачып җибәргән иде, Җәмилә басып тора. Үзе әсәренгән.

– Абау, Зариф, җаным, тормадыңмыни әле? Нинди көн икәнен оныттың мәллә?

Зариф, кашын-күзен җимереп, бераз басып торды. Нинди көн? Ә-ә-ә... Диплом тапшыралар ич бүген.

– Онытмадым. Кичә егетләр белән вагон бушатырга бардык. Дипломны юарга акча кирәк булыр бит? Арыткан...

Җәмилә коридорда тәрәзә янагына сөялеп басып калды, Зариф, сөлгесен асып, юыну бүлмәсенә кереп китте.

Бигрәк самими инде бу кызый. Нәрсә әйтсәң дә ышана. Мөгаен, гомерлек яр итеп шуны сайлар да. Моңа кадәр йөргән кызлары гел үртәп тора үзен. «Кай җирен ошатасың шул авыл гыйбадының? Синең кебек ут егетләргә чәчрәп торган кыз кирәк. Ә моннан он суы да, тоз суы да юк», диләр. Менә шул ягы ошый да инде Җәмиләнең! Чәчрәп торуы кирәкми аның, сезнең кебек һәр адымын тикшереп торучы да кирәкми.

Баштарак Рәсим дә үзәгенә үтте:

– Ник өметләндерәсең баланы, беткәнме сиңа башка кызлар? Бәхетле булмаячак ул синең белән. Җәмилә, ни әйтсәң дә, миңа туган тиешле, аңа синең кебек артык шустрыйлар кирәкми, – дигән иде.

Өметләндерә дип... Зариф бит аңа алтын таулар вәгъдә итми, башын югалтып гашыйк булып та йөрми. Җәмилә үзе ярата. Ташласа, егет аңа ялынып йөрмәячәк. Ә болай... тормыш итәр өчен иң «удобный» вариант ул. Әле дә «вагон бушаттым» дигәнне болай гына әйтте. Ә Җәмилә ышанды. Теләсә нинди җавап теленә бик тиз килеп тора Зарифның. Күзен дә йоммый. Соң, вагон бушатканга санап бирәләр, ә кичә акчаны ул уч тутырып алып кайтты. Өстәвенә, ашаттылар, эчерттеләр. Йокларга калырга да кыстаганнар иде әле. Иртәгә диплом аласы көн булганга гына кайтасы итте.

Җәмилә, Зарифка ияреп, эчкә үтте.

– Күлмәгең үтүкләнмәгәндер әле... Кая, китер, тиз генә үтүкләп бирим. Ә галстугың? Андый җиргә галстуксыз барырга ярамый.

Ул гел шулай кайгыртырга ярата, аның өчен борчылып яши. Зариф моңа ияләнгән инде, сүз әйтми.

– Йә, ничек, ярыймы?

Җәмилә «ялт» итеп киенеп куйган Зарифка сокланып карады. Чибә-әр! Пиджагындагы чүпне сыпырып төшерим дип якынрак килгән иде, йөзе сүрәнләнеп китте.

– Фу-у! Сүз биргән идең бит инде син бер!

– Аракы исе түгел бит ул, матурым! Кичә егетләр белән әз генә сыра каптык, арыганлыкны бетерер өчен генә! Син борчылма, урамга чыккач бетә ул, җилли...

Шулай да Җәмилә аны күңелсезләнеп озатып калды.

Дөресен әйткәндә, бу дипломда аның өлеше дә зур. Зариф моны белми түгел. Ул «вагон бушатып» арып кайткан чакларында Җәмилә, җәлләп, аңа гел булышкалап торды. Китапханәгә барып, кирәкле брошюраларын тапты, күчерәсен күчереп бирде, язган кадәресенең хаталарын тикшереште. Йә, моннан да тугрылыклы ярдәмче була аламы?

...Практика үткән мәктәп директорының «туры үзебезгә кил» дигән сүзләрен бераз уйлап йөрде дә онытты Зариф. Юк, шәһәр тормышы аның өчен түгел. Нәрсә, монда кемнеңдер почмагына фатир төшәргәме? Иркенлек, хөрлек ярата ул, бер мәктәп тормышы гына аның өчен тар булачак. Аннары, шәһәрнең үз законнары, анда олтан булып яшәгәнче, авылда солтан булу күпкә рәхәтрәк. Авыл дигәч тә, туган авылы түгел бит ул аның. Анда ул «Закир малае» түгел, ә «Зариф Закирович» булып кайтып төшәчәк!

Институт юлламасы буенча җибәрелгән районның мәгариф бүлеге мөдире белән дә Зариф бар осталыгын җыеп сөйләште. Профком рәисеннән искиткеч шәп характеристика яздырып алып килгән иде, аның белән танышканда, мөдир бер кәгазьгә, бер Зарифка карап-карап алды.

– Болай итәбез, – диде, берникадәр пауза ясап. – Мәктәпләргә «тәрбия эшләре буенча директор урынбасары» дигән яңа вазифа кертелде. Сезне Чияле мәктәбенә җибәрәбез, шул вазифаны йөклибез. Билгеле, сынау срогы белән. Характеристикагызга караганда, сезгә кулай эш булырга тиеш...

Чиялене килеп төшү белән ошатты Зариф. Йортлары төзек, халкы байларча яши булса кирәк. Авыл кырыеннан киң сулы, камышлы-төнбоеклы елга агып ята, ерак түгел генә нарат урманы башланып китә. «Мәктәп фатиры» дигәннәре дә юан нарат бүрәнәләрдән салынган алты почмаклы йорт булып чыкты. «Урнаш, эшеңне башла. Кем белә, безнең авыл кияве булып китүең дә ихтимал. Монда кызлар җитәрлек. Киленне башлап шушы йортка төшерүең дә бар. Аннары карарсың. Монда бер килгән кеше китми, бөтенесе йорт җитештереп, башлы-күзле булып яши», – диде директор аның белән беренче танышканда.

Кызлар кайда да җитәрлек лә ул. Аның Җәмиләсе кебекләр бар микән менә? Аерылышканда елап калды...

– Соң, әйдә, бергә китәбез, – диде аңа Зариф. – Укуыңны читтән торып та бетереп була аны. Аннары... отработка ике ел инде ул. Шуннан соң кабат әйләнеп тә кайтырбыз. – Бусын сүз югында сүз булсын дип кенә әйтте, алдагысы өчен бер планы да юк иде аның.

– Белмим инде. Әйтеп караган идем, әниләр борчыла. Беләсең бит...

Җәмилә беркатлы шул ул, бөтенесен сөйләп бармаса да була, югыйсә. Ышанычлы егеткә охшамаган, дип әйтәләр ди туганнары. Кызларын кем дип белә торганнардыр? Рас күңеле Җәмиләгә яткан икән, Зарифка рәхмәт кенә әйтсеннәр инде. Аның бит бер сызгыруы җитә, янына кызлар өерләре белән килеп басачак...

## Көнләшерлек шул!

– Абый, абый, бүген репетициягә калабызмы?

– Абый, ә сез безне баян уйнарга өйрәтә аласызмы?

– Ә сез шәһәрдәнме, авылданмы? Кайсы авыл матуррак? Безгә озакка килдегезме? Сезгә кадәр укыткан Харисов бер ел да тормады...

Дәрес беткәч тә укучылары җибәрми Зарифны, көн саен яңа сораулары туып тора. Өлкән класслардагылар якын ук килеп сөйләшә, артыннан чыгып, коридор буйлап озата китәләр:

– Йөргән кызыгыз бармы соң?

Бусын дәрестә аңа чекерәеп карап утырган Рәисә бирде. Үзе четер-четер көлә. Иптәшләре дә көлешә.

Зариф эшен бик җиңел башлады. Директор урынбасарларына дәрес атнага унике генә сәгать тиеш икән. Калган вакытында хет балалар белән бәйрәм концерты әзерлә, хет укытучылар бүлмәсендә берәрсе белән шахмат уйна, хет башка укытучыларның дәресенә кер. Әмма монысын «башкалар» өнәп бетерми. «Бер практикасы юк бит аның. Ять-яшь башы белән кеше дәресләрен тикшерергә! Вазифасы ул түгел...» – дип зарланалар. Берсендә директор андыйларны үзенчә тынычландырды:

– Тикшерми, ә өйрәнә, тәҗрибә туплый. Ә ошамаган якларын әйтә икән, аны ул кадәр фаҗига итеп кабул итмәгез инде...

Ә, алаймы? Шул көннән Зариф укытучылар коллективын үзе өчен икегә бүлде. Дәресләренә керүне ошатмаганнарның дәрестән тыш чараларын тикшерергә тотынды. Аннары җыелышларда кайнар чыгышлар ясый торган булды. Аны мөкиббән китеп тыңлыйлар кебек тоела, андый чакларда Зариф, гадәтенчә, үз тавышына үзе соклана башлый иде.

Ә менә авыл кешеләре белән уртак телне тиз тапты Зариф. Кичен клубка бер чыгып керүе җитте. Клуб баянының тавышын тикшергән булып уйнап карады, шуңа үзе үк кушылып җырлап та алды. Ун минут үтмәгәндер, яшьләр аны түгәрәккә алган иде инде, «тагын, тагын!» дип дәртләндереп тора башладылар.

Ул кичне Зариф клуб мөдире Әхияр белән туганлашып диярлек кайтты. Аннан аерылгач та, үзе яши торган йортны таба алмыйча, авылны өч әйләнде... Кичтән дәрес планы язарлык хәле калмаган иде инде. Дәреска дә көчкә җитеште. Класска килеп керүгә, урындыкка ишелеп төште дә, теманы дәреслектән балаларның үзләренә укырга кушты. Гөнаһ шомлыгына, «үтеп барышлый» дәрескә директор сугылды. Зариф кызарынды, «безнең мөстәкыйль эш», дип акланды. Малайлар исә парта өстенә ятып пырхылдады...

...Ярый, аның ишеләре, әтисе әйтмешли, ерунда, тик менә ялгызлык изә. Керләреңне үзең уасы, үзең үтүклисе. Идәнне дә сөртми булмый – кайчак әйтми-нитми, йомыш тапкан булып, укучылар килеп керә. Беркөнне Рәисә чәчрәп чыкты:

– Абый, кая, идәнегезне юып бирик әле! – ди. Юк, ярамый. Аннары дәрестә «скидка» ясыйсы булачак бит аңа.

Ашау-эчү дә канәгатьләндерми. Мәктәп буфетында буш шулпа эчеп кайтканнан соң, үзеңә нидер әмәлләргә кирәк. Андый эшләрне элек тә өнәми иде ул.

Болар хакында зарлангач, Әхияр ике дә уйламады:

– Өйләндерергә кирәк сине, малай! – диде. – Иртәгә үк любой кызны табып бирәм мин сиңа!

Юк, «любой» кирәкми. Андыйларны башта үзеңә ияләндерергә кирәк әле.

Ул «ияләндерүләр»нең кыйммәткә төшүен Зариф яхшы белә. Аның әзер кәләше бар – ныклап торып бер сөйләшү җитә, хәзер кайтып төшәчәк ул.

...Җәмилә июнь ахырларында – җәйге сессиясен тәмамлагач кайтып төште. Авылга да, мәктәп коллективына да тиз ияләште – әллә Зарифына булган мәхәббәте ярдәм иттеме? Баш-аягы белән эшкә чумды. Йөгерә-йөгерә бара, йөгерә-йөгерә кайта. Өй эшләрендә дә Зарифына ярарга тырыша. Тик менә авыл кешеләренең атна саен диярлек мәҗлес-кичәләргә чакырып торуы гына эчен пошыра. Парлап килегез, дип дәшәләр, безнең авылда ялгыз йөрүне өнәмиләр, диләр. Җәмилә үзе дә барырга яратмый, Зарифны да җибәрәсе килми.

– Ярамый алай, аппагым! – диде беркөнне Зариф. – Җәмгыятьтә яшәп, җәмгыятьтән аерым булып булмый, – дип үзенчә акыллы сүзләр сөйли башлады. – Алар бит безнең укучыларыбызның ата-аналары. Үзеңне авыл кешеләреннән өстен кую һич тә килешә торган эш түгел!

Кайсы эш килешә, кайсысы килешми икәнен кем белә инде!

– Җырласаң җырла, түлке эчмә инде, зинһар! – дип ялынды Җәмилә гадәтенчә.

– Кайчан эчкәнем бар инде, матурым? – дип, күзләрен хәйләкәр уйнатты Зариф. – Хуҗаның хәтерен калдырмас өчен әз-мәз кабып кую эчүгә керми бит ул!

Әй, күпме сөйләсәң дә, бер сүз инде! Ахыры да бертөрле тәмамлана: мәҗлестән көчкә өйгә кайтып егылу, Зарифны ялына-ялына йокларга яткыру, аннары ярты төнгә кадәр дәрес конспекты (үзенекен дә, аныкын да!) язып утыру. Иртән көчләп-зурлап йокыдан уяту, Зарифның: «Бүтән андый хәл булмас», – дип антлар эчүе, Җәмиләнең аңа чираттагы ихлас ышануы...

Институтның кышкы сессиясенә бик авырлык белән кузгалды Җәмилә.

– Зариф, җаным, мин югында үзеңне тәртипле тота күр инде берүк! – диде. – Укытучылар арасында төрлесе бар, чебеннән фил ясап куймагайлары!

– Кайчан тәртипсезләнгәнем бар минем? Әйтеп карасыннар! Миңа җитәргә әле аларга!

Ул шулай кистереп, имән бармагын югары каратып, нык тавыш белән әйтеп куярга ярата. Андый чакта хатын да тынычланып китә.

...Шәһәрдән кайтканның икенче көнендә үк Җәмилә эшкә чыкты. Зарифны да, мәктәпне дә сагынган иде. Гадәттәгечә, хатын-кызлар белән чәй өстәле артына утырып, каникул хәлләрен сөйләшергә тотындылар. Җәмилә дә: «Минем Зариф...» – дип нидер әйтә башлаган иде, тегеләр бер-берсенә сәер генә карашып алды. Җәмиләнең йөрәген нидер тырнап куйгандай булды. Эчкән килеш күренгән микәнни, Ходаем?! Кайтыр юлда Хәлимәне куып тотты – ул кеше хәтерен саклап тора торганнардан түгел, күңелендә ни булса, шуны тота да әйтә.

– Ни... Зариф белән бер-бер хәл булмагандыр бит мин юкта? – Җәмиләнең тавышы калтыранып чыкты. Хәлимә:

– Ни булган? Белмим... Син аны унынчыдагы Рәисәдән сора, ул белә булыр, – диде дә адымын кызулатып китеп тә барды.

Кайтып керү белән иренә ташланды Җәмилә – аның мондый кызулыгын Зарифның моңарчы күргәне юк иде әле.

– Унынчыдагы Рәисәгә ни булган?

Зариф бер мизгелгә генә югалып калгандай булды. Аннары, тавышын күтәреп, һөҗүмгә күчте:

– Син дә гайбәт җыеп йөри беләсеңмени? Китче! Чирегенә «өч»ле чыккан иде, шуны төзәтергә дип өйгә килде. Ну, бер түгел, ике килде. Монда нинди

начарлык күрәсең? Ә анасы, теге Давыл Миңзифа инде, җилбердәп кереп, кызын бәргәләп алып чыгып китте. Җитмәсә, директорга барып әләкләгән. Җыен надан!

Җәмилә дәшмәде. Кеше сүзенә карап, ник чыгырыннан чыга соң әле ул? Чыннан да, ни гаебе бар монда Зарифның? Дөрес әйтә ул, көнләшәләр аннан. Көнләшмәслекме? Авыл халкының телендә гел ул, «Илһам Шакировың бер якта торсын!» дип кенә җибәрәләр. Концерт буласы көнне Әхияр өйгә үзе килеп җитә: «Җәмилә ханым, Зариф Закировичтан башка һич тә эш бармый безнең», – дип төчеләнә. Балалар да ярата үзен – дәрестән соң кайтып китми, гел аның тирәсендә кайнашалар.

Әйе, көнләшәләр аннан.

## «Кем икәнлегемне беләсеңме?»

Гәүһәриягә бишек элгән көннән йорттан тынычлык качты.

Хәер, «бала» сүзен Зарифның башта ук ишетәсе килмәде.

– Син нәрсә! Яши дә башламаган килеш! Безгә башта йорт җиткерергә кирәк әле. Директор һаман искә төшереп тора, «мәктәп фатиры яшь белгечләр өчен ул», ди. Ә син бала дисең! Каян башыңа кереп утырды ул?!

Андый чакта хатын җавап бирми, үз эченә бикләнеп тик йөри. Дөрес анысы, биш ел буена (шулкадәр вакыт узып киткән инде монда тора башлаганнарына!) Зарифның «йорт» дип сөйләнгәне юк иде. Нинди акчага җиткерсен аны? Җәмилә үзе кызык ул, мәктәптә артык эш килеп чыктымы, уйлап-нитеп тормый, беренче булып килеп ябыша. Кем декрет ялына китә, кем больничный ала, кемдер уку елы уртасында китеп үк бара... Кайчакта атнасына утыз алтышар сәгатькә җиткән чаклары да була – ике ставка дигән сүз бит ул! «Акча дип үләсең инде, – дип көлә Зариф. – Тормышның тәмен белеп яшәп калырга кирәк!» Үзе ул шул унике сәгатеннән арттырмый, алай да кичләтеп кенә көчхәл белән кайтып егыла. Җәмилә:

– Үзең йорт дисең, үзең өстәмә акча эшләү турында уйламыйсың... – кебегрәк сөйләнә башласа, җен ачуы чыга:

– Ни җитми сиңа? Тамагың ачмы? Иҗат кешесе мин, беләсең килсә! Мин эшләгәнне берәү дә булдыра алмый! Үзең шуңа риза булып кайттың түгелме! – дип тавышлана.

Кайткан иде шул, анысы хак. Баштарак мәлне Зарифы авыл сәхнәсендә чыгыш ясаганда мөкиббән китеп тыңлый иде Җәмилә. Аның өчен горурлануы бугазын каплагандай була, халыкның котыра-котыра кул чабуы колагына матур музыка булып ишетелә. Ә хәзер... шул баян тавышын ишетмәс өчен башын әллә кайларга алып качасы килә. Соңгы вакытларда иренең мәктәп җыелышларында ясаган чыгышын, имән бармагын өскә каратып: «Гаепле кеше җәзасын алырга тиеш!» – дип зур пафос белән тәмамлап куюы да саруын кайната башлады. Коеп куйган артист... Андый чакларда ни өчендер ул үзен гаепле сизә, башын аска иеп утыра...

...Бик елак бала булып чыкты Гәүһәрия. Төннәр буе йокы күрсәтми. Зариф, башын-күзен томалап, зал ягына чыгып ята. Алай да Җәмиләнең кыштыр-кыштыр кереп-чыгып йөрүе ачуын китерә. Иртән мәктәпкә кара янып чыгып китә.

Соңгы вакытта эшендә еш кына командировкалар килеп чыга башлады тагын. Җәмилә – декрет ялында, ялгызы бала карап утырудан бик алҗыган иде.

– Ник һаман сиңа кушалар аны? Башка берәү дә юкмыни соң мәктәптә? – дип ризасызлыгын белдереп алды.

– Син минем кем икәнлегемне оныттың мәллә? Нинди должностьта икәнлегемне? – дип җикеренде Зариф. – Ашыйсың килсә, анысына гына түзәсең инде!

Түзми кая барасың! Анысына да түзә, кичке концертларына да. Аларыннан Зарифны төн уртасында Әхияр җилкәсенә салып алып кайта.

– Җәмилә ханым, компенсациясе күкрәк кесәсендә. Карап алыгыз... – дип аклана.

Җәмилә, ул әйткән кесәдәге алтыга бөкләнгән зәңгәр бишлекне, чыннан да, карап кына ала да кире куя. Иртән таптыра башласа, чыдап кына тор аннары!

Беркөнне Гәүһәрияне көч-хәл белән йоклатып кына җибәргән иде, давыллап, Миңзифа апа килеп керде. Исәнме юк, саумы юк, урындыкны дөбердәтеп (баланы уята дип, Җәмиләнең коты очты) килеп утырды да төкрекләрен чәчә башлады:

– Нинди мокыт соң син, ә? Иреңнең кайда йөргәнен беләсеңме әзрәк?

Җәмиләнең йөрәге «жу» итеп китте. Кайда йөри? Нишләп йөри? Каян белергә тиеш соң ул? Бала белән өйдә утыра ич! Башына мамык тутырылганмыни, Миңзифа каршында аңгыраеп тик басып тора.

– Минем кыз янына шәһәргә йөри ул! Рәисә янына! Бер акыл кермәсә дә кермәс икән сиңа!

Ничек килсә, ул шулай давыллап чыгып та китте. Хакмы бу, нахакмы? Әгәр хак булса?.. Ничекләр яшәп бетермәк кирәк, уф!

Зариф күтәренке күңел белән, шаулап кайтып керде. «Гәүһәриям, бәгъреем!» дип җырлый-җырлый, гомер булмаганча, хәтта баланы да күтәреп алды, үчтеки-үчтеки иттерде. Җәмиләнең кәефсез икәнен сизмәде дә. Моңа хатынның тагын да ныграк ачуы килде. Сыйлап кайтарганнар, димәк... Баланы идәнгә төшереп җибәрмәгәе... Кайнарланып килде дә Гәүһәрияне иренең кулыннан тартып алды, дәшми генә кече якка кереп китте.

– Нәрсә сытылып каршылыйсың әле мине? Ирең кайтты, ашыйсы килеп кайтты... – Зариф, каты-каты басып, аның артыннан иярде. – Бәйләнәсең килә мәллә?

– Килә! – Җәмилә ярсыды. – Туйдым! Ялганыңнан да... үзеңнән дә!

– Ә, алаймы?

Ярый әле баланы караватына салып өлгергән иде Җәмилә – Зариф, бармакларын тырпайтып, аның өстенә ташланды. Уңлы-суллы биргәләде дә ишекне каты ябып чыгып китте:

– Артымнан эзләп йөрисе булма!

Бала, әсәренеп, башта беркавым тынсыз ятты, аннары ачы тавыш белән кычкырып елап җибәрде.

...«Эзләп йөрисе булма!» Әй, ярата инде шулай куркытырга Зариф! Әле студент чакта ук, нәрсәгәдер көйсезләнеп, трамвай тукталышында калдырып киткән иде ул аны. Үзе, кызулап барган шәпкә башын гына борып, шул сүзләрне кычкырды. Җәмилә үзен гаепле сизде (гомер буе шулай үзен гаепләргә яратты инде ул), бик борчылды. Зариф үзе белән бер-бер нәрсә эшләмәгәе дип шикләнде. Тулай торакка кайткач, эзләмәгән җире, сорашмаган кешесе калмады. Йокысы йокы, ашы аш булмады. Өч көн үтте микән, Зариф, берни булмагандай, аның янына үзе ялтырап килеп житте... Чияледә дә вакыйгалар нәкъ шул тәртиптә дәвам итте. Зариф көйсезләнә, чыгып югала, Җәмилә төне буе үлә-бетә аны эзли, тегесе иртән берни булмагандай кайтып утыра...

Ә бу юлы... бу юлы хатын гомерендә беренче тапкыр иренең чыгып китүенә сөенде. Калтыранган куллары белән баланы күтәреп алып, күкрәгенә кысты. «Нишлик, балам?» Әле өйләнешкәнче үк бер кул күтәргән иде инде Зариф аңа. Артыннан ук гафу үтенде. Җәмилә кичерде. Аһ, кичермәгән булса шунда! Хәзер яшь бала белән кая китә алсын соң инде ул?!

## «Юк», дип әйтергә дә кирәк...

Соңгы араларда Зариф белән мәктәп директоры арасында әледән-әле низаг чыгып тора. Беркөнне кабинетына алып кереп сөйләште.

– Беренчедән, сез клуб работнигы түгел, ә мәктәп укытучысы, – диде, үзе кулындагы карандашы белән өстәлгә бәреп-бәреп алды. – Ә сез укучыларыгызга нинди үрнәк күрсәтәсез? Ата-аналардан да туктаусыз жалоба килә! Тегендә эчеп егылган, монда кәмит күрсәтеп йөргән...

Зариф аңа кызыл чүпрәк күргән үгез шикелле карап утырды. Кем соң әле син миңа акыл сатарга? Ярар, урынбасарлыктан алдың инде, үз дигәнеңә ирештең. Аңа карап, халык алдында абруем кимедеме әллә? Юкса, үзешчән сәнгатьтә ничә еллар буе алар мәктәбе гел беренче урында булды – Зариф исеме район башлыклары теленнән төшмәде.

Әлегә ул шулай эченнән генә кайнап утырды. Менә-менә тагын бер сүз...

– Икенчедән, мәктәп фатирын кайчан бушатасыз? Хатыныгыз киткәнгә дә бишбылтыр. Анда гаиләле яшьләр керергә тиеш – ничәнче кат исегезгә төшерәм инде...

Монысына Зариф түзмәде, «ялт» итеп урыныннан сикереп торды.

– Фатирың да кирәк түгел, мәктәбең дә! Иртәгәдән күрмәссең монда мине! Артымнан үзең эзләп килерсең әле!

Директор селкенмәде дә. «Ә» дә, «җә» дә димичә, шул халәттә утырып калды.

...Бөтенесенә әнисе гаепле! Артист булырга тиеш иде ул, монда балалар көе көйләп йөрергә тиешле кеше түгел иде! Шушы караңгы авылда талантын күмеп куйды, үзе бер кирәксезгә әйләнде. Җәмиләсен әйтер идем! Эт шикелле үзе ияреп килде бит ул монда, аңа ялынган кеше бар идеме? Кеше булды да ташлап китте. Кул күтәрәсең, дип елады. Хатын-кыз белән шунсыз буламыни? Баланы берүзем тәрбиялим, дип тә зарланды. Ничек берүзе? Ун яшькә кадәр бергә үстермәделәрмени аны? Артыннан ялынып килер дип уйлагандыр инде. Аннан башка тормышы бармас дип куангандыр. Юк! Тайгага кереп адашса да, ачтан үлә торган түгел Зариф абыең! Горур кеше ул!.. Хәер... Җәмилә китмәсә, бу көнгә төшмәгән дә булыр иде, мөгаен...

Шундый буталчык уйлар эчендә бара Зариф. Автобус сикертеп куйганда уянып киткәндәй була да, тагын шуларга кире кайта. Ялынып бармаса да, шәһәргә килгәндә керә ул Җәмилә янына. Шәһәр читеннән йорт сатып алган – туганнары булышкандыр инде. Үзе шуннан ерак түгел мәктәптә укыта. Гәүһәриясе – төс-кыяфәте белән өзелеп төшкән Зарифның үзе. Кечерәк чагында җырларга да яратты, тик Җәмилә гел тыеп килде: «Атаңа охшамагаең!» – дип, Зарифның үзе алдында ук кисәтеп куя иде.

Ә нәрсә! Тотарга да, Җәмилә янына барып, бөтенесен сөйләп бирергә! Хәер, бөтенесен дип... Кирәклесен генә инде. Үпкә-сапкаларны онытырга вакыт. Ахыр чиктә, рәсмиләштереп аерылышмаган да әле алар. Авырлык килгәндә, ир – хатынга, хатын иргә булышырга тиеш...

Күптәннән күрешкәннәре юк иде инде – Гәүһәрия җиткән кыз булган. Әүвәлге шикелле алдына утыртып ярата да алмады. Кызы аны чит тә итмәде, авыз тутырып «әти» дип тә әйтә алмады. Килгән саен «кунак абый» итеп кенә карады.

Җәмилә дә җитдиләнгән. Әллә олыгайганмы? Йөзендә бернинди җылылык юк, Зарифны да эшлекле кыяфәттә тыңлап утырды.

– Булгандыр инде гаеп икебездә дә... Ялгызлык рәхәт нәрсә түгел. Сезгә дә шулайдыр. Үз йортыгызда торгач, монда да ирләр кулы кирәктер...

Шул урында Җәмиләнең йөзендә мыскыллы елмаю чагылып киткәндәй булды. Зариф түзде, кабынып китүдән үзен тыеп калды. Ярамый хәзергә... Эшне бозып куюы бар.

– Синең шәһәргә күчеп килү теләгең бар, димәк. – Җәмилә авыр сулап куйды. – Нәрсә дим, торып карарсың инде – урамга куып чыгарып булмас. Ну белеп тор – элекке гадәтләреңне авылда калдырып килгән булсаң гына...

Зариф эченнән генә тантана итте. Сиздe бит ул Җәмиләнең аны кабул итәчәген. Белмәссең, шушы көн җитәчәген көтеп тә торгандыр әле. Холыкны үзгәртеп булмый – килеп-китеп йөргәндә дә ашатты, эчертте, өстен-башын да карап чыгарды. Чын мәхәббәт дигәннәре шулдыр, мөгаен. Зарифның үзенә андый хисләр ят булды инде...

Икенче көнне туп-туры үзе укып чыккан институтка китте – теге вакытта профком рәисе булып торган Хәниф Хатыйповичның күптән инде шунда декан икәнлеген белә иде. Кем белә, иске дуслык хөрмәтенә ярдәм итеп куймасмы әле...

Хәниф Хатыйпович аны колач җәеп каршы алды.

– У-у... Ничә җәй, ничә кыш! Яле, яле, карыйм әле үзеңә... Тукта, болай гына булмас, күрешү хөрмәтенә... – дип шкафына үрелә башлаган иде, Зариф туктатты:

– Юк, юк, Хәниф Хатыйпович! Күрешкән чаклар булыр әле. Мин менә киңәшим дип кенә сугылдым сезнең янга.

Шул минутта үзенә шаккатты Зариф. «Юк» дип әйтә алуын күр син! Кирәк чакта булдыра ала икән бит. Җәмилә өйрәтеп чыгарганга гына түгел инде бу, язмышың кыл өстендә торганда, түзеп була икән!

Мәсьәлә ул көткәннән дә әйбәтрәк хәл ителде – Хәниф Хатыйпович аңа беренче курста тарих сәгатьләре тәкъдим итте.

– Мәктәп стажың җитәрлек. Синең эшкә җитди карый торган егет икәнлегеңне яхшы беләм. Ну башка өлкәдә дә деканат эшендә актив катнашырсың дип ышанам...

Аның яныннан чыкканда, Зарифның күңеле тулы кояш иде. Бар ул яхшы кешеләр! Чияле директоры үзен дөньяның кендеге дип исәпләп ялгыша! Менә күрсәтсен әле ул аңа! Синең укучыларың ук килмәсме минем янга укырга кертергә сорап. Менә шуннан соң карарбыз...

## «Әле син алаймы?!.»

– Озакка килгәнме соң ул безгә?

Әллә ничә кабатлады инде Гәүһәрия бу сорауны. Җәмилә дәшми, авыр сулап куя да икенче якка чыгып китә.

Урамга куып чыгара алмый бит инде ул аны! Ни әйтсәң дә, күпмедер гомер иткән ире. Өметсез – шайтан, ди, кем белә, акыл утыртып та килмәде микән әле? Эшкә дә урнашып кайткан әнә.

– Соң, атаң бит ул синең! – диде аннары, кызының кара коелып йөрүеннән туеп. – Элек эти ник безнең белән түгел, дип аптыраттың. Инде болай да ярамый. Аптыраш...

– Элек кирәк иде ул! Азып-тузып беткәч, килеп егылды. Хурланмыйсың дамы?

– Җәллим... Торып карыйк, аннан күз күрер...

Урам як тәрәзәсеннән Зарифның җил-җил атлап кайтып килүе күренде.

Әнә бит, бәхетеннән ташып тора. Ничек күңелен сүрелдерәсең инде аның?

Ул сүзендә торды – хәмер дигән нәрсә онытылды, дус-ишләрен җыеп кайту гадәтен мондагы йортка гомумән кертмәде. «Арткы як койма ишелергә тора, кыш чыгу белән рәтләп куярга кирәк», – дип тә сөйләнә башлады. Беренче хезмәт хакын, кош тоткандай, Җәмиләгә кайтарып бирде.

Тормыш җайлануга таба китте. Моңа Җәмилә генә түгел, хәтта Зариф үзе дә ышана башлаган иде. Шәһәргә йомыш белән килгән Әхияр харап итте. Ничек

эзләп тапкан диген – Зарифның лекциясе бетүен коридорда көтеп торган. Кочаклашып күрештеләр.

– Вәт мала-ай! Борыннарына чирттең син безнекеләрнең! Институтның үзенә килеп бит!

– А как же! Чияле – дөньяның кендеге түгел лә ул!

– Авылда сине сорашмаган кеше юк, үзем барып күрим әле, дидем.

– Сәлам әйт бөтенесенә дә!

– И уындылар син киткәч. Бер эшләре бармый. Кире кайтыр дип көткәннәрдер инде.

Арттыра инде Әхияр, Зариф моны белми түгел. Шулай да матур сүз ишетү колакка рәхәт.

– Ни... Өйгә чакырыр идем... – Җөмләсенең ахырын уйлап бетермәгән иде, Әхияр үзе бүлдерде.

– Юк, юк! Моннан вокзалга ике адым, шуннан гына кайтып та китәрмен. Вакытың булса, әйдә, озат, алайса...

Кереп кенә чыгабыз диешкәннәр иде, кич җиткәнче утырдылар вокзал ресторанында. Әхияр сыйлады. Анысы яхшы булды, Җәмиләгә отчёт бирәсе булмаячак...

Ничек чыктылар алар рестораннан (әллә чыгардылар микән) – менә монысын хәтерләми Зариф. Әхияр белән ничек аерылышуларын да белми. Айныткыч эскәмиясендә җилкәсен ду китереп селкетүдән уянып китте.

– Тор! Хатының килеп җитте, әнә, топай өеңә!

Хатының килде, диме? Ник килгән? Кем чакырган аны?

Өстерәлеп кенә торып басты, ишеккә таба юнәлде. Анда, дөрестән дә, Җәмилә басып тора иде.

– Ай-яй, әтәчләнеп тә карады! Сез минем кем икәнемне беләсезме, дип янады. Кем соң ул?

Җәмилә айныткыч хуҗасына җавап биреп тормады, кулын гына селтәде.

Зариф бер карышусыз хатыны чакырткан таксига чыгып утырды. Юл буе бер авыз сүз сөйләшмәделәр. Кайткач, Зариф акланмакчы булып авызын ачкан иде, Җәмилә туктатты:

– Аннары. Юын, ял ит, айны...

Иртән сүз каты булды. Җәмилә элекке елак хатын түгел иде инде.

– Соңгы сынау сиңа. Торыр урыныңны алдан әзерләп куй. Тагын бер генә тапкыр кабатласаң да, бу йортка юлыңны ябык дип бел.

Ә-ә, әле син алаймы?! Зариф айнып җитмәгән иде, башында ботка әйләнә иде. Җилфердәп торып басты – чак әйләнеп барып төшмәде.

– Тукта, тукта... Син үз теләгең белән керттең түгелме мине монда? Керттең. Чөнки икебезнең дә паспортта пичәт бар. Бармы? Дөрес түгел диген... Димәк, син – минем хатын, мине карарга тиеш. Бу йортта пропискада тораммы? Торам. Анысын да үзең яздырдың, мин мәҗбүр итмәдем. Шулай булгач, хакың бармы синең минем белән алай сөйләшергә?!

Кара син аны, кеше булган бу хатын! Чияледә ничә ел буе аңа дип бирелгән фатирда яшәп ятты, Зариф хакына дип эшен дә таптылар. Ә хәзер Зариф хәтле Зариф белән, күр, ничек сөйләшә! «Ирсез хатын – йөгәнсез ат» диюләре хак! Күптән кулга алырга кирәк иде моны, килеп-китеп кенә йөргәч, артык иреккә чыккан бу!

Хатын, кулын селтәп, күптән аның яныннан чыгып киткән иде инде. Зариф кулларын болгый-болгый тагын бераз йөренде дә караватына йөзтүбән килеп төште.

## Кем гаепле?

Арзанлы туны эченә башын яшерә төшеп, таеп егылудан курка-курка гына, бозлы сукмактан Җәмилә атлый. Өйләре турысына килеп җиткәч, туктап, хәл алды. Күзләре белән капка янындагы аяк эзләрен тикшерде. Кайтмаган булса кирәк – эзләр күп, капка төбе чуарланып беткән, электән калгандыр. Ярар, ул юкта ятып, ял итеп алыр, ичмасам. Хастаханәдә врачка керү өчен чират иде, ярты көне бер мәгънәсезгә шунда үтте.

Соңгы арада кан басымы күтәрелеп, йөрәге кысып азаплый. Врач язган дару төймәләренең дә бер файдасын күрми.

– Ничек файдасы булсын, гел өстәлеп торгач! – дип тирги аны Гәүһәрия. – Гомерең шул алкашның көен көйләп үтте. Гарип-гораба түгел бит ул! Самолюбиең бер дә юк инде, әни, абау! Ничек туймыйсыңдыр!

Туймаган кая! Тик нишләтсен соң инде ул аны?! Авылдан килеп тора башлаган мәлендә: «Гаилә җылысы күргәнем юк минем», – дип зарлана иде. Миннән калмасын, дип, кадер-хасияттә яшәтергә тырышты Җәмилә. Булмады, барыбер ычкынды. Башта сирәк-мирәк кенә эчкәли иде, торган саен ешайта барды. Бөтен Чияле яшьләрен институтка кертеп бетерде бугай инде. Алар бит буш кул белән килми, әрҗәләп шәраб ташыйлар!

Аптырагач, чыгарып җибәрергә дә маташып карады. «Ә-ә-ә! Кумакчы буласыңмы? Бер көн дә тормыйм, үзем китәм! Яшә шунда үзең генә, артымнан эзләп йөрисе булма! Чияледә любой хатын колач җәеп каршы ала мине!» – дип җикеренә иде дә ике көннән, берни дә булмагандай, янә кайтып утыра иде. Читенсенүнең әсәре дә юк! Җәмилә түзә инде, ул шулай яратылгандыр, күрәсең. Менә институтында ничек түзәләр икән?

– Әни, неужели һаман яратасың син аны? – дип гаҗәпләнә Гәүһәрия. Үзенең кияүгә чыгуына да хәйран булды инде, терекөмеш шикелле малае үсеп килә. – Мин иремә үземнең яратуымны сиздермим, эти шикелле муенга менеп утырыр аннары, – дип акыл да өйрәтеп куя.

И кызыкаем, нинди ярату ди ул! Мәхәббәте күптән янып көлгә әйләнгән инде. Аның урынында нәфрәттән башка берни юк. Тагын... кызгану бар. Чыгарып җибәрсә, сукбай шикелле тегендә кунып, монда теләнеп йөриячәк бит ул. «Дуслары» күп, әле дә «тегендә аунап ята иде», «монда эчеп утырганын күрдек», дип, гел ирештереп торалар.

Беркөнне Зарифның балачак дусты кереп чыкты. Җәймәгә төреп, гармун күтәреп килгән. «Моны миңа әниең сакларга биргән иде, – ди. – Мин үлгәч, үзенә тапшырырсың, дигән иде. Аннан соң да илтергә җай чыкмады. Тиз генә барып җитә алмадым, гафу». И сөенгәннәре инде Зарифның, салмыш кайткан чагы иде, гармунын үбә-үбә елады. Бер дә кулыннан төшергәне юк хәзер. Шуның тавышын ишетмәс өчен Җәмилә еш кына кызларына китеп котыла.

Шуларны уйлый-уйлый, хатын озак кына кесәсеннән ачкычын эзләде. Тапкач, йозак тишегенә туры китерә алмый азапланды – куллары тыңламый, тора-торса гел калтырана башлыйлар шул. Ул арада ишек үзеннән-үзе ачылып китте – бикләми китте микәнни? Шулай үз-үзен битәрли генә башлаган иде, эчтән шаулашкан тавышлар ишетеп, тынып калды. И, Ходаем! Тагын...

Керде дә, чит йортка эләккәндәй, тукталып калды. Өстәлгә күз ташлады – аракы, сыра шешәләре, ачылган консерв банкалары... Табасы белән кыздырылган күкәй менеп кунаклаган... Ә кунаклар кем? Зарифның үзеннән башкалары – яшьләр: бер егет, ике кыз.

Бер мизгелгә тынлык урнашты.

– Бәрәч! Синең... онык карарга бара торган көнең түгел идемени бүген? Кунып кайтам, дигән идең...

Зариф хәйран «оешкан» иде, сүзләрен әвәләп кенә сөйләште. Кызларына бара торган көне иде шул – исерек булса да, анысын хәтерли тагын. План үзгәрде, Җәмиләгә врачка барырга туры килде – менә анысы хакында сине кисәтергә оныттым шул, җаным...

Хатын агарынды, җилпенеп, өстәлгә турылап китте. Аның хәрәкәтеннән шикләнеп калган Зариф аркылы басты:

– Чү, чү, сиңа артыгын кызуларга ярамый... Нервыланырга да... Менә, студентларым зачёт бирергә килде. Монда минем ни гаебем бар?

«Гомер буе бер гаебең дә булмады синең, Зарифкаем. Бөтен гаеп – минем үземдә. Сине үземнән артык яратуымда. Гафу, барыбер кеше итә алмадым...» Җәмиләнең башына килгән соңгы уе шул булгандыр, мөгаен. Ул җан ачысы белән эскәтерне йомарлап тотты да үзенә таба сөйрәде. Савыт-саба, шалтырап, аның өстенә ишелде...

## Соңдыр шул, соңдыр...

Базар кайный иде. Шагыйрь әйтмешли, кемдер алдый, кемдер алдана... Зарифның боларның берсендә дә эше юк. Фанер әрҗәсен җайлап урнаштырып, гармунын ачты. Утырды, шыңгырдатып алды. Тавышы бозылган дип әйтимме... Бүген салкынча шул. Үзенең дә тамагы әчетеп тора. Гармуны белән икәүләшеп чирләп китмәгәйләре.

Гадәтенчә, «Сарман» көеннән башлады. Җырлап та җибәрмәкче иде, төртелеп калды. Юк, бусы булмый. Көннән-көн авырлаша бара анысы. Тавышы ыңгырашып чыга. Берәү үзенә үк килеп әйтте: «Абзый, уйнасаң уйна, түлке җырлама гына», – диде. Әйтсә әйтер, тамагын туйдырырга ярап куя әле ул.

Шул урында аның исенә кабат әнисе килеп төште. Тамак туйдыра торган үнәр түгел, дигән идеме әле? И әни, менә шуның көненә калды бит инде улың. Гармун булмаса, нишләр иде хәзер?

Бераздан аның янына сәләмәгә төренгән тагын берәү килеп төртелде. Көн саен шулай. Зариф аның исемен белми, бер-берсенә «яшьти» дип кенә дәшәләр. «Яшьти» аның янына бүтәннәрне якын җибәрми, сатучылар тиргәнә башласа да, күкрәген киереп, аны якларга торып баса. «Тән сакчың мин синең», – дип, тешсез авызы белән кетер-кетер көлә. Зарифка кайнар чәй дә алып килә. Пластик стаканда җыелган тиеннәрне дә ул санап бара. Кичен шуларны тотып, базар артындагы арзанлы кафега тамак чылатырга кереп китәләр...

Бүген салкынча. Зарифның бармаклары туңа башлады. Ул гармунын шыгырдатып япты да торып басты. Аякларны язып алырга кирәк...

Бусы кем тагын? Нәрсә дип аңа текәлеп каткан? Булса, акчаңны сал да, торма монда ачу китереп...

Уйлап кына калмыйча, сүзләрен кычкырып әйтмәкче иде, теге кеше аңа тагын да якынрак килде.

– Син дә кебек, син түгел дә... Ялгышсам, ачуланма берүк...

Зариф аңа күзләрен кысыбрак карады. Бә-әрәч! Әхияр бит бу!

– Каян килеп чыктың әле син?!

– Чыктым менә! Баядан бирле тыңлап торам... Безнекеләр күреп кайткан булган сине. Әйткәч, ышанасым килмәде. Булмас, аңа охшаган гынадыр, дим.

Зариф тураеп басты. Һе, ышанмаган, имеш! Аның кебек тагын кем шулай уйный алсын инде!

«Яшьти» тынычсызланды, бер алдына, бер артына төшеп, Зарифны танышы янынннан читкә алып китәргә маташты.

– Туктале син! – Әхияр аңа ачуланып дәште. – Торма әле күз көеге булып! – Аннары пластик стаканны җирдән иелеп алды да андагы бер уч тиен акчаны чыштырдатып тегенең кесәсенә бушатты.

«Яшьти» күзләрен чепелдәтеп Зарифка карады. Тегесе кулын гына селтәде. Миннән башка гына бар, янәсе. Бүген аның тамагы болай да тук булачак.

– Болай итәбез... Сиңа әйтер сүзләрем күп, Зариф туган. Синең өйгә кайтып буламы? Булса, кибеттән тегесен-монысын җыеп чыгабыз да...

«Тегесе-монысы» арасында бер генә шешә дә шәраб юк иде. Зариф тоташтан кара коелды. Ичмасам, пластик стакан да «яшьти»дә китте.

– Тукта, ярсыма әле, дус кеше. Бер генә кичкә килгән кеше мин. Түз. Аннары үзеңә карарсың.

Түзми нишлисең? Зариф Әхиярның өстәл әзерләгәнен иреннәрен чәйни-чәйни карап торды.

– Менә, кайнар чәй йотып җибәр. Өшеп үләсең бит син анда.

Зариф бераз тынычланган кебек булды. Әхиярдан авыл хәлләрен сораштырды. Тик аның сөйләгәннәре бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты.

– Үзең ничек?

– Ник, күрдең бит инде ничек икәнне... Хатын вафат, бишенче елга китте. Кыз ташлады, үзе дә килми, барсаң да кертми. Эштән кудылар. Пенсия акчасын санап кына бирәләр. Ашарга да җитми. Кызыкмы? Менә шундый көнгә төште Зариф абзагыз. Ә кем идем мин, ә?!

Зарифның борыны мышкылдады, күзләре яшьләнде. Җәмилә исән булсамы?! Үзен карамады шул, балалар дип чапты. Ул исән булса, мондый көнгә төшмәгән булыр иде...

Әхияр аны күрмәмешкә салышты.

– Авылда мәчет салдырдык, – дип, сүзне икенчегә борып сөйләп китте. – Үземне мулла итеп куйдылар. Шәһәрдә укып кайттым. Ну мин элек тә белми түгел идем.

Зариф башын күтәрде, Әхиярга акаеп карап куйды. Әйттерерсең әлләни! Син дә булдыңмы мулла!

– Мин сине махсус эзләп килдем. – Әхияр аның мыскыллы карашын күрмәмешкә салышты. – Яхшылыкларың күп тиде. Әйбәт кеше иде, әрәм була бит, мин әйтәм.

Зариф үзен тагын жәлләп алды. Борыны кабат юешләнде.

– Торыйк иртән. Мунча ягып керик. Мин карап килдем – монда мәчет ике йорт аша гына икән. Барып килик.

Зарифның дәшми утыруын күреп, Әхияр тагын да дәртләнеп китте, аның салпы ягына салам кыстырырга тотынды.

– Теләсәң, булдыра торган кеше син. – Монысында Зариф тураеп ук утырды. – Мин булып мин эшли алганны. Син бит укымышлы кеше, зерә әрәм булып йөрисең. Менә бер генә кереп кара әле...

...Ап-ак карны шыгырдатып, урам сукмагыннан Зариф атлый. Мәчеттән кайтып килеше. Теге көнне Әхиярның бер алып керүе җитте – күңеле йомшарды, җанына тынычлык инде. Базарга йөргән чакларын хәзер чирканып искә ала. Шул шыксыз вакытларны хәтерләтеп тормасын дип, гармунын да ераккарак яшереп куйды. Йортка хәмер кермәгәнгә дә байтак. Сәрхуш дуслары да кайсы кая таралып бетте.

Ул айныды. Ләкин югалтасын югалтып бетергән иде инде...



Фирүзә
Җамалетдинова

# ҖИР ШАРЫНА ӘЙЛӘНҮЛӘР ТЕЛӘ

## Ана йөрәге

Юллар киң  дисеңдер, дөнья киң дисеңдер,
Улкаем, артыңнан җил көчкә өлгерә.
Мин сине гомергә җилләрдән сакладым,
Машинаң алдыннан йөрәгем йөгерә.

Юлларда кешеләр уйсызмы, гамьсезме,
Юлларда кешеләр тизлеккә тарыган.
Әниең йөрәге, улкаем, белсәңче,
Машинаң алдыннан йөгереп арыган.

Юлларда кешеләр тизлеккә тарыган,
Күкләрме эндәшә: «Аллаһ бар, син белмә!»
Җилләрне өзгәләп барганда, уалыр,
Син минем йөрәккә, улкаем, бәрелмә...

Син чорга бәрелмә, шул йөрәк белән бит
Халкымны, аннары телемне якладым.
Һәм сине, улкаем, давылдан яшердем,
Югыйсә гел алкын яшьлекне акладым.

Син моны белмисең, күңелең – далада,
Хәер, бар микән соң белүнең кирәге?
Гомереӊ буена алдыңнан йөгерер,
Яшәвең сагында – әниең йөрәге.

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА – *шагыйрә, прозаик; «Тулымлы ай», «Җирбизәк», «Хикәяләр» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

## Җеп суздым

Кисмәдем кеше юлларын,
Юл бирдем җилләргә дә.
Рәнҗеш төшмәсен дип, риза
Мин әллә ниләргә дә.

Сүземнән җирдә беркемнең
Таммады тамчы яше.
Диңгездәй түгелде яшем...
Инде тып-тыныч яшим.

И заман, син явызлана
Барасың икән никләр?
Мин җил тидермәм гөлгә дә,
Өемә куйдым бикләр.
Уйларыма сакчы – шикләр,
Җаныма куйдым чикләр.

Язмышны узып булмый, ди,
Барыбер уздым бит мин.
Үрмә гөлгә дә үрелер
Өчен җеп суздым бит мин...

## Ап-ак сагыш

Сагышларның, ап-ак сагышларның
Аклыгыннан башлар әйләнә.
Син еракта.
Үз яныңа бүген
Чакырма син мине, әйдәмә.

Ни аңлаткан безгә ап-ак кышлар,
Бураннары нидер сөйләгән.
Сагышларның, ап-ак сагышларның
Патшалыгын җаным биләгән.

Ак хатирә мине эзләп килә,
Ак бураннар таба төшләрдә.
Ап-ак сагыш сибә чәчләремә,
Ак салкынлык тия тешләргә.

Адашканнар хисләр, төсләр, сүзләр,
Сагышланган шуннан йөзебез.
Ап-ак хатирәләр адашмаган,
Адашканбыз бары үзебез...

## Телә!

Күз яшьләрең җиргә сеңгән кебек,
Югалыр көн, җанны телә-телә.
Хисләреңә йөгән тапмаганда,
Җир шарына әйләнүләр телә!

Карашларың җиргә кадалган күк,
Меңләп уең бер юл тапмый килә.
Чишмәләр дә дәрьяларга коя, –
Җир шарына әйләнүләр телә!

Без – аста, дип кояш күрми йөрмә,
Өскә карап яшә көлә-көлә.
Заманалар ябык, яхшы ат юк?.. –
Җир шарына әйләнүләр телә!

Үз урынына куя бара Вакыт,
Үз урының кайда? Йә кем белә?
Ә киләчәк хак дөресен әйтер, –
Җир шарына әйләнүләр телә!

Һәммәсе дә фани ласа Җирдә,
Яхшы-яманнарга Вакыт бүлә.
Аңлау кирәк шуны! Ышан да син,
Җир шарына әйләнүләр телә!

## Минем язмыш

Елаганмын, әллә белеп инде,
Елаганмын әллә белмичә.
Әнием дә янда гына булган,
Әнкәй бер ул, түгел берничә.

Елаганмын, бәлки бәхеттәндер,
Көннең сөйгән мине кайнары.
Каты куллы язмыш шул мәлдә үк
Эләктереп алган аннары.

Мин шул мәлдән язмышымның колы,
Бер карусыз үтим кушканын.
Минем язмыш сөйми җир өстенең
Икейөзле, явыз, куштанын.

Минем язмыш үз юлыннан йөртә,
Ә юллары чокыр, баткаклы.
– Кеше күзенә туры карарга, ди, –
Кем туры юл салса, шул хаклы.

Еламыймын күптән. Юлымдагы
Чуерташтай каткан күз яшем.
Күңел генә йомшый бара һаман,
Пышылдыймын һаман: «Мин яшим!»

Әнкәм барда бала булып яшим,
Илем барында мин кешемен,
Эшләр эшем һич төшемле түгел,
Кемнәр белсен гомер төшемен?!

Бар да гади, бар да кешечә тик.
Бәхет бирим диеп колыма,
Аллаһ мине сөеп яраткан да,
Яшәтергә теләп тапшырган ул
Каты куллы язмыш кулына.

Һич җибәрми карыш-карышма,
Мин рәхмәтле шушы язмышка!

## Мин игелек чәчтем

Беркатлырак булып яшәлде шул,
Аермадым дустан дошманны.
Аермадым, елмайдылар миңа,
Күңелдәнме, әллә тыштанмы?

Мин игелек чәчтем җир өстенә,
Күз нурымны түктем сүзләргә.
Нәрсә диим, явызлыкка таргач,
Ниләр диим икән сезләргә?

Яманлыктан мин яхшылык эзлим,
Бер очкыны булыр яхшыга.
Шул бер очкын дөрләп китәр дә күк,
Әверелер кинәт яктыга.

Шул яктылык яшәтәчәк безне,
Шул яктылык төшәр дошманга.
Һәр караны агартасым килә,
Минем бары күңел кушканга.

Яктылыкны ябыйм җаннарына,
Яулык итеп ябыйм, йә шәлме?
Их, хәерле булсын!
...Аермадым дусны дошманнан һич,
Беркатлырак булып яшәлде.

## Хатирә

Дөмбер-дөмбер... Ерак-еракларда
Офыктамы күкләр күкрәде.
Кайлардадыр, димәк, яңгыр ява,
Иркен сулар җирнең күкрәге.

Дөмбер-дөмбер... Ерак-еракларда
Яшәүләргә ялгар бу яңгыр.
Хәлсезләнеп, сусап, табигатьнең
Күзен йомган гөле уяныр.

Дөмбер-дөмбер!.. Баш очымда күкрәү!
Күкләремне яшен-ут телде.
Җаннарымнан нидер кыйпылды да,
Сискәндереп нидер өзелде...



Наилә
Харисова

# ЭССЕ ҖӘЙНЕҢ УН КӨНЕ

БӘЯН

### БЕРЕНЧЕ КӨН

И Раббым! Хәерле көннәр кыл! Бәндәләреңне рәхим-шәфкатеңнән ташлама! Үзең җибәргән бу эсселеккә түзәргә сабырлыклар да бир инде.

Сабира, болдырдан төшеп, абзарга юнәлде. Кояш күтәрелеп кенә килә, ә үләндәге чык инде кибеп өлгергән. Бер тамчы яңгыр төшмәгәнгә айдан артты. Һавада да дым калмагандыр. Абзар ишеген ачуга, йөзенә парлы җылы һава килеп бәрелде. Хатын тиз генә талгын су алып кереп, сыер алдына салды. Аның йотлыга-йотлыга эчкәнен кызганып карап торды.

Малкайларга бигрәкләр авыр шул. Кешеләр теләгән чагында күләгәгә кереп, сусаганда су эчеп, авыр булса да, бу чилләкызуыннан кача ала. Ә маллар үзләренә хуҗа түгел.

Сабира сауган сөтенең өстен генә каплады да, урамда чыбыркы шартлаткан тавышны ишетеп, абзар ишеген ачты. Сыер белән тана ашыкмый гына урамга юнәлделәр. Капка төбендәге чирәмне чемченеп караганнар иде дә, авызга керердәй яшеллек таба алмагач, гадәтләнелгән сукмактан авыл башына юл тоттылар. Сабира карашы белән малларын борылышка кадәр озатты. Капка янында баскан килеш, бераз урамга карап торды. Көтү куучы сирәк. Берничә йорттан гына мал чыкты. Элек көтү куу үзе бер йола иде. Урам башына кадәр озату мәҗбүри булмаса да, авыл халкы малына ияреп бераз баргандай итә, күршесе белән тегесен-бусын сөйләшә, хәл-әхвәл сораша, төн эчендә туган яңалыклар белән таныша иде.

Мал асрардай кешесе дә кимеп бара бит аның авылда. Саный китсәң, авылда йә карт-коры, йә риэлторлар китереп тутырган шәһәр ялкаулары. Аннан тыш ата-анасы белән яшәп картая баручы берничә егет-җилән, колхоз эшеннән башканы белмичә, кияүгә чыга алмый калган берничә карт кыз белән ирдән аерылып кайткан хатын. Ул ялгызлар, болай да катлаулы дөньяда тагын ир хатыны мәшәкатен дә тартмыйм әле дип, сыңар канатлы булып яшәүне өстенрәк күреп гомер итә бирәләр. Пенсиягә чыккач, авылга кайтып төпләнүче

---

Наилә ХАРИСОВА – *чәчмә һәм тезмә әсәрләр иҗат итүче укытучы; «Агымсулар ни сөйли?» (хикәяләр), «Гомер йомгагын сүтәм» (шигырьләр) дип аталган ике китап авторы. Әгерҗе төбәгенең «Күңел чишмәләре» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, 2009-2015 елларда аның җитәкчесе була. Әгерҗедә яши.*

берничә гаилә бар барын. Ә авылда җир җимертеп эшләүче, үзен авылда хуҗа итеп тоеп дөнья көтүчеләр сирәк, ай-һай сирәк!

Сабира өйгә кергәндә, ире Мидхәт торып чәй куйган, өстәл янында ипи кисеп тора иде.

– Бүген көтүгә кем чыкты? – диде, эшеннән аерылмыйча гына.

– Әхтәмнекеләр иде бугай.

– Балалары кайтты микән, берәрсен яллаганнармы?

– Кичтән Чаллыдагы малайларының кайтып туктаганы күренде, шул чыкмады микән?!

– Әхтәмнекеләр авыл юлына тузан төшерми. Миһербанлы балалар булып үстеләр. Узган атнада Маратлары кайткан иде. Аның белән сөйләшеп тордык. Авылны сагынам, Мидхәт абый, кайтып шушында гына төпләнер идем, үземә берәр шөгыль дә табар идем – балаларга бигрәк бернәрсә дә юк бит, ди.

– Мәктәп булып мәктәбенә кадәр бетерделәр бит. Коллективы унбиш кешедән артмаган мәктәпне башлангычка калдырып, зур экономия ясаганнардыр инде, адәм тәганәләре, – диде Сабира, ярсый төшеп.

Мидхәт, бу темага сүз башлап, дөрес эшләмәгәненә төшенде, тиз генә теманы алыштырырга тырышты. Гомерен мәктәпкә багышлаган хатынын бик яхшы аңлый ул. Оптимизация дип, гөрләп торган мәктәпне бетереп, унбер яшьтән балаларны күрше авылга йөреп укырга мәҗбүр итәләр. Авылдан бертөркем ата-ана кулларыннан килгәнчә көрәшеп караганнар иде дә, кая ул! Хакимияттә «чебен дулап тәрәзә вата алмаячагын» әйбәтләп аңлатып җибәргәннәр. Мәктәп директоры, үзенең туган авылында директорлык тәкъдим иткәч, сөенә-сөенә китеп барды. Монда ник мәктәпне бөтенләй ябып куймыйлар – исе дә китмәде. Райондагы бер мәктәпне бер елга булса да яптырмый калдыра алган директор турында сөйләделәр. Аларныкы яптырмаска тырышып та карамады.

– Килмешәк – килмешәк инде. Аңа синең авылың ни дә, балаларың ни, – дип, авыл халкы гөжләде-гөжләде дә ахырдан язмышына буйсынды. Салонында солярка исе аңкып торган автобуслары күпмегә чыдар тагын.

Шушы хәлдән соң берничә яшь гаилә авылдан күченеп китте. Кайсы – мәктәпле күрше авылга, кайсы – шәһәргә үк.

– Балык – тирән суны, кеше яхшы җирне эзли, диләр бит инде. Ата-баба нигезе дип авылга ябышып ятучылар юк хәзер.

Авыл киләчәге турында иртәнге сөйләшүләр, гадәттә, шундыйрак рухта тәмамлана.

– Әнисе, мин, болындагы эшләрне оештырып җибәргәч, районга кереп чыгармын. Югалтма. Ихсанны озак йоклатма. Көн кызуында бәрәңгене эшкәртеп кайтсын. Тагын бер-ике көнгә соңласак, тырпаеп торган сабактан башка берни дә калмаячак.

– Ярар, әтисе, исән йөр. Вакытың булса, мәгариф бүлегенә кереп, белешеп чык әле: ремонтка буяу кайтмадымы икән?

Сабира, гараж ишеген ябып, ирен озатып калды. Өйгә кереп киткәненә күп булса ярты сәгать вакыт үткәндер, ә кояш шул арада никадәр биек үрмәләгән. Иртән иртүк кыздыра. Күктә кулъяулык кадәр дә болыт кисәге күренми. Иртәнге җиләслек турында әйтәсе дә юк. Хатын, уйлана-уйлана, кош-кортка җим салды, качып чеби чыгарган ак тавыгын чебиләре белән иркен читлеккә чыгарды. Бозауны тыкрыкка чыгарып бәйләде. Улакларга су агызып куйды да бакчадагы беседкага кереп утырды. Көн дә шушы эш. Яшь барган саен, хуҗалыктагы мәшәкатьнең күплеге сиздерә. Ире дә, балалары да мал-туар,

кош-кортны киметү, яшелчә бакчасын кечерәйтү ягын каерсалар да, Сабираның һаман да яшь чактагыча барысын да булдырып яшисе килә. Мидхәтнең көндәлек хуҗалык эшенә элек тә вакыты калмый иде, хәзер бөтенләй дә юк. Колхоз таралганчы, баш агроном булып эшләде. Берничә ел рәис булып та алды. Булдыклы булудан тыш, андый эштә кирәкле «өстәгеләргә ярый белү» дигән фәнне өйрәнергә теләмәү сәбәпле, озак тоткарланмады. Хәзер менә авылдашларының пай җирләрен туплап, фермер хуҗалыгы оештырды да, тырышып-тырмашып, шуны тарткан көне. Бусы инде колхоз гына да түгел. Үзең өчен эшлисең дисәләр дә, үзең дигән кешегә күпме кала икән? Гомумән, нәрсә кала икән? Тузган нервылар, йөрәк чире – анысы кала. Гаилә тормышында тынгысызлык: һәркөн күккә карап, Ходайдан яңгыр яудыруын, йә туктатуын теләү, көнгә ничә мәртәбә яхшыга өметләнеп, телевизордан, интернеттан алдагы көннәргә һава торышын карау... Сабираның соңгы елларда кәефе, яшәү рәвеше нәкъ һава торышындагыча: һәр катаклизм аның йөрәге аша үтә. Иренең борчылганын күреп, аннан да ныграк үрсәләнә, берничек тә ярдәм итә алмавыннан, гаҗизлектән интегә иде.

Хатын, бераз уйга чумып утыргач, өйгә кереп китте. Улы Ихсанны да уятырга вакыт.

Студент уллары – җәйге каникул вакытында әтисенең уң кулы. Авыл хуҗалыгы институтында укучы егеткә атасы басудагы теләсә нинди эшне, теләсә кайсы техниканы ышанып тапшыра. Кичә ташылып бетмәгән печән түкләрен саклап, әле таң алдыннан гына болыннан кайтып ятты. Әзер печәнгә хуҗа тиз табыла. Ташып бетерергә өлгермәсәң, иртәнгә күрше авыллар, кайчагында үзебезнекеләр үк, эшне «ярыйсы ук җиңеләйтеп» куялар.

– И бала-бала, иптәшләрең төн буе күңел ачып, төшкә кадәр йоклыйдыр инде. Син җәй буе эштән башканы күргәнең юк. Рәнҗемә инде безгә, – диде ана эчтән генә.

Әтисе белән кичтән сөйләшү буенча, ул хәзер гөнаһ шомлыгы колорадо коңгызларыннан бәрәңге басуын эшкәртеп кайтырга тиеш. Берсе булмаса, берсе булыр дип, Мидхәт игенчелеген дә, терлекчелеген дә ташламаска тырыша. Үзләренә бик күп кирәк булмаса да, ел саен берничә гектар бәрәңге дә утыртмый калмый.

– Бартерга, вак-төяк йомышка ярап куя ул, – ди.

Өстәл әзерләп, чәен кайнарлатып алды да Сабира верандага Ихсанны уятырга чыкты.

– Әни, тагын ун гына минут йоклыйм инде...

Балаңны җәлли-җәлли уятудан да авыр нәрсә бар микән? Кодрәтеннән килсә, үзе күптән эшләп куйган булыр иде инде. Юк шул, монда Ихсан кирәк. Вакыт та көтми. Сыекчасын әзерләп, басуга барып җиткәнче, кояшның нәкъ кыздырган чагы булачак.

Ярый, икенче тапкыр эндәшүгә, егет авырлык белән булса да торды. Тышта билдән салкын су белән юынып керүгә, Сабира улы алдына кайнар чәен куйды, сөт өстен, балын алдынарак этте.

– Әни, кичә болында бер кызык булды бит әле. Су буенда учак яктык та утырабыз шулай сөйләшеп. Төн урталары үткәч, Ташлы ягыннан машина тавышы ишетелә башлады. Тавышына караганда «КамАЗ» булырга тиеш, дибез. Бераздан фара яктысы да күренде. Таһир әйтә: «Әйдә, утны сүндерик тә төйи башлагач кына яннарына барырбыз, – ди. – Өстендә тоткач, милициягә тапшырсаң да була», – ди.

Илнур:

«Кирәкми, йә танышлар булып чыгар. Аннары гомергә Ташлыга кызлар янына да бара алмассың», – ди. Ул арада машина туп-туры безнең янга килеп туктады. Кабинадан егетләр коела башлады. Карасам, берсе үземнең группадаш Мәгъсүм». «Нишләп йөрисең?» – мин әйтәм.

«Әбигә печән әзерләшергә кайткан идем», ди. Аның әнисе Ташлыдан бит. «Әзерләдеңме соң?» – дим. «Булмады бит әле. Саклап утырасыз бит,– ди.– Ярар, башка җирдә бетмәс әле.» «Урлашып йөргәнче, нигә чапмыйсың соң?» – дигән идем, кычкырып көлде.

«Җүләрме әллә син, – ди. Әбисе дә ничек «әзерләгәнен» белә бит инде аның. Риза булып, чыгарып җибәрә. Үзе намаз укыган буладыр әле. Менә сөйләшеп кара син шундыйлар белән.

– Кеше һаман фермер хуҗалыгын элекке колхоз дип белә инде ул. Колхозныкы урлашсаң да җитә, урлашмасаң да бетә иде. Председательләр, белгечләр күпме кирәк урлаштылар, шуңа халыкка да каты кагылырга курыктылар.

– Исеңдәме, әни, бер елны бөтен кеше Сабантуйда ял иткән көнне, без бәрәңге утырткан идек.

– Ничек истә булмасын, улым. Онытырлык бәрәңге булдымыни ул. Беренче ел булгач, орлык бәрәңгесе дә, алырга акчасы да юк иде бит. Әтиең күрше районндагы бер колхоз базыннан чыгарып түгәсе калдык-постык, черек –чарык бәрәңге төяп кайтты. Шуннан әйбәтрәк дигәннәрен чүпләп утырттык бит ул елны. Мин аннан бәрәңге үсәр дә димәгән идем инде. Үсте бит. Көзгә таба хуҗалар да күбәйде. Берсендә әтиең шашардай булып кайткан иде. «Басуга төшсәм, кеше өмәгә килгәнмени! Кем матай белән, кем машина белән килеп туктаган. Янып-пешеп бәрәңге алалар. Мин күренүгә, күбесе качу ягын карады. Бер хатын һаман каерып-каерып казуын белә, ди. Янына килдем дә: «Ходай ярдәм бирсен», – дип әйтәм, ди. «Ярар, телеңә салышып торма. Эшләп тапкан малың түгелдер әле. Бер-ике капчык бәрәңгең кимегәннән хәерчеләнмәссең», – ди икән теге хатын. Шәһәр тикле шәһәрдән кайталар иде бит. Каравылчы ялламыйча булдыра алмады әтиең.

– Безнең як халкы ничек тә булса тир түкми мал табарга ярата. Үзебезнең тулай торакта яшәүчеләрдән дә сизәм мин аны. Нәрсәнедер башкалардан алданрак эләктерә алса, ул аны үзенеке дип исәпли. Хаклымы, түгелме – анысында эше юк. Дөреслекне эзли башласаң, «Бармаклар да тигез түгел», дип, үзен аклап куя.

– Эшләп табу почётта түгел шул хәзер, улым. Дөньясы шундыйга әйләнеп бетте. Алга таба тагын ни язгандыр.

Кечке ашка Мидхәт борчылып кайтып керде.

– Улым, син препаратны инструкциядә күрсәткәнчә салгансыңдыр бит?

– Әйе инде, әти. Беренче эшләвеммени? Нигә? Нәрсә булган?

– Син сиптереп чыккансың. Бер коңгыз да үлмәгән. Хәшәрәтләр бәрәңге сабагында берни булмагандай кукраеп утыралар. Районнан кайтышлый басуга кереп чыккан идем.

– Белмим инде, мин инструкция кушканча эшләдем, әти. Ялган препарат булгандыр.

– Менә ышанып ал син. Ел саен ала торган базадан алган идем, югыйсә. Шул гына җитмәгән иде. Тагын күпме расход, күпме солярка яндырырга кирәк!

Көн-таң атса, борчу-мәшәкать, планлаштырылмаган бер расход килә дә чыга.

Мидхәт районнан болай да кәефсезләнеп кайткан иде. Язгы чәчүгә ярдәм йөзеннән дәүләт бүлеп биргән акчаны һаман ала алмыйлар. Урак өсте җитә бит инде. Комбайннарга ягулык алырга иш янына куш булыр дип, өметләнеп торалар иде бит.

– Иртәгә үк икенче төрлесен алып кайтып сиптерергә кирәк инде.

– Менә шуннан соң, үзебез үстергән экологик чиста бәрәңге ашыйбыз дип ашыйбыз инде, – дип сүзгә кушылды Сабира. Ирнең болай да янган йөрәгенә бу сүзләр утка керосин сипкән кебек тәэсир итте.

– Мин гаеплемени соң аңа? Сатып алып ашыйк алайса. Анысы чистарактыр.

Үзен гаепләмәгәнне белсә дә, соңгы вакытта бик тиз кызып китә торганга әйләнде Мидхәт. Хәлен сорамасаң: «Эшләрең ничек бара дип тә сорамыйсың», – дип үпкәли. Кайчагында, ялгышып, вакытлы-вакытсыз сорасаң: «Син дә сорап торма ичмасам. Ничек булсын инде!» – дип, орышып ташлый. Сабира иренә рәхәт булмавын яхшы аңлый. Тик һава торышы өчен дә (Ходай эше!), апрель аена кергәч кенә, алда чәчү торганын искә төшергән чиновниклар өчен дә, намуссыз алыпсатарлар өчен дә, авылны, халкын язмыш иркенә ташлаган җитәкчеләр өчен дә якын кешесеннән авыр сүз ишетәсе килми шул. Иренә үзе кебегрәк итеп җавап бирәсе килсә дә, хатын, Ходайдан сабырлык сорап, кулын гына селтәде дә ишегалдына чыгып китте. Бераздан, тынычланып, Мидхәт тә болдырга чыгып басты.

– Мин РОНОга кереп чыктым. Буяуның кайчан буласы билгеле түгел әле, диделәр.

– Нигә билгеле түгел, диделәр инде?

– Сезгә буяуны кайдан аласын да белмиләр әле. Поставщиклар арасында тендер уйнатылмаган диме.

– Июнь үтеп бара бит инде. Аны беренче сентябрьгә ремонтлап та чыгарга кирәк бит. Җиң сызганып, төзүчеләр бригадасы көтеп тора дип беләләрме?

– Менә анысын мин белмим инде, әнисе.

Мәктәпләрен башлангычка калдырып, балалар бакчасы белән куштылар да, яңа статус биреп, Сабираны мөдир итеп калдырдылар. Пенсиягә чыгар алдыннан чит коллективта эшләргә туры килер микәнни дип борчылып йөрүләр юкка булды булуын. Шулай да педагогикага кагылышы бик аз булган хуҗалык эшләре белән шөгыльләнү бер дә җанына канәгатьлек китерми шул. Тик эшләргә кирәк. Юкны бар итеп эшләргә! Ач паёкка утыртылган җирле үзидарәгә тагын кереп карарга кирәк инде. Буяудан башка да күпме эш башкарасы бар бит анда. Башына мең төрле уй салган авыл хатыны хуҗалыктагы кичке эшләренә тотынды.

## ИКЕНЧЕ КӨН

«Имеш, җирдә күмелмәгән мәет ятса, яңгыр яумый икән». Авыл халкының җәһәннәм кызуыннан туюы тәмам җитеп, чигеннән ашты. Сәбәбен эзләп, төрле фаразлар кора. Кем: «Кешеләрнең гөнаһлары күбәйгәнгә, Ходай Тәгалә җәзасын җибәрә, – ди; кем табигать эшенә кеше күп тыкшына, шуның аркасында, ди. Ипилек-тозлык дога укый белгән мәчет картлары, югары басуга менеп, Ходайдан яңгыр сорап ялварып та карадылар инде. Әллә кызык өчен сөйләделәр, әллә чын булган, кайсыдыр авылда соңгы нәсел үгезен корбан итеп тә чалганнар, имеш. Тик яңгыр гына һаман юк. Ни генә булмасын, тормыш арбасы шыгырдый-шыгырдый алга тәгәри иде.

Сабира, гадәтенчә, көтү куугa, капка төбендә бераз басып торды да кереп китим дип борылса, тыкрык буйлап бер ир-атның менеп килүен шәйләде.

Болай иртәләп болын ягыннан кем кайтып килә соң әле? Таныш та кебек үзе. Сабира, юк эшен бар итеп, капка төбендә тоткарланды.

– Исәнмесез, Сабира апа!

Шешенгән йөзле, таушалган киемле ир-атның элекке укучысы Вахит икәнен чамалап кына таныды. Аның эчүгә сабышканын белә, тик үзен күптән күргәне юк иде.

– Вахит, үскәнем, ни булды сиңа?

– Нигә алай дисез, Сабира апа?

Ир-ат, сорауга җавапны үзе дә белгәнгә, гарьләнгәндәй, йөзен читкә борды.

– Авырмый торгансыңдыр бит, дим. Йөзең бер дә матур түгел.

– Безнең чир билгеле инде, Сабира апа. Фермада каравыл өендә йоклаганмын. Шуннан кайтып киләм.

– И-и, бала, бала! Әти-әниең борчыла торгандыр бит. Ни дип уйлап төн чыктылар икән? Яшьләре зур. Нигә борчыйсың инде аларны?

– Алар өйрәнде инде. Борчылып-борчылмый нишләсеннәр.

Вахитка бу сөйләшү авыр иде. Хәле болай да мөшкел, башы чатный. Кешене түгел, үзен дә күрәсе килмәгән чакта, кирәк бит, мәктәптә укыганда бик хөрмәт иткән укытучысы каршысына килеп чыкты. Хәзер маңка малай кебек акланып тор инде. Шулай да укытучысының тавышында шелтәгә караганда кызгану тойгангамы, үзе һаман китми, таптанып тора.

– Сабира апа, ишегалдыгызга кереп, су гына эчеп чыгыйм әле.

– Әйдә, Вахит, кер соң. Бит-кулларыңны да ю. Азрак хәл кереп китәр үзеңә.

Сабира мәхлук хәленә калган егетнең йотлыга-йотлыга су эчүен, йомарланган битен шомартырга теләгәндәй, кабат-кабат юынуын күрмәмешкә салышып, юк-барны эшләп йөрде. Вахит, нигәдер, юынгач та чыгып китәсе итмәде, башын иеп, чиләкләр тезелгән эскәмиянең башына барып утырды.

– Менә шундый җүнсез булып чыктым инде мин, Сабира апа, ачуланмагыз инде.

Сабира, эшеннән туктап, сәрхушның янына килде.

– Мин ачуланмыйм ачулануын, Вахит. Эш анда түгел бит. Миңа син үзең кызганыч. Әрәмгә үткән яшь гомереңкызганыч. Картайгач, таянычыбыз булыр дип үстергән әти-әниең кызганыч. Өйләнеп, балалар үстереп, тормышка куанып кына яшәр вакытың бит, Вахит.

– Әй Сабира апа, сезгә әйтергә генә җиңел ул. Әллә мин теләмәс идемме аның шулай булуын. Ярар, тагын бер кат гафу. Ачуланмагыз, исән булыгыз!

Вахит укыганда иптәшләреннән берни белән дә аерылмаган авыл малае иде. Шаянлыгы булса да, явызлыгы юк; бик яхшы укымаса да, утырып калганы булмады. Башкалар кебек армиядә хезмәт итеп кайтты. Төпчек бала буларак, өйдә калды, СПТУ бетереп, тракторга утырды. Юлдан тайпыла башлауга беренче сәбәп, мөгаен, мәктәп елларында ук дуслашып йөргән сөйгән кызы Алсуның, медучилище тәмамлагач, авылга кайтмавы булгандыр. Эш урыны булмагач, кая кайтсын инде ул. Ике штаттан торган ФАПның язмышы да кыл өстендә торганда. Вахит Алсу артыннан шәһәргә китмәде, тегесе авылга кайтмады. Шулай аралары суынды. Алсу кияүгә чыгып, бала үстерә инде. Аннары колхозлар бетеп, дөнья инвестор дигән алпавыт кулына күчте. Фермалар бетте. Трактор-машина паркы бушап калды. Алар белән бергә авылда эш тә бетте. Элек ярыша-ярыша башкара торган җир эшкәртү, чәчү, урак уру кебек эшләрне инвесторның чит илдән кайтартылган көчле техникасы авыл кешесен мәшәкатьләми генә башкарып китә. Пай җирләрендә үзең хуҗа булып эшләргә Вахит кебек бик күпләрнең кулыннан килми шул.

Шторм вакытында ярга чыгарып ташланган вак балыкка охшаган иде Вахит кебекләр. Тыпырчына-тыпырчына, елгага кадәр төшеп, йөзеп китә алырлармы, ярда җан бирерләрме? Үзләреннән тора дип әйтеп бетереп кенә дә булмый...

Мидхәт, иртәнге аш вакытында хатынының уйчанлыгын күреп:

– Ни булды, авырмыйсыңдыр бит? – дип сорады.

– Юк, тәнем авыртмый, җаным гына сызлый, – диде Сабира, ачылып бетми генә.

– Ни сәбәпле инде?

Хатын Вахит белән булган очрашу турында сөйләде.

– Ул эшләрдәй берәр эш юкмы соң синдә? Техника гына димәгән бит. Ялкауга охшамаган иде ул малай укыганда. Эшләсә, әллә эчмәс иде.

– Да-а-а... Минем хатын бөтен авыл юксыллары проблемасын хәл итәргә алынган икән, – диде Мидхәт көлемсерәп. – Фермада эшләп карады бит инде. Печән урлап саткан өчен куып чыгардым мин аны. Кабат, гафу үтенеп, ялынып килгән иде дә – алмадым. Шуннан бирле әти-әнисенең пенсиясен эчеп, теләсә кайда йоклап йөри инде ул.

– Бетә бит инде ул болай булса. Вакытлы булса да эш юкмы соң? Печән әзерлисең. Шунда кеше кирәк түгелме?

Мидхәт – эшкә бик җаваплы карый торган кеше.Үзендә эшләүчеләрдән дә шуны таләп итә. Вахит кебекләргә ышанып эш тапшыру ягында булмаса да, хатынын кызганыпмы:

– Ярар, уйлап карармын, – диде.

Аннары:

– Эчми чыдый алса, – дип өстәде.

Өйдәгеләр иртәнгене ашап-эчеп чыгып киткәч, Сабира көндәлек мәшәкатьләренә чумарга да өлгермәде, ишектә күрше хатыны Рәйханә күренде. Рәйханә гади күрше генә түгел, аның белән бергә мәктәптә эшләүче башлангыч сыйныфлар укытучысы, Сабираны әниседәй якын күрүче, эштә дә, хуҗалыкта да аның уң кулы иде. Әле кайчан гына йөзеннән нур коеп, кайчан карама борын астыннан күңелле генә җыр көйләп, өендә дә, мәктәптә дә җир җимертеп эшләүче хатыннан соңгы айларда күләгә генә калып бара. Әнә бүген дә йөзеннән нур качкан, агарып калган.

– Ни булды инде тагын, Рәйханә, төсең беткән? Балаларга ул-бу булмагандыр бит?

– Юк-юк, Сабира апа, балалар исән-сау, Аллага шөкер. Атлас...

Рәйханә сүз әйтерлек дәрәҗәдә түгел иде. Сабира апасының йомшак сүзен ишетүгә, моңарчы тыеп килгән яшьләренә ирек бирде.

– Каргамаган да идем югыйсә, Сабира апа, бик рәнҗесәм дә каргамадым. Күз яшьләрем төште микәнни?

– Тукта, Рәйханә, тынычлан әле. Атласка нәрсә булган?

– Машинасы белән әйләнгән... Үзен авыр хәлдә Актай больницасына алып киткәннәр... Машинаның бер төзек җире дә юк ди, үзен кабинадан көчкә сөйрәп алганнар, «Ничек исән калган?» – дип әйтәләр ди.

Хатын тыела алмый үкси иде. Сабира, күршесенең җилкәсеннән сүзсез генә кочып, аңа кайгысын күз яшьләре белән юарга вакыт бирде. Салкын суга тынычландыргыч тамчылар салып алдына куйды. Хәзергә нәрсәдер әйтү, юату файдасыз иде.

Рәйханә бераздан тынычлангандай булды. Суны алып эчте.

– Алмаз әтисе янына бармакчы була. Сабира апа, җибәрим микән? Янына барыбер кертмәсләр инде. Мидхәт абыйның районга барасы юк микән дип

кергән идем. Үзен генә җибәрәсем килми. Бала бит әле. Үзем алып барыр идем, теге нәрсәсен очратырмын дим. Йә бугазына ябышырмын. Пычранудан куркам.

– Барам дигән сүзе булмады бүген булуын. Бәлки, барасы да бардыр. Төшке ашка кадәр сабыр итеп карагыз әле. Аннан күз күрер тагын. Хәле авыр чакта әтисе янына җибәрмәсәң, бала аңлап бетермәс.

– Үзем дә шулай дим инде. Теге вакытта да әтисенең китүендә мине гаепләгәндәй йөрде бит, беләсең.

– Исемдә, исемдә. Онытырлык булмады бит инде.

– Ярар, Сабира апа, чыгыйм әле мин. Керәм дә үз проблемаларым белән синең башыңны катырып чыгып китәм. Ачуланма инде син.

– Ачулана ди тагын. Кайчан кирәк, шунда кер. Үзеңне бик бетермә әле. Хәле бик куркыныч та түгелдер, бәлки. Мидхәт абыең кайтсын. Киңәшербез.

Рәйханә бераз тынычланып чыгып китте. Ә Сабираның күңеле урыныннан кубып калды. Атлас белән Рәйханә, өйләнешкәннән соң, күршеләрендәге буш йортны сатып алып, монда күчкәннән бирле, күршеләр якын туганнардай бик тату яшәделәр. Мидхәт абыйсының киңәше белән Атлас яхшы гына эшкә тотынган иде. Моңарчы ул җәен Мидхәттә комбайнда эшләде. Сезонлы эш гаиләне мулдан тәэмин итәрлек акча бирми. Эшкә төгәл, тырыш күршесенә нинди житдирәк шөгыль табарга дип, күптән уйлап йөри иде Мидхәт. Мәсьәләнең чишелеше аяк астында гына булган икән. Беркөнне Сабира сөт тапшырып кайтты да зарланып куйды:

– Торган саен оятсызлана бу сөт җыючылар. Һаман ике ел элек куйган бәягә алалар. Үзебезнең авылдан булсалар, ул кадәр кыланмаслар иде. Ни дисәң дә, авылдашың белән иртәгә дә яшисе.

– Берсе дә алынмый бит шул эшкә, – диде хуҗа, хатыны белән килешеп. – Алам дисә, кечкенә литражлы сөт машиналары да бар хәзер. Лизингка да алып була. Эш юк дип яту җиңелрәк бит.

– Кара әле, нигә бу Атлас белән сөйләшеп карамыйсың? Тәвәккәллеге бар бит ул егетнең.

Сабираның әйткәне фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килдеме, Атлас ике ел элек Мидхәт абыйсының киңәш-ярдәме белән лизингка машина алып, авыл эшмәкәре булып китте. Исәп-хисап эшенә Рәйханәсе булышты. Бер ел эчендә тирә-яктагы берничә авылның шәхси хуҗалыкларыннан сөт җыеп, эш рәтенә ярыйсы гына төшенде, акча тәмен дә сизде. Сөт тапшыручылар белән исәп-хисапны вакытында алдау-йолдаусыз башкаргач, кеше арасында абруе да күтәрелде. Гаиләсендә тәртип, ике малае үсеп килә. Олысы Алмаз инде кул арасына керә. Җиңел машина да алып җибәрделәр. Уңган-булган хатыны Рәйханә белән дә соклангыч яшиләр иде. Бүген «иде» дияргә генә калды шул. Әллә күз тиде үзләренә, заман афәте – бозыклыкның авылда ныклап тамыр җәю галәмәте булдымы, узган җәй тормышлары бозылды да куйды. Көзен бөтен авылны шаккатырып, Атлас гаиләсен ташлап чыгып китте. Кемгә диген – өч-дүрт ел элек Казан базарында сату итүче «кара кошларның» берсенә тагылып чыгып киткән, кыш көне каяндыр авылда пәйда булган Юмарт Сәлимә кызына. Ир-атны кулга төшерүнең бушлай академиясен яшьли тәмамлаган Венерага Атласны иялләштерү бөтенләй дә кыен булмады. Актайдан авылга кайту юлында, нишләптер, бик еш очрашудан башланган танышлык, тора-бара оят-әхлакны көйдереп юкка чыгарыр дәрәҗәдәге азгын хисләргә әверелде. Әй гарьләнде Рәйханә бу турыда ишеткәч! Дөрес, Атласына табыну дәрәҗәсендәге мәхәббәте башта ышанырга ирек бирмәде. Үз күзе белән күргәч, Атласка бер генә сорау бирә алды:

– Нигә?

Һәм кыска гына җавап ишетте:

– Мин – ир кеше.

– Ә мин нишләргә тиеш?

– Моңарчы ничек яшәсәң, шулай яшә. Яшисең килмәсә, яшәмә.

– Балалар?

– Балаларга нәрсә булган? Мин аларны ташларга җыенмыйм.

Ирнең намусын уятырга маташуның мәгънәсе булмады. Күз яшен, ачу-рәнҗешен эченә җыеп күпмедер газаплангач, Рәйханә, җанын кая куярга белмичә, Сабира апасына киңәшкә керде.

– Аерылам да, балаларны алып, әнкәй янына кайтып китәм, Сабира апа. Бу оятсызлыкка түзәрлек хәлем калмады.

– Ашыкма әле, акыллым, кисү җиңел ул, ялгавы авыр. Ничек оста ялгасаң да, төене кала. Аннары әниең янында абыең гаиләсе барын да онытма. Ирдән аерылып кайткан хатын – эт тибенкесендәге кеше инде ул. Анысын да уйла.

– Яшереп тә тормый бит! Үзен хаклы саный. Әйтерсең, гөрләшеп яшәгән унбиш ел гел булмаган, әйтерсең, мәңге бергә булырга антлар эчмәгән. Миннән артыграк кеше белән булса, бер хәл иде, эткә салсаң, эт иснәргә җирәнә торган нәрсә бит.

– Шундый булсалар да, кулыннан эш килә торган ирләрне танып, чат ябыша белә андыйлар. Берсе дә урамда селкенеп йөргәннәргә якын килми, ялгыз булсалар да. Чөнки аларга акча кирәк, ир хисабына рәхәт яшәү кирәк. Әллә син аны Атлас белән дөнья көтү турында сөйләшәдер дип беләсеңме? Ә син үзең соңгы вакытларда ireң белән эштән башка нәрсә турында сөйләшкәнең булды? Ярар, балалар турында сөйләшкәнсездер инде. Тагын нәрсә турында сөйләштең? Хисләр турында...

– Анысы унбиш ел торгач, болай да аңлашыла бит инде, Сабира апа. Миңа үзеннән башка берәүнең дә кирәк түгеллеген дә белә. Кайчан кайтып керсә дә, якты чырай, өстәл тулы яраткан ризыгы. Тагын ни кирәк?

– Ир-атка иң беренче нәрсә кирәген үзең дә яхшы беләсең. Мин аңлатып торасы түгел.

– Бу бит – азгынлык, гаиләң алдында җавапсызлык. Моны бернәрсә белән дә аклап та булмый. Аңлый да алмыйм. Мин хәл иттем инде, Сабира апа, иртәгә Актайга барып, аерылырга гариза бирәм.

– Әй бала, бала! Ә син кияүгә чыкканда, аның ир генә түгел, балаларыңның атасы да буласын уйлап чыкмадыңмыни? Ирдән аерылу синең эш булса да, балаларыңны атасыз итәргә синең хакың бармы соң? Алар ризалык бирделәрме?

Рәйханә гариза бирмәде. Тик Атлас үзе чыгып китте. Олы улы Алмаз, теле белән әйтмәсә дә, әтисенең гаиләне ташлавына әнисен гаепле санап, башта үпкәләп йөрде. Рәйханә бая шул турыда искә төшерде.

### ӨЧЕНЧЕ КӨН

Мидхәт печән ташучы соңгы машиналарны озатты да бушап калган болынга карап уйга бирелде. Аллага шөкер, малкайларга кышлык печән әзер. Пайчыларның да күңелләре булды. Һәркем үзенә тиешлесен алды. Эшләгән егетләрне әйтәсе дә түгел. Яздан бирле яңгыр яумагач, печән калын булып үсмәсә дә, кирәк кадәрен чабып, коры килеш җыеп алдылар. Кирәк булса, тагын чабарга да мөмкин. Ник дисәң, авылда мал асрап чиләнми хәзер халык. Кул белән чабучы бөтенләй юк диярлек. Шуңа күрә трактор белән кереп булмаган

уйсулыклар, еллар буе чабылмыйча, кыргыйланып бара. Элек борынга төреп тыгарлык хуш исле болын печәне үскән кишәрлекләрне камыл баса. Чабыйм дисәң дә чабып булмый.

Мидхәт, бер яктан, төгәлләнгән эш өчен күңеле булып, икенче яктан, чабылмый калган җирләрне кызганып, болынга тагын бер күз салды да кайтыр юлга чыкты. Колхозчыларның болын тулып печән чапкан чакларын искә төшерде. Заманына күрә техникасы, эшлим дип торучылар да җитәрлек иде. Учакта зур-зур казаннарда ашарга пешереп, бергә әбәт ашаган, уен-көлке белән авыр эшне дә җиңел итеп башкарып, ярыша-ярыша печән әзерләгән вакытлар кайда икән?!

Гел-гел үткәнне сагынып кына да яшәп булмаганын аңлый Мидхәт. Замана кушканча яшәргә тырышу кирәк. Бүген аның авыл хуҗалыгында эшләр өчен тәҗрибәсе дә җитәрлек, авылда гына түгел, районда да яхшы җитәкче дигән авторитеты бар. Никадәр авыр булмасын, хуҗалыгы да үз аягында. Дәүләт ярдәмен чумырып ала торган эре хуҗалыклар белән ярышырлык булмаса да, җиргә дә тезләнмәгән.

Мидхәткә эш буенча республикадан читтә төрле төбәкләрдә булырга туры килә. Күбесендә авыл үзгәреп кенә калмаган, бөтенләй беткән – авыл үлгән. Ничәмә тапкырлар: «Без юкка зарланабыз икән, без әле оҗмахта яшибез икән әле!» – дип, туган төбәген, авылын сагынып кайтып кергәне бар. Шаккатмалы хәлләр: республиканың читен генә үт, такта, хәтта салам түбәле өйләр, электрсыз авыллар, челтәрсез тәрәзәләр, асфальтны төшендә дә күрмәгән йөзләрчә чакрымнарга сузылган басу юллары... Бу якларда әллә соңгы илле ел бөтенләй дә булмаганмы соң дип уйлап куясың. Әле кайчан гына күп колхозларның төшенә дә кермәгән җиһазлар куелган фермадан яки гөрләп үскән иген кырларын урап, шартлары шәһәр йортларыннан берни белән дә аерылмаган өенә кайтып кергәндә, аның күңеле сөенеч белән тулган була. Ни дисәң дә, боларны ул үз куллары белән булдырды бит. Тегесе кирәк, бусы юк дип, кемнәндер көтеп ятмады. Фермерларны – өстәгеләр дисеңме, авылдашларымы – халык дошманына тиң күргән чорда, йөрәге җитеп, яңа эшкә алынды. Тырышты-тырмашты, көнне-төнне белмәде, авыр булса да, авылда хәләл көчең белән яшәргә мөмкин икәнен исбат итте.

Тик... тик... Мидхәт бу «тик»нең нәрсә аңлатканын үзе дә белеп бетерә алмый. Соңгы елларда авылның йөзе генә түгел, җаны да үзгәрде кебек. Әллә нәрсә җитми. Нәрсә үзгәрде соң? Бу сорауны ул үзенә еш бирә, җавап кына таба алганы юк. Нигә авылы турында уйлаганда, аның җаны сыкрый, күңелен канәгатьсезлек талый? Карап торышка әллә ни үзгәрмәде дә бит. Шул ук басу, шул ук болыннар. Язын тузынып алса да, соңыннан сабыр гына агып ятучы Киндерле елгасы да, авыл башындагы зират та шул ук. Авылдашларның да күбесен Мидхәт бала чагыннан ук белә. Дөрес, күчеп килүчеләр дә бар.

Ә уйлап карасаң... Адәм көлкесе бит: авыл кешесе кибеткә чыгып сөт, йомырка сатып ала. Озакламый бәрәңге утыртучы да калмаячак. Колорадо коңгызы ярдәме белән бакчалар болай да бәләкәйләнеп беткән иде, кайчан теләсәң, шул чагында юнь бәягә сатып алырга мөмкин булгач, нигә чиләнсен адәм баласы. Бәрәңгесен, икмәген үстергән фермер өчен күпмегә төшкәнен сорап торамыни ул. Анысы аның эше түгел. Алар турында хөкүмәт уйлансын, булышсын. Тик фермерга ярдәм итәргә ашыгып торучы юк икәнен Мидхәт һәм аның кебекләр генә белә. Дәүләт ярдәмен күрүче бәхетлеләр күп түгел. Ә җиткән кыз-малайларның эшсезлектән аптырап көндез йоклап, төнлә интернет

# ТАТАРЛЫКТА ТАТАР УЛЫ... КЕМ?

**Кызыксынган кешегә мәгълүм: соңгы елларда халыкларның генетикасын өйрәнү киң колач җәйде. Бу эш безнең җөмһүриятне дә читләтеп үтмәде, һәм, ихтимал, моңа фәкать куаныргa гына кирәктер: шулай, үзебезне үзебез өйрәник. Комачау итмәс. Юкса кичә-өченче көн Мәскәүдәге бәгъзе фәнни академияләр дә җиң сызганып татар геномын өйрәнергә керешкән иде. Шактый кызыклы мәгълүматлар да казып чыгардылар. Мәсәлән, урыслар, баксаң, ике өлештән тора икән: беренчеләре (Россиянең үзәк һәм көньяк төбәкләрендә яшәүчеләр) ДНК җәһәтеннән – славяннарга тартым, икенчеләре (аларын «төньяк урыслар» дип атыйлар) – угырларга. Һәм, калын-калын пыялалы күзлек киеп карасаң, төньяк кардәшләренә караганда без фәкыйрьләрегез (ягъни, татарлар) «гадәти» урысларга якынрак икән. Бернишләтә алмыйсың! Кызганыч, мондый чакта күңелгә корт төшми каламыни: «Әллә, уф Илаһым... сәясәт кенәме бу?» – дип тә уйлап куясың. Бердәм «российский» милләт ясау максатының чираттагы күркәм чарасымы?**

**Бүген татар кешесе үзенең килеп чыгышын төрлечә аңлата: кемдер – болгарның дәвамы, кемдер – Чыңгыз туруны... Шуларга өстәп, «тегесе дә, бусы да – хәзер барыбер шул ук без бит инде ул» дип кырт кисүчеләр, ихтимал, күпчелекне тәшкил итәдер. Аптырамассың да: төйнәлеп-чуалып беткән тарихи-иҗтимагый бәйләнешләр арасында җеп очын табып кара син! Һәрвакыттагыча, монда да җиңел юлдан китү мәгъкуль. Икенче уйласаң, парадокс: телләре, гадәтләре, йолалары үзгә ике кавем бәрелешсен, бер-берсен суешсын да... бербөтенгә әверелсен. Мөмкин хәлме?**

**Хәер, куркынычы бу түгел әле...**

**Ә алга таба – ун, егерме, илле, йөз, ике йөз елдан – милләтебез әүвәл маңкортлашып, аннары – урыслашып бетсә (тәүбә, тәүбә! Аллам сакласын!), яңа буын үткәнгә, буй җитмәслек еракта калган уналтынчы гасыр вакыйгаларына өрфиядәй җиңел караш ташлап, исе китмичә: «Икесе дә без бит инде!» – димәсме соң? Киләчәк кай тарафта? Кая барабыз?**

**Минем урыс-татар яисә татар-урыс кушылмасыннан гыйбарәт «суперхалык» өчен чимал буласым килми. Тамырларымда, җелегемдә имин сакланган бабамнар хәтере мондый винегретка риза түгел! Кабер җылылыгына сусаган кавемнәрнең (дәригъ!) гайрәтлерәк күршесенә кушылудан гайре чарасы юктыр. Вәләкин нинди тойгы бу, белмим – калебемдә якты өметләр тыпырчына.**

**Без бик куәтле әле. Без әле Мөхәммәдьярлар сөйләшкән телдә дөнья җәүһәрләреннән калышмаган әдәби әсәрләр, Аурупаның иң мәһабәт концерт залларында яңгырарлык музыка тудырырга сәләтле. Безнең япь-яшь егет-кызлар татар театрын тагын да зуррак үрләргә күтәрергә омтыла, татар киносын булдырырга тырыша, яңа Илһамнар, Хәйдәрләр дөньяның төрле почмакларына татар моңын тарата. Димәк, бездән җан чыкмаган әле. Ә җан биргәнгә җүн бирер, дигән борынгылар. Мин иртәгә кичәгедән яхшырак буласына ышанам. Һичшиксез! Барыбыз да шуңа ышансак иде. Фикер – матди ләбаса. Аның чынга аша торган гадәте бар.**

**Рүзәл МӨХӘММӘТША**

**Редакциядән:**

***Бу мөһим мәсьәләгә карата галимнәребез дә үз фикерләрен әйтсен иде.***

киңлекләрен айкап утырулары, йә бер максатсыз, әти-әни акчасына алынган матай-машинада чабулары, кулларына сәнәк-көрәк тота белми торган егетләр, сыерның кайсы ягыннан килеп сава белмәгән кызлар буыны үсеп килү берәүне дә борчымый. Әти-әниләрнең кайберләре сөенә дә: «Балабыз безнең кебек чиләнми, рәхәттә үсә».

«Авылда эш юк, яшьләр шуңа китә», диләр. Авылда эш бар, эшләргә теләүчеләр генә бик аз. Бүгенге көндә менә ул үзе тагын дистәгә якын кешене даими эш белән тәэмин итә алыр иде. Вакытлы эшне әйтәсе дә юк. Вакытлы гына дисәләр дә, алар еш кирәк булып тора. Шәһәрдә кеше почмагында кысылып, ярты хезмәт хакын түләп торса тора, авылга кайтып эшлисе килми хәзер кешенең. Авылдагылар арасында картлар пенсиясен ашап ятучылар җитәрлек. Көтүче булып эшләүне хурлыкка саныйлар, ата-анасы җилкәсендә яту – хурлык түгел.

Уйларның очы-кырые юк. Җавапсыз сораулар да җитәрлек. Авыл хуҗалыгы институтын бетереп, туган авылында эшли башлаганына утыз биш ел икән инде. Бер кеше гомере дисәң дә була. Март аенда сабакташлар белән очрашуга бардылар. Бер төркемдә укыган утызга якын кешенең дүртесе генә белгечлеге буенча эшли. Аның да берсе министрлыкта кәгазь эшендә. Мидхәтнең һаман авыл хуҗалыгында эшләвенә кемдер эчтән генә көлеп, «башка эш кулыннан килмәгәч», дип карады. Кемдер кызганды. Сокланучылар да булмады түгел. «Сабырлыгың да, белемең дә, җегәрең бар икән, молодец! Бүген җиргә тугры булып калу – батырлык ул. Безнең кулдан килмәде инде», – диючеләр дә булды. Иң авыры – Рафис сабакташының, болганчык елларда эшсез калгач, эчүгә бирелеп, дөньядан китеп баруын ишетү булды. Тулай торакта бер бүлмәдә торганнар иде. Теләсә нинди кыен хәлдән чыгу юлын таба белгән, күңел төшенкелегенә бирелми торган егетне дөнья каты китереп кыскан, күрәсең. Ташландык амбарда асылынган килеш тапканнар.

Мидхәт тамак ялгап алырга һәм уракка әзерләнүче комбайнчылар янына барырга планлаштырып, капка төбенә кайтып туктады. Кайтканын көтеп кенә торганнар. Юынып, ашарга утырырга да өлгермәде, капканың ачылып ябылуы ишетелде. Ул арада ишек кыңгыравына бастылар. Сабира:

– Нәҗиядер инде. Көндез үк сине сорап кергән иде, чык, – диде. Мидхәт, тынычлап ашарга да ирек бирмәгәннәренә ачуы килсә дә, чыгасы итте. Ишегалдында, чыннан да, Нәҗия атлы авылдашы көтә иде. Мидхәттән берике яшькә генә өлкәнрәк булса да, ул нигәдер аны баласытып сөйләшә. Бу хәл Мидхәткә ошап бетми, шулай да һәрвакыт: «Әйдә, вак-төяккә игътибар итеп, хатыншаланып тормыйм әле», – дип уздырып җибәрә. Бу юлы да Нәҗия, Мидхәтнең баскычтан төшеп җиргә басуын да көтеп тормыйча, үзенә бик ышанган тонда сүзгә күчте:

– Мидхәт энем, менә без Якуб абыең белән аңлап бетермәдек: күрше Гамирларга да, Керәшен Микулайларга да, Бөке Хәйретдиннәргә дә печән кайтты – безгә юк. Безгә дигән печәнне кайчан кайтарырга җыенасың икән дип белешергә кердем.

– Нәҗия, мин бит үзенең җир паен миңа ышанып тапшырган кешеләр белән печәндә эшләгәннәргә кайтарттым. Сезнең җирегез инвестор кулында. Паегыз өчен печәнне сезгә ул бирергә тиеш.

– Син нәрсә, укымаган дигәч тә, безне аңгырага санама. Колхозда ундүрт яшьтән бил бөккән Якуб абыеңның, башкалар алганда, дүрт-биш рулон печән алырга хакы юкмы әллә? Колхоз җирен син чабасың. Гомер-гомергә безнең

нәсел печән чапкан Әхми аланын син чабасың. Әллә кайдан килгән инвесторга бил бөгеп барырга мине кем дип белдең?

– Нәҗия, мин сиңа татарча, аңлаешлы итеп әйтәм ләбаса. Мин үземнең исемгә яздырып алган, налог түләп торган җирләремнән чабам, үземнең пайчыларыма, эшләгән кешеләргә печән әзерләп бирәм. Сезнең паегыз «Кызыл көч» кулында. Бирсәләр, аннан бирерләр. Минем сезнең өлешегездә бер катнашым да юк.

«Башкалар үз паен миңа биргәндә:«Бүген-иртәгә аяк сузасы Мидхәт хуҗалыгына бирәмме соң, Рәсәендә танылган чын хуҗага бирмичә», дип сөйләнеп йөргәнеңне оныттыңмыни?» – дип әйтәсе килде Мидхәтнең. Шулай да авылдашы белән бозылышасы килмичә:

– Чабасы килгән кешегә хәзер дә болында печән җитәрлек. Төшегез дә чабыгыз. Балаларыгыз да авылда бугай. Кайтарырга кирәк булса, булышырмын, – дигән иде дә, ник әйткәненә үкенде.

– Син нәрсә, әллә кем булдым дигәч тә, мине мыскыл итеп, кул белән печән чабарга кушасың? Кем дип белдең үзеңне шулкадәр? Сиңа гына управа табылыр. Иртәгә үк главага барам! Кешенекеннән артыграк итеп кайтарып аударганыңны сизми дә калырсың.

Нәҗия төкерек чәчә-чәчә кычкырды да капканы дөбердәтеп ябып чыгып китте.

## ДҮРТЕНЧЕ КӨН

– Әй, бу өйдә берәр кеше бар микән? Ерактан кунакка кайткан кызларын нигә чыгып каршы алмыйлар?

Сабира, сепарат тәлинкәләрен юган җиреннән бүленеп, верандага ашыкты. Кызы ич, Илсөяре кайткан!

– Әй балакаем, нигә шалтыратып хәбәр бирмәдең кайтасыңны? Йә абыең, йә әтиең каршы алыр иде.

– Җәйге кызу эш өстендә потомственный игенчеләрне изге хезмәтләреннән ничек бүләсең инде? Әтинең кәефсез чагына эләксәң, бетте баш! Бусы шаярып кына, әнием. Хәзер кешегә караганда машина күбрәк бит. Нигә кайгырасың, иномаркаларда җилдереп кенә кайттым. Миндәй яшь, чибәр кызга проблемамыни ул кырык чакрым юлны үтү?!

Илсөяр белән бергә өйгә күтәренке кәеф, шатлык, сөенеч кайтып керде. Төпчеге Казанда пединститутта укый. Җәйге сессиясеннән соң, төзелештә акча эшләргә дип, шәһәрдә калган иде. Чәй янында ана белән кызның сөйләшеп сүзе бетмәде.

– У-у, әни, күрсәң син ул Универсиада объектларын! Ул стадионнарны, спорт сарайларын, Универсиада үткәч, кем белән тутырып бетерерләр икән? Анда без кырмыскалар кебек, эшчеләрне әйтәм: үзебез күп, үзебез ул биналар янында кырмыска кебек шундый вак күренәбез. Әкәмәт инде менә!

– Кайтып булмас, бер көннән артыкка эштән китеп булмый, дигән идең бит.

Илсөяр шаян гына елмаеп куйды.

– Үзең әйтәсең бит, җан биргәнгә җүн биргән, дип. Безгә дә Ходай Тәгалә яшь, акыллы һәм чибәр прораб бирде. Атна саен чиратлашып, ике көнлек ял алабыз. Бу атнада минем чират. Калганнар тырышып эшләп, киткән кешенең нормасын тутыра.

– Ярый инде сүзе булмаса. Эше бик авыр түгелме соң?

– Без авыл балаларына нинди эш чыдасын! Буяучы эше шундый кызыклы

эш икән. Бригададагы кызлар да шундый әйбәтләр. Мин пединститутны ташлап, әллә төзелешкә китим микән дип уйлый башладым инде.

– Мондый сүзләр сөйләп син мине борчыма әле, кызым. Авызыңнан җил алсын.

– Үзегез бит бөтен эш тә хөрмәткә лаек дип өйрәттегез. Миңа гади эшче булу ярамасмыни?

Кызының шулай нинди дә булса бер сүзне кызыкка алып аптырата торган гадәтен белсә дә, Сабирага бу фикер ошап бетмәде.

– Мин ярамый дип әйтмәдем бит. Тик яңа эш белән танышкан саен, фикерне үзгәртергә димәгән. Әллә син төзелештә эш җиңел дип беләсеңме? Яшьлегең белән генә сизмисеңдер. Эссе җаенә түзсәң дә, аның салкын кышы бар әле.

– Син нәрсә инде, әни, шаяртам гына бит. Авыр дигәннән, әллә укытучы эше җиңел булдымы сиңа? Ничек «җиңел» икәнен күреп үстем инде мин. Төзелештәгеләр ичмасам, эшләгәннәренә күрә акчасын да алалар. Өйгә кайткач, эшләре турында исләренә дә төшермиләр. Ире белән бергә йокларга ята, ире белән тора укытучы булмаган хатын. Төн буе дәфтәр тикшереп, план төзеп утырмый.

Авырткан җиренә басты кызы. Тик шулай да ул хаклы иде.

Сүз авылдагы хәлләргә, әтисенең басудагы эшләренә һәм Ерак Көнчыгышта хезмәт итүче абыйлары Камилгә күчте. Узган җәй өйләнешкән Камил белән Мәликә бәби көтәләр. Вакыты якынайган саен, мондагыларның да борчулары арта. Бигрәк тә булачак әби белән бабай беренче оныкларын дулкынланып көтәләр. «Кем туар?» – дип гөманлыйлар. Тегеләре дә УЗИ ни күрсәткәнне әйтми. «Сюрприз!» – диләр.

Кич гаилә бергә җыелды. Илсөярнең шаянлыгы башкаларга да күчтеме, соңгы көннәрдә эш күплектән күзенә ак-кара күренмәгән әтиләренең дә кәефе шәп иде. Уен-көлке сөйләп, кичке ашны ашадылар.

– Бүген шимбә. Клубта дискотека буладыр әле. Абый, син чыгасыңмы? – диде Илсөяр.

– Нәрсә калган анда миңа?

– Ничек инде нәрсә калган? Син – яшь, чибәр, перспективный кияү. Бүген-иртәгә югары белемле белгеч. Бәлки әле галим булып та китәрсең. Кызлар күзләргә, үзеңне күрсәтергә чыгарга кирәк. Хәер, рөхсәт итсәң, синең арттан кызлар өерләре белән үзләре йөгереп йөрергә мөмкин.

– Әйе!!! Бигрәк тә әби-бабайларының пенсиясен ашарга кайткан шәһәр кызлары. Мин аларны су керергә Киндерле буена төшкәч тә күреп туям. Ни кызыгын табалардыр, көн буе шунда су кереп, кызынып яталар. Әбиләре бакчада колорадо корты чүпли.

– Абы-ы-ый! Аркаң кычытмыймы синең? Кашырга кирәкмиме?

– Нигә минем аркам кычытырга тиеш әле? Мин көн дә бик шәпләп юынып торам.

– Фәрештә канатлары чыкмый микән, дим.

– Ну сине! Ни сөйли дисәм... Тотсам, кирәгеңне бирәм.

Илсөяр чыелдап верандага чыгып качты. Абыйсы аның артыннан йөгерде. Буй җиткән балаларының үртәшү-шаярулары кызык иде. Бәхетле әти-әни яратып кына:

– И-и бу кызның теле! – диештеләр.

Клубта, чыннан да, дискотека бара иде. Дискотека мәйданына килеп җитүгә, Илсөяр дус кызларын очратты да алар белән түгәрәккә биергә кереп китте. Ихсан, көчле музыка астында аңлаешсыз хәрәкәтләр ясап, уртада селкенеп торуның мәгънәсен тапмый. Шуңа күрә читтә торучылар арасыннан танышларын эзләде. Ял булгангадыр, кайткан кешеләр күп, таныш

булмаганнары да җитәрлек. Егет сабакташларын күреп, алар янына атлады. Нәрсә турындадыр бәхәсләшүче егетләр Ихсан белән кул биреп күрештеләр дә үзара сүзләрен кызу-кызу дәвам иттеләр.

– Миңа бер кыек-мыек сүз әйтеп карасын, ник туганына үкендерәм бит мин ул падланы, – дип Тәбрис гайрәт чәчә. Калган егетләр тынычландырырга маташалар.

– Пычранма дидем бит мин сиңа, ахир. Ничаклы дөрес булсаң да, сине б...лап калдырачаклар. Көчленеке замана. Төкер. Бала-чага белән бала-чага булма! – ди берсе.

– Нәрсә, «Пычранма!» дип, җыен килмешәктән куркып, койрыкны кысып утырыйкмыни? Үз авылыңда аяк атларга куркып торыргамыни хәзер?

– Синдә дә гаеп бар бит, Тәбрис. Нигә дип аның машинасына килеп бәйләндең соң? Иномарка белән килсәни сиңа, «Жигули»дамы, «Белорусь» тракторындамы – барыбер түгелмени? Үзең башладың.

– Каным кайный минем шундыйларны күргәч. Эчәгеләрем актарыла. Нәрсә кырган әле бу маңка малай монда «Джип» белән килеп туктап, әллә кем булып йөрергә?

– Нинди маңка малай турында сүз бара, миңа да әйт әле сер булмаса? – диде Ихсан янәшәсендәге Барыйга.

Барый бераз читкәрәк китеп, хәлне аңлатып бирде:

– Әй, «Кызыл көч»нең безнең райондагы хуҗасы Хәсәновның малае авылга – Әхсән Хәйрулловичларга кунакка бик еш кайта башлады. Гөлүзәгә күзе төшкән бугай. Ә Тәбрисне беләсең инде, шул Гөлүзә дип саташа. Тегесе килеп туктарга өлгермәде, Тәбрис барып бәйләнергә тотынды: «Бу машинаны кем акчасына алдың? Монда нигә килдең? Дармоедлар, канэчкеч кандалалар...» Берсе дә калмады инде. Тегесе үзе генә түгел, әзмәвердәй ике иптәше белән. Алары башта катнашмый гына лач-лоч сагыз чәйнәп тордылар, аннары Тәбрисне култык астыннан күтәреп, читкә алып куйдылар да клубка кереп киттеләр. Хәзер Тәбрис тиресенә сыя алмый. Холык холык кынамы!

– Ә-ә, имәндә икән чикләвек! Зурга җибәрмәскә кирәк инде моны. Тәбрисне моннан алып китәргә кирәк, берәр җүләрлек эшләгәнче.

– Алып китеп булмый бит. Малайлар тырышып карадылар. Машинасына берәр каза салса, мәңге түләп бетерә алмаячак инде.

Ул да булмады, клубтан Гөлүзә белән чыгып килүче егет күренде. Кич булуга карамастан, кара күзлек, кысан джинсы чалбар белән футболка киеп, мускулларын уйнаткалап килүче җирле олигарх малае бер кулы белән машина пультын чөя-чөя, икенчесе белән кызның биленнән алган килеш, машинага юнәлде. Барый әйткән тән сакчылары якында күренмәде.

– Да, малай, егете ачуны китерә торганрак икән шул, – диде Ихсан эчтән генә. Ул арада Тәбрис кунак егет каршына килеп басты. Үзенең хаклыгына бер бөртек тә шикләнмәгән тавыш белән егеткә сүз катты:

– Син кая алып киттең әле безнең авыл кызларын?

– Абзыкаем, синнән сорарга онытканмын икән. Пардон! Гафу ит, ягъни,– диде кунак, бөтен кыланмышына мыскыллы төсмер биреп.

– Оныттың шул! Энекәш! Тыңла һәм исеңдә калдыр: иртәгәдән башлап, кайсы аягың белән безнең авылга аяк бассаң, шул аягыңны кулыңа тотып китәрсең. Беренче һәм соңгы кисәтү шушы. Онытмаска әйбәт булыр, хәзергә менә монсын ала тор, Түбән Кизләү егетләреннән күчтәнәч.

Тәэсире көчлерәк булсын өчен, ташка басарга оят булганнарын да кушып

әйтелгән соңгы сүзләре белән бергә Тәбрис кунак егетнең колак төбенә ямады. Гөлүзә чыелдап ярдәмгә чакыра башлады. Сандык эченнән чыккан егетләр кебек, әллә кайдан гына тән сакчылары пәйда булды. Алар Тәбрисне бәргәли башлауга, кайсы аны яклап, кайсы сугышны туктатырга теләп, авыл егетләре килеп кушылды. Матавыкның ахыры канаган чырайлар, кызларның чыр-чуы, тәрәзә, машина фараларының ватылуы һәм кунакларның машинага көч-хәл илә утырып качуы белән тәмамланды. Ахыры бу булмаган икән әле. Авыл яшьләре булганын-булмаганын бергә кушып, кат-кат сөйләп чыгарга да өлгермәделәр, район үзәгеннән милиция наряды килеп, берничә егетне, шул исәптән Ихсанны да, машинага утыртып, сигналларын улата-улата алып киттеләр.

Илсөяр абыйсын кыстый-кыстый дискотекага алып чыгуына үкенеп бетә алмады. Үзе сугышып йөрмәсә дә, Ихсанда «һәр җирдә дөреслек урнаштыру теләге» көчле икәнен белә иде. Гауга башлану белән йөгереп килгән кыз, абыйсының сугышып түгел, авыл егетләрен кызмаска өндәп, тынычландырырга тырышуын күрде дә соң – аннан ни файда!

«Нишләргә? Абыйга бу хәлдә ничек ярдәм итәргә була? Әтисез генә эш майтарып булырмы? Ничек әнигә сиздермәскә? Болай да кан басымы борчып тора». Кызның башында сораулар өермәсе. Кем белән киңәшергә белмичә, клуб каршында басып калган икән. Дискотеканың яме китте. Яшьләр булган хәлне яңартып, үзара сөйләшә-сөйләшә, әкренләп таралыша башлады. Тукта әле, Илсөяр! Юкка гына сине мәктәптә укыганда «ут борчасы» димиләр иде бит. Син нәрсә булса да уйлап табарга тиеш! Тик нәрсә? Илсөяр клубка кереп китте. Клуб мөдире Эльза апаларының улы Рафаэль аппаратураларны җыеп ята иде.

– Нәрсә булды соң анда, Илсөяр? Аңлый алмый да калдым. Шушы эш белән гел иң кызык хәлләрне күрми калам инде мин, блин.

– Сиңа кызык. Минә миңа нишләргә хәзер? Абыйны да алып киттеләр бит. Өйгә кайтып әти-әнине борчыйсы килми. Бүген булса да тыныч йокласыннар инде. Кайтып йоклый да алмыйм. Нидер эшләргә кирәк, Рафаэль. Тик нишләргә, әйдә уйлыйк әле.

– Ихсанны да алдылармыни? Менә кызык! Менә мәзәк! Ул да сугыштымыни?

– Анда син сугыштыңмы дип сорап торучы булмады инде. Килеп төштеләр дә Тәбрис тирәсендә җыелып торган берничә кешене эләктереп, машинага тутырдылар.

– Кызык хәлләр, мәзәк хәлләр диген, ә!

– Таптың инде кызык нәрсә. Тычканга үлем, мәчегә көлке! Берәр нәрсә эшләргә кирәк дим мин сиңа. Киңәш сорыйм! Ә сиңа һаман «мәзәк», сиңа «кызык». Нишлибез? Куеп тор әле шушы бандураларыңны.

Рафаэль Илсөяргә кызык түгел икәнен, ниһаять, аңлап, эшеннән туктады да тавыш көчәйткеч өстенә менеп утырды.

– Нишләргә дисең инде алайса? Нәрсә булганын төгәл генә белүчедән сорашыйк әле башта. Ситуацияне белмичә нишләп була?

Рафаэль җайлап утырган «подиум»ыннан ялт кына сикереп төште дә клуб ишек төбенә чыгып кемгәдер кычкырды:

– Әй, кил әле монда!

Чакырган кешесе белән сүзне кыска тотты:

– Бер аягың монда, икенчесе тегендә булсын, тиз генә Бәләкәч белән Көтекне җир тишегеннән булса да табып китер. Рафа чакыра, диген.

Карышып маташкан малай белән Рафаэльнең талканы коры булды:

– Нәрсә,бушлай кино карыйсың килми башладымыни?

Чыннан да, күпмедер вакыт үтүгә, бөтен ыгы-зыгыда катнашса да, судан коры чыга торган, утта янмас, суда батмас өч яшүсмер пәйда булды.

– Хәзер миңа «олигарх» малае белән нәрсә булганын бәйнә-бәйнә сөйләп бирегез әле, балалар! – диде Рафаэль. «Балалар», чыннан да, махсус карап торгандай, булган хәлләрдән бик хәбәрдар булып чыкты.

– Ну... алар теге ни... Кендекне... Гөлүзәне дискотекадан чакырып чыгардылар да...нитмәкчеләр... алып китмәкчеләр иде, Тәбрис нитте... аңа килеп бәйләнде ...» Нигә безнең авыл кызларын алып китәсең», дип.

– Шуннан?

– Анда Тәбрис башлады, кәнишне.

– Безнең авыл егетләре юкка башламас. Гаеп безнекеләрдә була алмый, балам. Колагыңа киртләп куй. Димәк, «олигарх» башларга мәҗбүр иткән! – диде Рафа, ике төрле сөйләшүгә урын калдырмыйча.

– Шуннан китте инде. Безнекеләг өегелеп килделәг дә моның иптәшләген тәпәли башладылаг, – диде Көтек дигәне.

– Анда Ихсан бар идеме?

– Бар иде. Ул...

Рафа сөйләүченең сүзен бүлеп дәвам итте:

– Ул сугышучыларны аерып йөргәндер, шулаймы?

– Әйе, тегенең иптәшләрен нитәләр иде безнекеләр, изәләр иде. Ярый Ихсан булды. Рәхмәт әйтсен «Олигарх».

– Гөлүзә кайда икән? Тегеләр белән киттеме?

– Юк, Гөлүзә кайгысы идемени аларда. Үзенә кайтып киткәндер ул.

– Короче, аны табып сөйләшергә иде.

– Алып киликмени?

– Юк, кирәкми. Башта үзебезнекеләрне җыйыйк әле. Аннан карарбыз.

Ярты сәгать дигәндә, клуб ишегалдына яшьләр кабат җыелды. Нигә җыелганны аңлатуга, «моя хата с краю» диючеләр шыпан-шыпан гына караңгылыкка чумды. Калганнары, киңәшә торгач, төп шаһит Гөлүзәне табып сөйләшергә, ничек тә авыл егетләре файдасына «сайратырга» мәҗбүр итәргә дигән фикергә килделәр. Кыз яшәгән өйдән ерак түгел тыкрыкка җыелдылар. Гөлүзәне, кесә телефонына шалтыратып, яннарына чакырып чыгардылар. Гөлүзә, ни гаҗәп, «дәрәҗәле делегация»нең шартына бик тиз күнде. Сәбәбе болайрак булган: «кәттә кияүнең» авылдан чыгып качуына берничә минут үткәч, Гөлүзә «кыргый», «культурасыз» авылдашлары өчен оялып, егеткә шалтыраткан, хәлен белергә теләгән икән. «Олигарх малае» бөтенесен берьюлы, шул исәптән кызның үзен дә аты-юлы белән бик еракка җибәргән, «тирес кортлары» дип атаган. Киләчәккә матур хыяллары җимерелеп, һавадан җиргә төшерелгән кыз авылдашларының нәрсә теләгәнен бик тиз аңлады. Тагын бераз «кайдандыр килеп, монда хуҗа булырга маташкан акча капчыклары»н эт итеп сүгеп, иртәнге җидедә очрашырга сүз беркетеп, өйләргә таралышканда, җәйге таң атып килә иде инде.

Төнге оештыру эшләренең нәтиҗәсе булачагына бик ышанып, Илсөяр мыштым гына верандага кереп ятты. Иртәгә ничек тә әнисенә сиздермичә, (әтисенә белдерми калу мөмкин түгел, аннан ярдәм сорамый хәл итеп булмас) район үзәгенә барып, абыйсын коткарырга иде исәбе. Бөтенесе дә артта калгач, көлә-көлә әнисенә сөйләрләр, абыйсы да, әти-әнисе дә шундый эш майтарып чыгарганы өчен аны мактарлар! Илсөяр йокламаска бик тырышып ятса да, ничек изрәп киткәнен сизми калды. Аны борчылудан йөзе агарынган әнисе уятты.

– Абыең кайда? Төнлә нәрсә булды анда сезнең?

Иртән көтү куарга чыккач, Наҗия килеп, «төнлә кызы Гөлүзәнең егетен аларның Илсөяре, көнләшүенә чыдый алмыйча, абыйсы Ихсаннан кыйнаткан. Хәзер Ихсанның башы төрмәдә черриячәк икән. Егетнең, ягъни «чүт-ли не кияүнең», этисе шулай дип әйткән»ен сөйләгән.

Илсөяр әнисенә, төнлә нәрсә булганын бәйнә-бәйнә сөйләп, хәлнең ул кадәр үк куркыныч булмавын аңлатты. Бераз тынычланган кебек тоелса да, ананың күңеленә шом инде. Торып чыккан гаилә башлыгына вакыйганы бәян иттеләр. Мидхәт бер сүз дә әйтмичә тыңлады. Чынлап та шулай уйлапмы, хатынын тынычландыру өченме:

– Яшьләр сугышмый тормый инде. Каннары кайный, көчләрен кая куярга белмиләрдер, бездельниклар. Кирәк бит, кырык эш кырык җирдә кырылып ятканда, шул гына җитмәгән иде, – диде.

Ананың йөрәге урыныннан купкан иде инде. Ул баласының хулиганнарча сугышып йөрмәвенә ышана. Тик бүген ул сак астында. Кайда, кем белән утыра? Кешечә мөнәсәбәт бармы? Гаепсезлеген исбатлый алырмы? Ичмасам, Мидхәт тә берни әйтмичә чыгып китте. Кем белән бәйләнгән бит! Гади сугыш чукмары гына булса, бер хәл. Болар бит районда хуҗа. Кәгазьдәге хуҗа үзе дә алар кубызына бии. Теләсәләр, тик торган багананы да гаепле дип табып аударырга, юл читенә алып атарга мөмкиннәр. Алар йөргән юлда тормасын! Без үзебез дөрес юлдамы соң дип уйлап тормаячаклар.

Илсөяр, сәгать җиде тулганчы, сөйләшенгән урынга барып баскан иде. Бераздан, йокысызлыктан кызарган күзен уа-уа, Рафаэль дә күренде. Соңгы сәгатьләрдә Илсөяр өчен аннан да якынрак кеше юк. Әгәр ул булмаса, кичә яшьләрне җыеп та булмас иде. Бераздан тагын берничә кыз белән егет-малай күренде. Гөлүзә юк та юк. Көтекне Гөлүзәләргә җибәрделәр. Анысы биш минуттан әйләнеп кайтты.

– Хана, малайлаг, эш. Гөлүзә киге уйлаган.

– Бармыйм димени?

– Мин аның үзен күгмәдем дә. Минем сызгыгуым булды, Наҗияттәй килеп чыкты капкадан. Фугия кебек. Чыккан шәпкә бәгеп очыга дип тогам, малай. Бег кая да багмый ул, показания бигеггә аны милиция начальнигы үзе килеп алачак, олы Хәсәнов үзе шалтыгатып,лично үзем белән сүләште: «Зинһаг, Гөлүзә килеп бөтен дөгеслекне сөйләп бигсен, малай аякка басу белән шаулатып-гөгләтеп туй ясагбыз дип әйтте», – ди.

– Ишкән икән ишәк чумарын. Олы Хәсәновның Наҗиягә мәңге шалтыратасы юк. Ул шалтыратса, милиция начальнигына шалтыратыр. Эш Гөлүзәдә. Үзенең бай егетне ычкындырасы килмиме, әнисе туздырганмы? – дип үзе белән үзе сөйләште Рафаэль.

– Кирәктер инде Гөлүзә андыйларга, күп булса берәр төнгә.

– Кендекләргә байлык кирәк бит, мактанырлык сәбәп кирәк, – диештеләр яшьләр.

Ике җиңел машинага төялеп, район үзәгенә чыгып китмәкче булып җыенып кына беткәннәр иде, тузан туздырып яннарына Мидхәт килеп туктады.

– Нишләргә җыенасыз тагын? Майтарганыгыз җитмимени? – диде машина тәрәзәсен төшереп кенә.

– Без, әти, егетләрне яклап, милициягә барырга җыенабыз, – диде Илсөяр, үзен башлап сөйләргә тиеш дип табып.

– Дөресе ничек булганын сөйлибез, Мидхәт абый. Ихсанның бер гаебе дә юк анда.

– Йөрмәгез анда буталып. Сездән башка да чыгарырлар, гаепләре булмаса.

Мидхәт, ничек килеп туктаган булса, шулай кузгалып китте. Яшьләр ни әйтергә белми сүзсез калдылар. Илсөяр әтисенең болай кылануын һич аңламый, аңа үпкәләп, күз яшенә тыгылды. Башкалар да аптырап калды.

– Менә сиңа мә! Без аның малаен яклап бармакчы булабыз, ә ул...

Мидхәт, әйтерсең яшьләрнең күңелендәгесен ишетте, барган җиреннән шып туктады да машинасын артка биреп кенә кире килде. Бу юлы машина ишеген ачып, берни дә әйтми бераз торганнан соң:

– Ярар, егетләр-кызлар, алайса болай итик без: мин башта барып үзем обстановканы белеп кайтыйм. Ярдәм кирәк булса, сезне кайтып алырмын. Сөйләштекме? – диде. Илсөярнең иңеннән таулар төшкән кебек булды. Мидхәт аның:

– Әти, мин синең белән барам! – диюенә дә каршы төшмәде. Илсөяр башкаларга сиздерми генә Рафаэльгә төртеп алды. Егет аны сүзсез дә аңлап:

– Мидхәт абый, минем дә ГИБДДга барасы бар иде. Алмассыз микән? – диюенә:

– Утыр әйдә! – дигән җавап ишетте.

Арттагы ике урынга, рөхсәт тә сорап тормыйча, Ихсанның ике классташы – кичке вакыйганың шаһитлары менеп утырды. Мидхәт сүзсез генә кузгалып китте. Ул үзе дә улы өчен нык борчыла. Иртән әйткән, «Яшьләр сугышмый тормый», – дигән сүзләренә үзе үк башкача карый башлаган иде. «Кирәк бит кешесенә эләгергә! Бу инде безнең замандагы ике урам сугышы түгел. Ул вакытларда кызлар өчен тәпәләшеп алалар иде дә бергә утырып тәмәке тартып, дуслашып кайтып китәләр иде. Хәзер заманалар башка шул. Кешеләр дә башка».

Ял көне булгангадыр, полиция башлыгы эш урынында юк иде. Дежурный аңлаешлы бер сүз дә әйтә алмады. Мидхәт, полиция башлыгы белән моңа кадәр үзара яхшы мөнәсәбәттә булганга, ни булса да куып чыгармасына өметләнеп, туры өенә барып керергә җөрьәт итте.

– Мидхәт абый, аңлавын бик яхшы аңлыйм мин сине. Тик, ситуация белән ныгытып танышмыйча, һичшиксез, булышырмын дип сүз бирә алмыйм. Сәбәбен үзең дә аңлыйсыңдыр. Турыдан-туры гаебе булмаса, тикшерү озакка бармас анысы, тиз чыгарырлар. Тик бүген түгел инде.

– Аның гаепсез икәнен шунда булган иптәшләре раслап тора. Ул аерырга гына кергән. Мин, шаһит кирәк-фәлән булса дип, бер-икесен утыртып та алып килдем.

– Мин дежурныйга шалтыратып әйтермен. Күргәннәрен дөп-дөрес итеп язып калдырсыннар. Кирәк булсалар, кабат үзебез чакыртырбыз, – диде баш тәртип сакчысы.

«Әйе, үзегезгә кирәктә башкачарак сөйләшәсез сез. Безгә кирәк булса гына...» Мидхәт, сабырлыгын югалтмаска тырышып, машинасына чыгып утырды.

– Нәрсә диде, әти? – дип сорады Илсөяр, әтисеннән беренче сүзне көтеп ала алмагач.

– Хәзергә берни дә.

Егетләр, күргән-белгәннәрен мөмкин кадәр авылдашлары файдасына язып, анык кына берни дә белмичә, кире авылга кайтып киттеләр. Мидхәт: «Эшләрем бар», – дип кайтмый калды. Дөресе: ул алга таба нишләргә тиешлеген белми иде. Полиция башлыгының булышырга ашыкмавы аның ачуын китерде. Аңа

ял көне булса да, авылдагы ничә гаиләнең тынычлыгы югалганын аңларга була бит. Аннары Мидхәт башлыкны үзе үк аклап куйды: «Синең өчен ЧП булса, алар өчен гадәти хәл бит инде. Берәү дә үлмәгән, олы җинаять кылынмаган. Тикшерерләр дә кайтарып җибәрерләр. Менә басудагы эш туктап тора. Бүген комбайннарны уракка әзерләүне оештырып җибәрәсе иде бит ул. Ихсанның бүген анда булуы һава кебек кирәк».

Запчасть кибетләреннән кирәк-ярак җыеп, тынычланырга тырышып, берике сәгать вакытны сузгач, Мидхәт тагын полициягә сугыласы итте. Дежурный белән сөйләшеп, улы белән очрашырга иде исәбе. Ә анысы:

– Бу мөмкин түгел. Мин тәртип бозуга бара алмыйм, – дип кырт кисте. Мидхәтнең башын иеп чыгып китүдән башка чарасы калмады.

## БИШЕНЧЕ КӨН

Сабира бу хәбәрдән аптырап калды. Ничек инде, бөтен шау-шуга сәбәпче Тәбрисне чыгарганнар, бер гаепсез Ихсанны – юк?

– Тагын үзем бармый булмас, ахры, – диде Мидхәт. – Тәбриснең үзен күрим дә Актайны әйләнеп кайтыйм әле. Ә син алдан ук борчылып, үз-үзеңне бетермә. Бүген чыгармау утыртып кую дигән сүз түгел бит әле ул.

Мидхәт Тәбриснең туры өенә барып керде. Ул кергәндә, тавышын бөердән чыгарып, өйдәгеләргә нидер сөйләүче егет, Мидхәтне күрүгә куырылып килгәндәй булды. Ирексездән Мидхәтнең башыннан: «Нәрсәдер чиста түгел монда», – дигән уй сызылып үтте.

– Йә, герой, ниләр булып бетте анда сезнең? Нигә Ихсанны чыгармадылар?

– Мин ничек булган, шулай сөйләп бирдем. Гаебемне таныйм, салган баштан кызып кителгән, дидем. Ә Ихсанны нигә чыгармаганнарын әйтә алмыйм, Мидхәт абый. Допростан бик кызып кайткан иде ул.

Тәбрис нигәдер күзгә карап сөйләми. Кечкенә генә елтыр күзләре, тукталыр нокта эзләгәндәй, әрле-бирле йөгерешә.

– Бәлки, башкачарак булгандыр, уйлап кара әле, егет.

– Башкача дип... Мин нәрсә кушсалар, шуны эшләдем. Ихсан андагылар белән бәхәсләшкән бугай. Минем бер гаебем дә юк, Мидхәт абый, валлаһи менә, баскан урынымда җир йотсын.

– Чамалап сөйләш, чыннан да йотуы бар!

Машина район үзәгенә тәгәри. Чакрымнарның саны булса да, ирнең башындагы уйларның чуты да, рәте дә юк. Соңгы көннәрдәге тынгысызлык йокыдан калдырды, хәлне алды. Әле дә күргән-ишеткәнен күз алдыннан үткәреп бара.

Мидхәттә Тәбрискә карата җирәнүгә охшаш бер хис туды. Сәбәбен хәзергә үзе дә аңлатып бирә алмас иде. Хәтерендә күп еллар элек булган бер вакыйга яңарды...

...Ата – улны, ана кызны белми торган 90нчы еллар иде. Мидхәт колхозда агроном булып эшли. Ничек тырышса, нинди яхшы уңышлар алса да, хуҗага эш белән ярап булмый. Идарә карары белән билгеләнгән премиясен бирмәс өчен, председатель чираттагы тапкыр төрле сәбәпләр табарга маташа. Мидхәт ул көнне дә хуҗаның затлы кабинетыннан ярсып чыгып бара иде, ишек кемгәдер каты гына бәрелде. Караса, ишек артында маңгаен уып, амбар мөдире Рахил басып тора. Мидхәт чыгуга, ул елгыр гына ишеккә чумды. Ә аннары озак та үтмәде, урамда Мидхәтне куып җитте.

– Әй, туймаса да туймас икән бу адәм баласы. Күсәкне әйтәм (авылда

хуҗаның кушаматы шундый иде), ел тәүлеге колхозга бил бөккән кешеләрнең кадерен кайчан белә башлар бу?!

– Белер, көт! Андыйлар кеше кадерен белүнең ни икәнен күптән онытkан инде. Аларның корсакларын гына түгел, намусларын да, хәтерләрен дә май баскан. Ничава, элекке заман түгел, бер очы чыгар әле.

Бу сөйләшүне Мидхәт онытkан да булыр иде. Дүшәмбе көн идарә утырышында үзенең сүзләре, ноктасы-өтере дә югалмыйча, төкереккә манчылып, хуҗа авызыннан кире үзенә кайткач, Рахилнең кем икәненә төшенде. Рахил Тәбриснең әтисе иде.

«Уеннан уймак чыккан, ахры, монда. Әллә эш бөтенләй Ихсанда түгелме? Кемнең канына тоз салды соң әле ул үзе соңгы вакытта? Кемнең бугазына сөяк булып утырды?»

Мидхәткә эшне алып баручы тикшерүчене табуы кыен булмады. Кичәле-бүгенле генә диплом алган яшь егет. Аны үзеннән өлкәннәр белән әдәпле сөйләшергә өйрәтмәгәннәр. Монысы беренче минутта ук аңлашылды.

– А-һа, геройның влиятельный әткәсе килеп тә җитте. Ким дигәндә ун ел төрмә көтә сөекле улыгызны! Хокук саклау хезмәткәрләренә каршылык күрсәткән өчен җиде елга кадә-ә-ә-әр, бер гаепсез кешеләрне авыр тән җәрәхәтләренә китергән кыйнау оештырган өчен дә өстәгә-ә-ә-әч... Йә кесәгезне бераз юкартасы була инде, абзый кеше.

Тикшерүче ике кул бармакларыннан рәшәткә ясап күрсәтте. Мидхәтнең бугазына төер килеп тыгылды, тыны кысылды. Бу яшь әтәч белән сүз көрәштереп тору мәгънәсез эш икәне болай да аңлашыла иде. Алай гына да түгел, чал башын иеп, аннан үзен тыңлавын, ситуацияне аңлатып бирүен үтенүне үзе өчен түбәнсенү дип санады. Әтисе еш кына: «Аюны җиңгән ярты ир, ачуын җиңгән бөтен ир», – ди торган иде. Күз аллары караңгыланганны сизеп, кабинеттан борылып чыгып китте.

Мидхәт туп-туры полиция башлыгының кабинетына юнәлде. Тик «иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас» дигән кебек, анысын да урынында тота алмады. Ишегалдына чыгып: «Инде ни хәл кылырга?» – дип басып торганда, машина белән үзләренең авыл егете Илдар күренде. Ул берничә ел инде хокук саклау органнарында эшли, яшенә күрә званиесе дә бар. Мидхәт фикеренчә, Илдар – төпле егет. Мондый очрашуга сөенеп, Мидхәт Илдарга каршы барып кул сузды, үзенең гозерен аңлатмакчы булып сөйли башлаган иде, Илдар аны бүлдерде:

– Мидхәт абый, мин барысын да беләм. Бу аяк өсте генә хәл ителә торган нәрсә булып чыкмады әле. Әйдә, бер сәгатьтән «Ядкарь» кафесы янында очрашыйк. Шунда сөйләшербез. Хәзер үк булдыра алмыйм. Кичектерә алмый торган эшләрем бар.

Мидхәт бер сәгатьне көчкә уздырды. Бик гади генә тоелган эшнең нинди борылыш алып катлауland катлаулануы мөмкин? Ата үз улын яхшы белә: Ихсан акылсыз егет түгел, уйламыйча берни дә кылмас. Дөрес, үзенә охшап, хакыйкать эзләп маташа торган гадәте бар анысы, күрәләтә оятсызлана башласалар, кискен итеп җавап бирергә дә мөмкин. Тик дөреслек эзләүнең туры юллары һәрвакытта да кирәкле нәтиҗәгә китермәгәнен үз тиресендә татыганы юк. Тормыш тәҗрибәсе сайрак, китапчарак эш йөртергә ярата.

Илдар сүзендә тора белүчеләрдән булып чыкты, бер сәгать узды диюгә, кафе янына килеп тә туктады.

– Ну кыздыра бүген тагын. Әйдә, күләгәлерәк җиргә кереп утырыйк әле,

Мидхәт абый, – диде дә түбә астына тезелгән өстәлләрнең иң аулагына юнәлде. Салкын минераль су эчеп, сусавын бераз баскач, Илдар төп сүзгә күчте:

– Алдан ук әйтеп куям, Мидхәт абый, бер куркыныч нәрсә дә юк. Нервыларыңда уйнап алырлар алуын. Анысына әзер булсагыз иде. Әйт әле дөресен генә, «Кызыл көч» белән мөнәсәбәтегез, Хәсәнов белән дип әйтүем, ничегрәк?

– Ничек дип, Гали – үз эшендә, Вәли – үз эшендә. Очрашканда, эш турында сөйләшәбез, кунакка йөрешкән юк. Бер-ике тапкыр техника белән ярдәм итүен сорап кердем – булышты. Баштагы мәлне, инвестор кергәндә, бераз проблема булып алган иде инде. Мөстәкыйль булып калуымны яратып бетермәделәр. Аннан соң ничә ел узды бит инде. Аннары ул чагында Хәсәнов та түгел иде әле.

– Шуннан башка берни дә булганы юк дисең инде. Син әһәмият бирмәгәнсең генәдер. Хәсәновка ошамастай нәрсәләр булды бугай инде. «Кызыл көч»некеләр: «Нигә безнең хезмәт хакы түбән? Пай җирләренә түләү юк», – дип кызып йөргәннәрен хәтерлисеңме? Ул чагында бит үзләрен синдә эшләүчеләр белән чагыштырып күрсәттеләр. Мисалга, синекеләрнең зарплаталарын китерделәр. Җиргә керде инвестор, ә авылны эш белән тәэмин итә алмый. Пайларын кире сорап йөрүчеләр бар. Хәсәновның ачуын китерердәй сәбәп дип уйламыйсыңмы моны?

– Мин котыртып эшләнгән эш түгел бит болар берсе дә. Аннары Ихсан белән булган хәлне моңа ничек бәйләп була?

– И Мидхәт абый, авылдан торып, бәлки, мондагы хәлләр ачык күренмидер дә инде. Алар бит берсе белән берсе бәйләнеп беткән. Син малаеңны утыртып куйганны иртән генә белдең әле, шулаймы? Ә аның язмышы син йокыдан торганчы хәл ителгән иде инде.

– Ничек? Барыбер аңламыйм.

– Авылдан тукмалып чыгып качуга, Хәсәновның малае шунда ук әтисенә шалтырата. Бу вакытта безнең начальникның «олигарх» дачасында шашлык кимергән чагы була. Әлбәттә инде, төяп алып килгән авыл егетләре арасында кемнең кем икәне бик тиз ачыклана. Хәсәновка теге коры куык Мәҗнүн кирәкмени? Ун елга утыртып куябыз дигәнне ишетүгә, нәрсә кушсалар, шуны язып кул куя да аны чыгарып җибәрәләр. Калганнарыннан сорау алу тәк, исеме өчен генә эшләнә. Тәбрисне – төп шаһит итеп, аның күрсәтмәләренә нигезләнеп, бөтен гаепне Ихсан өстенә өеп куялар, ягъни аннан сугышны оештыручы ясыйлар. Эшнең ак җепләр белән тегелгәне юләргә дә аңлашыла, шулай да азрак сезне эштән аерып, чәчләрегезне агартырга сәбәп булырга ярап тора. Хәзер аңлашылдымы инде, Мидхәт абый?

Мидхәт эндәшмәде. Ишеткәннәр аның башына сыймый иде. Ни өчен? Хәсәновка ни зыяны тиде аның? Кызык өчен генә кеше язмышы белән шулай уйнап буламы? Тук песинең мескен тычкан белән шаяруы кебек.

Тиздән уракка төшәргә кирәк. Комбайннар әзер түгел. Корылыктан вакытсыз өлгергән игенне тиз генә җыеп алмасаң, ансыз да калуың бар. Ә ул монда талантсыз язылган комедиядә катнашып йөри.

– Илдар, син сөйләгәннәрнең дөреслегенә шикләнергә минем сәбәбем юк. Син шул кухня кешесе, нинди киңәш бирәсең: алга таба нишләргә, нинди адым ясарга миңа?

– Алдыңда ике юл, Мидхәт абый. Беренчесе – баш иеп, берни белмәгәндәй Хәсәновка бару, Ихсанның бу эше яшьлек юләрлеге генә икәнлеген аңлатып бирү, аның бик үкенүе турында әйтеп ярлыкауны сорау. Аннары ул

коллегасының хәленә керә, малаеннан гаризаны кире алдырта. Икенче юл – әйбәт адвокат табып, улыңның гаепсез икәнен исбат итү. Аннары, Мидхәт абый, Ихсан кызулыгы белән эшне бераз катлауландырып куйган. Ялганга түзә алмыйчадыр, тикшерүчегә каршылык күрсәтеп, янап та алган. Шуңа күрә башкаларны чыгаргач та аны сак астында калдырганнар. Андый вакытта сүзне аеруча уйлап сөйләшергә кирәк шул. Һәр сүзең үзеңә каршы эшләргә мөмкин.

– Ихсан белән күрешә аламмы?

– Юк, рөхсәт итәрләр дип уйламыйм, Мидхәт абый.

– Соңгы сорау, энем: син боларны каян бик төгәл беләсең һәм нигә миңа сөйлисең?

Илдарның йөзенә сәер елмаю чыкты, аннары Мидхәткә карап көлеп куйды.

– Беләм, чөнки мин боларны белергә тиеш. Ни өчен әйтәмме? Моның ике сәбәбе бар. Беренчесе – мин сезнең намуслы кеше икәнегезне беләм, хөрмәт итәм. Икенчесе – бу уендагы кайберәүләр минем менә монда утыралар инде. – Илдар кулы белән бугазын сызып күрсәтте.

## АЛТЫНЧЫ КӨН

Ихсанны утыртып куйганнарына атна тулырга бара. Сабираның кулыннан эш төште. Көндәлек эшләрне үзен мәҗбүр итеп кенә башкарып йөри. Җәйге ялда булса да, эшенә дә барып килергә кирәк. Анда бакча балалары бар бит әле. Укырга керәсе балаларның ата-аналарын тагын бер тапкыр күреп сөйләшәсе бар. Ремонтка да керешелмәгән. Җәйге ялда үзен алыштырган Рәйханә белән киңәштеләр дә, укучыларның ата-аналары белән сөйләшеп, әкренләп бояу эшенә тотынырга булдылар. Буяуны Сабира үз акчасына алып тормакчы. Җае чыккач, берәр ничек кайтарыр әле.

Сабира үзен озатырга чыккан Рәйханәдән сорыйсы итте:

– Атласның хәле ничек икән соң? Белешкәнең юкмы?

– Белешмәгән ди инде, Сабира апа. Көн саен Алмаздан хирургия бүлегенә шалтыраттырам. Хәле бик шәптән булмаса да, реанимациядән чыгарганнар инде. Кулына ясалган операциясе уңышлы булган ди. Оча сөягенә кире ясарга туры килмәгәе дип әйтә ди врачлар.

– Янында микән соң Венерасы?

– Белмим шул. Баладан сорый алмыйм бит инде. Үзе аны-моны әйтми.

– Шалтыратып, врачлар белән үзеңнең дә сөйләшәсең бар. Ни дисәң дә, балаларыңның атасы, ничә ел гомер иткән ирең. «Кеше булдыра алган иң бөек гамәл – кичерү», – дип әйткән ди бер акыл иясе. Кичер син аны. Хыянәте өчен аласы җәзасын алды инде ул. Үзеңнең дә күңелеңә җиңелрәк булып китәр.

Рәйханә җавап бирмәде. Сабира саубуллашып китеп барды. Аның соңгы атнада урамга чыкканы да юк диярлек. Чыкса, барысы да улы турында сорашып, йөрәген яралар кебек. Качып та ята алмыйсың. Хатын хуҗалык товарлары сатучы шәхси кибеткә юнәлде. Кибеттә булган буяуларны карады. Җитмәгәненә заказ бирде дә, эреле-ваклы пумалаларны сумкасына тутырып, өйгә кайтырга чыкты.

Соңгы көннәрдә күктә болытлар күренгәли. Тик бер тамчы яңгырның да төшкәне юк. Телевизордан гарасатлы яңгырлар яуганы, килгән зыяннар турында көн дә сөйләп торалар. Озак торган кызу көннәрдән соң шифалы тыныч яңгырлар – бик сирәк хәл. Сабираның соңгы вакытта интернетка кереп, алдагы көннәрдә көтелгән һава торышын да караганы юк икән. Ихсан турында борчылулар барысын да арткы планга күчерде. Ник әллә нишләп бетми шунда барысы! Улы гына бу нахак бәладән тизрәк исән-имин котылсын!

– Сабира апа! Сабира апа, дим, туктап тор бер генә минутка!

Тавышка сискәнеп артка борылып караса, Кәринә йөгерә икән. Кәринә – авылда яңа кеше. Мөсәгыйт агай белән карчыгы бер-бер артлы үлеп киткәч, шәһәрдәге малайлары туган йортларын риэлторлар аша шушы хатынга сатып җибәрде. Үзләре хәтта кайтып та карамады, диде күршеләре. Карт белән карчыкның әллә ниләре булмагандыр булуын. Шулай да туган-үскән нигездә җанга якын ни дә булса каладыр дип тә уйламаганнар икән. Таш арасында яшәп, күңелләрнең катылануы шулдыр инде.

– Уф, Сабира апа, көчкә куып җиттем. Яшьләргә биргесез икән әле үзең.

Кәринә үзе әйткәнгә үзе куангандай авызын ерып җибәрде. Тәмәкедән саргаеп беткән тешләре арасыннан кичәге кәеф-сафа сасысы аңкып чыкты. Сабира артка чигенеп куйды.

– Иртүк торып, бүген урманга җиләккә мендем. Кура җиләге быел, Сабира апакаем, учлап җыярлык менә. Олы кеше үзе җыеп йөри алмый торгандыр, мәйтәм. Сатам, алмыйсыңмы соң? Сиңа арзанга гына бирәм. Бераз акча җыеп, Мишага мәктәп киемнәре алып булмасмы, дим. Үзегез матур киендереп йөртергә кушасыз бит.

Кәринә тагын авызын ерып хихылдады.

Кәринәнең берсеннән-берсе бәләкәй өч баласының олысы былтыр укырга керде. Беренче сыйныфка кемнәндер калган, ике-өч үлчәмгә зур костюм белән килде малае. Җиләге өчен акча бирсәң, аракы алып эчәчәк, малай тагын шул искесе белән йөриячәге көн кебек ачык. Җиләген алсаң ярар иде. Үзенең, чыннан да, урманга йөреп җиләк җыярлык мөмкинлеге юк. Мидхәт тә кайнатмасын ярата. Кышка киптереп куйсаң да әйбәт булыр иде. Тик бу сәрхушның кулына акча бирәсе килми. Нишләргә соң әле?

– Ярар, Кәринә, болай итәбез. Әле көн иртә. Мин хәзер чиләгеңне бушатып бирәм дә тагын бер чиләк җыеп төш. Аннары чутлашырбыз. Сиңа – акча, миңа – җиләк.

– Әй рәхмәт, Сабира апакаем! Тик син баш төзәтерлеген хәзер үк бирерсең инде, яме.

Башы төзәлеп кәефләнгән Кәринә чиләген тутырып кайтканчы, Сабира аның улын кибеткә җитәкләп барып, яңа костюм алып куйган иде инде. Малайның куанычының чиге булмады. Ике чиләк җиләк өчен түлисе акча җитеп тә бетмәде әле, үзенекен өстәде. «Мескен сабыйга хәердән булыр әйдә», – дип уйлады хатын. Укытучының хәйләсенә төшенгәч, Кәринәнең ачуы чыкты чыгуын, шулай да теле белән әйтергә намусы кушмады.

– Менә тагын өч йөз сум акча сиңа. Балаларыңа ризык алып кайт. Иртәгә тагын бер чиләк җыеп китерерсең. Тик ятмыйча дөрес эшлисең, Кәринә. Ходай бушка биргәндә файдаланып кал. Кыш көне кар астыннан табып булмас, – диде Сабира хатынның салпы ягына салам кыстырып. Кәринә, буш чиләге белән акчасын кыстырып, кибеткә чапты.

Кәринә үзе татар хатыны булса да, теле ташка үлчим. Фатир өчен түли алмыйча, «риэлторлар ярдәме белән» авылдагы иске өйләргә кайтып урнашкан аның кебек тагын берничә гаилә арасында татарча беравыз сүз белмәгәннәре дә бар. Шуларның берсе узган ел «татарча белмәгән өчен генә баласының укуы начар булуына борчылып», русча укытуларын таләп итеп, мәгариф бүлегенә барган иде. Завроно Сабираны чакыртып алды. Ата-ананың таләбе хаклы булуы, шартлар тудырылырга тиешлеге турында лекциянең ахырын тыңлап бетерергә Сабираның сабырлыгы җитмәде:

– Роберт Альбертович, бу гаиләне авылга – татар авылына сез чакырып кайтардыгызмы?

– Нишләп мин кайтартыйм ди аларны.

– Менә мин дә кайтартмадым. Ул – ялкаулыгы аркасында, бер тамагын тыя алмыйча эчеп, шәһәрдәге фатирларын югалтып кайткан хатын. Олы балаларын карамаганга күрә, ана хокукыннан мәхрүм ителгән инде ул. Бу бала – фәләненче ирдән. Мәктәпкә килгәндә, сумкасын да, кием-салымын да авыл эшмәкәрләре алып бирде. Рәхәт бит хәзер: хатыннар ана капиталы өчен бала ташый, көне-төне эш дип чапкан кешеләр аларның балаларын мәктәпкә әзерли. Бу хатынның да баласы ничек укуы турында кызыксынганы юк. Баласы белән утырып берәр тапкыр дәрес хәзерләтсен иде хет! Иртән чәен эчертеп, мәктәпкә озатсын иде – юк бит! Ә монда килә белгән. Дәүләткә бер тиенлек файда китермәгән сорыкортлар семьялыгыннан ул. Аннары, рус авылына күчеп килгән татар баласы өчен берәр җирдә татарча укыту оештырылганын күргәнегез бармы Сезнең?

– Алай тирәнгә китмик инде, Сабира Хәмитовна. Безнең эш сәясәт түгел, балалар укыту. Балалар, кемнеке булуына карамастан, тигез хокуклы.

– Мин дә шулай дим, Роберт Альбертович. Ун татар баласы бер килмешәк хакына туган телдә белем алудан мәхрүм ителергә тиеш түгел. Математик булсам да, туган тел язмышына ул дәрәҗәдә битараф кеше түгел әле мин. Сезгә дә киңәшем шул.

Шушы сөйләшүдән соң Сабираның күңелен нидер талап, борчып йөри. Уку елы башланганчы әлеге темага әйләнеп кайтачакларын эчке тоемлау белән сизә.

Сабира, өйгә кереп, телевизорны ачты. «Хәбәрләр» тапшыруы башланды. Тагын бер чиновникның казна акчасын үзләштерүе фаш ителгән икән. Миллиардлап кына урлашалар хәзер. Вакланып тормыйлар. Күптәннән игътибар итеп килә Сабира: тотылучылар турында күп сөйлиләр, ә шул акчаларның дәүләткә кире кайтарылуы турында әйткәннәрен бер тапкыр да ишеткәне юк. Кайтарылмый микән, кайтарылуы турында әйтеп тормыйлар микән? Шулай дип сорагач, өйдәгеләр аннан кычкырып көлде хәтта.

– Шушы яшькә җитеп, балаларча самими булып кала алуыңа сокланам мин синең, әнием, – диде Илсөяр, тәгәри-тәгәри көлеп туктагач.

Көтү кайтырга иртәрәк. Сабира, өстен алыштырып, җиләк чүпләргә утырды. ТНВ каналын ачты. Анда концерт бара икән. Тавышы да, озынрак күлмәк алырга акчасы да булмаган кыздан соң, Раяз Фасыйховны куйдылар. Аны тыңларга була. Сабира бигрәк тә Раяз башкаруында «Кыр казлары» җырына мөкиббән. Бәгырьләрне актарып, күңелләрне иләсләндереп, әллә кайларга алып китә ул җыр. Йолдыз чире йоктырып, артыгын кылана гына башламасын. Таланты бар егетнең.

Концерт бетүгә, республика хокук органнары турында тапшыру башланды. Соңгы көннәрдә бу даирә кешеләренә ачуы ташып тора Сабираның. Шуңа тапшыруның һәр сүзенә бәйләнеп, сөйләгәннәренә ышанмыйча, игътибарсыз гына тыңлап утыра иде, таныш исем-фамилияне ишетүгә, ялт экранга күтәрелеп карады. Экранда – кайчандыр җанга бик якын булган, төн йокыларын качырган Булат Ганиев иде. Еллар үз эзен тирән итеп салырга тырышса да, йөз чалымнары бик таныш, сөйләү рәвеше, кул хәрәкәтләре дә нәкъ шул ук. Ул Казандагы криминаль хәлләргә аңлатма бирде. Экраннан нәрсә сөйләгәннәрен Сабира аңламады, аңларга да тырышмады. Ул бары Булат атлы кешенең экрандагы сурәтеннән үзенең үткәннәрен эзли иде. Тапшыру озакка бармады.

Журналист Булат Ганиевның вазифасы һәм эш урынын кабатлап әйтте дә икенче темага күчте.

Булат, Булат... Менә нинди икәнсең син хәзер. Озак еллар бу исемне очратырга мөмкин булган бөтен җирдән эзләп барса да, бүгенге көнгә кадәр таба алганы булмады. Очратса да, берни дә эшләмәс иде. Бүгенге кебек: «Менә нинди икәнсең син хәзер!» – дияр иде дә хәтеренең иң ерак, кадерле истәлекләрне генә саклый торган урынына салып куяр иде. Казанга барса ничә еллар, күзләре гел аны эзләде. Соңгы елларда гына бу «чир»дән арынып килә. Югыйсә, Булат белән мәхәббәт тарихына нокта куючы Сабира үзе булды. Үзе китте. Яратып китте. Нәкъ Равил Фәйзуллин әйткәнчә: «Туеп кем дә китә, ә син яратып китеп кара...»

Тормыш тарафыннан яшьлегендә дә хисләр белән түгел, акыл белән яшәргә мәҗбүр ителгән иде Сабира. Тормышы авыр булса да, горур иде. Аңа җебеп төшәргә, мескенләнергә ярамый, үзе өчен ул һәрвакыт үзе хәл итәргә тиеш иде.

Сабира, сыерын савып, сөтләрне урнаштырып йөргәндә, Рәйханә килеп керде. Ремонт хакындагы иртән башланган сүзне дәвам итеп, алга планнар кордылар. Рәйханә: «Ихсан турында яңалык юкмы?» – дип сорашты. Аннары чыгарга кузгалды. Тик үзе чыгып китми: нәрсә турындадыр әйтәсе киләме, Сабираның нидер әйткәнен көтәме?

– Алмаз ни белән шөгыльләнә соң әле бу арада? Күзгә-башка күренми, – дигән булды Сабира, сүзнең очын ялгар өчен генә.

– Сабира апа, мин синең янга киңәшкә кергән идем бит. Үз хәсрәтең дә җитәрлек дип әйтергә кыенсынып торам. Алмаз бүген больницага шалтыраткан. «Әтиеңнең янында карарга бер кеше дә юк. Әниең ике көн инде килеп күренми. Ул бит үзе берни дә эшли алмый. Кем дә булса карарга килсен», – дигәннәр. Улы дигәч, теге шакшыныкы дип уйлаганнардыр инде. Ә ул, дөрес булса, авылда да юк икән. Монысын бакчада нянечка Гадилә апа әйтте.

– Гарип ир кирәк түгел инде аңа. Чыгып качкандыр алайса, тегендә дә, монда да булмагач.

– Алмаз: «Әтине карарга үзем барам», ди. Иртәгә илтеп куярмын инде. Үзе янына кермәсәм дә, врачлар белән дә сөйләшермен.

– Керсәң дә берни дә булмас. Ул синең законлы ирең ләбаса. Сездән башка бер якын кешесе дә юк аның. Ярый әле ата-анасы бу хәсрәтләрне күрми, мәрхүмнәр. Җаннары җәннәттә булсын инде.

– Әйе, оят өстенә кайгыны күтәрә алмаслар иде. Бигрәк тә әнкәй. Атласны соңгы көнгә чаклы сабыйны яраткандай яратты бит ул.

Рәйханә, күңеленнән уй-юшкыннар бераз юыла төшкәндәй, җиңел адымнар белән чыгып китте.

– Ярата, һаман өзелеп ярата. Ахыры хәерле генә бетсен, Ходаем.

## ҖИДЕНЧЕ КӨН

Кичә Мидхәт, Казанга барып, Ихсан өчен адвокат сөйләшеп кайтты. Казандагы дуслары тәкъдиме белән сайланган тәҗрибәле белгеч дүшәмбедән эшкә керешергә тиеш. Мидхәт ике арада чәбәләнә. Монда уракка төшәр вакыт җиткән. Эшлисе эшнең очы-кырые күренми. Соңгы көннәрдә юлдан кайтып та кергәне юк. Юллар озын. Уйлар тагын да озын һәм буталчыграк. Ә ул уйларының очына чыга алмый. «Бу дөньяда гаделлек бөтенләй дә калмадымыни соң? Гаеплеләр тыныч кына рәхәт чигеп яши бирәләр, гаепсезләр газап чигә; намуслыга тормыш итәр өчен җиде кат тир түгәргә

кирәк, намуссызларга, тагын да ныграк баер өчен, оятларын югалтып тору да җитә. Үзеңне, якыннарыңны гаделсезлектән яклыйм дисәң дә, акчасыз булмый. Гаделлекне акчага сатып алган кебек була. Бер логикага да сыймый бит бу!»

Сабира өй тирәсеннән читкә китә алмый. Телефон шалтыраса, тизрәк трубкага ябыша: Камилләрдән хәбәр бармы, әллә Ихсан шалтыратыр җай тапканмы?

Кичә Вахитны җирләделәр. Ялган аракы эчеп агуланган, диделәр. Төштән соң эчеп кайтып яткан. Икенче көнне иртән әнисе: «Нишләп бу бала бер дә селкенми дә йоклый соң?» – дип барып караса, суынып беткән булган инде. Көннәр эссе. Мәетне озак тота торган түгел. Шул көнне үк җирләделәр. Авылда ялган аракы сатучының кем икәнен дә беләләр, чара күрүче генә юк. Күрәсең, кемнәргәдер файдалы.

Мәктәптә буяу эшләрен башладылар. Һаман баласы яхшы укыган ата-аналар йөри. Кәринә кебекләргә синең мәктәбең ни дә... Шулай үтә көннәр.

Рәйханә – больницага барып кайтканнан бирле икенче кеше. Монда – хуҗалыгы, ике баласы, тегендә – хыянәте белән бәгырьләрен телгәләгән булса да, бүгенге көндә аның ярдәменә мохтаҗ ире. Кемнеңдер ярдәменә өметләнә торган түгел.

Атласка операцияне яңадан ясадылар. Кем дә булса янында булырга тиеш. Яткан килеш кулы белән нидер эшли алса да, утырып та тора алмый, аякка басу турында уйлыйсы да юк. Тулысынча кеше кулына карап ята.

Рәйханә, беренче тапкыр больница капкасыннан үткәндә, Атлас янына керермен дигән ныклы карарга килмәгән иде әле. Дәвалаучы табибын күреп сөйләшкәч, керәсе итте. Палата ишегең ачуга, койка белән тулы бүлмәнең кайсы почмагында ире ятканын тиз генә абайлый алмый торды. Түрдәге койка янында улы торып баскач кына, андагы авыруның Атлас икәненә төшенде. Чәчләре яртылаш агарган, күзләре эчкә баткан, йөзе саргайган кеше аның иреме? Гәүдәсенең күп өлеше марляга уралган. Әнисенең халәтен аңлап, Алмаз әтисенең өстенә җәймә япты. Рәйханә якын килеп иренең күзләренә карауга, җан газабы, рәнҗеш белән узган соңгы ел хәтердән югалып торгандай булды. Ул койка янындагы урындыкка утырды, Атласның, бармакларын гына калдырып, терсәгенә кадәр гипс белән катырып куелган кулын учларына алды. Атлас хәлсез генә аның кулын кысты. Монда сүзләр артык иде.

Авылга кайтырга чыкканда, Рәйханә ни булса да ирен ташламаячагын ачык белә, алга таба гарип ир белән тормышны ничек корырга дип уйлана иде инде.

## СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

Уракка төшкәнче яхшы гына бер яңгыр яуса иде дигән өметләр акланмады. Кояш җәй башында ничек кыздырса, шулай кыздыра. Болында маллар ашарлык яшеллек калмады. Үзләре ябыктылар. Алардан сөт өмет итү хәтта оят кебек. Авыл халкының мал тотканы пошаманда. Утарга кайтып кергәч, тегесен-бусын мал алдына салалар салуын, тик ел тәүлеге кулдан ашатырга калса, мал тотуның ни файдасы кала соң? Атлас авариягә эләккәннән бирле сөт җыюның да рәте китте. Алып киткәненә әле ачыган, әле майлылыгы түбән дип юньләп түләмиләр. Сыер тоткан хуҗалыклар өчен әйбәт кенә бер ярдәм иде – ул да бетте.

Мидхәт авыл хуҗалыгы идарәсеннән кәефе кырылып кайтып керде. Ашлыкка куелган якынча бәяләрне белеп кайткан. «Комбайн яңарту турында хыяллар быел да юл тузаны кебек җилгә оча икән болай булгач. Керем чыгымнарны да капларга җитмәячәк», – дип ачынып уйланды ул. Эксплуатация

срогы күптән узган комбайннарны басуга чыгарлык итәр өчен күпме суммалар кереп киткәнен үзе генә белә.

Ихсанның эшендә дә яңалыклар юк. Адвокат, килеп, әллә ни кыра алмыйча, коры өметкә таяндырып китеп барды.

Ире кайтып керүгә, Сабира аның күзенә карый. Бүген дә өметләнеп төбәлгән карашы җавапсыз калды. Димәк: «Сөенерлек бер сәбәп тә юк, сорашып тормасаң да була», – дигән сүз инде бу.

Мидхәт тиз генә ашады да комбайнчылар янына ашыкты. Сабира өйдә тагын үзе генә калды. Иптәшкә – балалары турындагы бетмәс-төкәнмәс уй. Камилләр белән көн саен сөйләшеп торалар, шөкер. Интернетны күпме сүксәләр дә, тормышны аннан башка күз алдына да китереп булмый хәзер. Аралашуны никадәр җиңеләйтә. Элекке сыман атналар-айлар буе хат көтеп утырасы юк. Ерак Көнчыгышта кич булганда, аларда көн. Сабира, килене белән сөйләшеп, хәлләрен белде. Камил өйдә түгел. «Өйрәнүләр бара, Мәскәүдән зур кешеләр көтәләр», – диде килене. «Хатынының тулгагы башланганда, өйдә генә булса ярар иде, беренчесе бит, нишләргә дә белмәс», – дип борчылып куйды каенана. Югыйсә, борчылырлык сәбәп тә юк. Мәликә – үзе шәфкать туташы. Тирә-ягында күршеләре яхшы, диделәр Тик барыбер өтәләнергә кирәк бит. Нигә шулкадәр тынгысыз була икән бу ана йөрәге?

Олы улы тормышыннан да, хезмәтеннән дә (тфү-тфү, күз тимәсен!) хәзергә бик канәгать. Мәликә белән мәхәббәтләренә дә сокланып туймаслык. Коры мәхәббәт кенә түгел, хөрмәткә, бер-берен аңлауга нигезләнгән мөнәсәбәтләр. Үз тиңен тапты Камил. Тормышның бу ягы, мөгаен, иң мөһимедер. Халык юкка гына тибешкәндә дә үз тиңең кирәк» димәгән инде. Хәер, ул гел шулай булган. Яшьләрнең башына гына соңлабрак барып җитә. Ә Сабирага әнисе бу турыда бик ныгытып сеңдергән иде. Булат белән дә... Йә Ходай! Теге көнне экранда күргәннән бирле хәтернең әле бер, әле икенче почмагыннан килә дә калкып чыга. Онытылып бетте дигәндә...

...Югыйсә, мәхәббәт күгендә бер генә караңгы болыт та юк иде кебек. Булатның – юридик, Сабираның математика факультетында укулары тәмамланып килә. Университет белән саубуллашыр вакыт якынлаша. Тик алар бер-берсе белән саубуллашырга җыенмыйлар. Планнар инде күптән корылган, матур киләчәк бергәләп юралган. Булатка әти-әнисе күптән инде эш табып куйган. Кызыл дипломлы Сабираны да теләсә кайсы Казан мәктәбенә бишкуллап алачаклар. Әнә шулай җиңел генә, алар теләгәнчә генә барып чыгар кебек иде. Булат әти-әнисен сөйгәне белән таныштырды да инде. Башкаланың эре генә предприятиесендә баш финансист булып эшләүче әнисенә Сабираның киеме, үз-үзен тотышы, сөйләме артык гади, артык авылча тоелды. Әнисе белән генә үскән кыз икәнен белгәч, бигрәк тә эче пошты Казан бичәсенең. Тик улы алдында йөзенә чыгармады. Үзенең Казан кызы булуы белән чиксез горурланучы Фәсәхәт ханым (әти-әнисенең Казанга өйләнешкәч кенә килеп урнашканын, үлгәнче авыл белән элемтәләрне өзмичә яшәүләрен бик чәчелеп сөйләргә яратмый иде ул) улына затлырак партия юраган иде. «Тагын бер авыл гыйбадын кеше итәсе була икән», – дип уйлап куюдан башка берни дә әйтә алмады әни кеше. Хәзергә әйтә алмады. Хәзергә!

«Авыл гыйбадының беренчесе» – аның ире. Бүгенгә көндә аның шәһәр прокуратурасында эшләвен Фәсәхәт ханым, һичшиксез, үзенең булдыклылыгы аркасында дип уйлый. Җае килгән саен иренә «кем аркасында кеше булганын» исенә төшереп торырга ярата. Җәүдәт әфәнде эшендә дәрәҗәлеләрдән санала.

Өйдә дә үзен хуҗа исәпли. Тыштан шулай күренә. Фәсәхәтнең һәрнәрсәне ире исеме белән үзенчә эшләвен белсә дә, аның бу турыда уйлаганы да юк, уйлыйсы да килми. Бу хәл, Җәүдәт әфәндене артык вак-төяк мәшәкатьләрдән коткарганга күрә, икесенә дә кулай иде.

– Нәрсәсе ярамаган тагын? Акыллы кызга охшаган, югары белеме бар. Бер-берсенә ярагач, тагын ни кирәк сиңа?

Улларының булачак кәләшенә карата хатыны белдергән фикергә каршы җавап шундый булды. Җәүдәт әфәнде әйтәсен әйтте дә, хатынына арты белән борылып, гырылдап йоклап та китте. Фәсәхәт кенә йоклый алмады.

Ә вакыйгалар берәүдән дә сорамыйча гына, Фәсәхәт теләгәнчә генә борылды да куйды. Хәтта аның бер катнашы да булмады кебек.

Имтиханнар бетеп, күптән көтелгән җиңеллек, рәхәтлек килгән көннәр иде. Бүген алар Казансу буена төшәргә тиеш. Булат аны тулай торактан килеп алачак.

Тик Булат ул көнне дә, икенче көнне дә күренмәде. Сабираның билгесезлектән бәргәләнүен күреп, бүлмәдәше Римма егетне гаепләде, төрле сәбәпләр юрады. Дустын «бу алдакчыдан» башын алып качарга үгетләде.

– Аңа нидер булган. сәбәбен аңлатып тормыйча, болай гына югала торган кеше түгел Булат.

Үпкәсен җиңеп, гашыйк кыз Булатның өенә китте һәм кичен бүлмәсенә шакшы су белән коендыргандай хурланып кайтып керде. Булатның әнисе аны башта сәерсенеп каршы алса да, кызның егетне югалтып, борчылып килүен белгәч, ситуацияне үзе теләгән якка оста гына борып җибәрде.

– Ун көнгә базага тренировкага китте бит Булат. Чыгарылыш кичәсенә генә кайтачак. Сиңа әйтмәгән идемени? Күптән билгеле иде, югыйсә, барасылары. Әйтүне кирәк тапмагандыр инде, – диде дә Фәсәхәт ханым авызын кыйшайтып көлемсерәде. – Син, акыллым, Булатка өметләнеп йөрмә инде. Аңа пар түгел икәнеңне болай да аңларлык.

Тавис кошына охшаган кыяфәтле бу ят хатын, бармагы саен алтын йөзекле кулларын җәеп, затлы фатирга ымлады. Сүз шунда өзелде. Сабира, атыла-бәрелә, урамга ташланды. Әйтүне кирәк тапмаган! Әле соңгы очрашкан көнне дә сбор турында бер сүз дә булмады. Кыз сөйгәненең волейбол буенча университетның җыелма командасында уйнаганын, еш кына берничә көнгә шәһәр читендәге базага тренировка чыгып йөргәнен яхшы белә. Белә генә түгел, Булат уйнаган ярышларны карап барырга тырыша, аның оста уенчы булуы белән горурлана иде. Ә болай ...бер сүз дә әйтмичә... кирәк тапмыйча... Шундый вакытта... Сабира аңа икесе өчен дә бик-бик мөһим сүзне әйтмәкче иде бу очрашуда. Бу яңалык икесе өчен дә бик кыйммәтле булырга тиеш кебек иде. Хәтта киләчәккә планнарны да үзгәртергә тиеш иде. Ә Булат, аңа әйтеп торуны да кирәк тапмыйча, ун көнгә шәһәрдән китеп барган!

Сабира, үзен дөньяда иң бәхетсез кешегә санап, елый-елый бүлмәсенә кайтып егылды. Ярый әле Римма чыгып киткән. Җанга тиеп, төпченеп торучы юк. Булат та юк. Нишләргә дигән сорау һәм Сабира гына бар.

Казанның Сабира өчен яме бетте. Чыгарылыш кичәсенә кадәр әле бер атна. Гомумән, кирәк микән аңа бу кичә? Сабира егеткә үпкә тулы хат язып салды да авылга кайтып китте. Чыгарылыш кичәсе узгач, килеп дипломын алды, тулай торактагы урынын тапшырды. Казан белән алыш-бирешне бетерде, балтасы суга төшкән кешедәй башын иеп, барлы-юклы киемнәре белән китаплар тутырылган иске чемоданын сөйрәп, елга портына төште. Билет алып, теплоходка кереп утырды.

– Нигә бик моңсу утыра әле бу чибәр кыз? Әллә Казаннан аерыласы килми инде.

Уйга батып, үзеннән алдагы рәттә генә кайтучы күрше авыл егете Мидхәтне дә күрмәгән икән. Мидхәт авыл хуҗалыгы институтында укый. Каникулга кайтканда-киткәндә еш кына юллары бергә туры килә. Әйбәт егет ул Мидхәт. Элегрәк, җәйге каникул вакытларында Сабираларның авылына дискотекага килгәч, аны озатып та куйганы бар. Болай, дусларча гына. Мидхәт аның Казанда йөргән егете барлыгын белә. Кыз ошаса да, сагызланып, үз дәрәҗәсен төшерми.

– Ә, Мидхәт, сәлам! Күрми дә торам. Син дә Казан белән саубуллашып кайтасыңдыр инде?

– Әйе, диплом кулда. Утте дә китте биш ел. Көне-көне белән качасы килә иде бу Казаннан, хәзер әллә ничек, үземә дә ямансу кебек әле.

– Ә эшкә кайда билгеләделәр соң? – диде Сабира, Казан темасына әйләнеп кайтасы килмичә.

– Үзебезнең авылга инде. Мин бит колхоз стипендиаты. Ә син Казанда каласыңдыр инде?

Авырткан җиренә тиде бу сорау. Сабира, сер бирәсе килмичә:

– Мин кая теләсәм, шунда китә алам. Кызыл диплом.

Мидхәт Сабира янындагы буш урынга күчеп утырды.

– Дипломым кызыл дип кенә Казан егетен ташлап китмисеңдер инде. Туйлар кайчан була?

– Булмый! – диде кыз. – Туйлар билгесез срокка кичектерелә!

Ул көнне Мидхәт Сабиралар авылына дискотекага килде. Икенче көнне дә. Өченче көнне дә. Әллә ни дә сөйләшмәделәр бугай. Һаман да шул Казан тирәсендә әйләнде сүзләре. Атна-ун көннән Мидхәт үзенә хас турылыгы белән әйтеп куйды:

– Сабира, аңлавымча, синең Казан егете белән аралар өзелгән. Шулаймы?

Сабира сүзсез генә башын селкеде.

– Сабира, син миңа күптәннән ошыйсың. Егетең булганга күрә, моңарчы әйтми йөрдем. Әгәр мин нәрсәгәдер өметләнә алам икән, әйдә очрашуларны дәвам итик. Бүген үк димим, тора-бара, бәлки син дә мине ошатырсың.

Сабира эндәшмәде. Мидхәт моны уңайга юрап, килеп йөрүен белде. Иң авыр көннәрендә артыгын бәйләнмичә, аның күңелен ачып, башка бәйләнчекләрдән аралап, егет әкренләп кыз күңелендә үз урынын яулый бара иде. Тик үткәннәрне генә онытып булмый. Оныттырмас җепләр белән бәйләнгән иде Сабира Казанга. Бу турыда иртәме-соңмы Мидхәт тә белергә тиеш. Егетне билгесезлектә өметләндереп йөртмәскә кирәк. Сабира бер кичне, тәвәккәлләп, Мидхәт белән сөйләшергә булды.

– Мидхәт, син бик әйбәт егет. Ышанычлы дус. Шуңа да мин синең белән ачыктан-ачык сөйләшергә телим. Син уйлаганнан катлаулырак минем хәлләр. Очрашуларны дәвам итәбез дисәк, син моны белергә тиеш. Алга таба нишләсен үзең хәл итәрсең. Бәлки инде болай да аңлагансыңдыр.

Мидхәт кызның иңнәреннән тотып, озак кына күзләренә карап торды.

– Булган идемени хәлләр?

Сабира эндәшмәде.

– Күпме?

– Ике ай була.

Мидхәт кызны җибәрде. Мотоциклына барып сөялде, читтән урап килде, тагын утырды. Чәчләрен аралап, чигәләрен уды. Сабирага моны карап

тору авыр иде. Сүзсезлек озакка сузылган кебек тоелды. Мондый вакытта эндәшүнең мәгънәсезлек икәнлеген аңлап, кыз китәргә кузгалды. Үзе генә калып уйласын. Соңыннан үкенерлек булмасын.

– Тукта!

Егет, аны үзенә таба борып, йомшак кына итеп күкрәгенә кысты. Икесенең дә йөрәге дулап тибә. Күкрәк читлекләрен каерып чыгып очарлар кебек. Моңарчы кочаклашулар булыштырса да, болай түгел иде бит. Әллә нәрсә үзгәрде.

– Ашыкма! Китәргә ашыкма әле.

Икенче көнне Мидхәт кыз сорарга әтисе белән әнисен алып килде.

...Сабира хатирәләргә чумып шактый утырды. Өч дистә ел элек булган хәлләр аны хәзер ул кадәр бик дулкынландырмый икән инде. Вакыт барысын да үзе дигәнчә урнаштырып куйган. Кайчандыр мәңге гафу ителмәслек тоелган нәрсәләр бүгенге проблемасы белән чагыштырганда бөтенләй чүп кебек кенә, бала-чага капризы гына икән. Хатын тормышыннан канәгать, бик канәгать иде әле, бу каза килеп чыкканчы.

Казан, Казан... Аларның саф хисләренә шаһит Казан урамнары һаман да шулдыр. Алар гына күптән икенче кешеләр... Булат хәзер әнә кем икән! Яхшы гына карьера ясаган. Шулай буласына Сабираның шиге юк иде. Егет үзе дә булган, әти-әнисенең мөмкинлекләре дә ярыйсы. Димәк, Булат – Казанда. Ничә ел офыктан югалып торганнан соң. Шулвакыт Сабираның зиһенендә, күк капусы ачылгандай, бер якты уй сызылып үтте: «Менә кем коткара ала Ихсанны!»

– Мин, укулар башланганчы, Казанга барып, Сәгыйдә апаның хәлен белеп кайтыйм әле. Әбәткә кайткач, кош-кортка тугым салсаң, калганын Рәйханә карар. Сөйләштем. Мин озак тормам, бер-ике көннән әйләнеп кайтырмын, – диде Сабира иренә кичен.

– Ярар, барып кайт. Ике көнгә генә түзәрмен. Механикның Казанга запчасть алырга барасы бар иде, иртәгә шуның белән җибәрермен. Кайтканда үзең карарсың инде.

Мидхәтнең бик күп яхшы якларының берсе – хатынының иреген тыймавы. Сабира гомер буе барасы җиренә барды, теләгән эшен эшләде. Бәлки, хатынының уйламыйча бернигә тотынмасына, чама хисен югалтмасына нык ышанганга шулай иткәндер. Бу юлы да иренең ризалыгы белән чыгып китте. Тик гомерендә беренче тапкыр сәфәренең чын максатын әйтмәде. Максаты – Булат белән ничек тә очрашу, аның ярдәме белән Ихсанны мөмкин кадәр тизрәк таш капчыктан чыгару иде.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

Булатның кабинет ишек төбендә кабул итүне көтеп торучылар шактый күп, ә Сабираның түрәләр ишек төбен саклау буенча тәҗрибәсе әллә ни түгел. Шулай да әдәп саклап, чират көтеп утырсаң, бүген эләгә алмаячагың көн кебек ачык. Ә аның эше ашыгыч, бик ашыгыч! Аның йөрәк парәсе кайчаннан бирле бер гаепсезгә ябылуда ята. Ана өчен баласына шундый чакта ярдәм итә алмаудан да зур газап бармы? Ул бүген теләсә кайсы принципларны атлап чыгачак!

– Зинһар, Булат Равилевичтан мине кабул итүен сорагыз. Исем-фамилиям шушында язылган. Үтенеп сорыйм.

Өлкән яшьтәге сәркатип хатын (ни гаҗәп, андыйлар да калган икән әле! Югыйсә, сәркатип дигәч, кыска итәкле, әнисе дә танымаслык итеп бизәнгән озын ботлы кызлар күз алдына килеп баса) Сабираның сүзләренә төшенеп бетмәсә дә, күзләреннән аның халәтен аңладымы, кабинет бушауга, кулына

Сабираның запискасын тотып, ишеккә юнәлде. Көтүнең һәр мизгеле сәгатькә тиң, диләр. Сәгать түгел, гасырга тиңдер ул.

Сәркатип, чыгып:

– Булат Равилевич Сезне көтә, – диюгә, мамык кебек йомшаган буыннарын тоймыйча, биек ишеккә юнәлде.

Булат аяк өсте иде. Сабира килеп керүгә, аңа каршы китте. Аннан, ярамаган эш өстендә тотылган кебек, кинәт кенә туктап калды. Сабираның ишек төбендә үк туктап:

– Рөхсәтме? – дип эндәшүе генә аны айнытып җибәргәндәй булды.

– Исәнме, Булат!

– Исәнме, Сабира! Бу чыннан да синме, күземә генә күренәсеңме?

– Мин бу, Булат, мин. Кабул итәргә, мине тыңларга риза булуыңа мең рәхмәт. Яшьлектә сине яратып ялгышмаганмын икән. Сине вакыт та, кәнәфи дә үзгәртә алмаган. Һаман да шулай кешелекле икәнсең.

Бу сүзләр кычкырып әйтелдеме, күзләр генә сөйләштеме – исенә килгәндә, Булат аның кулларын учында тотып, әкрен генә сыйпый иде.

...Сабираның Ихсан турындагы кыйссасын Булат Ганиев булдыра алган кадәр игътибар белән тыңлады. Сабира сөйләп бетерде дә, Булаттан җавап көтеп, тынып калды.

– Сабира, бүгенгә планнарың ничек синең? Бүген Казанда буласыңдыр бит әле, – диде Булат, бөтенләй башка темага күчеп.

– Әйе, бер килгәч, Сәгыйдә апаның да хәлен белеп чыгам. Кунарга шунда туктармын, дип уйлаган идем. Сәгыйдә апа – минем туган апам, аны син дә белә идең. Исеңдәме?

– Оныттыра торган апамыни ул! Синең янга йөргән чакларда, вәгазьләрне аз тыңламадым мин аннан. Исәнмени әле ул? Яше байтактыр инде. Ул чакта ук өлкән яшьтә иде.

– Ул чакта үзебездән зуррак бөтен кеше безгә әби-бабай кебек иде бит. Хәзер үзебезнең генә бер дә картаясы килми.

– Әйе, күңел һаман унсигездә кебек. Әллә миңа гына шулаймы дисәм... Менә хәзер дә синә карыйм да күрешмәгән утыз ел булмаган да кебек, Сабира. Әллә чыннан да булмаганмы соң? Менә бит каршымда – син. Нәкъ яшь чактагы кебек. Хәтта матуррак та бугай. Икенче төрле матур.

– Ярар, оялтма инде, Булат. Авыл хатыны утыз ел буе ничек матур кала алсын инде.

– Ә сиңа оялу шундый килешә. Элек тә шулай иде... Алайса, без болай итәбез. Минем тәмамлыйсы эшләрем бар. Син Сәгыйдә апаның хәлен белә тор. Сине хәзер анда илтеп куярлар. Мин дә эшләремне бетерим. Сөйләшүне кич дәвам итәрбез. Аңа кадәр мин кайберәүләргә шалтыратып та алырмын.

Булат торып басты. Мәһабәт гәүдәле ир-ат янында Сабира үзен кечкенә, яклауга мохтаҗ сабый итеп сизде. Шул ук вакытта аңа нигәдер рәхәт, бөтен проблемалары хәл ителгән сыман рәхәт иде.

Кич Булат Сәгыйдә апага күчтәнәчләр күтәреп килеп керде. Ә Сабирага ак чәчәк букеты сузды. «Онытмаган! Минем яраткан чәчәкләремне дә онытмаган!»

– Гөлкәем, болары сиңа!

Сабира ялт итеп Булатка күтәрелеп карады. Тәненнән ток узгандай булды. Ике уй арасында буталып, зиһене таркалды. Чигәсенә шаулап кан йөгерде. Аның бу халәтен Булат та сизеп алды бугай.

– Яшь чактагыча, «Гөлкәем!» дип эндәшкәнгә ачуланмыйсыңдыр бит? Кара әле бер генә тапкыр күзләремә туры итеп, бер генә тапкыр, Сабира!

– Булат, ул чакларны искә төшереп торма инде син. Беренчедән, буласы булган, гомер узган. Икенчедән, миндә күзгә-күз карашып утыру кайгысымыни?

– Гафу ит, Сабира, онытылып киткәнмен. Гафу, мең мәртәбә гафу! Ул вакытта безне ашыгыч кына җыеп алдылар да Саратовта студент командалары арасында узасы ярышка әзерләнергә, диделәр. Мин сине эзләп тулай торакка чаптым. Римма: «Туган апаларына китте», – диде. Записка язып, Риммага тоттырдым, онытмыйча тапшырырга куштым. Ә сбордан кайтуга, әни синең хатны бирде. Сүзләреңне акылым һич кабул итә алмады. Бер минутта сине мәңгегә онытырга кирәк дип уйлыйм, икенчесендә эзләп чыгып чабасым килә. Бүлмәдәшең Римма:«Кияүгә чыкты ул, күрше авыл егетенә», – дип әйткәнче, шушы ике уй арасында өзгәләндем. Синең ни өчен болай эшләвеңнең сәбәбен аңлый алмадым. Сине хыянәттә гаепләдем. Тик күңелнең түрендә барыбер гаепсез булуыңа өмет үлмәде. Горурлыгымны җиңеп эзләп бармавыма күпме үкендем мин соңыннан. Римманың записканы сиңа бирмәве турында аерылышканда гына белдем. Аның белән тормыш барып чыкмаганына инангач, әни дә елый-елый әйтте: «Улым, синең бәхетсез булуыңда мин гаепле, зинһар, кичер. Ялгыштым мин. Әгәр очратсаң, Сабирадан да минем өчен гафу сора», – диде. Шул сөйләшүдән соң күп яшәмәде. Шуны сизгән булгандыр, ахры, үзе дә... Ә бу очрашуга мин бик шат, Сабира. Анам өчен гафу үтенә алган өчен генә түгел, сине күрә алганым өчен. Язмышның тагын бер кат синең күзләреңә карарга мөмкинлек биргәне өчен. Мин бу турыда гомер буе хыялландым. Ә үпкәләр күптән бетте инде алар. Үкенеч кенә калды. Ә улың...

Булат сүзеннән туктап калды. Башын түбән иде. Сабира өчен алда әйтелгән сүзләр шул мизгелдә бөтен әһәмиятен югалтты.

– Нәрсә, Булат? Әйт инде тизрәк, көттермә! Булып чыкмадымы әллә?

– Эшенең кыйммәте өч тиенлек кенә булса да, олы кешеләргә бәйле булып чыкты әле ул. Монда хикмәт җинаятьнең зурлыгы-кечкенәлегендә түгел, кайберәүләрнең минминлек чирендә.

– Ничек – чирендә?

– Сабира, син акыллы хатын бит. Уйлап кара! Сезнең Актаегыздагы зур абзыйның монда тагын да зуррак абзые бар. Эшләр катлаулана башлагач, хәлне Казандагы абзыйның да колагына салып куйганнар. Болай гына. Сүз арасында гына. Ничек әйтелсә дә, эшнең ахыры бу кечкенә «империя» файдасына булырга тиеш бит инде. Сезнең анда тыпырчынуларыгыз – мондагылар өчен чебен дулаган кебек кенә.

– Өметсез дип әйтмәкче буласыңмыни? Ә мин шулкадәр ышанып килгән идем сиңа.

Булат башын иде. Нәрсәдер әйтергә тели. Тик әйтә алмый иде бугай.

– Вакытсызрак, вакытсызрак чакка туры килде шул.

Бу сүзләр Сабира өчен әйтелмәгән иде. Булат үз-үзен нәрсәгәдер ышандырырга тырышамы?

– Нәрсә турында әйтәсең, Булат? Нәрсәгә вакытсыз?

Ир-ат эндәшмәде. «Сезнең малаегызның эше өчен мин карьерам белән түләячәкмен», – дип әйтсенмени!

– Булат, син миңа турысын әйт: эш нидә? Ихсанның гаепсез икәненә ышандыра алдым шикелле бит инде сине.

– Гаепсез... Их, Сабира, белсәң иде син...
– Нәрсәдер эшләргә мөмкинме? Син булдыра аласыңмы?
– Булдыруын булдыра алам да...
– Эш нәрсәдә соң? Акчадамы?
– Акчада түгел.
– Алайса, синең үзеңдә?

Бу минутта Булатның кыяфәте бик мескен иде. Көндез генә үзе сокланган гайрәтле, горур бөркет кыяфәтендәге ирне Сабира хәзер шәбәргән тавыкка охшатты.

– Әгәр бу синең өчен уңайсыз эш булса, көчәнмә, турысын әйт – аңлармын, – диде Сабира. Аның тавышындагы боз салкынлыгы очрашудан туган җылы хисләрне мизгел эчендә юкка чыгарды. Алга таба сүз ялганмады. Булат, Ихсанның эшен уңай хәл итүгә бөтен көчен куячагына ышандырырга бик тырышып, тагынниләрдер сөйләде. Сабира әдәп йөзеннән аны тыңлап утырды. Аннары ничектер кисәк кенә башына килгән сорауны биреп куйды:

– Булат, синең балаларың бармы?

– Юк, Сабира, Ходай миннән, нигәдер, кызганды ул бәхетне. Мәхәббәт булмаган җирдә булмаулары да хәерле булгандыр, бәлки. Риммага сиңа үч итеп кенә өйләндем бит мин. Дөресрәге, ул мине үзенә өйләндерде.

Салкын гына аерылыштылар. Булат үзенең визиткасын бирде. Сабираларның телефонын язып алды. Эш барышы турында хәбәр итеп торырга вәгъдә бирде.

– Исән бул, Сабира... Очрашырбыз әле.
– Хуш, Булат!

«Элекке мин яраткан Булат дип ялгышканмын икән. Ә балаң бар синең. Бер дигән улың бар. Тик син бу турыда беркайчан да белмәячәксең. Чөнки аңа мондый әти кирәкми».

## УНЫНЧЫ КӨН

Кайтыр юлда күкне болыт сарганын күреп, Сабира сөенеп туймады. Юлы уңмаудан туган борчу да бераз арткарак күчкән кебек булды. Ниһаять, яңгыр килә! Их, рәхәтләндереп яусын иде бер, ашыкмый гына, сеңдереп кенә! Табигатьне баскан тузанны юып кына түгел, өметсезлек сарган җаннарны да сафландырып җибәрер иде. Шулкадәр кирәк бит бүген яңгыр! Дөньясы коргаксыды бит. Басулар яргаланып бетте. Шул ярыклар кочагында бер тамчы дым өмет итеп тә көтеп ала алмаган мескен ач башаклар... Озакка сузылган кызу көннәрдән соң яуган яңгыр, бик көтелгән булса да, дымы белән бергә проблемалар да алып килүчән. Хәере белән генә яусын иде инде.

Тик, кайта-кайта, сөенече куркуга күчте. Җил көчәйде. Хәтта машина булып машина каршы искән җилне сизә. Өермә тәрәзәгә җирдәге чүп-чарны, сынык агач ботакларын күтәреп китереп бәрә. Аннары ялтыр-йолтыр яшен яшьнәп, күк күкрәп коеп яварга тотынды. Боз катыш яңгыр машина тәрәзәсенә китереп сылый. Баш бармак тикле боз машина түбәсенә түгел, Сабираның башына бәрәдер кебек. Тоташ стена булып яуган яңгыр олы юлдагы хәрәкәтне туктатты. Чакрымнарга сузылган машина агымы катып калды.

Сабира авылга кайтып кергәндә, авылдан гарасат узган иде инде. Ялтырап кояш чыкты. Урамны иңләп яңгыр суы ага. Урам тулы сынган ботак, ауган агач, каерылган түбәләр, бакча ягына өелгән чүмәләләрдән таралган печән... Бакчадагы яшелчә, бәрәңге яфраклары боздан теткәләнеп беткән. Авыл кешесе

миңгерәүләнгән кебек урамга сибелгән дә, ни булганын да аңламыйча, әле тегендә, әле монда йөгерә иде.

Ишегалдына килеп керүгә, беренче күзгә ташланган нәрсә тәгәрәшеп яткан үрдәк бәбкәләре булды. Кереп качарга өлгермәгәннәрдер инде бәләкәчләр. Аналары булса, җыйган булыр иде дә, инкубатор бәбкәләре иде шул. Бәрәңге бакчасында буразна аралары су белән тулган, бар яшеллек теткәләнеп туфрак белән буталган, теплица ишеге, каерылып, бакчаның икенче башына очкан иде.

– Нинди гөнаһларыбыз өчен бу җәзалар, әй Ходаем!

Өйгә, абзар-курага зыян килмәгән, Аллага шөкер! Сабира, ишекне ачып, өйгә керде. Мидхәт өйдә юк. Анысына бик гаҗәпләнмәде. Мондый көнне өйдә утырган булса, гаҗәп булыр иде.

Компьютерны кушты. Камилләрдән берәр хәбәр юк микән? Йә Раббым! Бар бит! Камил бүген төнлә уллары туганын, Мәликәнең дә, баланың да хәле яхшы булуын язган. Үзе белгән кадәр бөтен нечкәлекләре белән авырлыгын, буен, кайчан кычкырганын, күзенең төсе нинди булуын һәм тагын әллә нәрсәләр турында тезгән. Улының һәрбер сүзеннән әйтеп бетереп булмастай шатлыгы, сөенече ташыганы сизелә, күңеленең иң нечкә кылларына барып җитеп, яшь аралаш елмайта иде.

– Мидхәт белмәгәндер бит әле. Ничек хәбәр итәргә? Телефонына да җавап бирми.

Сабира,бер карарга килә алмыйча, ишекле-түрле йөргәндә, Рәйханә килеп керде. Гарасат ясаган хикмәтләрне сөйли башлаган иде, Сабира аны бүлдерде:

– Әй Рәйханәкәем, буласы булган инде, аны хәзер берни дә эшләтеп булмый. Безнең сөенчебез бар бит, улыбыз туган. Бәхете-тәүфыйгы белән генә туган бала булсын берүк. Мул ризыгы белән, ныклы сәламәтлеге белән туган бала булсын. Яңгыр ява да китә ул, Рәйханә, ватыкны төзәтерләр, ауганны торгызырлар. Әтиләре белми бит әле, ничек сөенче алырга белми торам менә. Телефонын алмый.

Рәйханәгә сүз әйтергә дә ирек куймыйча, шатлыгыннан нишләргә дә белмәгән Сабира тагын телефонына барып ябышты.

– Сабира апа, ул буа тирәсендә түгел микән? Ташу буаны алып киткән бит. Әллә барып кына кайтасыңмы? – диде күрше хатын, сәер генә.

– Буа киткән? Соң буа киткәч, түбән басулар нишләде икән соң? Мидхәтнең бөтен өмете шул басуларда иде бит.

– Белмим инде, Сабира апа, үзем барып күрмәдем. Алмаз гына әйтте. Механизаторлар су гүләгәнен ишетеп шунда йөгерделәр, диде. Шуңа әйтәм инде, Мидхәт абый да шундадыр дип.

Сабира ялт итеп Рәйханәгә күтәрелеп карады. Анысы карашын читкә алды.

– Нәрсә булды? Әйт дөресен!

– Берни дә белмим, Сабира апа. Сиңа мондый вакытта Мидхәт абый янында булуың хәерлерәк булмасмы дип әйтүем.

Сабира чыгып чапты. Рәйханә – аның артыннан. Урамга чыгуга, чыннан да, ерылган буаның гүләве аермачык ишетелә иде. Алар гына түгел, бу шомлы тавышны ишеткән олысы-кечесе буага таба йөгерә.

Сабира белән Рәйханә буа янына килеп җиткәндә, алданрак килүчеләр яр буенда туктап калганнар иде. Яр астында, ике якка җәелеп киткән уйсу болынлыкларда юылып төшкән иген сабаклары белән катыш пычрак су кайнап утыра. Буа тирәсендәге басулар су белән юылган. Табигать афәте алдында иген тамырлары көчсез булып, басу тоташ ерганакны хасил иткән.

Мидхәтне коры елларда уңышы белән авыр хәлдән азмы-күпме коткарган Түбән басулар танырлык түгел. Дамбаның ишелгән җире бераз эчтәрәк, каршы яктагы басуга таба, бетон белән ныгытылмаган ягында иде. Дамба өстеннән су ага. Кешеләр анда керми. Ерактан гына аргы якта нинди мәхшәр булуын гөманлап сөйләнәләр.

– Мидхәт абыегыз кайда икән? Күрмәдегезме?

Биленә тиңле балчык чәчрәп пычранган Сабирага башта ни дип тә җавап бирергә белми тордылар. Аннары берсе:

– Ә-ә-нә тегендә кереп китте, – дип, су белән көрәшә-көрәшә, буа ерылган җиргә баручы кешене күрсәтте.

– Кермә дип карадык, тыңламады. Су ярны юа бара бит. Төшеп китеп харап кына булмаса ярар иде, – диде икенчесе.

– Нигә керә инде ул анда? Кереп кенә нәрсәнедер үзгәртә торганмыни!

Хатын аягындагы чүәген салып ташлады, итәкләрен бераз күтәрә төшеп, ераклаша баручы Мидхәт артыннан суга кереп китте.

– Сабира апа, син нишлисең, икәүләп бетәсез бит, – дип өзгәләнүче күршесенең сүзләрен су гүләве каядыр алып китеп барды. Дамба өстендәге су тирән түгел, шулай да агымсуны ерып баруы авыр иде. Ул Мидхәтнең шушы минутта ниләр кичерүен беркем дә аңлый алмаганча аңлый. Бүген ире ел тәүлеге, юк, ел гына түгел, ничә еллар бөтен акыл көчен куеп, тир агызып тарткан хезмәтенең Алла алдында гына түгел, бәндә алдында да кадерсезләнә баруыннан, киләчәккә өметсезлектән гаҗизләнеп, төзәтеп булмаслык гамәл кылырга мөмкин. Соңгы вакытта Ихсан белән булган вакыйгалар, Ходай сынавы – корылык, кемнәндер ярдәм көтүнең мәгънәсе юклыгын аңлау – барысы бергә ир-егетнең җелеген суырган иде. Мидхәт үзен табигать тудырган упкын алдында түгел, тормыш упкыны алдында итеп хис итә, өметсезлек аны упкынга таба алып бара булыр. Ялгыш адымнан туктатса, аны бары гомер иткән хатыны гына туктата ала. Сабира берничә мизгел эчендә Мидхәт белән узган гомерен күз алдыннан уздырды. Бер шатлыкны ике итеп, борчу-хәсрәтләрне бергәләп күтәреп төзегән тормышлары челпәрәмә килергә тиеш түгел. Бирешергә иртәрәк. Аларның бит әби-бабай бәхетен татыйсылары бар. Дөнья бүгенге белән бетми, иртәгәсе көнгә өмет уятып, оныклары туган бит. Аларның дәвамы туган! Сабира хәле китеп туктый, суга тезләнә, тагын алга таба атлый. Тукталмаска гына кирәк, туктап калмаска! Тик көче бетеп бара шул. Сабира, суның шомлы гүләвен җиңәргә тырышып, бар көченә аваз салды:

– Мидхәт! Әтисе-е-е! Юк, бабасы-ы-ы! Оныгыбыз туган бит! Сөенче-е-е! Ми-идхә-ә-әт, сөенче-е-е!



Лениза
Вәлиева

# МӘҢГЕЛЕК БӘХЕТКӘ ЫШАНАМ

* * *

Җәй көзгә авышкан моңсу мәл...
Ә күңел язларда адаша…
Елмаю чаткысы – иренемдә.
Төпсез күк чигенә җан аша.
Мин куркам үземнең бәхтемне
Җуюдан бу шаулы дөньяда.
Барсы да буталган бер дәвер…
Белмәссең: дошман кем, дус кайда.
Мин куркам җуюдан бәхетемне,
Күкләрдән ялварып сораган,
Өметнең азаккы соң кылы
Өзелер чигендә табылган.
…Көйдерә кайнар яшь, тынмас җан
Тәкъдиргә җиңелгән, откан да.
Язмышның буталган юллары,
Ниһаять, кисешкән ноктада.

* * *

Буразна-буразна язмышым сызыгы
Юллары учыма уелган.
Мең еллар Галәмне иңләгән күңелем,
Ниһаять, куеныңа сыенган.
Күңелем төпкеле хисләре – күзләрдә.
Берсүзсез ачарлар серләрен.
Бар җиһан тик безгә багышлар үзенең
Илаһи моң тулы сүзләрен.
Учларың җылысы учымда сүнмәсен.
Мәңгелек бәхеткә ышанам.
Өметем, хыялым, йөрәгем – барысын,
Мин сиңа язмышым тапшырам.

Лениза ВӘЛИЕВА – *шагыйрә; «Диңгездә йолдыз коена», «Хәят күгем» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Күзеңә карыйм да сүз тапмый тын калам.
Кадерлем, сөеклем, син миңа – бар Галәм.
Ялкыным сүрелмәс карамый һичнигә,
Табылып югалдым мин синдә гомергә.
Бу сөю бер булыр дәверләр, чорларга,
Кайтаваз шикелле кушылыр җырларга,
Яңгырар тауларда, дәрьялар шавында...
Һич тынмас Галәмдә тереклек барында.
Бәхетем син минем, язмышым юраган,
Күкләрдән илереп, ялварып сораган.
Күкрәктә йөрәгең тибеше булырмын.
Мин сиңа мәңгегә багышлыйм барлыгым.

* * *

Кагылам күңелеңә:
Кыллары моңлы.
Бу илаһи аһәң чыңы
Җаныма тулды.

Кагылам күңелеңә:
Кыллары кайнар.
Ялмады ялкын. Җанымда
Мәңгелек ут бар.

Кагылам күңелеңә:
Тибрәлә кыллар.
Җуелмасын сөю төсе,
Үткәч тә еллар.

Кагылам күңелеңә –
Тирән, дәрьядай.
Дулкынында тибрәләмен,
Иркә баладай.

Кагылам күңелеңә:
Ешая сулыш.
Икебезгә уртак безнең
Бәхетле язмыш.

* * *

Таңнан алып, ул көн җанга былбыл кунды.
Февраль карын бертуктамый яңгыр юды.
Караңгылык канат япты җиргә тоташ –
Балкып, мулдан нурын чәчте җанда кояш.
Җир белән Күк тоташты күк: су – һәр тараф.
Бу халәттә һаман көләч минем караш.
Шау чәчәкле хәят язым бакчасында
Бөреләнде алтын җимеш бирер агач.

* * *

Сынауларның иң ачысы, иң татлысы.
Иренемдә никтер тозлы чык тамчысы.
Берни көтмим бу язлардан, тик шулай да
Күкне яра өметемнең ут-камчысы.
Берни көтмим, үрсәләнеп көтә күңел.
Бәргәләнеп, ярларыннан ташый Идел.
Шашкын уйлар кушылалар дәрьяларга.
Суларга да юлын табу җиңел түгел.
Мин җиңәргә тиеш, шиксез, бу алышны,
Таратырга язгы җилдә бар сагышны.
Алмагач та тиздән шаулап чәчәк атар.
Аклык, шатлык чолгап алыр һәр тарафны.

* * *

Нурга төреп бар җиһанны сызыла таң.
Илаһи моң дулкынына күмә азан.
Тыелып кына көлемсерәп карый кояш –
Көзнең соңгы талпынуы, кышны тойгач.
Әй шашынып вальс әйләнә сары яфрак!
Аңа ияреп бөтерелә һәр күзәнәк.
Күкрәгеңә башым салып, тып-тын калам.
Без берсүзсез аңлашабыз, алтын алмам.
Күзләреңдә күрәм нәни бер чагылыш –
Мәхәббәттән бөреләнгән яңа тормыш.

## Сагышланма

Искән җилләр туктап калыр, шау-шу тынар.
Күк, мин булып, күзләреңә тутырып багар.
Сагышланма, үтенеп сорыйм, елмай бары.
Янсын дөрләп бу җиһанның бар аһ-зары.

Пакь сөюем һәр яз җиргә кабат кайтыр,
Сирень булып, өй каршымда чәчәк атар.
Сагышланма, йөрәк парәм, тыңла бары.
Минем серле пышылдавым – тынлык шавы.

Ә кышларын кайтырмын мин, карга кунып,
Һәм эрермен, күзләреңнән синең үбеп.
Буран булып, әрнүләрең таратырмын...
Сагышланма, мәңге-мәңге яратырмын.



Рүзәл
Мөхәмматша

# ХИКӘЯЛӘР

## Җиктереп пар ат, Казанга...

Мин йокы сихереннән кайта башлаганда, җиһанда көз тантана итә иде инде. Аптырарсың да: кичә генә сыерчык бураны котырды лабаса. Тәүге яңгыр, тәүге яңгыр... кара син аны! Чын күңелдән, түбәләрне дөбердәтә-дөбердәтә ява, тәрәзәләрне челпәрәмә китерәм дип кага! Ә юрган астында җылы, рәхәт. Ачык калган форточкадан кергән җепшек кар исе, яңгыр исе килеп яңакны сыйпый, борынны үбә. Иренеп кенә кулымны чыгарам да өшегән танавымны сыпырып алам. Торырга кирәк, биш тулгандыр инде. Зәңгәрсу ялан тәпиләр ялтыравык идәнгә орынуга, бөтен гәүдә буйлап кырмыскалар йөгереп уза, бала йоннары тырпая. Үз-үземне кочаклап, бер аяктан икенче аякка ава-ава, бии-бии кече якка юнәләм. Әтәй чәй эчеп утыра. Башы салынган. Хәле авырдыр. Мин аңа карамаска тырышам. Авызымны турсайтып:

– Сәлам, әтәй, – дим дә, җавабын ишетеп тормастан, ишек уемына кереп югалам. Юлымда дәвәнәй очрый. Аның мал карап керүе булса кирәк.

– Сәлам, дәвәнәй.

– Намаз карчыгы алдында шәрәтән йөрмәсәң, ыштыр бит! – дип ул да миңа хәерле иртә теләп кала...

Мин кече йомышымны үтәп лапастан чыккан арада яңгыр йорт кыекларыннан яшь түгеп утырган үксез сабыйга әверелгән. Күк болытлы. Аяк асты – лыгыр. Төне буе дулап, тәки үзенекен иткән: язгы кар белән яңа күкрәк ачып килгән җир пычрагын бергә әвәләп, дөньядан зур бер сазлык боткасы ясап куйган. Менә кем ул ыштыр бит!

Өйгә кергәндә, әтәй «әппәр» итмәгән иде әле. Һаман чәй эчеп утыра. Мин аның янәшәсенә арт төрттем.

– Казанга барабыз.

Чалу сөягемә китереп суктымыни, бугазыма төер тыгылып, көчкә йотып җибәрдем, мәлҗерегрәк булсам, ихтимал, үкереп еларга да күп сорамас идем.

– Нигә? – дидем мин, чокыр өстенә иелә төшеп.

– Укырга керергә. Бүген ачык ишекләр көне, ди...

– Кем әйтте?

---

Рүзәл МӨХӘММӘТША (1989) – *шагыйрь һәм прозаик; «Каралама», «Бүре мин» дигән китаплар авторы, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

– Эчеп бетер дә җыен.

Шулай да, әтәйнең бу сүзләреннәнме, әллә буы ирен өстендәге төкләрне кытыклап, тамакны яндырып үткән кайнар куе сөтле чәйдәнме, эчкә җылы йөгерде. Казанга! Училищега!

Дәвәнәй бутыйларны юып куйган иде инде. Ботинкаларны пакетка тутырдык та, кулга алып, өчәүләп авыл башына юл тоттык. Әтәйнең хәле бик авыр, ахры. Көчкә бара. Аның каруы, дәвәнәй ыжгыра гына, артыннан куып җитмәле түгел. Сиксәннең якасына ябышкан булуына карамастан, ут уйната әле ул, әтәйнең дә, минем дә кирәгебезне бирә, баскан җирендә йоклап торсаң, урысча белгән өч-дүрт сүзен кушып, пешекләп алырга да күп сорамый. Намаз карчыгы, имеш! «Бисмилла» белән «җаппашмайт»ны аера белсә иде, ичмасам. Хәер, сүгенү дип уйламый да бугай ул аны. Кемнәндер ишетеп теленә кергән дә инде, кирәк санаганда, хәтер сандыгыннан актара да чыгара, чыгара да сала. Һаман саен шаккатам: шундый җеннән ничек шундый җебегән әтәй туа алды икән?

Тукталышка килеп җиткәч, бутыйларны пакеттагы ботинкага алыштырдык. Тезгә кадәр пычрак менгән иде, билгеле. Чирек сәгать саз ерып бар да! Дәвәнәй аяк киемнәребезне умырып алып, сукрана-сукрана, берүзе генә өйгә таба кайтып китте. Мескен карчык. Аңа бу яшьтә сөекле килененең кайнар ашларын ашап, үз почмагында мыдыр-мыдыр дисбе тартып ятасы лабаса. Ә ул... бөтен хуҗалык аның өстендә. Мин көне буе мәктәптә. Әтәй көне буе эштә. Аны, гадәттә, төн җитәрәк кайтарып кына куялар. Андый бәхет елмаймаган чакларда миңа авыл бетереп эзлисе. Дәвәнәй себереп чыгара: салкын карда йоклап әрәм булмасын, өстеннән трактор-мазар узмасын, этләр ботарламасын. И-и, минем күргәннәр...

Район үзәге белән ике арада автобус сәгать саен йөри. Шуңа күрә озак көтәргә туры килмәде. Дәвәнәй иртәнге алсулыкка төренгәндә, без авылдан чыгу юлына борылган идек инде. Их, юллары да юллары, ичмасам!.. Автобуста беркем дә юк. Әтәй белән икәү. Тиешле хакын алып, билет бирмичә генә үз урынына барып утырган йөртүченең дә тәмәке төтене генә күренә...

Дөнья караңгы.

Мин бу караңгылыктан бер котылырмын әле!

***

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап...

Сорасалар, шушы шигырьне сөйләп күрсәтермен, мөгаен. Күңелемә бик туры килеп торган чагы. Нократ Аланына килеп җиткәнбез икән. Халык коела башлады. Шәһәр эчендә йөргән автобуска күчеп, вокзалга барасы да хәзер, аннан электричкада Казанга... Моңлы Казанга! Нурлы Казанга!

Аһ, ул кала төшләремә кереп йөдәтеп бетерде инде, валлаһи! Татарстан гәҗитләре дә, телевидениесе дә мактап туймый үзен! Меңьеллык мәркәзем! Чү, күңел төбендәге нинди уй «синең мәркәзең түгел ул» дип кәефемне кырмакчы? Нигә минеке булмасын?! Башка төбәктә тусам ни! Татарстанның Толлысына бездән бер карыш ара инде, чик буйлап чәнечкеле тимерчыбык сузылмаган алай, сакчылар тормый... Кемнеңдер йодрык төеп татар дөньясын вак кисәкләргә таркатканына минем ни гаебем бар? Җырдагыча, мин дә татар баласы ла...

Әтәйдән бөркелгән махмыр исе үземне дә шактый йомшарткан, ахры, оеп утырган җирдән бигүк торып китәсе килмәде.

– Нәрсә соң ул әртис? – дип тиз генә сөйләнеп алды әтәй, кырыкмаса-кырык төштән ямаулы, ватык йөрәкле һәм черек үпкәле «ПАЗ»дан төшешли.

Ул һәрвакыттагыча ихлас иде. – Инжынир дисәң, аңлар идем әле, ыстраител дисәң... Әртислеккә дә укыталармыни? Нәрсә соң ул?

Халык агымын ерышлый, буфет янынннан үтәргә туры килде. Мин әтәйне тагын бер кызганып куйдым:

– Кереп чыкмыйбызмы соң?

– Нигә?

– Җиңелрәк булмасмы, дим...

– Юк.

Әтәй кытыршы иреннәрен бер-берсенә ышкып алды. Аннан ары узмады. Дәвәнәй аңа тиенenә кадәр санап кына биргәндер шул.

– Миндә акча бар.

– Кирәкми. Син урысча яхшы беләсең бит, вокзалга илтә торган автобуска кайда утыралар икән?

***

Каршыма ук ыжгырып килгән тимер тауны күргәч, йөрәгем бертуктаусыз тибенә башлады – күкрәгемне бәреп чыга хәзер: «сау чагында табанны ялтыратыйк, юкса бу безне тирә-юньгә чәчрәтеп кенә ташлаячак!» ди бугай. Поездның ялына чытырдатып ябышкан алагаем гәүдәле зимагур җил перронда таптанган халыкны бер канаты белән сыпырып алыр да үзенә ияртеп китәр сыман тоелды. Тәгәрмәчләр сызгыра, сызгыра-а! Дөнья гүли, гүли-и! Бусының офык тарафыннан йотылуы җитте, артыннан куа килгән шикелле, яңасы пәйда булды, ул арада диктор җандагы иң рәхәт хисләрне сыйпап алырга ашыкты:

– Казанга бара торган поезд икенче юлга килә...

Халык бертөсле измәгә әверелеп вагоннарга ябышты, эчкә үткәч, агач урындыкларга җәелеп төште. Әтәй белән капма-каршы утырдык без. Ул салмак кына тизлек җыя башлаган дөньяга тәрәзәдән күз ташлады һәм янә үз эченә чумды.

Шундый матур иде минем әтәй! Шундый яшь иде! Әле кайчан гына бер агарган чәче, йөзен тырнап үткән бер җыерчыкның әсәре дә юк иде. Шундый көчле, зур иде ул! Өйгә килеп керүгә, мине күтәреп ала, түшәмгә кадәр чөя иде, мин көләм, миңа – куаныч! Үтереп кытык килә! Әти шырпыдай тыгыз сакалын муеныма батыра, сабый тәне тырнала, әчетә, ләкин барыбер коточкыч рәхәт, рәхәт! Ул вакытта әнәй дә бар әле. Дәвәнәй генә, уенын-чынын бергә кушып: «Төшер баланы, имгәтерсең!» – дип мырлап ала иде...

Картайды әтәй. Агарынган ефәк чәчләре тыңлаусызга әверелде, яңгыр бәргән печәнлек сыман әвеш-тәвеш яталар әнә, арадан кайбер әрсезрәк бөртекләре генә, табигатьнең бу холыксызлыгына буйсынырга теләмәгәндәй, тырпаеп тора бирә. Битенә дә түп-түгәрәк сакалы урынына өч-дүрт озын төк хуҗа. Маңгайда – буразналар. Яңаклары шәлперәеп төшкән, аскы ияктән күпмедер асылынып та торалар кебек. Куллары тупас, кытыршы, яргаланган. Киселмәгән калын тырнак аслары кер тулы. Механизатор бит ул. Аңа, ихтимал, шундый булу тиештер дә. Үзе алтын куллы инде! Теләсә нинди техниканы күз йомган килеш сүтеп-җыя ала! Кемнең «дружба»сы, кемнең матае, кемнең машинасы ватылды – барысы да аңа килә. Әтәй һәрвакыт ярдәмләшә, билгеле. Рәхмәт урынына сыйлыйлар. Аннары ул кереп түнә генә... «Капиталистлар дәүләте»ндә тугангамы:

– Нигә акчалата алмыйсың? – дип ачуланганым да булмады түгел. Хак ич: болай да дәвәнәйнең пенсиясендә утырабыз, букчам тузды, ботинка келәйдә генә тора, ә ул эчеп йөри...

– Авыл кешесеннән ничек оялмыйча акча аласың инде?

– Алайса чамалап кына эч, төтенгә әверелгәнче булмасын!

– Анысы безнең кулдан килми.

Отыры Кукмараны, Шәмәрдәнне уздык... Икеләнү хисләрен таратып: «Курса», – дип төгәллек кертте поезд радиосы.

Вагон гырлый. Әтәй дә изрәгән инде. Ләкин һаман, нишләптер, ныклап йокыга китә алмый изалана. Вакыт-вакыт елмаеп ала. Ул үзе белән бик горурланадыр хәзер: улын Казанга алып бара бит...

Мин, һичшиксез, училищега керергә тиеш! Менә ни-нәрсә икәнен белешеп кайтыйк та, җиң сызганып имтиханнарга әзерләнә башлармын. Мин, һичшиксез, артист булырмын! Мин меңләгән тамашачының күңеленә нур сибәрмен, йөрәгенә җылы салырмын, җаннарына утырган юшкыннарын юармын! Мин зур сәхнәдән берсеннән-берсе гүзәл шигырьләр сөйләрмен, җырлар башкарырмын! Халык мине алкышларга күмеп туймас! Минем Булатым «аһ» иттерер аларны, минем Хәлилем бәгырьләрен елатыр, минем Жан Баевичем егылганчы көлдерер, минем Хлестаковым чиркандырыр, минем Сатиным уйга калдырыр, минем Гамлетым алар белән бергә миллионлаган сорауларга җавап эзләр!

Әй-йа! Хыял-лый җүл-ләр!

Нәсел-нәсәбеңдә таш салучыдан югарырак һичкемең булмаган килеш!

Әтәй бер кәефсез чагында аңлаткан иде бит инде: «Башыңны чүбек белән тутырма, әнә, миннән калачак трактор ишегалдында көтә сине», – дип...

***

Безнең авыл елга буенда урнашкан. Агым буенча аскарак төшсәң, гаҗәп матур үзәнлекләр җәйрәп ята. Тал арасында калган болыннар элгәре заманнарда күмәк хуҗалыкныкы саналган, печәне чабылып, малларга кайтарылган, халык монда җәй буе гөр килгән, хәзер исә һичкемгә хаҗәтсез килеш, сагышлы күл-күзләрен күккә төбәп, тик аунап ята бирә. Хәер, алай ук түгелдер... Авыл көтүе шушы тарафларга төшеп утлый. И ул көтүнең рәхәтлекләре!

Таң тишегеннән авыл башына менәсең, чыбыркы шартлатып дөньяны мәрттән уятасың да, акрын гына малны җыеп, түбән очка төшә башлыйсың. Башта иң беренче йортлардан дүрт-биш сарык, бер-ике сыер чыга, түбән очка якынлашкан саен, мал-туар саны арта гына, утыз-кырык сарыкка, ун-егерме сыерга җыела, алары исә, аннары, авылдан чыгып китәрәк, ниһаять, чып-чын көтүгә әверелә!

Көзге салкынча иртә. Елга буе. Саргаеша башлаган үләннәрнең колак яфрагында энҗе чык тамчылары эленеп тора. Һавага дым сарган гүя. Юешлек исе. Кулыңны җилпеп җибәрсәң, җиңең, һичшиксез, сыгып алмалы булыр кебек.

Әтәй белән көтүдә һәрвакыт рәхәт. Җил куып йөрсәң дә, бер сүз әйтми. Ул, гомумән, ачулана белми. Кул күтәрүе турындагы уйны башыма да китерә алмыйм. Тфү-тфү! Тәүбә! Тугызлар җитәрәк, дәвәнәй тутырган әбәттән авыз итәсең. Анда, гадәттә, пешкән йомырка, ит салынган була. Иң әүвәл әтәй ала. Аннан алда ризыкка үрелергә йөрәк җитми. Йомыркага кул сузасың. Сак кына әрчисең дә, кабыгын җил уңаена очырып, тәмләп карарга ашыгасың. Шулвакыт әтәй пакет суза:

– Табигатьне чүпләмә, мә, җыеп ал.

– Монда бөтен тирә-юнь чүплек ич, – дип карыйм. Чыннан да, аяк асты – консерва савытлары, тәмәке каплары, аракы шешәләре...

– Булсын. Ә син чүпләмә, – ди ул.

Менә нинди ул минем әтәй!..

Чүбеңне җыеп, шыпырт кына йөгереп киләсең дә урыныңа утырасың.

Тагын бер хәл истә калган. Җәй көне. Коеп яңгыр яуды. Җелеккә кадәр салкын үтте. Өс – манма! Якын-тирә тулы агачлык булса да, учак ягып җибәрә алмыйбыз, булганы – чи, чи түгеле – дымлы... Көч-хәл белән әллә каян туз табып, ниһаять, ут тергездек, уч төбендә җылынган кан, йөрәк тарафыннан куылып, бөтен гәүдәгә таралды, тәнгә рәхәтлек керде. Көне буе ул утны күз карасыдай сакладык без. Кайтып китәрәк, артык калган тузны да үрсәләнеп янган ялкын кочагына ыргытырга уйладым, әмма әтәй бу ниятемә кискен каршы төште:

– Шунда, учак кырыенда калдыр син аны, бездән соң килгән кешеләргә җиңелрәк булыр.

Менә нинди ул минем әтәй!

***

Әнәй шул юашлыгы аркасында ташладымы икән аны? Миңа, әлбәттә, «аны» дип чикләнү җиңелрәк, болай дигәндә, җан ярасы ул кадәр кузгалмый. Гәрчә, билгеле, әнәй аны гына түгел, икебезне дә ташлап китте. Дөресрәге, киткән. Мин ул вакытта сабый әле. Аннары икенче кешегә кияүгә чыккан дип ишеттек, ләкин әтәйдән дә начаррагы туры килгән, ахры – кычкырыша-талаша яши торгач, буып үтергән ирен. Төрмәгә тыкканнар. Миңа моның барысын тәфсилләп сөйләүче юк, әлбәттә. Тегеннән-моннан, авыл хатыннарыннан һәм... бергә укыган малай-кызлардан ишетеп кенә беләм. Икенче сыйныфларда идемме, берзаман кайтып җитте ул. «Каян килдең, шунда китеп югал! – диде әтәй. Юк, юк, җикеренмәде, тавышын беркадәр күтәрә генә төште. – Бу авылны, бу йортны оныт!» Әмма әнәй күпмедер вакыттан соң тагын пәйда булды. Әтәйнең эштә чагы иде. Дәвәнәй – бакча ягында. Мин берүзем ишегалдында таптанам. Чакырып алды да үземне, машинага утыртып, әллә кая алып китте. Рульдә күн курткалы куркыныч адәм утыра иде. Чәкәш, Мәтвиләрне узып, бераздан шәһәргә килеп кердек. Мин чыр-чу җылыйм! Әнәй тынычландырырга тырыша. Менә бу кеше яңа әтәең була инде, ди. Искесе нишләгәндер? Йортларына килеп кергәч, һушымны җуеп егыла яздым – черегән байлар икән ләбаса! Диварларда картиналар, баш очында әллә нинди төсләрдә уйнаган люстралар, сервантларында әллә нәрсәләр ялык-йолык килеп тора, ә уенчыкларныңниндие генә юк! Җәннәткә үттеңмени! Ике катлы, кышкы бакчасы булган чып-чын оҗмах, валлаһи! Мин андагы чагымны Тукайның Соснада уздырган көннәренә охшатам. «Исемдә калганнар»ны укыганыгыз бардыр, шәт? Әмма әтәй әллә каян пәйда булып, мине табып алганда, бу эчпошыргыч затлылык үзәгемә үтәргә өлгергән иде инде: юк, алтын читлектә бикләнеп тотылган сандугач булганчы, иректәге тиресендә казынган тавык булу мең артык! Шул дүрт дивар арасында күпме азапланырга мөмкин? Бәдрәфенә кадәр өйдә бит аның, ичмасам – һич югы, печ итеп кергән арада азатлык сулап калыр идең.

Әтәй үзе генә түгел, милициядә эшләгән Азат абый белән бергә иде. Анисына тагын икәү ияргән. Без чыгып киттек. Алар калды. Дәвәнәй сөякләремне авырттырып бетергәнче кочаклап, буыла-буыла елады... Елаганын шунда беренче һәм бердәнбер тапкыр күрдем.

Бераздан «Вятско-Полянская правда»да «яңа әтәемне» атып үтерүләре турында хәбәр чыкты. Ишләре белән «асфальт» бүлешә алмаганнар, диелгән

иде. Әнәйне, нишләптер, тагын төрмәгә олактырдылар. Дәвәнәй бик озак вакыт авыз эченнән: «Бәхетсез хатын», – дип сөйләнеп йөрде әле.

Ләкин тормыш, гомумән алганда, яңадан үз көенә кайтты, бер көн икенчесен алыштырып, шулай бертөсле ага бирде, ага бирде...

***

Без Казанга кергәндә, монда да, календарьны инкарь итеп, көз тантана итә иде. Җанны изеп торган авыр болытлар белән офыктан-офыккача капланган дымлы, караңгы башкала идәннәре баскан саен аяк астында кыштырдый, ыңгыраша төсле иде.

Эри башлаган аксыл соры кар эреп бетә алмый интегә. Җиргә сылашкан ярымҗимерек йортларның нигез-почмакларындагы чүп өемнәре (гүя махсус эттереп куелган чүп өемнәре!) белән бергә бөгәрләнеп-череп яткан кар көртләре кимсенеп кенә, ниһаять, сап-сары кояш чыгып, аның кылычтай нурлары тарафыннан туракланып, бу калада җан асраргa мәҗбүр язның каһәрле күз яшьләре булып агып китәргә телиләр иде...

Без аяк астындагы туңдырма кәгазьләренә, тәмәке төпчекләренә һәм файдаланылган мәхәббәт капчыкларына басмаска тырышып, эчкәрәк – Казангарак керә бардык, керә барган саен, мәркәз махмырдан айнып бетмәгән бомжны хәтерләтте миңа. Җанымдагы нindидер бер бик нечкә хис җебе вокзал төбендә үк чертләп өзелгән иде инде...

Халык чаба, чаба, чаба! Кая чаба, ник чаба? Машиналар ыжгыра, автобуслар, көчәнә-көчәнә, алардан калышмаска тырыша, зәһәр матайларга атланган гаярь матайчылар рәтләр арасыннан тиз генә, шома гына үтеп чыгарга тели. Күк тимерчыбыклар белән капланган. Кешенең өскәрәк, күккәрәк чыгарга хакы юк! Трамвайлар, троллейбуслар, шуларны алып атарга теләгәндәй, кулларын сузган, әмма орынуга, фәләнчә вольтлы читлек челтәре тешләп ала үзләрен, һәм алар, чабуына ут капкан шикелле, бу урыннан җәтрәк эз суыту ягын карый...

Трамвайга утырып күпмедер келтерәгәннән соң, ниһаять, таныш йортлар күзгә чалына башлады: Камал театры, «Болгар» кунакханәсе... Янәшәдә Милли университетка әзерләнгән бина, диделәр. Зу-ур бер кибет янындагы тукталышта төшеп калдык.

– Әйдә, Казанны күрсәтәм, – диде әтәй.

Унбергә кадәр вакыт бар әле, нишләп беркадәр сәйран кылмаска?

Әтәй бик күп еллар элек авыл хуҗалыгы институтына укырга керергә теләгән дә... урыс теленнән инша яза алмыйча кайтып киткән. Шулай да үзен мәркәзне белә саный.

Без Бауман урамына аяк бастык.

– Да-а, донҗалар үзгәргән икән, – дип, куян бүреген баш чүмеченәрәк этеп куйды ул. – Монда гел икенче төрле ие...

Иң беренче эш итеп игътибарым чатта урнашкан гарәп хәрефле сәгатькә төште, башымны әле бер, әле икенче якка аударып, ни язылганын укып та маташтым әле: «Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан...»

«Макдоналдс»ны, «Казан» кунакханәсен, татар китабы кибетен (кайсыдыр гәҗит аны озакламый ябачаклар дип язган иде) урап чыкканнан соң, эскәмиягә гөрселдәп төштек. Аннары яңадан тәпиләп училищега юл тоттык. Тирләп-пешеп уку йортына килеп кергәндә, аяклар да, гәүдә дә ярыйсы гына алҗыган иде инде. Ишек төбендә басып торган бөкре әзмәвер белән ике-өч сүз алышып

алган арада, безгә шактый күңелсез хәбәр килеп ирештe: баксаң, ачык ишекләр көне... кичә булган икән. Йөрәк кысылып куйды.

– Бүген ничәсе соң? – дип сорады әтәй, каушап. Мин: «Унысы», – дигәч, маңгаена шап итеп берне сукты ул: – Ананңны-сс...

***

Казан дегеттәй төнгә чумды. Пыскаклап кына яңгыр ява. Шагыйрь әйтмешли: «Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый... Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы...»

Бик күп дөньяларга чыгара торган ишегенә җиткәч тә, мәркәзнең безне тиз генә үткәреп җибәрәсе килмәде әле. Әүвәл өч вокзал арасында адашып йөрдек. Аннары ялгышына кереп, ерак сәфәрләргә илткән поездга билет алдык. Нократ Аланына кадәр. Ат бәһасенә. Әтәй дурак калганын аңлап, билетларны кире тапшырырга ашыкты, әмма берьюлы ике урындыкны биләгән сөбханалла гына кассир ханым ярты бәядән артыгын кире кайтарырга уйламады да. Тәртибе шундый икән.

– Монда җитми бит инде, – дип үртәлде әтәй.

– Минем акча бар...

Шулай йөреп, төшке электричкага соңардык. Кичкесен көтәбез.

Әтәй терсәген тезләренә таяндырган да кәкре-бөкре бармаклары белән чәчен капшый, баш сөяген тишеп үтеп, эчтәге бер ми күзәнәгендә яшеренеп калган кайсыдыр фикер төшен чокып чыгармакчы була гүя. Үзе әледән-әле авыр көрсенеп куя. Ләкин бер сүз дә дәшми. Бер сүз дә. Ә мин дәвәнәйне кызганам. Бутыйларны күтәреп ничә кабат тукталышка чыккандыр инде ул...

## Гадәти бер кич иде

Сәгадәт апа бу юлы да, сәламемне алып тормастан, сүзен арт сабагымны укытудан башлады:

– Кичә «Хәерле иртә»дә карадым. Чыгышың бер дә ошамады. Андый шигырь сөйлисе түгел иде... Ничек әле... Мин ватык ояның... ялгыш исән калган бер кошы... Шулаймы? Нишләп алай дисең? Гаиләң тулы түгелме? Кагылып үстеңме? Горабасыңмы? Җирбит!

Кич җитүгә карамастан, Сәгадәт апаның тавышы утырмаган иде әле, язгы җилдә кыюсыз яфрак лепердәве кебек кенә ишетелсә дә, тарткан саен языла барган йон йомарламыдай җиңел, үтә күренмәле сүзләренә кушылган зәһәре, үзегез күрәсез, чатнап чыкты.

– Мин дә сине күрүемә шат, Сәгадәт апа...

– Ничек кайтып җиттең? – дип беркадәр йомшара төште ул.

– Әйбәт кенә. Башта электричкада. Кукмарадан әти килеп алды.

– Җирләдегезме?

– Җирләдек...

Ленар абый турында сорашуы. Ай буе айнымыйча эчеп йөргән дә, өченче көн, болай булмый, дипме, ниһаять, элмәккә менеп котылырга уйлаган. Әнисенең бердәнбер өмете иде. Хәзер ул карчык ялгызы нишләр?

О, ул Ленар абыйның футбол тибүен күрсәгез сез! Дистәләгән Пелеларың яисә, кем әле анда хәзер, Мессиларың читтә торсын! Үзе шундый таза, шундый чибәр – куаклыкка кызлар үзләре ябышып керә иде артыннан. Бик озак Казанда эшләп алды. Аның чия «девятка»сы авылның җәйрәп яткан сазлавыклы урамнарыннан очып кына үтә иде!

Шул... Нәрсәдер килеп чыкмады менә... Кырау сукты үзен. Күпмедер вакыттан соң авылга кайтты. «Девятка»сын әүвәл кытай тракторына, бераздан анысын белорус мотоблогына, тагын күпмедәндер велосипедка, ахырдан анысын бер яртыга алыштырды. Әйе, әйе, валлаһи, нәкъ теге мәзәктәге кебек.

– Кеше күп идеме соң?

– Бар инде. Яшьләргә халык йөри бит...

– Мәгъсүм төшмәде, – диде Сәгадәт апа. Аннары сүзсез калды. Бер тынга. Соңрак, озакка сузмыйча, үт сытарлык ачы соравын чыгарып салды ул:

– Ник асылына алар?

Каушап калсам да, әһәмият бирмәскә тырышып, «тормышлары авырдыр» дип кенә котыласым килгән иде, әмма, бәхеткә, тыела белдем. Тормыш авыр, ансы. Авылда эшсезлек, азганы азды, талыйсын таладылар... Җитмәсә, ярты Татарстанны үзләштереп, хәзер менә, ничектер, «банкротка чыккан» инвесторның бурычларын да якын ун-унбиш ел эчендә авылдан савып алачаклар икән... Ләкин тормышның, гомумән, кайчан җиңел булганы бар соң? Бусы – бер. Икенчедән, җиденче елын ятакта аунаган сырхау карчыкка ничек алай дип әйтәсең инде?

Ә Сәгадәт апа бетерешкән. Бетерешкән Сәгадәт апа... Түшәккә сеңгән, бөгәрләнгән җәймәнең бер башыннан шырпыдай нечкә ике ап-ак аягы чыккан да, икенче башыннан йодрык кадәр ап-ак башы гына тырпаеп тора. Чиргә сабышкач, ире әллә кая шабашкага китте дә шуннан соң кайтып күренмәде. Улы үсеп җитеп, килен алып кайткач, алар арасына да сыймый башлады. Гадәти хәл, кыскасы! Моңарчы кереп-карап кына йөргән буйдак энекәшенең кулына калды. Әле дә ярый ул булды. Башта этисен, аннары зиһене зәгыйфьләнгән әнисен соңгы юлга озатканнан соң, бушанып калган вакыты иде аның. Апасын үзе янына алды. Хәзер бергә яшиләр.

– Белмим шул, – дип мыгырдандым. Бүлмә янә тынып калды. Раил Садриевның телевизордан сикереп чыккан катыклы-әрсез тавышы гына дүрт дивар арасында адашып йөрде.

– Мәгъсүм абый эштәме соң?

– Кайтты инде. Каралты-кура тирәсендәдерме.

Һич рәхәт күрмәде инде ул, мескен. Өйләнгән иде дә... Әнисе белән тәлинкә-вазаларны вата-җимерә бер талашканнан соң, хатынын: «Үзегезгә булсын!» – дип, алган җиренә кире кайтарып куйды. Шуннан соң буйдаклыкта. Авызына бер тамчы да капмый. Капса дураклана чөнки. Башы китә. Үзе җен кебек тырыш, эш аты инде. Былтыр зеңләп торган сап-сары чыршы бүрәнәсеннән нинди йорт җиткереп куйды, абзар тулы мал, чебидән алып сыерына кадәр бар, ишегалдында «УАЗ» кетердәп утыра... Өйгә килгәндә, анысына хатын-кыз кулы җитми инде, билгеле: идән ярыклары пычрак белән томаланып беткән, тәрәзәдә таплар, чебен тамгалары... Түшәм белән дивар кавышкан почмаклардагы пәрәвездә үрмәкүчләр Сабан туе ясап мәш килә...

Ишегалдыннан: «Каһәреңне себерим!» – дигән янау белән бергә тереләй ысланган чучкадан чыккан җан ачысыдай хәтәр чинау ишетелде: Актүш тагын аяк астында буталып маташкан, димәк.

Бераздан тупсада Мәгъсүм абый үзе күренде.

– Нихәл, студент?

– Ярыйсы...

– Хәзер оныттың син безне, маңка чакта гына «чиле-пешле йомырка пешереп ашат әле» дип төшеп җитә идең...

– Юкны сөйләмә инде, кайткан саен киләм ич.

– «Ич»ләп җибәргән була тагы!

Мәгъсүм абыйның сипкелләрен каплап йөзенә чыккан шаянлыгы шул арада сүрелергә дә өлгерде, беркадәр җитдиләнә төшеп, әмма елмаюын җуеп бетермичә, Сәгадәт апага борылды ул һәм иллә дә ягымлы рәвештә:

– Ашап алабызмы, апа? – диде.

Җавап урынына түшәктәге җан иясе күзен генә йомып алды.

– Озак сөйләштегезмени?

– Әллә ни түгел инде...

Сәгадәт апаның беркадәр вакыттан соң шым булачагы мәгълүм иде миңа: тел очыннан ярты аваз да шудырып төшерә алмаган халәттә, ияген алга сузып, иреннәрен балык сыман чуп-чуп кына китереп ятканын үз күзләрем белән күргәнем бар. Чире нерв системасы белән бәйле. Тавыш ярыларына да тәэсир итәдер инде, күрәсең.

– Башта тәһарәтләник әле...

Эшнең нидән гыйбарәт икәнен аңлап, шыпырт кына кухняга чыгып киттем. Хәзер Мәгъсүм абый апасының астын алыштырачак. Газ мичендә быгыр-быгыр ботка кайнап утыра, утын беркадәр бастым, чәй ташыган, анысын сүндердем. Сөт салынган чокырда чалкан ятып йөзгән черкине калак арты белән генә алып аттым да, эчемлекне бер йотым уртлап куйдым. Залда карават шыгырдавы тынганнан соң, ике бүлмә арасындагы ишек тәрәзәләре зеңләп куйды:

– Манныйны бер тәлинкәгә салып чыгар әле...

Мин күндәм рәвештә аның боерыгын үтәргә ашыктым. Мәгъсүм абый «Бисмилла...» дип бер кашык тәгамне апасының авызына китерде, изге кәлимәне никадәр олылап әйтергә тырышса да, аның авызыннан кара көеп кыйналган бер имгәк сүз кебек мәтәлеп төште ул. Күпме шулай утырганбыздыр, карашым һич көтмәгәндә Сәгадәт апада абынып, умыртка баганасы буйлап җан өшеткеч салкын йөгерде: аның шар ачылган күзләрендә... яшәү уты дөрли ләбаса! Хәлсез иреннәре, бакчы, тәмсез боткалы ямьсез кашыкны ничек кысып капкан! «Җибәрмим!» – дип кычкырып тора! Беләзек кадәр генә калган муенына Газраил бармакларын батырырга уйласа, ул аны да, сау калган ярым-йорты дүрт-биш теше белән кимереп ташлаячак, чәрдәкләп бетерәчәк, ахыр чиктә, барыбер өзәчәк кебек иде. Билләһи!..

– Йә, соң инде, киттем, – дип, хушлашырга ашыктым мин. Пәлтәмне ябынып, ишегалдына атладым да, Актүш оясына җиткәч, кадакланган төсле, баскан җиремдә катып калдым. Эт авыр көрсенергә дә куркып ята иде. Каты эләккәндер шул. Исәңгерәгән халәттә кайнар кар кәзе белән чыраемны сыйпап алган арада артымда Мәгъсүм абыйның аяк тавышы ишетелде. Өйалдыннан чыкмады ул. Шундагы баскычка чүгәләп шырпы сызды.

– Түбән оч Марат югалган иде бит әле... Кордашың...

– Ул миннән олырак...

– Бүген тапканнар шуны... Ташландык сарайга кереп буылган...

Саубуллашырга өлгердемме икән, юкмы, кабаланып үзебезгә, Югары очка томырылдым: тизрәк, тизрәк өйгә кайтып җитәргә! Җанны изгән бу авыр тәэсирләрдән котылырга! Әмма никадәр генә кызуласам да, Сәгадәт апаның әрнүле авазы «ә» дигәнче куып җитте мине, куып җитте дә, чирәмлеккә егып салып, бертуктаусыз яңаклый башлады:

– Нигә асылына алар?!

Мин чирәмгә буялган ямь-яшел кулымны йөземә китердем. Кеше үлгәнне ишеткәч, ни диләр соң әле? Тик кысылган ирен арасыннан бер сүз дә таммады. Мин бернинди дога да белми идем.



Гөлгенә Кәримова

# КАЙГЫЛЫГА КУЛЫМ СУЗДЫММЫ?

## Рәнҗемәскә көч бир, Ходаем!

Читләр сүзе мине һич бетерми,
Якын кешемнеке үтерә –
Иң авыр сүз булып ишетелә,
Йокысыз төн, әрнү китерә.

Иң бәхетсез кеше иттерсә дә
Бер авыр сүз, бары бер адым,
Иң кадерле якын кешем бит ул,
Рәнҗемәскә көч бир, Ходаем!

Ятлар сүзе мине һич җылытмый,
Якын күргәннеке эретә –
Авыр яраларны төзәтә дә
Зәмзәм суларыдай терелтә.

Көтеп-көтеп тә бит җан атканым
Ясамаса мөһим бер адым,
Көткән сүзем әгәр ишетмәсәм,
Рәнҗемәскә көч бир, Ходаем!

Гамәлләре белән үпкәләтеп
Тапмый калса юату җаен,
Кайгыларың белән тик түләтмә,
Рәнҗемәскә көч бир, Ходаем!

Гөлгенә КӘРИМОВА – *журналист, шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Үзем таптым, үзем югалттым» исемле китап авторы. Азнакайда яши.*

* * *

Изге гамәлләрем булдымы соң,
Пакьтән идеме соң уйларым,
Үлчәүләрдә ни соң өскә калкыр,
Җитә калса соңгы туйларым?!

Ана хакын хаклый белдемме соң,
Балам дөрес тәрбия алдымы,
Китә калсам инде бакыйлыкка,
Дога укыр кешем калдымы?

Атам сүзен өстен куйдыммы соң,
Туганнарым якын күрдемме,
Вафат булган якыннарым өчен
Дога кылып, хәер бирдемме?

Мохтаҗларга ярдәм кылдыммы соң,
Кайгылыга кулым суздыммы,
Гөнаһлардан качып калалдыммы,
Юлларымны дөрес сыздыммы?

Дусларыма чын дус булдыммы соң,
Бәхетләрен күрә белдемме,
Кайгыларын ихлас уртаклашып,
Алар хакын өстен иттемме?

Чын дус таба алдыммы икән соң,
Авыр чакта терәк булырлык,
Соңгы көнем җитсә, чын йөрәктән
Соңгы юлга озатып калырлык?

* * *

Бозмый яшик Коръән аятьләрен,
Истә тотып җавап бирәчәгең.
Ялгышлардан язмыш үрәчәгең,
Онытмыйча гүргә керәчәгең.

Истә тотып ике иңдә изге
Фәрештәләр саклап торачагын,
Хәрәм эшләр тәкъдим кылып,
Иблис-шайтан мәкер корачагын.

Беркем белми күпме яшисен дә,
Кунак кына һәркем бу җирдә.
Беркем белми нәрсә күрәчәген,
Аллаһ кына хаким һәркемгә.

* * *

Һәрбер татар татар булсын иде,
Татарларны татар сатмасын.
Бер-беренең барыр юлларына
Киртә булып һич тә ятмасын.

Милләт данын берәү яклаганда,
Башкалар да йоклап ятмасын,
Милли төркемнәргә бүлгәләнеп,
Бергәлекне һич тә ватмасын!

Татар итеп үстерәсе иде
Һәрбер туган татар баласын.
Кайда гына язмыш ташласа да,
Татар булып килсен каласы.

## Табигать күңеле

Нишләдек, ни булды, нигә соң
Һәлакәт артыннан һәлакәт...
Кешелек, тын кал да уйлан бер –
Җавап тот, соңламый сүзең әйт.

Яшәсә игелек, иминлек
Булганда без сабыр һәм түзем,
Сакланыр табигать, кешелек,
Югалтмый саклыйкчы җир йөзен!

Ни булган, табигать зар елый –
Ул безне күзәтә, кисәтә.
Фасыллар тынгылык табалмый,
Җир-Ана, тыңлыйкчы, ни әйтә?

Ходайның, галәмнең кодрәтен,
Җир-Ана безгә бит аңлата.
Соңармыйк, саклыйкчы без аны,
Туачак буыннар хакына!

# «ЙӨРӘКЛӘР ТУРЫНДА ЯЗАСЫ БАР ӘЛЕ...»

## ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ 75 ЯШЬ

Шагыйрь Гәрәй Рәхим (Григорий Васильевич Родионов) 1941 елның 15 июлендә Татарстанның Шөгер (хәзерге Лениногорск) районы Федотовка авылында туа. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, колхозда, авыл китапханәсендә эшли, 1962-1967 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Укуын тәмамлагач, «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә, Татарстан китап нәшриятында эшли. 1972-1979 елларда Язучылар союзында әдәби консультант, «Казан утлары» журналының проза бүлеге җитәкчесе вазифаларын үти. 1979-1981 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда белемен күтәрә һәм РСФСР Язучылар берлеге идарәсенә Россиядәге төрки әдәбиятлар буенча консультант итеп эшкә калдырыла, 1987-1992 елларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә бүлек мөдире буларак хезмәт юлын дәвам итә. 1992 елдан – Татарстан Дәүләт Советында референт, мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр бүлеге мөдире, җәмәгать эше тәртибендә Татарстан Язучылар берлегендә әдәби фонд рәисе вазифаларын башкара.

Шагыйрьнең беренче шигырьләре мәктәптә укыганда ук языла һәм районның көндәлек матбугат битләрендә басыла башлый. Поэзиянең олы мәйданына Г.Рәхим алтмышынчы еллар уртасында чыгып, шигърият мәйданында «алтмышынчы елгылар» буынының бер вәкиле буларак урын ала. Беренче китабы «Вәгъдә» исеме белән 1967 елда басыла һәм шигърият мәйданына үзенчәлекле шагыйрь килүен хәбәр итә. Аннан соң дөнья күргән «Хәтер» (1970), «Гөрләвек» (1974), «Зирек бөдрәләре» (1976), «Моңнарым» (1978) кебек шигырь китаплары белән ул татар поэзиясендә традицион шигырь калыбын яңа алымнар белән баетучы лирик шагыйрь булып танылa. «Чәчәк сатучы малай» (1968), «Шатлык елы» (1972), «Ак күлмәкле кыз» (1977), «Көннәр язга авышкач» (1979) кебек җыентыклары Г.Рәхимнең проза, драматургия өлкәләрендә дә каләм сынап каравын хәбәр итә, тик гомумҗәмәгатьчелектә ул, иң беренче чиратта, шагыйрь буларак танылу ала, хикәя, парча, пьеса, скетч жанрларында язылган әсәрләрендә дә шагыйрь булып кала, лирик каләме сизелеп тора.

Г.Рәхимнәр буыны үз чорында шигырь төзелешендә «торгынлыкка» каршы чыгып, традицион кысаларга сыеша алмаган фикерләрне укучыга җиткерүдә яңа формалар тәкъдим итә, аналитик, фәлсәфи фикерләү калыбының үрнәген бирергә омтыла. Иҗатларының башлангыч чорында алар татар шигъриятен шәкел өлкәсендә тәҗрибәләр белән дә баета һәм әлеге үзенчәлек Гәрәй Рәхимнең башлангыч чор әсәрләрендә дә урын ала. Р.Фәйзуллиннар буынына хас булганча, Г.Рәхимнең 60-70нче еллар иҗатында да ике-, өч-, дүртьюллыклар аерым урынны били, кыска шигырьләрендә мәхәббәткә бәйле югалту һәм өмет, яшәеш мәгънәсе мотивлары зур урын тота, тормыш хакында уйланулар алга чыга. Аларга хикмәтле сүз әйтергә омтылу, яшәешнең төп кануннарын аерып чыгарырга яки тормышның «кыекларын» төзәтергә омтылу сыйфатлары хас. Мондый шигырьләрдә лирик герой тормыш-яшәешнең ике чиген тоташтыручы – табигать белән гармониядә яшәүче һәм шушы халәттә тормыш-яшәешкә бәя бирүче герой булып төгәлләшә. Мәсәлән:

*Көндез монда ап-ак кызлар су коена,*
*Ә төннәрен күләгәләр туе гына.*
(«Су буе» (Этюд))

*Әйтерсең лә узган гасырларда*
*Басып калган илсез сукбайлар –*
*Су эчендә тырпаешып тора*
*Каторжаннар суккан субайлар.*
(«Җимерек күпер яныннан узганда»)

Беренче шигырь тукымасында көн-төн, ап-ак кызлар һәм күләгәләр кебек капма-каршы якта торган образлар кеше яшәешендәге ак-кара башлангычларын төгәлләштереп, лирик геройның яшәешкә бәясен алга куйса, икенчесендә субай һәм сукбай образларын уйнату аша Г.Рәхим тормыш рәхимсезлегенә юлыккан кеше язмышлары, җимерек тормыш хакында уйлана.

Тагын бер тенденция төсендә Г.Рәхимнең кыска шигырьләрендә кеше халәте – табигать янәшәлеге, параллелизмы алымының еш кулланылуы күзәтелә. Табигать образларына мөрәҗәгать итү, хис-кичерешне җиткерү юлында файдалану татар поэзиясе өчен традицион алымнардан санала. Ләкин Г.Рәхим укучының игътибарын табигать картинасындагы бик вак детальләргә, мизгел-күренешләргә юнәлтә һәм шигырь тукымасында табигать күренешләре, идеяне тулысынча ачыклаудан бигрәк, автор фикерен, позициясен эзләп табуга ачкыч хезмәтен үти. Мәсәлән: *«Инде март, инде яңару, / Туктатам димәсеннәр. / Котылырсың инде, яфрак, / Бөреләр төрмәсеннән»*. («Яз»)

Беренче укылышта шигырь табигать күренешләре, яз килүе хакында хәбәр итә кебек, ләкин әсәр тукымасында бөре янәшәсенә язгы табигать матурлыгына хас булмаган төрмә образының урнаштырылуы аны башкача шәрехләү мөмкинлеген дә бирә. Әлеге ачкыч сүз аша укучы алтмышынчы еллардагы яңарышны, халык күтәрелешен дә таный ала, шушы дулкында дүртьюллык «йокысыннан уянган» халыкны туктату мөмкин түгеллеген искәртә.

*Карамыйсың гөлгә кызыгып,*
*Чәчәкләре беткәч коелып.*
*Тик бит, дускай, нәкъ шул гөлләрдә*
*Яңа чәчәк өчен мең орлык.*
(«Карамыйсың...»)

Биредә чәчәкләре коелып беткән гөл образы – өлкән, орлык – яшь буынны төгәлләштереп, автор фикерен ачуга этәргеч бирә һәм шигырь структурасында буыннар бәйләнешен, буыннардан буыннарга тапшырыласы тәҗрибәләр хакында уйланулар тергезелә. Аерым кыска шигырьләрдә Г.Рәхим, ассоциатив образлылыкка таянып, бер-берсеннән ерак торган төшенчәләрне тәңгәлләштереп, аларны көтелмәгәнчә берләштереп, яңа образ-сурәтләр дә тудыра. Мәсәлән: *«Тал башында калды карга оялары, / Хуҗалары ташлап киткән авыл кебек. / Җәй буена шаулап торган ялгыз талга / Кыш чыгарга монда калу авыр кебек»*. («Каргалар киткәндә»)

Әсәр тукымасында сурәтләнгән карга оялары һәм шаулап торган талның ялгыз калуы көзге табигать күренешен күзалдына бастыра. Шул ук вакытта татар поэзиясенә хас традицион көз-картлык янәшәлеге шигырьне башка дулкында уку мөмкинлеген дә калдыра. Икенчел яссылыкта ул балаларын төрле тарафларга озатып, ялгыз калган аналарның яшәешен, татар авылларының халәтен тергезә. Шул рәвешле, гадәти генә күренешләр ярдәмендә автор татар авылларының язмышы, аналарның хәсрәте турында сөйли. Шулай да Г.Рәхим каләменнән төшкән кыска шигырьләрнең күбесендә дидактик фикер алга чыга, эзләп табылырга тиешле идея шигырь тукымасында турыдан-туры әйтелә.

1970 елларда ачык күренгән салмаклылыкка омтылыш тенденциясе бу буын шагыйрьләр иҗатына да тәэсир ясый, сыйфат үзгәрешенә алып килә: тышкы ярсу кими, алар да «тыныч лириклар» эзләнүләренә якынлаша. Беренче булып бу юлга Г.Рәхим чыга, хис-кичерешләр дөньясына үз юлын табып, сабыр лиризмга, төгәл ритмикага өстенлек бирә башлый. «Сандугач», «Оныттың бугай», «Уйнагыз, гармуннар», «Моңлы уй», «Сагышланма» кебек шигырьләрендә мәхәббәт, яшьлек, гомер агышы, кеше һәм табигать кебек мәңгелек төшенчәләр турында уйланулар урын ала.

Г.Рәхим иҗатының шактый өлешен иҗтимагый барышка бәя мотивына нигезләнеп язылган әсәрләр тәшкил итә. Мондый поэтик үрнәкләрдә камил булмаган җәмгыятьтә яшәүче халык тормышына бәя бирелә, аларны җәмгыятьтәге тәртипләрне тәнкыйтьләүче лирик герой тибы бер бәйләмгә туплый. Аларда, традицион төстә, метафора-символлар, эзоп теле аша җәмгыятькә, сәяси системага бәя урын ала, кешенең үз-үзен танып-белү мәсьәләсе төп проблема буларак күтәрелә, әсәрләрнең үзәгенә «без нигә мондый, тормыштагы гаделсезлеккә мин ничек җавап бирәм?» кебек сораулар куелып, тормыш гаделсезлеге тудырган борчылу, үкенү хисе эчтәлеккә үтеп керә. Шагыйрьнең «Үлән арасыннан йөгергән

бөҗәк», «Әлли-бәлли бәү итмә», «Сызыклы уен», «Кеше башлы Гыйфрит», «Өч плакат» (Триптих), «Безнең ил» һәм башка шигырьләре шул хакта хәбәр итә.

Мәсәлән, «Өч плакат» әсәрендә плакат образы һәм аларның эчтәлеге аша кешеләр тормышына, шул чор хакимияте алга сөргән идеалларга бәя бирелә. Әсәрнең «Ышанырга!» дип аталган беренче өлешендә «Аллага ышанырга» гыйбарәсе уйнатылып, көрәк алласы, балта алласы, җир асты, җир өсте аллалары һ.б. аша динсезлек һәм денсезлек сәясәтенә ирония алымнары аша бәя бирелә. Әсәрнең икенче, өченче өлешләрендә дә икенчел эчтәлек аша кешеләрнең кушылганны үтәп яшәргә мәҗбүр ителү сыйфаты тәнкыйтьләнә. Лирик геройның борчылуы, сызлануы кешеләрнең бу тормыштагы авыр көнитешләре, өстән куелган таләпләргә буйсындырылуы белән бәйләп аңлатыла: «Кызганмаска / Җирдәге беркемне һәм бернине дә. / Табигать бар иткән / Һәр әйбер, һәр күзәнәк, һәр күренеш / Чиксез бөек. / Ә бөекләр булмыйлар кызганыч беркайчан да! / Шул исәптән син үзең дә!» («Өч плакат»)

1960-1980 елларда эзоп теленең хакыйкать темасы белән бәйләнештә активлашуы юмор-сатира үсешенә китерә, әлеге сыйфат Г.Рәхим иҗатын да читләтеп үтми. Шагыйрьнең «Ялган шигырь», «Гаилә рифмалары», «Шәрә шар», «Эт белән мәче кебек» һ.б. юмористик шигырьләрендә кеше холкындагы кимчелекле яклар, төзәтелергә тиешле сыйфатларын яхшы итеп күрсәтергә омтылган типлар ятратып көлү үзәгенә алына. «Шәрә кендекле кызга», «Элек һәм хәзер», «Әйләнәдер куласа», «Ертык җырлар», «Тезләнүче акыл» кебек сатирик әсәрләрендә исә яшәп килүче җәмгыятьтәге бюрократлык, әхлаксызлык, социаль-көнкүреш җитешсезлекләр ачы тәнкыйтькә дучар ителә.

1990 еллардан Г.Рәхимнең иҗтимагый эчтәлекле шигырьләрендә милли теманың көчәюе күзгә ташлана. Аларга хас төп тенденцияләр буларак татарның бәйсезлеге, киләчәге, язмышы, үткәне өчен сызлануның яки аның милли сыйфатлары белән горурлануның алга чыгуы күзәтелә, символик образ, метафора, детальләргә мөрәҗәгать ителсә дә, алдагы әсәрләр белән чагыштырганда, милләт язмышы хакындагы фикерне турыдан-туры белдерергә омтылу сыйфаты калкулана, үзгәртеп кору биргән мөмкинлектән файдаланып, фикер әйтеп калу теләгенең көчәюе эзоп телен икенче планга күчерә. Мәсәлән, «Тамыр», «Татар җыры», «Татар кешесе», «Тукай», «Әй, Идел-йорт», «Халкыбыз дәшә», «Мин ирекле» һ.б. шигырьләрендә әлеге сыйфатлар калку чагылыш таба.

Г.Рәхим иҗатының буеннан-буена сузылган мотивларның тагын берсе – туган якны сагыну мотивы. Ул еш кына туган якка, әнигә мәхәббәт темасы белән керешеп китә. Мондый шигырьләргә тирән лиризм, табигать образларының байлыгы хас, аларны туган ягына мөкиббән, еракта аны сагынып сыктаучы лирик герой бер бәйләмгә туплый. «Сандугач», «Уйнагыз, гармуннар», «Урамнар артында яшел болын...», «Елагыз!», «Елыйсы да, көләсе дә», «Җилләп барам», «Натюрморт», «Туган як имәннәренә», «Кылганнар», «Хатирә», «Романтика» һ.б. шигырьләрендә Г.Рәхим туган як образын лирик-фәлсәфи төсмерләрдә баетып, үзенә иң якын, изге урын буларак төгәлләштерә:

*Мин бит сезне бик сагынып кайттым,*
*Мин ич шушы җирнең баласы.*
*Имәннәрем, сезнең яшәештән*
*Килә минем өлге аласым.*

(«Туган як имәннәренә»)

Югарыда аталган шигырьләрдә туган як белән горурлану, матурлыгына соклану хисе яки туган якны сагыну тойгысы алга чыкса, шагыйрьнең аерым лирик әсәрләрендә туган як темасының башка яссылыкта ачылышы да күзгә ташлана. Әйтик, «Туган якта» шигырендә лирик геройның әрнү хисенә кайчандыр шаулап-гөрләп торган, тулы канлы тормыш белән яшәгән авылның югалуы, андагы рухи яшәешнең үткәннәрдә калуы, яшь буынның әхлаксызга әверелүе, буыннар арасында рухи бәйләнешләрнең өзелүе фаҗигале төсмер бирә, авылның рухи бөтенлеген сакларга тиешле яшь буынның «нахалга әверелүе», илаһи матурлыкның югалуы, табигатьнең бозылуы хис тудыручы сәбәп булып килә: *«Сары балчык... / Тузанлы юл... / Көтү таптаган ярлар... / Нахал оныклар үстерә / Без сөйгән асыл ярлар»*.

Һәр шагыйрь иҗатындагы кебек үк, Г.Рәхим шигъриятендә дә мәхәббәт мотивы әйдәп баручы сукмакларның берсен тәшкил итә. «Оныттың бугай», «Мәхәббәт», «Сөюдар»,

«Мәхәббәт хаты», «Йола сүз», «Камыш һәм кувшин», «Соңладык», «Кышкы җыр» һ.б. шигырьләре шул хакта хәбәр итеп мәйданга чыга. Аларда, гомумән, мәхәббәткә сокланучы, хәтта табынучы, сөйгән ярына мәдхия җырлаучы лирик герой алга чыга, традицион образ-сурәтләр мәхәббәтне яшәеш нигезе, яшәү мәгънәсе, асылы югарылыгына күтәрә. Мондый шигырьләрдә шагыйрь еш кына үзләре мәхәббәт символына әверелгән типларга яки шәркый символикага мөрәҗәгать итәргә ярата. Мисал өчен «Мәхәббәттә синең белән» шигырендә Таһир-Зөһрә образлары мәхәббәттә тугрылык темасын ачарга ярдәм итә:

*Ләкин син дә минем белән*
*Чатырлар куялмадың.*
*Син Зөһрә булган чакларда*
*Мин Таһир булалмадым.*

*Нишлисең, безнең сөюләр*
*Яшиләр ике якта.*
*Икесе бер үк ялгышу,*
*Икесе ике хата.*

Аерым шигырьләр традицион мәхәббәт-нәфрәт каршылыгына корыла. Әйтик, «Боз сөңге» шигырендә ут-боз сөңге янәшәлегенең мәхәббәт-нәфрәт көчешен җиткерүгә юнәлтелүе матур шигъри табыш булып тора.

Г.Рәхим иҗатында актив мотивларның тагын берсе – иҗат мотивы. Ул еш кына шигырь структурасында яшәү мәгънәсе, яшәү кыйммәте турында уйланулар белән үрелеп китә. «Шигырь», «Көч», «Тамыр», «Китап», «Сүз тәме», «Төрлесеннән язып карадык без», «Туар булсаң әгәр өтек хисләр», «Кечке шигырь» һ.б. шигырьләрендә иҗат мотивының мондый фәлсәфи уйланулар белән бер үремтәдә бирелүе Г.Рәхим иҗатының бер үзенчәлеген тәшкил итә. Мондый лирик үрнәкләрнең асылы шагыйрьнең «Вәгъдә» шигырендә үк урын ала, ул, гомумән, бу бәйләм шигырьләр арасында «программ шигырь» буларак та бәяләнә ала:

*Йөрәкләр турында язасы бар әле –*
*Һәм исән йөрәкләр,*
*Һәм үлгән йөрәкләр,*
*Һәм сүнгән йөрәкләр турында.*
*(Мин беләм:*
*Бер исән йөрәкнең күптәннән сүнгәнен,*
*Бер үлгән йөрәкнең һаман да сүнмәвен...)*

Экзистенциаль мотивлар белән сугарылган шигырьләрдә дә шигърияткнең мәңгелеге, үлемсезлеге сыйфаты калкытып куела. Мәсәлән, «Китмә» шигырендә әлеге күренеш белән очрашабыз:

*Беркөн мине үлем алып китәр,*
*(Белмим, шагыйрь аңа ник кирәк?!)*
*Тик ул чакта китмә минем белән,*
*Бу дөньяда кал син, шигърият!*

Охшаш мотивлар шагыйрьнең «Быжылдап оча божан», «Җир яңара» кебек шигырьләрендә дә урын ала.

Шул рәвешле, Г.Рәхим иҗатын иҗтимагый барышка бәя, туган якны сагыну, мәхәббәт, иҗат мотивлары иңләп ала. Шагыйрь поэзиясенең үзәгендә төрле статуслардагы – тормыш-яшәешкә бәя бирүче яки милләт яшәеше хакында уйлануларын җиткерүче, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылучы, шуның белән янәшәдә мәхәббәткә табынучы – лирик герой тора. Әлеге сыйфат-үзенчәлекләр барысы да Г.Рәхим иҗатының шигърияттәге традицияләрне дәвам итүе, үстерүе, яңартуы хакында сөйли.

**Нурфия ЮСУПОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез Гәрәй Рәхимне олуг юбилее белән котлыйбыз! Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары, күңел көрлеге, рух ныклыгы, сәгадәтле гомер телибез!*

# ТУКАЙ ТУРЫНДА «КАРДӘШ КАЛӘМНӘР»

Анкарадагы Евразия Язучылар берлеге нәшриятының «Кардәш каләмнәр» журналы быелгы апрель санын тулысы белән бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлын яктыртуга багышлады. Тукай хакында мәгълүмат дөньяның төрле почмакларына – Россия, Украина, Казакъстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Төркия, Гыйрак, Иран, Мисыр, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Алмания, Америка, Франция, Англия һәм башка илләрдә яшәүче төрки телле халыкларга тарала дигән сүз бу.


Сүз уңаеннан шуны да әйтик: Төркиядә бер гасыр эчендә Тукайга тулысынча багышланган журналлар саны бишкә җитә. Татарстан һәм Евразия Язучылар берлекләре хезмәттәшлегендә чыккан «Кардәш каләмнәр»нең әлеге тупланмасы – шуның соңгысы. Дөрес, 2006 елда дөнья күрә башлаган әлеге журналда Тукай иҗаты даими яктыртылып килә. Мәсәлән, 2011 елда, Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан, татар шагыйренең шигырьләренә һәм аның турындагы язмаларга урын бирелде, 2015 елгы санында кардәш халыкларга Фатих Кутлу тәрҗемәсендә «Су анасы» поэмасы төрекчәдә тәкъдим ителде. Габдулла Тукайның 130 еллык юбилее уңаеннан оештырылган быелгы апрель саны Ф.Кутлу тарафыннан шагыйрьне һәм, гомумән, татар әдәбиятын төрек дөньясына таныту максатында эшләнде, нәтиҗәсе дә гүзәл дип әйтер идем.

Инде үз кешебезгә әйләнеп беткән Фатих бәй моңа кадәр дә төрек-татар әдәби бәйләнешләре юнәлешендә зур эш башкарды: Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Рабит Батулла һ.б. 50дән артык татар әдибенең әсәрләрен төрекчәләштерде. Бу тәрҗемәләр сыйфат белән дә, сан ноктасыннан да игътибарга лаек: 70тән артык хикәя, 4 повесть, 1 пьеса, 1 роман һәм күпсанлы шигырьләр Төркиядә һәм Татарстанда 13 тупланма булып дөнья күрде. Аның Тукай фәнен үстерүдә дә зур өлеше барлыгын махсус ассызыклыйсы килә: Али Акбаш белән берлектә шагыйрьнең 130 шигырен тәрҗемә итте – җыентык дөнья күрде.

Ф.Кутлуның Татарстан Язучылар берлегендә әгъза булып торуы шулай ук төрек-татар дуслыгының ныгуына хезмәт итә. Ул үзе дә якыннан аралашкан татар галимнәре һәм язучыларыннан төрек дөньясына яңгыратырга кирәк тапкан темаларга мәкаләләр яздырып, аларны төрекчәләштерде һәм «Кардәш каләмнәр»нең чираттагы басма эчтәлеген, структурасын төзеде. Үзе бу турыда: «Төрледән-төрле язмаларны тәрҗемә итү, аларга тиешле күрсәтмә материалларны әзерләү, эзләп табу шактый вакыт – айлар сорады. Бу – шундый җаваплы эшкә беренче мәртәбә батырчылык итүем. Мине моңа вөҗданым мәҗбүр итте. Чөнки, яшерен-батырын түгел, Тукайны фәнни даирәдә махсус өйрәнүче берничә галимнән кала Төркиядә белүчеләр юк дәрәҗәсендә. Шушы журналны укучыда Тукайга карата соклану-хәйранлык, аның шигъриятенә кызыксыну уяныр дигән өмет бар күңелдә», – ди. Фатих бәй сүзләренә кушылып, шуны өстисе килә: журнал белән китап бер-берсен тулыландырып тора, журналны алдан укып өлгергәннәрдә Тукайның төрекчә чыккан шигырьләр китабын кулга төшерү теләге туар, һәм киресенчә дә булырга мөмкин.

Журналда Тукайның тормыш һәм иҗат юлы фәнни-популяр һәм популяр мәкаләләр аша яктыртылып бара. Авторлар Татарстан галимнәре һәм язучылары язмаларыннан гыйбарәт булып, төрек вәкилләреннән тюрколог Мостафа Өнәр, шагыйрь Али Акбаш, тәрҗемәче Фатих Кутлуның язмалары Тукай турындагы фәнгә киңрәк күзаллау тудыруга ярдәм итә. Басмада Ә.Алиева һәм Ф.Ибраһимова тарафыннан 2003 елда төзеп чыгарылган китап нигезендә Тукайның тормыш һәм иҗат елъязмасыннан, иң мөһим вакыйгалар белән бергә, аерым тәрҗемәи хәле, З.Рәсүлева төзегән шәҗәрә, мәхәббәт тарихыннан Зәйтүнә истәлекләре дә китерелә.

Басмада Тукайның милли һәм дини юнәлештәге шигырьләреннән үрнәкләргә зур урын бирелә. «Милләтә», «Пәйгамбәр», «Милли моңнар», «Өзелгән өмид», «Мигъраҗ», «Ләззәт





вә тәм нәрсәдә?», «Күңел йолдызы», «Монафыйкка», «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Таян Аллага», «Туган тел» һ.б. әсәрләр Али Акбаш тарафыннан гаять төгәл – шигырь төзелешенең формасын, жанрын, ритмын, яңгырашын бозмыйча башкарыла. «Җөмлә фикерем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем; / Сыйххәтеңдер – сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер – гыйлләтем», дип җырлаган Тукайның милли шигырьләренә аерым игътибар бирү шагыйрь иҗатының төп асылын яктыртуга ярдәм итә. Г.Исхакый сүзләре белән әйткәндә, «Казан кулдан киткәннән бирле юксыллыкка, үксезлеккә баткан милләтенең кайгысы, моңы Тукайның үзенең шәхси кайгы-хәсрәте төсене ала вә Тукай милләт моңыны көйли торган, милләт бәхетсезлегене җырлый торган әллә никадәр шигырьләр мәйданга китерә, милли моңны шигыренең эченә ашлый».

Җыентыкта шигырьләрне сайлап алып урнаштыруда төрек темасы чагылыш тапкан әсәрләргә басым ясау ачык күренә. Тукайның башлангыч – Җаек чоры иҗатының дини, дини-суфичыл шигырьләре белән госманлы диван әдәбияты арасында жанр, тел-стиль, образлар бирелеше, шигырь төзелеше һәм эчтәлек уртаклыгы бар. Шагыйрьнең Балкан илләре белән сугышта Төркиягә теләктәшлек белдергән, Төркияне зурлап, мәдхия җырлаган «Тәмсил», яшь төрекләр җитәкчесе Әнвәр бәккә багышланган «Әнвәр бәк» шигырьләре китерелә. Соңгысы янына Әнвәр бәкнең Петербургта укучы татар кызлары арасында төшкән фотосы (Р.Батулланың шәхси архивыннан) да бирелә. Шигъриятнең – иҗатның асыл вазифасын чагылдырган «Күңел йолдызы» да Тәнзимат әдәбияты вәкиле Габдулла Җәүдәтнең «Кыйтга»сыннан эпиграф белән башлануы төрек укучысына кызыксынуны арттыра.

Татар шагыйренең төрек мәдәнияте, тарихына зур игътибар бирүе, кардәш милләтләрнең киләчәк яшәеше, мәгърифәте, азатлыгы өчен борчылып иҗат итүе җавапсыз калмый. Төрек матбугатында Тукайга багышланган язмалар шагыйрь үлеменнән соң ук дөнья күрә башлый: «Тасвире әфкяр», «Ислам дөньясы», «Төрек йорды», «Төрек сүзе», «Кырым» кебек госманлы газета-журналларында тәгъзияләр, татар шагыйре турында кечкенә күләмле мәгълүматлар басыла. Моннан тыш, Төркиядән татар редакцияләренә тәгъзияләр, кайгы уртаклашулар, хатлар килә. Шуның бер мисалы буларак, «Кардәш каләмнәр» үз битләрендә Истанбулдан Русияле таләба җәмгыяте җибәргән «Бөек милләтчемез Тукаевның вафатыннан долае милләтемезнең гаиләсенә бәяне тәгъзият иләрез» эчтәлегендәге телеграммага һәм «Истанбулдан мәктүб» дигән язмага урын бирә. Болар барысы да киң катлам укучы өчен зур яңалык булып тора.

Әлеге санда дөнья күргән олы, урта буын галимнәре һәм яшьләрнең шагыйрь иҗатындагы төрле проблемаларны яктырткан язмаларының үзара чиратлашып килүе Тукай фәненең бүгенге торышын ачык чагылдыра. З.Мансуровның «Тукай белән әңгәмәләр»е китабына – Р.Зәйдулла тарафыннан, Р.Исламов һәм Ж.Миңнуллин төзегән «Тукай ядкярләрдә» икетомлыгына тәфсилле күзәтү ясала. Персональ энциклопедияләре булмаган төрек дөньясы өчен Р.Харрасованың Тукай энциклопедиясенең төзелү тарихы белән таныштыруы аеруча мөһим. Бирелдә Тукай фәне алдына куелган яңа бурычлар да ачык күрсәтелә. Димәк, әлеге фән алга таба да үсәчәк дип уйларга кирәк.

Журналда Әмирхан Еникинең «Ялганны яклау» язмасы совет идеологиясе нигезендә үсеш кичергән Тукай фәнендәге хилафлыкларны читтәге кардәшләребезгә ачыграк аңлатуга хезмәт итә. Билгеле булганча, 1971 елда Ә.Еники, З.Ишмөхәммәтовның «Тукай атеизмы» китабы дөнья күргәч, Тукай клубында лекция укый һәм «Тукай – атеист» гыйбарәсен кире кага: «Тукайдан идеология эзләү белән генә чикләнмичә, аның рухи халәтен тоя-аңлый белү кирәк. Шул чакта гына чын хакыйкатьне дөрес чамалап булачак», – дип, шагыйрь иҗатына сакчыл булырга чакыра. Бары ике дистә вакыт узгач кына, әлеге фикерләрен матбугатта бастыра ала. Шуны да искәртү кирәк: «Тукай атеизмы» китабы




төрек дөньясы өчен дә таныш була. 1986 елда бу темага Төркиядә яшәүче милләттәшебез профессор Н.Дәүләт мөрәҗәгать итеп, «Тукай атеист идеме?» дигән язма белән «Төрек культуру» журналында чыгыш ясый.

Профессор Х.Миңнегуловның «Шагыйрьлеккә тугры Тукай», Н.Хисамовның «Шигъриятта Тукай феномены» мәкаләләре шагыйрь иҗатының асыл хасиятләрен ачарга ярдәм итә. М.Хәбетдинованың «Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә Тукай» мәкаләсе татар әдәбиятында Тукай традицияләренең чагылышын ачык яктырта. Р.Мөхиярова язмасында 90нчы еллар татар матбугатында Тукай шигырьләре ярдәмендә гарәп, фарсы, госманлы, төрки сүзләренең кулланыла башлавы мисаллар белән дәлилләнә. Р.Фәйзуллинның Тукайны «үлемсезлек символы», Р.Рахманның «халкыбызның бер тылсымы, дөреслек, милләтпәрвәрлек үлчәве» буларак бәяләве, Р.Гаташның «Тукайга мәхәббәт юлы»ндагы фәлсәфи-лирик уйланулары – татар шагыйренең бөеклеген аңлауга замандашларыбыз ясаган кирәкле адымнар ул.

Р.Батулла «Гасырлар могҗизасы» язмасында: «Без Тукайдан ерагая барган саен, Тукайның бөеклеге арта барыр; ул киләчәк буыннар өчен Алып батырдай биек-калку булып күренер, чөнки Тукай үз иҗаты белән Алып, үз шигыре белән каһарман», – диеп киләчәккә үз күзаллавын җиткерә. Басмада яшь буын фикерләренә дә аерым урын бирелә. Шагыйрь Р.Мөхәммәтшинның бер гасыр элек Тукай әсәрләрендә халкыбызның авыр иҗтимагый-сәяси тормышы нәкъ бүгенгечә яктыртылуы – Тукай фаҗигасе, безнең фаҗигабез булуы турында борчылулы язмасы бар. Язучы Р.Галиуллин хәзерге татар әдәбияты барышы хакында Тукай иҗаты югарылыгыннан торып сүз йөртә, профессиональлектән ерак торган, сүз-рифма уйнатуыннан буш эчтәлекле әсәрләр язып, үз акчасына китап чыгарып, исем алып йөрүче «шагыйрь, язучыларны» кискен тәнкыйть итә. «Тукайдан ераклашу – халыктан ераклашу», диеп җан ачынуын белдерә, Тукайга таянырга чакыра. Күргәнебезчә, тупланмага кергән әсәрләргә, теге яки бу проблемаларга автор мөнәсәбәте ачык чагылыш таба.

Журнал беренче битеннән үк Тукай фотолары белән бизәлеп бара. Тукай фотолары күп түгел. Алар 1903-1913 еллар аралыгында шагыйрьнең Мотыйгыя мәдрәсәсе шәкерте чакларыннан алып танылган шагыйрьгә әверелгәнче чорын, әйтик, Казанга күчеп килүен, татар язучылары, журналистлары арасында үз кеше булып китүен, төрле шәһәрләргә сәяхәт кылуын чагылдыра. Соңгы рәсемнәрдәге шагыйрь – Клячкин шифаханәсендә соңгы сулышын алучы Тукай. Шунысын да әйтеп узыйк: фотоларның төп нөсхәләре Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә һәм Казандагы Габдулла Тукай әдәби музеенда саклана.

Тукай исән вакытта үзе төзегән китаплардан үрнәкләр дә бирелә. Шагыйрь исән чакта 22 исемдә 46 китабы «Мәгариф», «Сабах», «Үрнәк» матбагаларында дөнья күрә. Әлеге китаплардан берничәсенең генә булса да тышлыкларын журналда тәкъдим итү әдипнең 26 еллык кыска гомерендә никадәр зур эш башкарылуы турында тагын бер кат уйлануга чакыра. Журналда Татарстанның Казан, Арча, Чаллы, Алабуга, Азнакай, Әлмәт шәһәрләрендә генә түгел, Мәскәү, Санкт-Петербург, Әстерхан, Барда, Җаек, Анкара, Истанбулдагы Тукай һәйкәлләреннән фотолар бирү – татар шагыйренең бар дөньяга танылу алуы һәм хөрмәт ителүе турында сөйли.

Халык язучысы Аяз Гыйләҗев заманында: «Безнең әле Тукайның бөеклеген бүтән милләт вәкилләре дә кабул итәрлек дәрәҗәдә ача алганыбыз юк. Без аның татар тарихында тоткан урынын әлегәчә аңлап та, аңлатып та бетерә алмыйбыз», – дип яза. «Кардәш каләмнәр»нең Тукай юбилее уңаеннан чыккан саны бөек шагыйребезнең иҗатын төрки дөньяга тирәнрәк танытуда зур эш башкарды.

**Алия МӨБАРӘКШИНА**

## Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхимгә — 75 яшь




Шагыйрьләр. Сулдан уңга: Гәрәй Рәхим, Илдар Юзеев һәм Рөстәм Мингалим. 1985 ел.




Гәрәй Рәхим Яңа Кырлай авылының Габдулла Тукай паркына үз исеменә аталган чыршы агачы утырта. 2009 ел.



Армия генералы Мәхмүт Гәрәев белән шагыйрь Гәрәй Рәхим Татарстан Дәүләт Советында. 2008 ел.



*Язучы-журналистлар. Сулдан уңга: Харрас Әюпов, Рашат Низамиев, Сәмигулла Хәйретдинов. 1979 ел.*



*Әбрар Сәгыйди (Әбрар Закир улы Сәгыйтов. 1895-1939). Шагыйрь, журналист, педагог.*



*Заманында әдәбият, мәгариф, нәшрият дөньясында мәйдан тоткан ир-егетләр. Сулдан уңга: Ислам Әхмәтҗанов, Хатыйп Миңнегулов, Фарис Харисов. Бөтендөнья татар конгрессы көннәре. Казан (Корстон бинасы), 2012 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# ТУКАЙ ОЧЫРГАН КАРЛЫГАЧЛАР: ОРКЫЯ ИБРАҺИМОВА

XIX йөз мәгърифәтчелек әдәбияты, милләт һәм халык төшенчәләрен аерып караудан бигрәк, гомумән, милләт исеменнән фикер йөртте, гомуммилли алгарыш һәм омтылышлар турында сөйләде. XX гасыр башында татар тормышында хәлләр уңай якка күпмедер үзгәрсә дә, милләтнең ирекгә кысылган, мөстәкыйльлек турында уйлау да куркыныч, хәтта икътисади барышы да бик нык артка калган иде әле. Болар, билгеле, әдәбиятта чагылыш тапмый калмый. Инде матбугат ирекгә алган татар шигърияте кискен үсеп китә, тематик һәм проблематик киңәя. Әлбәттә, ул иң башта татар милләтенең укымышлылыгы, аң-белемгә, төрле һөнәрләргә ия булырга тиешлеге хакындагы карашларны калкуландыра.

Әдәбиятыбызда хәтта тәнкыйди реализм методы формалашып җиткәннән соң да, аңа мәгърифәтчелек реализмы алып килгән билгеләр тиз генә юкка чыкмый. Габдулла Тукайның да, аның тәэсирендә иҗат иткән башка каләм ияләренең дә поэзиясен алар теге яки бу планда озак елларгача сугара. Әле каләмгә алынуының тәүге елларында Габдулла Тукай юкка гына: «Без – бу мәгърифәт гасыры сараеның ияләре һәм балалары», дип белдерми. «Гыйлемнең бакчасында...» әсәренең әлеге юллары XX гасыр башы талантларының үзләренең элгәреләре – Ш.Мәрҗани, Г.Чокрый, М.Акмулла, К.Насыйри кебек мәгърифәтчеләр корган нигездә формалашуы һәм алга таба алар төзегәнне сакларга, яңартырга, үстерергә тиешлеге хакында сөйли. Шагыйрь әле без дә яшәгән узган гасырның аң-белем ноктасыннан никадәр алга китәчәклеге хакында фаразлап та уза сыман.

Оркыя Ибраһимованың «Теләк» әсәрендә мәгърифәтчелек идеясенә хезмәт итүчеләрнең, милләттәшләрнең бер җепкә тыгыз бәйләнүе хакында менә мондый юллар бар:

*И Ходаем, безләрне берлек җебе илә бәйлә син,*
*Тугры фикереңне үзең сал, һәркем үзе аңласын.*

XX гасыр башы поэзиясенең кискен үсеше җәмгыятьтә шәхескә, аның иҗтимагый барыштагы роленә, мөнәсәбәт үзгәрешләренә барып тоташа. Татар шигъриятендә шактый активлашкан иҗтимагый лирикада, үз чиратында, шәхесне калкулату көчәя, чөнки һәр каләм иясе үз халкының әйдаманына әверелә, көрәшчеләр мәйдан тотар чак җиткәнлекне аңлап эш йөртә.

Г.Тукай, алгарыш дилбегәсен гадәт буенча һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, ир-атларга тоттырса да, хатын-кызларыбызның да алар белән бер арбада алга баруын кайгырта. Аның бу төр идеяләре хатын-кыз галәменә шулкадәр көчле тәэсир итә ки, әлеге тема шагыйрәләр һәм әдибәләр иҗатында иң үзәккә куела, һәрберсе моның өчен халык шагыйренә рәхмәт укый. Тукай язганнар тәэсирендә каләме формалашкан О.Ибраһимова кебек көчле рухлы талантлар татар хатын-кызларын җебегән, мескен итеп күрергә һәм күрсәтергә теләми, алар үз араларыннан якты йолдызларны табып алып, кылган гамәлләрен тасвирлап, шәхесләренә биргән бәяләмәләрен укучы хөкеменә чыгара.

Моңа кадәр мәдехнамәләр күбрәк ирләргә язылса, Г.Тукаевның беренче татар

профессиональ артисткасы С.Волжская кебек олуг затларны мактаган җиңел каләме белән, ниһаять, татар шигъриятенә илгә эш күрсәткән кыз затларны мәдехләү килеп керә. Әйтик, Оркыя Ибраһимова күренекле педагог, Казанда дөньяви фәннәр укытылган беренче кызлар гимназиясен ачкан Фатиха Аитованы күкләргә чөя:

*Китте кара болыт, чыкты кояш,*
*Атты якты, нурлы таңнары;*
*Калыкты хатын-кыз галәменең*
*Балкыган ак нурлы айлары.*

Автор «Китте кара болыт...» әсәрендә Фатиха ханымны исеме тарихларга калачак фидаилар арасында күрә. Ике шагыйрьне дә иҗтимагый-мәдәни мәйданда беренчелекне алган хатын-кызлар сокландыра, икесе дә тасвир объектын мондый очраклар өчен традицион булган кояш һәм ай образларына тиңли. Шушы уңайдан, Тукай әсәрен дә искә төшереп узыйк:

*Күр: ничек иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула, –*
*Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина.*

*Бу икәүгә Тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:*
*Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.*

Оркыя Ибраһимованың «Киңәш» дип исемләнгән шигыре белән Габдулла Тукайның берничә әсәре арасында текстара бәйләнешләр ачык тоемлана. Шулай да ул эчтәлеге белән шагыйрьнең «Кемне сөяргә кирәк?» шигыренә якынрак тора. Г.Тукай анда фаразланган әңгәмәдәшенә дөньяда беркемнең беркемгә кирәк булмавы, кеше хәсрәтенең башкаларга читлеге, дусларга ышаныч юклыгы, беркемнең ярдәмгә атлыгып тормавы һәм башкалар турында сөйли дә ахыр киңәшен шушы рәвешчә бирә: «Үзеңне сөй! Ярат үзеңне үзең!»

Инде Оркыя Ибраһимованың «Киңәш» әсәрен мисалга китерик:

*Бар сүзем шул: һичвакыт барма адәмләр каршына,*
*Үзләрен дә һич чакырма бервакытта каршыңга.*

*Дөньяда тор ялгызың тик, һичбер иптәш эзләмә.*
*Бу миңа ярдәм итәр, дип, берәүне дә күзләмә.*

*Шулай ит син: дөньяда тор ялгызың тик, берүзең,*
*Сөй үзеңне – якты булыр кичләрең һәм көндезең.*

Бигрәк тә Г.Тукай көче белән моннан бер гасыр элек татар сатирасында детальләштерү арта, интим лирикада кеше кичерешләренең бөтен нюанслары игътибар үзәгенә алына. Без моны О.Ибраһимованың «Китте шагыйрь» («Хатыннлар хамисе мәрхүм шагыйрь Габдулла Тукаевка ядкяран язылган») исемле әсәреннән дә күрәбез.

Текст, бер яктан, традицион көнчыгыш мәрсияләр рухында һәм аларның бөтен алымнарын кулланып иҗат ителгән: анда гомуми мактаулар да җитәрлек, кеше кылган реаль гамәлләр дә санала. Мактау объекты бик калку, сыйфатлары бары тик уңай, аны югалту – зур югалту. Шигырь электә патшаларны һәм югары урыннардагыларны, бигрәк тә вәзирләрне югалткач язылган ядкарьнамәләрне искә төшерә. Икенче яктан, әлеге жанр эчтәлек ноктасыннан шактый заманча, актуаль. Ул кешенең иҗатына, язганнарына бәя булып тора, анда интертекстуальлек гаять көчле. Автор Каләм иясен

«милләт шагыйре» сыйфатында сурәтли, аерым юллардан Тукай әсәрләренекенә тартым аһәңнәр дә тоемлана:

*И шагыйрь, ямьле шагыйрь, милли шагыйрь, син чын шагыйрь,*
*Күземездән түктереп яшь, хәсрәткә салган шагыйрь.*

Игътибарга алыйк:

*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!*
(Г.Тукай. «Пар ат»)

Алга таба шагыйрә Г.Тукай текстларындагы гыйбарәләрне, образ-хәрәкәтләрне үз әсәренә трансформацияли:

*Ул нарат, чыршы агачлар һәрбересе кайгылы;*
*/.../*
*Су буенда сайрый торган төрле-төрле кошлары –*
*Барысы да кайгыралар, ул Ходай былбыллары.*

О.Ибраһимова шулай ук Тукай бастырып чыгарган соңгы һәм мөһим җыентыкларны («Күңел җимешләре» – 1911; «Җан азыклары» – 1912) исенә ала. Әсәрдә шагыйрь каләме иҗат иткән образлар җанландырыла. Шагыйрә Алтын әтәч, Шүрәле һәм Су анасыннан табигатьне халыкка белдерүче, кадерле шәхеснең, милли һәм үткен телле шагыйрьнең китүе турында сүзләр әйттерә.

XX гасыр башында иҗтимагый тормыш никадәр генә җанланмасын, тормышчан интим лирика да, китаби образларга нигезләнгән абстракцион сурәтле мәхәббәт шигырьләре дә бихисап языла. Бу төр үзгәрешләр һәм Габдулла Тукай, һәм Оркыя Ибраһимова иҗаты мисалларында да ачык күзаллана. Хәтта ки «Китте шагыйрь» әсәрендә дә авторның гавам һәм табигать кичерешләре хакында үз интим хисләрен дә кушып сөйләвен ачык тоемларга була. Ахыр юлларны ул инде зур гомумиләштерү рәвешендә, милләт исеменнән сөйли:


*Милләтнең каһарманы, чын шагыйремез, калмадың,*
*Бары калды безләргә (синең) ядкарь әсәрләрең.*

*Һич тә чыкмас исмемездән, Тукаев, исмең синең,*
*Керсә дә шул кара җиргә вакытсыз җисмең синең!*

Әдәбият гомер бакый укучыга идеалдагы җәмгыять һәм кеше образын тудыру белән мәшгуль. О.Ибраһимова иҗатында аның иң көчле һәм ышандыргыч мисалы – Г.Тукай һәм ул хыялында күзаллаган ирекле, аң-белемле, башка дәүләтләргә тиңләшкән татар иледер.

**Рифә РАХМАН**

# ЯШӘҮ МАТУРЛЫГЫ – САУЛЫКТА



*«Кирәк вакытта, кыен ситуацияләрдә тәвәккәл адымнар ясауга сәләтле, төрле ясалма киртәләр аша чыгуны булдыра ала торган кыю зат», – дип сурәтли аны рәссам Нәҗип Нәккаш, Казан каласының 18нче шәһәр клиник хастаханәсе баш табибы, медицина фәннәре кандидаты, «Европа-Азия» Халыкара гуманитар академиясенең мөхбир-әгъзасы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы, күренекле җәмәгать эшлеклесе* ***Рөстәм Сәйфулла улы БАКИРОВ****ка атап ясалган тугрысында. Укучыларыбызга әлеге танылган шәхес белән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире* ***Илфак Ибраһимов*** *әңгәмәсен тәкъдим итәбез.*

***– Рөстәм Сәйфуллович, табигать үзе үк сәламәтләндерә дигән әйтем бар... Әлбәттә, табигать үзе таза-сау булса гына, сихәтләндерү сәләтенә иядер. Сез, гомер кичкән инсани зат кына түгел, ә бөтен гомерегезне сәламәтләндерү-сихәтләндерүгә багышлаган күренекле табиб. Сез – җиде меңнән артык операция ясаган хирург... Димәк, тәнне тузган, зарарланган әгъзалардан арындыручы, аларны төзекләндерүче... Кыскасы, әйдәгез, сәламәт яшәү турында иркенләп сөйләшик әле.***

– Әлбәттә, сәламәтлек хәзер кешенең үзеннән генә тормый. Нинди чорда яшәгәнебезне онытмыйк. Ходай Тәгалә Җир шарын, андагы тереклекне шундый итеп яраткан ки, бер генә җан иясе дә, үсемлек, хәтта бер күзәнәкләләр дә артык түгел. Алар һәммәсе үзара тыгыз бәйләнгән. Ошбу гармонияне күреп шаклар катарлык! Хәтерлим, берара, Кытайда чыпчыкларга каршы һөҗүм башлаганнар иде, имеш, үсемлекләргә зыян салалар. Төрле зарарлы кортлар үрчи башлауга, кытай дуслар чыпчыкларны кире читтән сатып алып кайттылар! Төлке, бүре дә кешегә зыян сала, дибез. Соң... алар булмаса, табигатьне, урманнарны төрле авыру хайваннар басып китәчәге дә мәгълүм бит. Мисаллар күп. Мәсәлән, сулыклар, елгалар кибә, юкка чыга, дибез. Әүвәл без үзебез елга буендагы әрәмәлек, агачларны кисеп аттык, ә алар исә үз чиратында суларны саегудан, кибүдән саклап торганнар икән! Саный китсәң, бихисап мондый мисаллар. Мин, хирург буларак, кешенең эчке органнарын үз күзем белән күргән кеше, бер генә артык әгъза да юк анда. Ләкин кайсыдыр орган эштән чыккач, аны кисеп атарга туры килә бит инде. Кеше аннан соң яшәвен яши, әмма организмдагы баланс бозыла да куя. Бер бөер белән туу очраклары да бар, бу инде Ходайдан сынау.

Чүп үләне дә, алабутасы да кирәк табигатькә. Аларсыз җир ашланмас иде. Сугыш вакытында бабайларның алабута күмәче аркасында исән калуы хакында әйтүем түгел. Сугышны Ходай башламый, кешеләр үзләре чыгара. Шуның белән тереклектәге баланс бозыла, адәм баласы шуның аркасында черек, өшегән бәрәңге, алабута күмәче ашарга мәҗбүр була. Монысы башка тема. Хәер, акрынлап, сорауларга җавап бирә-бирә, шул фикергә таба барабыз шикелле. Кешелек тарихына күз салсаң, исең китәр, адәм баласы гомер буе проблеманы үзенә үзе тудырып тора! Урмандагы бүре авызына кабып алып килми аларны, нәкъ менә үзе тудыра ул аны!..

***– Табигыйлек – табигатьнең үзе булса, кешеләр арасындагы, җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләр аерым кагыйдәләр, кануннар белән көйләнеп алып барыла... Аны инде традицияләр, йолалар белән ныгыталар. Гасырлар дәвамында тупланган милли йола, традицияләребезнең аеруча кайсылары кешелекнең саулыгын, икенче төрле әйткәндә, сәламәт яшәвен тәэмин итүгә юнәлтелгән? Милләтнең, гомумән, җәмгыятьнең***

***сәламәт яшәвендә бүгенге көндә сулаган һавабыз, эчкән суыбыз, ашаган ризыгыбызның сыйфаты ни дәрәҗәдә?..***

– Менә, мәсәлән, намазны гына алыйк. Беренче чиратта, ул адәм баласын рухи яктан сафландыра, сәламәтләндерә. Гомумән, шәригать кануннарының барысы да шундый! Соң, шулай булмыйча, намаз уку үзе үк сәламәтлек, хәрәкәт бит инде ул! Аннан соң намаз алдыннан тәһарәтләнү? Болар бит чисталык, сафлык, ягъни тагын шул ук сәламәтлек дигән сүз. Хәмер эчәргә ярамый, тәмәке тарту тыела, хәрәм ашамаска һәм башкалар! Татарның барлык фольклор уеннары да хәрәкәтле, ә хәрәкәттә – бәрәкәт инде. Шунысы кызык: милли йолаларны элеккеге патшалар үзләренең указлары нигезендә тудырмаган, алар – халыкныкы! Сәламәт яшәү рәвеше гади халыкның тормыш фәлсәфәсе ул, димәк!.. Безгә аны үзебезнең булыр-булмас ясалма кануннар белән бозарга ярамый. Болар безгә Фрейдның психология китаплары аша түгел, әби-бабаларыбыздан ук килә. Буыннан-буынга тапшырылып бара, күзәнәкләр аша сеңә, геннар аша бирелә. Безнең авыл Казаннан өч йөз чакрым ераклыкта. Ләкин мин оныкларым белән авылда бик еш булам, алар хәзер үзләре дә анда кайтырга атлыгып торалар. Һәр елны туган авылда «Авыл көне» бәйрәме уздырабыз. Быел аны «Бәрәңге бәйрәме» итәргә исәп, чөнки сугыш вакытында безнең әби-бабалар бәрәңге аркасында гына исән калган. Әти дә, әни дә шулай дип сөйлиләр иде. Илһамланып китеп, бәрәңге хакында җыр да яздык әле, бәйрәмдә башкарырга уйлыйбыз. Мондый бәйрәмнәр табигать белән дә якынайта. Адәм баласының бар авыруларының сәбәбе ул табигать кануннарына каршы килү һәм аларга буйсынмыйча яшәүдән! Мин моны табиб буларак әйтәм! Аннан соң, экология бит ул заводтан чыккан төтен генә түгел, ул кешенең үзенең эчке чисталыгы, яшәү рәвеше дә. Билгеле, хәзер бик күп төзелә, тиеш булмаган җирләрдә күп катлы йортлар да калка, кайвакыт саклану чаралары да кулланылмый.

***– Сезнең нәсел-тамырыгызны, шәҗәрәгезне барлап язылган китабыгыз белән танышканда, гаилә, нәсел-ыру традицияләренә булган тирән ихтирамыгыз нык сизелә. Тыйнаксызлык, димәгез, үзебезнең Хак динебезгә карата мөнәсәбәтегез ничек? Совет чорында атеистик темага лекцияләр уку табибларга һөнәри бурыч булып та йөкләнде бит.***

– Мин, бу соравыгызга җавапны алдан ук биреп куйдым кебек, ә менә дин хакында, әлбәттә, кичләр буе сөйләшеп утырырга була. Хәер, моның өчен кичләр генә дә җитмәстер. Беләсезме, әлеге сорау мине кайчакта куркытып та куя, чөнки мондый сораулар еш кына модага әйләнеп китүчән һәм җаваплары да! Шуңа күрә, матур сүзләр кыстырырга тырышмыйча гына, бер-ике сүз белән җавап бирәм: диннең кешегә мөнәсәбәте ничек – адәмнең дә аңа мөнәсәбәте шулай ук! Элегрәк, халыкка ислам динебезнең «мөнәсәбәте» богаулап куелан иде, гомумән, барлык диннәр дә тыелды бит инде. Ә менә без, Аллага шөкер, авылда үскәч, рәсми рәвештә тыелса да, бала чакта ук аның йогынтысында тәрбияләндек. Әти-әниләр ярдәме белән! Авыл җирендәге гореф-гадәтләр аша! Диннең безгә «мөнәсәбәте», тәэсире булды. Аннан соң, дин әле ул мәчет яки чиркәү генә түгел, Ходай Тәгалә адәми затның, һәр бәндәнең күкрәк читлеге эчендә булырга тиеш! Ә ул исә анда бары тик ана сөте белән генә керә ала! Менә шул, күңелеңдәге Югары Акыл Ходай белән тоташа да инде. Мондый тәрбия орлыклары бала чактан ук салынган булмаса, аны булдыру, ай-һай, кыен эштер... Дини кануннар – алар тормыш фәлсәфәсе. Тик хәзер динне төрле максатларда файдаланучылар күбәйде. Шунысы куанычлы: Татарстан җитәкчелеге инде менә ничә еллар буе үзенең «рухи мәхәллә»сен булдыру өчен тырыша! Безгә исламдагы төрле агымнар түгел, ата-бабаларыбыз инанган, аларның яшәү асылы булган динебез кирәк! Үзебезнең дин белгечләре, дини уку йортларыбыз кирәк. Болгар ислам академиясе ачылу да зур куаныч.

***– Әйе, Сез дөрес әйтәсез... Саулык, сихәтлек өчен инсаннарның акыл саулыгы, күңел-уй саулыгы тагын да әһәмиятле. Үзегезнең шәҗәрә китабында әтиегезнең яшәү рәвешенә, Ата кеше буларак гаилә тормышын алып барудагы роленә тирән ихтирам белдерәсез... Баксаң, гаилә – дәүләтнең бер күзәнәге, дип бәяләнү коммунистлар уйлап тапкан афоризм гына түгел. Безнең әткәйләр, сугыштан гарип-***

***гораба кайтсалар да, үз гаиләләренең башлыгы, ханы, президенты да була белделәр. Фронтовик әтиегез, җиде бала табып үстергән әниегездән Сезнең аша балаларыгыз, оныкларыгыз, тагын җиде буынга нинди сыйфатларның күчүен теләр идегез?***

– Ата-бабаларыбыздан килгән Иман нуры күчсен иде оныкларыбызга! Безнең тамырлар авылга береккән, дидек. Буш сүзләр генә түгел бу. 2011 елда «Сүз» нәшриятында туган ягым тарихына багышлап чыгарылган «Безнең тамырлар – Бизнәдә» китабы – шуның бер дәлиле. Китапка кереш сүздә оныкларга мөрәҗәгатем бар:

*Үсә төшкәч, бу китапны*
*Укып чыгарсың әле.*
*Анда – мең сорауга җавап,*
*Анда – яшәүнең мәне.*
*Анда – ата-бабаларның*
*Һәм минем тормыш гаме.*
*...Каләмеңнән төшкән һәр сүз*
*Килер буынга калсын.*
*Укып гыйбрәтләр алсын да*
*Юлыннан горур барсын!..*

Яшьләргә шундый сорау да бирәсем килә: «Кайчан да булса үткәнеңә – тарихка әйләнеп караганың бармы? Анданиләр күрәсең? Шул хакта балаларыңа, оныкларыңа ни рәвешле сөйләргә уйлыйсың, туган?» Оныкларның нинди булып үсүе дә фәкать үзебездән генә тора.

Оныклар дигәннән... Үзем җитәкләгән хастаханәнең ташландык балалар бүлеге хакында да берничә сүз әйтеп китим әле. Әйе, чынлап та, ташландык балалар анда! Кемдер сабыен вокзалда калдырып киткән, кайсысын чүплек савыты янынннан табып алалар һәм әлеге бүлеккә китерәләр. Мин аларның опекуны, ягъни «бабалары» булам. Ташлап киткәч, әлбәттә, аларның һәрберсенең диярлек сәламәтлегендә ниндидер тискәре үзгәреш була, без шуны дәвалыйбыз. Рәхмәт хөкүмәткә, ата-анасы баш тартса да, аларны ташламый. Менә бу балаларга иман нурын кем сеңдерер икән? Ана сөтен кем имезер? Күп нәрсә, ахыр чиктә, ана сөте белән керә, дидек бит. Никадәр генә яхшы шартлар тудырырга тырышсак та, без аларга барыбер әти-әнисен алыштыра алмыйбыз. Ана назын, ата кайгыртуын тоеп үсә алмыйлар бит алар – шунысы кызганыч. Гаиләләребезне, милли гаилә институтларын саклау, аның уңай үрнәкләрен алга чыгару каләм ияләренең дә эше, минемчә...

***– Әйтегез әле, намус-әхлак төшенчәсе бүген актуальме? Гамил Афзал: «Мин минизм алга киткән заман, акча санап хисләр киткән заман», – дип ачы гына көлгән иде безнең заманнан?***

– Кризис, икътисади кризис дип сөйләшәбез. Ходай кушса, узар ул, кайчан булса да. Ә менә рухи кризис килсә, китәргә дип килмәячәк! Монда таба килергә юлга чыккан инде ул!..

***– Әти-әниегезнең еш куллана торган нинди мәкаль-әйтемнәре исегездә калган?***

– Әти – сугыштан күп орден-медальләр белән кайткан кеше, аның турында тулы бер роман язып булыр иде. Кызганыч, исән чагында сугыш турында гади солдаттан алынган мәгълүмат буларак күбрәк сөйләтеп калдырмаганмын. Әти әйтергә ярата иде: «Җиде кат үлчә – бер кат кис», дип. Хирургка бу исә тагы да мөһим. Утын кискәндә дә ул безгә барсын да бер үлчәмдә итеп, 20 сантиметр итеп кистерә иде. Күтәреп алырга уңайлы, матур булып тезелеп торсыннар, дип. Операциядән соң да тәннең җөйләре тигез, күзгә артык ташланмый торган булып төзәлә алу мөһим. Моңарга бигрәк тә хатын-кызлар нык борчыла.

***– Гомер озынлыгы кыскара, авыруларның яше яшәрә, диләр. Кеше үзе гаепле-ме, әллә һаман да шул ук экология мәсьәләсеме бу? Табибларның профессиональ эшчәнлеге дә роль уйнамыймы? Бәлки, кешенең үзеннән дә торадыр, әйтик, вакытында табибка күренмәү...***

– Әйбәт табиблар күп булсын өчен, әлбәттә, табибка, беренче чиратта, яхшы шартлар кирәк. Түбән Камадан күчү көтмәгәндә булды. Республиканың ул чактагы сәламәтлек саклау министры Камил Зыятдинов тәкъдим ясагач, бераз икеләнеп тә калдым, Түбән



*Күренекле кардиохирург Ренат Акчурин, Америка кардиохирургиясе патриархы Майкл Дебейко һәм башка олы кунаклар 18нче хастаханәдә.*

Камада тормыш көйләнгән иде бит инде. Камил Шагарович бу хастаханәгә күп көч куйган иде. Монда баш табиб булып эшли башлагач та, аның эшен дәвам итүче буларак, үземә максат куйдым: әлеге хастаханә радиоприбор эшчеләренеке генә түгел, шәһәр күләмендә иң яхшы хастаханәләрнең берсе булырга тиеш, дип. Кеше гомере – иң кыйммәт әйбер, ул аны сиңа ышанып тапшыра. Дәвалануның нәтиҗәсе – авыруга төгәл һәм дөрес диагноз кую. Шуны күздә тотып, 1996 елны ук хастаханә базасында заманча җиһазландырылган, үз эченә компьютер томографиясен, ультратавыш, эндоскопия ысулларын алган район консультация-диагностика үзәге оештырдык. Бүгенге көндә хастаханә күп яктан алдынгы. Күпчелек табиблар хастаханә ачылган көннән бүгенгә кадәр эшлиләр икән – бу да хастаханәнең дәрәҗәсе турында сөйләмиме?! Алар барысы да югары квалификацияле белгечләр, күбесе фәнни дәрәҗәгә ия, мактаулы исемнәре бар. Терапия, неврология, хирургия һ.б. бүлекләр белән берлектә психотерапия бүлеге дә бар әле бездә. Көндәлек мәшәкатьләр, стресслар нерв авырулары килеп чыгуга сәбәпче була, биредә авыру комплекслы тикшерү уза, психолог киңәшләрен дә ала. Хастаханә каршында поликлиника булу да зур әһәмияткә ия, авыру тикшеренү узуга, тиз арада хастаханәгә урнаша. Сүз дә юк, һәр ясаган операцияң горурлык хисе бирә, ләкин яшь барган саен, ул хис кими төшә, ничек итеп кешенең гомер озынлыгын арттыру турында уйланасың. Анык беләм, 90 яшькә җитсә дә, кешенең үләсе килми. Без янгын сүндерүчеләр кебек: алар өйне саклап калырга тырышса, без кешеләрне саклап калырга тырышабыз, тик моның өчен чирне вакытында ачыкларга кирәк, янгынны да шулай бит. Без бүген бәхетле чорда яшибез. Югары технологияләр заманы. Медицинада бу бик мөһим әйбер. Безнең табиблар теләсә кайсы илдә эшли ала. Армиядәге кебек, медицинада да патриотизм хисе булырга тиеш. Авыруның табиб белән беренче очрашуында ук арада ышаныч туа алуы да бик мөһим әйбер. Сиздегезме, хастаханә ишегалдына килеп керүгә, үзгә бер һава, ис, мохит... Эрбет агачлары хикмәте бу. Эрбет агачлары паркы да безнең горурлыгыбыз. Авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, сугыш ветераны, агроном Габбас ага Камалетдинов тырышлыгы белән булдырылган алар. Нарат һәм эрбет агачларыннан үсеп чыккан «кедрач» 1998 елда табигать һәйкәле, республиканың милли хәзинәсе дип игълан ителә. Шифасы барлыгын бирегә килгән һәркем әйтә.

***– Мөмкин булса, түләүле медицина турында да сөйләшеп алыйк әле. Андый төре гадәтиеннән нәрсә белән аерыла? Халыкка кайсы яхшырак? Түләүледә чират юк, тик гади халык анда бик бара алмый...***

– Мин – ике заманда да эшләгән кеше. Ләкин хәзерге заман түләүлене дә таләп итә. Без бит чит илләрдән дә күрәбез. Медицинаны дәүләт үз өстенә алды, югыйсә. Кеше налогын түли, бу бит инде ике тапкыр түләгән кебек килеп чыга. Аерым затларның үз акчаларына ачкан шифаханәләре, билгеле, түләүле. Сайлау мөмкинлеге кешенең үз ихтыярында. Түләүсез медицина бар һәм булачак дип уйлыйм. Чит илләрдә дә шулай.

***– Табиблар, математиклар арасыннан иҗади сәләткә ия затлар, язучылар, көйязарлар чыкканын беләбез. А.Чехов белән үзебезнең Ш.Хөсәеновның исемнәрен әйтү дә җитә... Бүген дә ак халатлы дусларыбыз арасында иҗат белән шөгыльләнүчеләр бар. Республика клиник хастаханәсе табибы – пульмонолог, шагыйрь һәм прозаик Нәкыйп Каштанов та... Һәм – үзегез! Сезнең шигырьләргә җырлар***

***язылa... Әтиегезгә багышланган поэмагызны бүген һәр әдәби журнал бернинди ташламаларсыз бастырып чыгара алыр иде... Иҗатка ни-нәрсә этәрә?***

– Бәлкем, безнең заманда милли мәктәпләребездә туган тел, әдәбиятны бик үтемле укытудандыр... Әдәбиятыбыз, халык авыз иҗаты бик бай бит безнең. Тукайлы халыкның күңелендә шигырь уты булу табигыйдер. Тукай – үзе бер могҗиза. Ни өчен каләм аламмы кулыма, белмим, төгәл генә җавап бирә алмам кебек бу сорауга. Табигатем шундыйдыр инде, күрәсең. Минем уемча, әгәр дә бар табиблар да шигъри күңелле була икән, начар булмас иде. Җитәкчеләр дә бераз шагыйрь булса, ә? Минтимер Шәрипович күптән түгел булган бер очрашуда: «Мин кайчак күңелгә килгән шигырь юлларын кәгазьгә төртеп куярга гадәтләнгән!» – дию белән мине аяктан екты! Шагыйрь күңелле җитәкче! Шагыйрь күңелле олуг физик яки математик! Начармыни?!

***– Тагы да әйтегез әле: коллектив җаваплылык төшенчәсе бармы ул? Бүген үзегез эшләгән хастаханәдә тулаем хәлләр өчен баш табиб күмәк җаваплылык куямы? Куйса, моңа ничек ирешелә?***

– Бер генә җитәкче дә, эшендә нинди дер уңышка ирешкән икән, ул коллективтан башка була алмый. Мин үземнең коллективым белән чын күңелдән горурланам, аларның һәммәсенә рәхмәтлемен. Күз алдына китерегез: хирург кына операцияне башкарып чыга аламы? Һәр операциядә коллектив эшли. Җаваплылык та коллектив өстендә. Һәркем үз эшенең остасы булса гына, зур уңышларга ирешергә мөмкин. Һәрбер уңышыбыз – уртак җимешебез.

***– Узган елдан бирле халык экраннардан Г.Әпсәләмов романы буенча төшерелгән «Ак чәчәкләр» фильмын карый... Бүгенге өлкән яшьтәге табиблар, аеруча хатын-кызлар үзләренең әлеге һөнәрне сайлауда романның тәэсире булуын әйтәләр... Әлбәттә, романда да, фильмда да үрнәкләр бар...***

– Хәтерлисезме икән, 60-70 нче елларда авылда иң абруйлы кешеләр табиблар һәм укытучылар иде! Хәзер исә бу хәл бераз кими төште. Табиб белән укытучының абруе зур булгач, димәк, медицина белән мәгариф тә абруйлы, ягъни кирәкле дигән сүз бит инде! Әлбәттә, аларның бүген дә кирәге бетмәгән. Дөньядагы кебек безнең илдә дә үзгәрешләр бара. Ләкин үзгәрткән чакта элеккеге традицияләрне дә онытмаска иде, чөнки үткәнгә таянмыйча, якты киләчәкне корып булмый! Билгеле, кайбер урында алга китсәк тә, кайберләрендә әле тиешле дәрәҗәдә эшләнеп бетмәгән әйберләр бардыр. Әйткәнемчә, кешеләр үзләре дә сәламәтлекләренә, Ходай биргән гомерләренә сак карасыннар иде.

Фильм турында нәрсә әйтә алам: миндә роман тәэсире әле дә яши... В.Аксёновның «Коллегалар» әсәре экранга менде... Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»е, ниһаять, тасмага язылды... М.Маликованың табиблар турында язган романнары бар. Язучылар бүген дә гомерләрен кеше сәламәтлеген кайгыртуга багышлаган табиблар турында әсәрләр язсын иде.

***– Халык медицинасы турында да фикерләрегез белән уртаклашсагыз иде. Имтомчы, күрәзәче-диагностлар, «сыпырып алып төзәтүчеләр» кемнәр дә, чын-чынлап табигать үзе биргән сихәтләндерү көченә ия затлар кемнәр?***

– Сүзне ерактан ук башлыйм әле. Халык медицинасы да, аның йолалары да, ырымнары да юктан бар булмаган. Мәсәлән, минем җаныма «җиделе» саны якын. Безнең халык борын-борыннан бу санны үз иткән: җидегән чишмә, җидегән йолдыз, җиде юл чаты, җиде кат күк, җиде кат җир асты һ.б. Әтием белән әнием дә җиде малай тәрбияләп үстерделәр. Һәркемнең балачагы, яшүсмер вакыты, егетлек чоры була. Аннан инде гаилә корып җибәрәсең, балалар туа, ир уртасы дигән исем аласың... Мин, табиб булсам да, бервакытта да халыкның дәвалау чараларына өстән карамадым, аларны үз балаларым өчен дә куллана идем. Канга сеңгән инде ул авыл белән бергә. Без бит авыл малайлары, дип кабатларга яратам мин. Казанда гына түгел, Мәскәүдә, Парижда, Мисырда – пирамида иленә барып яшәсәк тә, шул ук авыл малайлары булып калырбыз. Кайчакларда, эчем пошып, үземә урын тапмый йөргәндә, хатыным Фәридә әкрен генә әйтеп куя: «Рөстәм, авылга кайтып килмисеңме соң?» Кайтып



*Гаилә учагы җылысы.*

китәм шулай авылга, тәнгә генә түгел, җанга да сихәт алып киләм!.. Халык медицинасы да, беренче нәүбәттә, шул авыл җирлегендә туган түгелме соң?! Тәнне генә түгел, җанны да савыктыра торган авыл нигезендә... Безнең әни һәр чәчәк-үләннең исемен генә түгел, аның нинди авыруга дәва икәнлеген дә яхшы белә иде. Ул чагында адым саен аптекалар булмаган бит. Ә җиде малайны сау-сәламәт килеш аякка бастырырга кирәк!.. Тик шулай да медицина төп урында булырга тиеш. Медицинада төп девиз нәрсә: «Зыян салма!» Халык медицинасында да шул әйбер онытылырга тиеш түгел. Акча эшлим дип кешенең гомере турында онытып җибәрмәсеннәр иде.

**– Сезнең нәсел белән танышканда, тагын бер гаҗәеп вакыйгага юлыгасың: бер гаиләдән генә дә дүрт фән кандидаты, барысы да ил-көндә абруйлы шәхесләр. Бәлки, сезнең үрнәк нигезендә балаларыгыз табиб һөнәрен сайлаганнардыр әле дип уйлыйсы килә.**

– Ике кызым – табиблар, бу һөнәрнең җаваплы да, дәрәҗәле дә, авыр да икәнлеген кечкенәдән күреп үстеләр, укыганда ук үземдә санитарка итеп эшләттем, кем әйтмешли, түбәннән күтәрелделәр, хәзер алар турында яхшы табиблар дип горурланып әйтә алам.

***– Очрашуыбызны әңгәмәбез башындагы сорау белән тәмамлыйк әле: саулык өчен, алдагы көнең өчен ышанычлы өмет, өмет саулыгы да кирәктер, шәт... Бүгенге глобаль дөнья кешелек өчен аңлаешлымы? Адәм баласының киләчәге ышанычлымы? Табиб, ил агасы Рөстәм Сәйфулла улының милләттәшләребезгә – «Казан утлары» укучыларына теләге нинди? Бәлкем, шигырь белән җиткерерсез?***

– Адәм баласының, иң беренче чиратта, үз-үзе белән килешеп, ягъни үз-үзе белән гармониядә яши алуы кирәк. Күп нәрсә кешенең үзеннән тора. Моны мин табиб буларак кына әйтмим. Әти-әниемә нык рәхмәтлемен. Әлеге рәхмәт хисләрен барча туганнарыбыз исеменнән дә энебез Рифкать Бакировның шигъри юллары белән җиткерәсем килә. Биредә барчабызның да уй-хисләре чагыла.

*Әткәй, Әнкәй, мең-мең рәхмәт Сезгә –*
*Сез йөрәктә безнең һаман да!*
*Җиде гомер безгә бирдегез бит,*
*Бер бала күп, дигән заманда.*

***– Ихлас әңгәмәгез өчен рәхмәт Сезгә! Һәммәбезгә дә исәнлек-саулык насыйп булсын!***

*Әңгәмәне басмага* **Гөлзадә БӘЙРӘМОВА** *әзерләде.*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЭТНИК ТАРИХЫН ЯҢАДАН БАРЛАУ

## Татарның кемлеге мәсьәләсе

Бездә милли тарих фәне барлыкка килгән заманнардан – ә ул XIX йөзгә туры килә – бер мәсьәлә гел бәхәсле калып килде. Ул – борынгы, ягъни VI-XII гасырлар арасында чыганакларда билгеле булган татар кабиләләренең этник йөзе нинди булганлыгы мәсьәләсе. Әле генә Казанда басылып беткән җиде томлы «Иң борынгы чордан башланган татар тарихы»нда да бу сорауга җавап юк, дөресрәге, күрсәтелгән хезмәтнең беренче томында (борынгы төрки чорына караган) ул проблемага багышланган бүлек бар (аның авторы – инде мәрхүм булган тюрколог-галим С.Кляшторный), ләкин анда татарның кемлеге мәсьәләсе әйләнеп узылган.

Чыннан да, бу турыдагы сорауга җавап бирү җиңел түгел, чөнки аны тикшергәндә, «татар-монгол» атамасы килеп чыга, аңа Алтын Урда һәм ул таркалгач барлыкка килгән татар ханлыкларында Чыңгызыйлар һәм «монгол-татар» кабиләләре хакимлек итүе кушыла. Ягъни, тулаем алганда, бүген яшәп килгән ике халыкның – татар һәм монголларның тарихлары урта гасыр чорында нык кисешү сәбәпле, куелган сорау катлаулы булып чыга. Шуның өстенә, Алтын Урда чорының урыс тарихында уйнаган ролен һәм аның «татар» буларак билгеле төп халкының урыс тарихчыларының хезмәтләрендә ничек бәяләнүләрен дә искә алсак, проблема тагын да четереклерәк булып килеп баса.

Чынлыкта дөнья гуманитар фәнендә борынгы татарларның кемлеге турында ике төп караш бар: беренче төркем аларны монгол теллеләр рәтенә кертә, ә икенче төркемгә караганнар татарны төркиләр дип саный. Историографиядә беренче караш күбрәк таралган. Әйтик, «Ислам энциклопедиясендә» «Татарлар» дип исемләнгән мәкаләдә күренекле тюркологлар В.В.Бартольд (иске басмаларда) һәм замандашыбыз П.Голден (яңа басмаларда) турыдан-туры «татарлар монгол телле халык булган», – дип язалар.

Иң кызыгы шунда: әгәр дә менә шушы карашны алга сөрүчеләрнең китергән фикерне нигезләүче аргументларын барлый башласаң, алар юк дәрәҗәдә аз булып, чыганакларга түгел, ә күбрәк фәнни авторитетларның инде күптән әйткән сүзләренә генә нигезләнгән булып чыгалар. Шул исәптән искә төште – быел җәй көне ТФАнең Тарих институтында чыгыш ясаган ике монгол галименә мин дә мондый сорау бирдем: «Бүгенге монгол тарихчылары Чыңгызхан белән сугышлар алып барган татарларны этник яктан кем дип саныйлар?» «Монгол», – дигән җавап ишеткәч, мин төпченеп болай дип сорадым: «Ә нидән чыгып андый нәтиҗә ясала?» Шунда ишеттем: «Монгол тарихи чыганакларыннан күренгәнчә, монголлар белән татарлар үзара аралашканда тел проблемасы булмаган, димәк, татарлар монгол телле булганнар». Әмма бу галимнәр (һәм бик күп башкалар да) ни өчендер Чыңгызхан дәверендәге монголларның төрки телне белгән булулары турында уйлап та карамыйлар. Ә ул заман вакыйгаларын һәм гомуми этносәяси вазгыятьне исәпкә алганда, бу вариант бик мөмкин бит.

Күрсәтелгән мисал юкка гына китерелмәде, чынлап та, ул татар-монгол мәсьәләсе тирәсендә фикерләүнең берьяклы булуын тагын бер кат раслый. Ләкин без шуны да истә тотарга тиешбез: мондый карашның дөнья фәнендә яшәп килүендә татар

тарихчыларының да гаебе бар, чөнки, беренче чиратта, ул безнең тарих өлкәсендә эшләнәсе эшләрнең тиешле дәрәҗәдә башкарылмаганлыгы белән бәйле.

Укучыларга тәкъдим ителә торган язма шул кимчелекне юкка чыгару юнәлешендә уйланылды да.

## XIII йөз башларына кадәрге дәвердә билгеле булган татарларның этник тамырлары

Татарлар VI-VIII гасырларга караган борынгы төрки чыганаклардан тыш IX-X гасырларда кытай һәм хотан-сак документларында да искә алына, ләкин, ни кызганыч, алардан да татарларның этник йөзен күреп булмый. Әмма бер нәтиҗә чыгарырга мөмкин: бу чорда алар инде уйгурлар белән нык бәйле булып, өлешчә Көнчыгыш Төркестанда яшәгәннәр. Шундый ук мәгълүмат 1030 елга караган Си Ся тангут хөкемдарының Сун-Кытай династиясе сараена хатында да бар.

Әйткәнемчә, татарларның этник яктан кем булганлыгы турындагы карашларның еш кына абруйлы монголовед һәм тюркологларның «фикерләренә» нигезләнгән булуларын искә алып, безгә иң башлап аларның тарихи чыганакларга туры килү-килмәүләрен тикшереп карау кирәк булыр. Моның өчен, билгеле инде, булган тарихи чыганакларны барлап чыгу – иң дөрес юл.

Безнең өчен беренче әһәмиятле чыганак – билгесез авторның X гасырга караган, фарсы телендә язылган «Худуд ал-алам» исемле географик хезмәте. Анда татарлар токузгузларның, ягъни, уйгурларның (з/р күчеше = гуз/огур) бер өлеше буларак күрсәтелә. Икенче бер әһәмиятле хезмәттә – фарсы географы ал-Гардизиның XI гасыр уртасында язылган «Зайн ал-ахбар» әсәрендә – татарлар турында берничә әһәмиятле хәбәр бар. Беренчедән, анда Кимак каһанлыгына (территориясе Иртыш (Әртеш) елгасы бассейнында булган) нигез салучы «Шад» исемле шәхеснең (чынлыкта бу – титул, чөнки борынгы төрки титулатурада шад – каһанның урынбасары, аның улы яисә энесе) «татар хөкемдары» булганлыгы күрсәтелә. Чыганакта әйтелгәнчә, соңыннан аның янына тагы 7 «татар туганы» килә (исемнәре: Ими, Имак, Татар, Байандур, Кыпчак, Лнкиаз, Аджляд). Бу исемнәр исә – эпонимнар, ягъни кабилә атамаларын чагылдыралар һәм Кимак каһанлыгына кергән кабиләләр арасында кимак (имак = йәмәк) һәм татар кабиләләре белән бергә кыпчак һәм уйгурлар (ими/йеми/эймур – билгеле уйгур кабиләсе) да булганлыгын дәлиллиләр, а татарларның монда югары катлам – элита тәшкил итүен раслыйлар. Үз чиратында, Гардизида китерелгән фактлар инде фәндә билгеле булган (ул турыда С.Кляшторный, А.Малявкин язды) татар-уйгур этносәяси бәйләнышларын ачык күрсәтә. Һәм, ниһаять, безнең өчен әһәмиятле тагын бер XI гасырга караган чыганак – урта гасыр төрки дөньясының иң күренекле филологы Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» хезмәте. Анда төрки телләрне һәм сөйләшләрне бик яхшы белгән татарлар һәм уйгурлар XI гасырда яшәгән җирләргә якын торган (галим Баласагун шәһәрендә туып, Кашгарда, ягъни Карахани каһанлыгында иҗат итә) Мәхмүд Кашгари татарны «төрки кабиләләрнең берсе», – дип күрсәтә һәм аларны 20 төп төрки кабилә рәтенә кертә. Алай гына да түгел, ул бер үк сүзләрнең татарлардан тыш йәмәкләрдә, кыпчакларда һәм кай (соңыннан кыпчаклар эчендә билгели) төркемендә таралганлыгын күрсәтә. Ләкин Кашгарида бер тел табышмагы да бар – ул татарларда «төрки тел» аларның «икенче теле, үз телләре түгел», дип яза, һәм алар бу очракта ике телле булып чыга. Игътибар итик, шундый ук вазгыятьне галим уйгурлар өчен дә күрсәтә: «Аларның телләре чиста төрки тел, шулай ук үзара аралаша торган башка телләре бар». Монда ким дигәндә ике аңлатма булырга мөмкин: беренчесе – татарлар һәм уйгурлар борынгы заманда төрки булмаган башка телдә сөйләшкәннәр (нинди тел – бусын әлегә белеп булмый); икенчесе – аларның борынгыдан килгән телләре төрки, ләкин стандарт төрки телдән нык аерылган тел булган. Соңгы караш дөреслеккә туры килә булса кирәк, чөнки бу очракта сүз болгар һәм хәзәр кабиләләре һәм аларның бабалары сөйләшкән үзенчәлекле огур теле турында барырга мөмкин. Шул уңайдан исегезгә төшерәм: токузгузларның = уйгурларның борынгы бабасы саналган легендар

Огуз каһанның башка исеме – Огуркаһан! Әйтелгәннәрне исәпкә алганда, Мәхмүд Кашгариның язганнарының очы-очка ялгана.

Тагын бер, Төрки каһанлык чоры буенча зур белгеч булган тарихчы Ю.Зуев хезмәтенә дә күз салу кирәк. Борынгы төрки чор буенча кытай чыганакларын тикшергәндә, ул кытайча «бомо» (төркичә – «ала ат») дип исемләнгән төркемгә игътибар итә. Кытай тарихының Тан чоры (Х гасыр) чыганакларында, галим билгеләп үткәнчә, ул кабиләнең исеме «элочжи/гэлочжи» дип бирелә. Югарыда аталган хезмәттә аның авторы бу кабиләнең исемен «алачи/алач/алчы» дип укырга кирәклеген күрсәтә һәм андый кабиләнең кыпчакларда да булганлыгын (улаш/алаш, русча – улашевичлар) искәртә. Ә без исә ул кабилә исемен Чыңгызхан белән көрәшкән көнчыгыш татарлары арасында булган «алчи/алчын» кабиләсе атамасына тәңгәлләштерәбез. Бу кабиләнең исеме монголларның «Яшерен тарихы»нда (XIII гасыр) һәм Рәшидеддиндә (XIV гасыр) күрсәтелгән татар кабиләләре исемлегендә дә бар. Менә ул исемлек: баргуй/алахуй, дутаут/тутукулйут, алчи, чаган/чаан, куин, терат. Тагы шуны искәртик, бәлки, монда китерелгән исемлектәге «терат» этнонимын кыпчакларда билгеле булган «дурут/терт» кабиләсе исеме белән тәңгәлләштереп буладыр. Ул очракта, татарларның кимаклар һәм алар арасыннан бүленеп чыккан кыпчаклар белән бәйлелеген исәпкә алсак, китерелгән фикер тагын бер тапкыр татарларның төркилеген раслый ала.

Ләкин татарлар турында сүз алып барганда, без XIII гасыр монгол чыганакларында һәм XIV гасырга караган Хулагуидлар дәүләтендә яшәгән фарсы галиме Рәшидеддиннең «Җамигъ әт-тәварих» исемле хезмәтендәге татар кабиләләре исемлеге белән генә чикләнсәк, мәсьәләнең төбенә үк төшеп җитә алмабыз. Ни өченме? Эш шунда ки, монголларның Чыңгызхан җитәкчелегендәге оешу дәверендә алар Үзәк Азиядә татарлар белән генә түгел, ә кайбер башка исемдәге кабиләләр белән дә (кереит, найман, меркит) каты сугышлар алып барганнар һәм төрки булганнар дигән фикерләр инде фәндә моңарчы да әйтелде. Сорау туа: ә аларның этник йөзен тагын да төгәлрәк итеп билгеләп булмыймы икән? Була дип уйлыйм һәм моны башкарып чыккач, шаккаткыч нәтиҗәгә килергә мөмкинбез. Моның өчен яңадан чыганакларга әйләнеп кайтырга тиешбез.

Иң әүвәл безне найман һәм меркит кабиләләре кызыксындырырга тиеш, чөнки алар монголлар белән каты сугышлар алып барган, алардан җиңелгәч, көнчыгыш кыпчаклары, ягъни кимаклар арасына чигенгән, соңыннан ахыргача тар-мар ителеп, Бөек Монгол империясенә кимаклар белән бергә кушылган. Ни өчен бу ике төркем игътибар үзәгендә булырга тиеш? Беренче чиратта, аларның төрки булганлыгыннан чыгып. Чыннан да, найманнарның исеме монголча «сигез» дигәнне аңлатып, VIII гасырга караган чыганаклардан билгеле булган «сикез огуз» конфедерациясенең атамасын чагылдырган, дигән фикер тарихи әдәбиятта моңарчы ук әйтелгән иде. IX гасырда алар, уйгурларны җиңеп, Уйгур каһанлыгын тар-мар иткән кыргызларны үз чиратларында җиңелүгә дучар иттереп, элегрәк Алтай тирәләрендә яшәгән кереитларны Көнчыгышка таба кысып чыгарып, Кара Иртыш елгасы бассейнын һәм Алтай буйларын биләп тора башлаганнар. Кайбер галимнәр (М.Ерзин) найманнарны соңрак чорда кытай чыганакларында цзу-бу дип билгеле булган төркиләрнең көнбатыш өлеше дип уйлыйлар. Ә менә киданьнар X-XII йөзләрдә цзу-бу дип татарларны атаганнар. Булган тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, найманнар үзләреннән көньяк тарафта яшәгән уйгурлар белән күп төрле бәйләнешләр тотканнар, аларның мәдәни йогынтысын тоеп яшәгәннәр. Аерым галимнәр XII гасырда аларга киданьнар (кара кытайлар) да нык тәэсир иткән дип уйлыйлар һәм найманнарның берникадәр дәрәҗәдә монголлашуы турында да язалар. Дини яктан бу төркем вәкилләре башта тәңречеләр, аннан соң несториан христианнары, соңга таба буддистлар булганнар (П.Ратчневский).

Найманнарның көнчыгыш күршеләре булган кереитлардан да ерак яшәгән меркитлар Байкал күленнән көньякта, Селенга елгасының түбән агымы буйларында биләмәләр тотканнар. Бу төркемнең дә төрки булуы турында тарихи әдәбиятта элегрәк тә язылды, хәзер дә язалар. Шуны да искәртим: меркитлар кереитлар кебек үк несториан динен тотканнар, ягъни рухи яктан әлеге ике төркем үзара якын булган. Ләкин бу төркемне искә төшерү алар төрки булган өчен генә түгел, моның өчен башка

бер сәбәп тә бар. Әйтик, Рәшидеддин биргән халыклар классификациясендә меркитлар «башта исемнәре монгол булмаган, хәзер генә монгол дип атала башлаган» халыклар рәтендә саналалар. Мәгълүм ки, татарлар да шул ук исемлектә күрсәтеләләр. Һәм бу бер дә юкка түгел, чөнки шул ук Рәшидеддин меркит кабиләсенең «патшасы» Токта турында: «... [ул] татар кабиләсеннән», – дип әйтә. Моңа өстәп, шуны да күрсәтеп китү кирәк: Рәшидеддин язганча, меркитларның 4 тармагының берсенең исеме «уйкур» булган! Димәк, бу очракта меркит кабиләсенең уйгурлар белән дә бәйләнгән булуы ачык күренә. Шулай ук меркитларның Чыңгызханга каршы найманнар белән союзда ахыргача сугышуына да игътибар итәргә кирәк, чөнки мондый хезмәттәшлекнең этник нигезләре дә булган дип уйларга тулы нигез бар. Әйтик, урта гасыр чорының күренекле тарихчысы Джуджаниның «Табакат-и Насыйри» (XIII йөз) исемле хезмәтендә найманнар «татар» дип билгеләнә, ә аларның монголлар басымы астында көнбатышка китеп кара-кытайларны җиңгән хөкемдарлары Кучлук ханның «татар» булганлыгы күрсәтелә. Гарәп тарихчысы Ибн әл-Асир шулай ук «Әл-Камил фи-т-тарих» (XIII йөз) исемле хезмәтендә Кучлук хан кул астында элекке ватаннарыннан күчеп килгән найманнарны «ас-Син ягыннан чыккан зур татар кабиләсе», дип атый, ә ханның «татар патшасы» икәнлеген аермачык тасвирлый. Шул исәптән, мәгълүм кытай-монгол чыганагы «Юань ши» әсәрендә сакланган найман-канглы төркемнәренең аксөякләре арасындагы кыз бирү-алу аркылы барлыкка килгән туганлык мөнәсәбәтләре турында да әйтергә кирәк. Ни өчен икәнлеге алга таба әле яхшырак аңлашылыр.

Ниһаять, меркитлар һәм кереитларның күршеләре, татарлар белән дә чиктәш булган жалайыр кабиләсенең дә төркиләрдән булганлыгы турында тарихи әдәбияттан инде билгеле. Әмма, бу төркем турында сөйләшкәндә, тагын бер фактны искәртү кирәк. Рәшидеддиндә китергән легендар мәгълүмат буенча, жалайыр кабиләсенең борынгы биләмәсе Каракорым янында булып, алар «уйгурларның хөкемдары гурханга» хезмәт иткәннәр. Күренә ки, бу төркем үз вакытында уйгурлар белән бәйле булган. Аларның Алтай төркиләре белән искедән килгән этник мөнәсәбәтләре турында жалайыр кабиләсенең джат/чат һәм тулангит/телингит, тури исемле тармаклары булуы да сөйли.

Ләкин иң кызыгы жалайыр кабиләсенең джат (чат) тармагыннан булган, Чыңгызханның иң ышанычлы батырларыннан саналган, аның Кытайдагы урынбасары дәрәҗәсенә (го-ван, ягъни «бөек хан») җиткән Мухулига кагыла. Эш менә нәрсәдә: 1221 елны кытайлы Чжао Хун үзенең Чыңгызханның Төньяк Кытайдагы урынбасары Мухули белән очрашуы турында сөйләгәндә, аның гел үз-үзен «без – татарлар», – дип атаганлыгын күрсәтә. «Аның кул астындагы дәүләт сановниклары һәм хәрби җитәкчеләр дә үзләрен шулай ук атап, монгол икәнлекләрен белмиләр», ди кытай илчесе. Һәм алар чыннан да монгол булмаганнар, чөнки 1217/1218 елларда Кытайны яулап алу өчен Мухулига бирелгән 23 меңлек гаскәрдә 10 мең онгут, 2 мең жалайыр, ә калганнары кидань һәм журжэн җайдаклары булганлыгы инде күптән билгеле (А.Кадырбаев). Шулай итеп, Мухулиның һәм аның якыннарының үз-үзләрен «татар» дип атаулары өчен, күргәнебезчә, ныклы нигез булган.

Нәтиҗәдә, монголларның Үзәк Азиядәге борынгы төркиләр җирләрендә көчәйгән дәвердә аларга нык каршылык күрсәткән татарларның күп тармаклы зур халык булганлыгы күренә: алты татар кабиләсенә без тулы ышаныч белән найман берләшмәсен, меркитларны һәм жалайырларны өсти алабыз. Аларга онгут (төгәл атамасы, бәлки, «он ук» булгандыр) исемле, Төньяк Кытай чикләрендә яшәгән, «ак татар» буларак билгеле кабиләне дә китереп куша алабыз. Моңа аларның атамасыннан тыш тагын бер өстәмә сәбәп тә бар: онгутлардан сакланган эпитафия материалларыннан күренгәнчә, аларның телләре кыпчак теленә якын булып, алардан бу «ак татарларның» найманнар белән тугандашлыклары да күренә (А.Кадырбаев). Димәк, бу төркемне юкка гына «ак татарлар» дип атамаганнар.

Күрсәтелгән этник массивтан кереит кабиләсе генә читтә кала кебек. Беренче чиратта, бу аларның этник тамырлары турындагы мәгълүматларның аз булуы белән бәйле. Шуңа да карамастан, кайбер галимнәр, мәсәлән, П.Ратчневский, кереитларның канглы һәм гуз (уз) төркемнәре белән туганлыклары булгандыр, дип яза. Чынлыкта, сүз күбрәк канглы кабиләләре белән этник бердәмлек турында барырга мөмкин, чөнки

кайбер кытай чыганакларында (мәсәлән, Ту Цзинның «Мэнуэр-шицзи» әсәрендә) туп-туры әйтелә: «Кереитлар – канглыларның бабалары, Көнбатышта булучыларның атамасы – канглы, Көнчыгыштагыларыныкы – киреит» (А.Кадырбаев). Шуның өстенә, кереитларның ханнарына (мәсәлән, Ван ханга) хезмәт иткән аксөяк канглылар аерым тарихи чыганаклардан («Юань ши» әсәреннән) яхшы билгеле. Гомумән, кимаклар белән бәйле канглылар һәм аларның татарга мөнәсәбәтләре турында алга таба тулырак мәгълүмат бирелер.

Күренә ки, санап кителгән барлык төрки төркемнәр (кереит, найман, меркит, жалайыр, онгут) теге яки бу яктан татарга мөнәсәбәтле булып чыга. Аларның кайберләренең (әйтик, жалайырларның) уйгурларга бәйле булганлыклары да әйтелгән фикергә каршы килми, бигрәк тә инде күрсәтелгән Кимак каһанлыгы кысаларындагы уйгур-кимак-татар төркемнәренең үзара бәйләнешләрен да истә тотсак.

Чынлыкта бу уйгур-кимак-татар төркемнәренең үзара этник якынлыгының тагы бер, моңарчы тарихчылар тарафыннан бик аз язылган ягы да бар. Сүз көнчыгыш кыпчаклар – кимакларның Җучи Олысы формалашуында тоткан урыны турында бара. Ә бу проблема исә монголлар көчәю дәвере алдыннан Урта Азиядәге һәм аннан төньяктагы далалардагы этносәяси вазгыять белән турыдан-туры бәйле. Шуңа күрә безгә хәзер шул мәсьәләгә күчү кирәк булыр.

## Хорезмшаһлар дәүләте һәм аның кимаклар белән бәйләнешләре

Мәгълүм ки, монголларның Урта Азияне яулап алулары анда төп сәяси көч булган Хорезмшаһлар дәүләтен (үзәге – Хорезм яисә Ургәнч) 1220-1221 елларда тар-мар итүләре белән бәйле. Ләкин бу мөһим вакыйгаларның гомуми контексты тарихи хезмәтләрдә җитәрлек дәрәҗәдә тасвирланмый, бигрәк тә аларда катнашкан сәяси берләшмәләрнең этник нигезләренә тиешле игътибар бирелми. Безгә шушы кимчелектән арыну кирәк булачак, аннан башка татар мәсьәләсен аңлап булмый.

Иң башлап, Җучи Олысының оеша башлау чорына бераз күз салу кирәк, чөнки соңыннан булган сәяси үзгәрешләрнең җеп очлары чынлыкта шул елларга барып тоташа.

Монгол чыганаклары буенча, Куян елында (1207) Чыңгызханның боерыгы буенча аның улы Җучи җитәкчелегендә Уң кул гаскәрләре «Урман халыкларын» яулап алу өчен җибәреләләр. Бу поход Саян-Алтай тауларыннан башлап Иртыш елгасы бассейнына кадәр булган җирләрдә яшәүче халыкларга каршы юнәлдерелә. Мәгълүм ки, моңарчы ук инде Субәдәй баһадур җитәкчелегендәге гаскәр меркитларны, ә башында Джэбе торган гаскәр Кучлук кул астындагы найманнарны тар-мар иткән була. 1205 елны монголлардан җиңелгән меркитлар Иртыш елгасын кичеп, «канглы һәм кипчаутлар ягына», ә Джувейнидан күренгәнчә, «канглылар яшәгән Караком җирлегенә» чигенәләр. Шуңа күрә, монголлар беренче тапкыр Иртыш буйларына инде 1205 елны ук чыккан булырга мөмкиннәр. Исегезгә төшерәм: найманнар «Еке (зур) Алтайда» һәм «Күк Иртыш», «Иртыш-мурэн» буйларында, алар белән кыргызлар (ул вакытта Саян таулары араларында яшәгәннәр) торган җирләргә кадәр сузылган тауларда биләмәләр тотканнар (Рәшидеддин). Ягъни Җучи гаскәрләре чынлыкта 1205 елны меркитларга һәм найманнарга каршы алып барылган сугышның дәвамы белән шөгыльләнгәннәр. Алтай-Саян җирләрендә көн иткән монгол (бурят, ойрат һ.б.) һәм күпсанлы төркиләрне буйсындырып, Җучи отрядлары Иртыш буйларына җитеп, анда «шибер» халкын (сабир/сувар төркемен, ягъни угорларны) да буйсындырып, көнчыгыш кыпчаклары-кимаклар торган урыннарга килеп җиткәннәр. Ләкин аларны яулап алу бераз соңрак чорга калдырыла, чөнки башта Чыңгызхан «сартаул халкын» – Хорезмшаһлар дәүләтен тар-мар итү бурычын куя.

Ә Хорезмшаһлар дәүләтен юкка чыгару җиңел эш булмый, чөнки ул дәвердә бу көчле дәүләт канглы һәм кимаклар белән дә бик нык бәйле булган. Кызганычка каршы, аерым белгечләр хезмәтләреннән тыш бу турыда гомуми монгол дәвере буенча тарих китапларында сез берни дә таба алмыйсыз. Чынлыкта исә, шушы

проблеманы тикшергәндә генә алда китерелгән монголлар дәверенә кадәрге татарларның Урта Азия һәм аннан төньякта урнашкан далаларда тоткан урыннары яңадан өскә калка.

Мәгълүм ки, меркитлар һәм найманнарны куып барган монгол отрядларының (Жучи җитәкчелегендә) хорезмшаһ Мөхәммәд б.Текеш гаскәрләре белән беренче бәрелешләре һиҗри белән 615 елны (1218/1219) була. Шул елны Хорезмшаһлар дәүләте гаскәрләре, Джуджаниның «Табакат-и Насыйри» әсәрендә күрсәтелгәнчә, «Кадыйр хан, Татарлы Юсуф углы артыннан барып, Төркестанга үтеп керә һәм анда шулкадәр ерак китә ки, уйгурга [I-ghir], төньякка, Төньяк котыпка җитә». Чынлыкта монда сүз меркитлар һәм найманнар чигенгән җирләр турында бара һәм ул җирләрнең кайда булганлыгын без тарихи чыганаклар буенча чамалый алабыз. Монголларның «Яшерен тарихы»нда монголларның меркитларны һәм найманнарны куалап барулары турында язганда, алар «канглылар һәм кипчаутлар юнәлешен алдылар», – дип әйтелә. «Юань ши» әсәрендә Субәдәй баһадурның меркитларны куып баруы турында сөйләнгәндә, болай диелә: «Алар (ягъни, меркитлар – *Д.И.*) обогы башлыгы Хуту кыпчаклар арасына качты, Субәдәй алар артыннан барып, кыпчакларда Юйюй [Уйгур– Д.И.] исемле тау үзәнлегендә аның белән бәрелеште һәм тар-мар итте». Джувейни хезмәтендә шул ук вакыйга ике хәбәр белән тасвирлана. Беренчесеннән күренгәнчә, меркитлар башлыгы Ток Тоган башта найманнар хөкемдары Кучлукка килә, аннан «Кам Кемчик (төгәл атамасы – Ком-Кыпчак – *Д.И.*) өлкәсенә» китә. Икенче хәбәрдә, бу автор шул ук вакыйгага кайтып, яза: хорезмшаһ Мөхәммәд б. Текеш «Ток Тоганның монголлардан качу хәбәрен алды», аларның «канглылар яшәгән Каракомга» китүләрен белде, – дип. Югарыда күрсәтелгәнчә, кыпчаклар (сүз монда кимаклар турында бара) башында нәкъ менә алда әйтелгән вакыйга вакытында яшәгән Кадыйр ханның татар булганлыгы күренә. Бу фактка беренче булып В.В.Бартольд игътибар иткән инде, ләкин ул Кадыйр ханның атасының ни өчен «татарлы» дип аталуына аңлатма бирмәде. Шуңа күрә, безгә мәсьәләгә ачыклык кертү өчен С.М.Ахинжановның кыпчакларга багышланган хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Казакъ тарихчысының фикере буенча, 1218/1219 елгы вакыйга Иргиз елгасы бассейнында, Кай һәм Кимгач елгалары арасында (хәзерге Оренбург өлкәсе һәм Казакъстанның Актүбә өлкәсе чикләренә туры килә) булып, анда кыпчак (кимакларның) һәм канглыларның мөстәкыйль биләмәсе яшәп килгән. Монда кимаклар (йәмәкләр), канглылардан тыш уйгурлар да булган. Хәтта аларның аерым кабиләләренең исемнәре дә билгеле – уран/оран, алпарлы/илбари, байаут. С.М.Ахинжанов язганча, кыпчак ханы Кыранның (Икран/ Акран) мөселман титулы «Кадыйр» (Гайр/Гайыр) булып, ул «Кадыйр/Кайр – Буку хан» буларак та билгеле. Аның атасының исеме – Алп-Кара Уран (монда Уран – кабилә исеме). Соңгысы исә, хорезмшаһ Текешнең бер юлламасыннан күренгәнчә, 1182 елны Дженд шәһәренә (үз чиратында, бу үзәккә тагы Сыгнак, Барчинлигкент һәм Рибат шәһәрләре буйсынган) килгән – ә анда ул вакытта шушы хорезмшаһның өлкән улы хөкемдар булып тора – Алп Кара җитәкчелегендәге илчелек килү уңаеннан искә алына. Кызыгы шунда, килүчеләр арасында «югурларның уллары» да була. Сөйләшүләр нәтиҗәсендә, хорезмшаһ Текеш Алп Караның кызына (исеме – Теркен-хатын) өйләнә һәм шулай итеп көнчыгыш кыпчаклар-кимаклар белән союзга керә. Чынбарлыкта мондый багланышлар элек тә булган – хорезмшаһ Текешнең атасы да исеме билгесез кимак ханы белән союзда торган. Алга таба мондый вакыйгалар билгеле: 1195 елны Сыгнак һәм Дженд тирәләрендә яшәгән кыпчаклар (җитәкчеләре – Кадыйр Буку хан) баш күтәргәч, хоремшаһ Текеш аларны бастыру өчен килә, шул вакытны Алп Кара Уранның оныгы булган Алп Дерек хорезмшаһ Текеш ягына чыга, аның белән гаскәрләрнең күпсанлы уран кабиләсе отрядлары да китә, Кадыйр Буку хан нәтиҗәдә алар кулына әсирлеккә эләгә. Ахыр чиктә Алп Дерек (ул, инде күренгәнчә, Теркен хатын белән туган булган), күрсәтелгән хезмәте өчен, хорезмшаһ Мөхәммәт б.Текешнең урынбасары буларак, Отрар шәһәрендә утыра һәм 1218 елны анда монголлар белән очраша (ул вакытта аның титуллары «Кадыйр/Гайр/хан» һәм «Инальчук»; монда «инал» – тәхет варисы мәгънәсендә).

Инде китерелгән мәгълүматлардан ачык күренә – соңгы чор хорезмшахлар

династиясе кимаклар белән тыгыз бәйләнештә булган, ә бу бәйләнешләр инде XI гасырда ук башланганнар, чөнки соңгы хорезмшаһлар династиясенә нигез салучылар – Ануш (Нуш) – тегин, яисә аның улы Кутб ад-Дин Айбек, XI гасыр ахырында Дженд һәм Хорезмга «Сахрадан, кыпчаклар һәм канглылар арасыннан киләләр» («Табакат-и Насыйри»). Бу йәмәк кыпчаклары уйгурлар белән нык береккән булганнар, юкка гына Джуджани Ануш-тегинны бекдали/бегдели исеме уйгур кабиләсеннән, – дип язмый. Менә шушы йәмәк-уйгурлар белән бәйләнгән соңгы дәвер хорезмшаһлар династиясенә без ныграк игътибар итәргә тиешбез, чөнки алар белән бәйләнгән көнчыгыш кыпчак-кимак кабиләләрен төгәлрәк билгели алсак, без аларнын борынгы тамырларын да эзләп таба алырбыз.

Инде күрсәтелгән соңгы хорезмшаһ булган Мөхәммәднең (1199/1200 елны үлгән) анасы Теркен хатын, кыпчак ханы Икранның кызы булып, бер мәгълүмат буенча канглы төркеменнән (Джувейни, ан-Насави), бүтән мәгълүматлар буенча уран/оран кабиләсеннән. Соңгы билгеләмә дөресрәк булыр, ләкин беренче вариант та мондый нәтиҗәгә каршы килми – уран кабиләсе канглы төркеменең өлеше булырга мөмкин. Чынлап та, уран кабиләсе Мөхәммәд хорезмшаһ тирәсендә мөһим роль уйнаган. Мәсәлән, Джувейни хәбәр иткәнчә, монголлар басымы астында ул Ирак ягына чигенгәндә, аның гаскәрләренең «зур өлешен оран исемле анасының кабиләсеннән булган төркиләр тәшкил иткәннәр». Ибн әл-Асир күрсәткәнчә, шушы ук кабилә вәкилләре хорезмшаһ Мөхәммәд уллары утырган аерым өлкәләрдә – Нишапурда, Гератта, Хамаданда хөкемдарлар булганнар. Джуджани язганча, Мөхәммәд хорезмшаһның тагы бер Арзали-шаһ исемле улы Олугхан Азам исемле (ул монголлар һөҗүме вакытында башта Багдадка, аннары Дәһли шәһәренә китә) кимак кабиләсе илбары/алпарлы төркеменнән чыккан шәхеснең кызына өйләнгән булган. Шушы хорезмшаһлар династиясенә кушылган көнчыгыш кыпчак тармагы турында Джуджани болай ди: «...аларның аталары Илбари кабиләсеннән булган күренекле шәхесләр булып, хан титуллы [иделәр] һәм күпсанлы ырудашлары һәм алардан бәйлеләр бар иде». Хәтта Джуджани хорезмшаһлар династиясе вәкиле белән туганлашкан Олуг хан Азали турында әйтә: «Ул Илбари ханы һәм йәмәкләрней шаһы [иде]», – дип.

Йәмәкләр һәм алар белән этник яктан бик якын канглы берләшмәсе вәкилләре чынлыкта монголлар Урта Азиягә бәреп кергәндә Хорезмшаһлар дәүләтендә төп хәрби көчне тәшкил иткәннәр. Әйтик, Джувейни күрсәткәнчә, 1220 елны Мөхәммәд хорезмшаһ Хорезмны ташлап китеп, анда үзенең улы белән шәһәрне саклау өчен 90 мең кешелек «төрки-канглы» гаскәре калдыра. Шушы ук автор, Җәләлетдин Мөхәммәднең Парван янында монголлар белән сугышуы турында сөйләгәндә, ул гаскәрнең бер канатында 40 меңлек канглы сугышчылары булуын әйтә.

Менә хәзер безгә инде анализланган Кимак каһанлыгының татар җитәкчелегендә оешуы турындагы мәгълүматларга кире кайту кирәк. Дөнья фәнендә татарлардан булган элитаның Кимак конфедерациясе башында торуы танылa (П.Голден). Кыпчаклар исә кимаклар арасыннан чыгалар. Хәлбуки, көнбатыш кыпчакларның этник составы көнчыгыш кыпчаклар-кимаклардан башка да булуы мөмкин. Шуңа күрә татарлыкны безгә беренче чиратта соңгылары арасында эзләү кирәк. Кимаклар арасында уйгурларның булуын да галимнәр таныйлар (П.Голден), димәк, инде күрсәтелгән «Сахрадан» Хорезмга килгән кыпчаклар (кимаклар) тирәсендә уйгурлар күренү бер дә очраклы түгел. Тагы бер фактны истә тотыйк: Мәхүд Кашгари татарлар турында язганда, аларның телләренең йәмәк, кыпчак, кай төркемнәре белән уртаклыгын күрсәтүен әйтеп үткән идем. С.М.Ахинжанов фикеренчә, «уран» этнонимының (мәгънәсе – «елан») монгол телендәге варианты – «кай». Шулай булгач, уран төркемендә татарлык чынлап та булган. Кайбер галимнәрнең XI гасырда яшәгән Газневид шагыйрьләренең кай кабиләсеннән чыккан гуләмнар турында язганда алар белән янәшә татардан чыгучыларны искә төшерүләре (С.Г.Агаджанов) бер дә очраклы түгел, димәк.

Шулай итеп, монголлар көчәю дәвере алдыннан татарлар арасыннан чыккан затлы төркемнәр көнчыгыш кыпчаклары – йәмәкләр, канглылар, конкретрак, илбари һәм уран кабиләләре хөкемдарлары составында бик ачык күзаллана. Аларның кабиләдәшләре

XI– XII йөзләрдә Хорезмшаһлар дәүләтендә дә мөһим роль уйнап, соңгы хорезмшаһлар үзләре дә шулар арасыннан чыгучылар булганнар.

Әгәр мәсьәлә шушы яссылыкта куела икән, монголларның Урта Азияне һәм аның төньягында җәйрәп яткан далалардагы кыпчак-кимаклар белән конфронтациягә керүләре бөтенләй башка төс ала һәм анда булган Үзәк Азиядәге монгол-татар сугышларының логик дәвамы булып чыга. Ә бу исә Җучи Олысы оешу мәсьәләсенә яңача карарга мөмкинлек бирә.

## Монголларның Урта Азияне яулап алулары һәм Җучи Олысы оешуның икенче чоры

Алда язылганча, Җучиның аерым биләмәсе барлыкка килү 1207 елны Көньяк Себердәге «Урман халыкларын» яулап алу белән бәйле. Бу җирләр – Иртыш елгасы бассейныннан Алтай һәм Саян тауларына кадәр, хәтта Енисей елгасының югары агымы якларын да кертеп – чынлап та шушы заманнардан башлап аның кул астында була. Моның шулай икәнлеген раслаучы фактларны барлап үтик. Беренчедән, 1217 елны «Урман халыклары» составына кергән тумат (тума/дуба) кабиләләре баш күтәреп, аларга кыргызлар да кушылгач, бу төркемнәрне яңадан бастыру өчен Җучи җитәкчелегендә гаскәр җибәрелә. Димәк, ул җирләр өчен шушы шәхес җавап биргән. Икенчедән, Рәшидеддин мәгълүматлары буенча, Урта Азияне яулап алу төгәлләнгәч, 1222 елның язында, «Җучи үзенең тукталыш урынына, олысына кайтып китә», ә ул җирләр түбәндәгечә тасвирлана: «... Иртыш ягында, аның олаулары булган [урынга], үз урдаларына юнәлде». Шул ук авторда Чыңгызханның бер карары турында сүз барганда болай дип әйтелә: «Чыңгызхан идарә итү өчен Җучига Иртыш елгасы һәм Алтай таулары тарафында булган барлык өлкәләрне һәм олысны бирде». Күренә ки, Җучи Урта Азияне яулап алуга кадәр Себер җирләрен биләгән, «Урман халыкларыннан» тыш аның биләмәләренә, бәлки, кайбер кимак төркемнәре дә кергәндер, ләкин чыганакларда бу турыда бер сүз дә юк. Ахрысы, 1220 елның язына кадәр, ягъни, Отрар шәһәренә (хорезмшаһлар биләмәсе) һөҗүм башланганчы, Бөек Монгол империясенең көнбатыш чикләре Иртыш бассейнында булып, Җучи Олысы җирләреннән үткән, чөнки Хорезмшахлар дәүләтенә каршы походны башлар алдыннан, Чыңгызхан «атлар [күзгә кадәр] туклансыннар өчен җәйне Иртыш буйларында үткәрде» (Рәшидеддин).

Югарыда китерелгән мәгълүмат безгә көнчыгыш кыпчаклар-кимаклар белән монгол гаскәрләре арасында булган сугышларны тулырак аңлау өчен кирәк. Дөресрәге, безне күбрәк сугыш хәрәкәтләре түгел – ул турыда күп язылды – ә ул вакыйгага катнашкан төркемнәрнең этник йөзләре билгеләнүе кызыксындыра.

1220 елны Чыңгызхан җитәкчелегендәге монгол гаскәрләре Отрар шәһәрен камаганда (исегезгә төшерәм, анда хөкемдар булган Кадыйр Гайир хан – уран кабиләсеннән, ягъни татардан чыгучы династ), Җучи гаскәрләре Янгикент, Дженд һәм Барчинлигкент шәһәрләрен һәм өлкәләрен яулап алалар. Янгикентны алгач, алар арасыннан бер отряд канглыларның төп ставкасына каршы юнәлә. Аннан соң Җучи атасының гаскәрләренә кушылып, 1220-1221 елларның кышында Хорезмны алуда катнаша. Шушы вакыйгалардан соң Җучи үзенең үзәк ставкасы булган Иртыш якларына юнәлә.

Ләкин монда бер аңлатма кирәк: монгол елъязмалары буенча, Субәдәй баһадур җитәкчелегендәге отряд 1221 елны «төньякка» җибәрелә һәм ул анда 11 «илне һәм халыкны» яулап алырга тиеш була (араларында «канглы» (канглин) һәм «кыпчак» (кибчаут), шулай ук «болар/биляр», «оросут», ягъни, руслар да санала). Чынлыкта, бу гаскәр (аңа Җәбе нойон да кушыла) «төньякка» түгел, ә көнбатышка, хорезмшаһ Мөхәммәд артыннан китәргә мәҗбүр була һәм ул китештән 1223 елны гына, Кавказ аркылы үтеп, русларны һәм көнбатыш кыпчакларны җиңеп кайтып җитә. 1221 елга әле кимаклар һәм канглылар (аларның төп биләмәсе – Күк Иртыш елгасы буйларында булган) монголларга буйсындырылып бетмәгән булганнар дип уйларга урын бар. Ләкин бу очракта без тагы башка мәгълүматларга да игътибар итәргә тиешбез. Әйтик, Рәшидеддин Чыңгызханның Җучига биләмәләр бирүе турында язганда, әйтә:

«...Чыңгызхан [Җучи] Дәште кыпчакны һәм шул яклардагы дәүләтләрне яулап алып үз биләмәләренә кушсын дигән боерык чыгарды», – дип.

Мондый боерык чыннан да булганмы һәм ул кайсы елга карый? Иң башлап, бу боерыкның 1221 елны Субәдәй баһадурга кушылган, әмма үтәлмичә калган планны кабатлавын әйтергә кирәк. Аннан соң, Җучига йөкләнелгән яу турында боерык чынлап та булган, чөнки ул турыда башка авторлар да язалар (Джувейни, Казвини). Шуның өстенә, Угәдәй каһан «төньяк өлкәләрне яулап алуны 1229 елны «Җучи нәселе вәкилләренә» йөкләгәндә, ул Чыңгызханның шушы турыдагы Җучига биргән боерыгына таянган дигән хәбәр бар (Рәшидеддин). Хәзер безгә ул боерыкның елын гына төгәлрәк анықларга кирәк.

Аерым монгол елъязмаларында әйтелгенчә, «Тавык елында» (1225 ел) Чыңгызхан яулап алган җирләрне идарә итү буенча фәрманнар биргәндә, «Җучины бүлеп чыгарып, аны кыпчаклар өстеннән хөкемдар итеп җибәргән», башкача әйткәндә, ул Җучины «кыпчакларның өлкән даругачысы[1] итеп юллаган» (Лубсан Данзан). Димәк, 1225 елны Җучиның Себердәге биләмәләренә кыпчаклар да – бу очракта сүз Хорезмнан төньякта яшәгән кимаклар һәм канглылар турында гына барырга мөмкин – кушыла. Ләкин, Рәшидеддин күрсәткәнчә, әйтелгән карарны үтәргә Җучи бер дә атлыгып тормаган, «төньяктагы илләрне» яулап алу эшенә тотынмаган гына түгел, атасы үз янына килергә боергач, авырганлыгын сәбәп итеп, Чыңгызхан янына килмәгән дә. Җучиның үзен шул рәвешле тотуын, Джуджани аңлатканча, аның «Кыпчак җиренә» мәхәббәте булуыннан күрү кирәк. Шушы автор язганча, «[Җучи] кыпчак җиренең суын һәм җирен күргәч, дөньяда бу җирдән дә матур, мондагы һавадан да яхшы, судан да тәмле, болыннардан һәм көтүлекләрдән дә киң [урыннар] дөньяда юклыгын күрде». Джуджани фикеренчә, аңарда атасына буйсынудан чыгу теләге туа һәм ул үз якыннарына болай дип әйтә: «Чыңгызхан шулкадәр халыкны юкка чыгарып һәм шулкадәр патшалыкларны җимереп, акылдан язган. Миңа аны ау вакытында үтереп, Мөхәммәд солтан (хорезмшаһ – *Д.И.*) белән якынаеп, дәүләтне чәчәк ату хәленә китерү һәм мөселманнарга ярдәм итү максатка яраклы булып күренә».

Бу бик мөһим мәгълүмат һәм чынлыкта Җучи Олысында 1225 елга кимак, канглы төркемнәренең һәм гомумән мөселманнарның күбәюе белән дә бәйле. Ләкин хикмәт анда гына түгел. Тагы бер сәбәп – Җучины тәхет тирәсеннән читләштерү. 1219 елны Чыңгызханның Урта Азиягә явы алдыннан Бөек Монгол империясенең тәхет варисы мәсьәләсе карала һәм сарайда шул вакытта Чагадай белән Җучи арасында низаг чыга – беренчесе үзенең абыйсын, ягъни Җучины, «меркит әсирлегенең мирасы» дип атый (Җучи аның анасы меркитларда әсирлектән кайткач туа) һәм шулай итеп аның Чыңгызханның генетик варисы булуын шөбһәгә ала. Чыңгызхан, Чагадайга нык шелтә белдерсә дә, тәхеткә өченче улы Угәдәйне утыртырга карар кыла, димәк, аңарда да Җучи турында төрле уйлар саклаган була. Шуның өстенә, башта Енисей буйлары һәм Саян таулары яклары Төп Монгол йортына кушыла, аннары Алтай да, бәлки, 1226 елны һәм әле тулаем түгел, империя үзәге белән бер булган биләмәгә күчә. Димәк, Җучи Олысы көнчыгыштан кысыла бара.

Джуджани язганнардан күренгәнчә, Чыңгызхан бу шартларда «ышанычлы кешеләрне» үзенең өлкән улын «агуларга һәм үтерергә җибәрә», хәтта башында Чагадай һәм Угәдәй торган гаскәр «Җучи тарафына» җибәрелә, Чыңгызхан үзе дә алар артыннан яуга чыгарга ниятли. Гаскәрләр хәрәкәткә килә, ләкин Җучи 1207 елның февралендә кинәт кенә үлеп китү сәбәпле – бәлки ул атасы боерыгы белән үтерелгәндер – яу булмыйча кала. Чыңгызхан өлкән улыннан соң озак яшәми, ярты елдан үзе дә бу дөньядан китеп бара, әмма Җучи Олысын улларының берсенә – Батыйга биреп өлгерә.

Шулай итеп, өстендә «меркит әсирлеге ләгънәте» эленеп торган Җучи, Себер-Алтай төркиләре, кимаклар, канглы төркемнәре һәм бәлки найман-меркитларны үз эченә алган биләмә башында торганда – аңлыйсыздыр, монда «татарлык» таралган булган – империя үзәгеннән котылу турында уйлый башлаган дигән фикер әйтү мөмкин. Алай гына да түгел, чыганакларда Батый ханның энесе Бәркәнең (1206-1207

[1] Даруга – монгол империясендә, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында административ-территориаль берәмлек. *Д. И.*

еллар тирәсендә туган) «туганда ук мөселман булып», ягъни аның мөселман булмаган хатыннарның сөтен иммичә, мөселман имезүчесенә тапшырылып, мөселман имамнары тарафыннан тәрбияләнүе турында мәгълүмат бар (Үтәмеш хаҗи, Джуджани). Аннан соң, ул үсеп җиткәч, аның кул астына Җучи Олысындагы мөселманнардан торган гаскәрне җыю турында хәбәр дә сакланган (Джуджани). Безгә бу хәбәрләргә игътибар итәргә кирәк, чөнки аларның Урта Азия җирләрендә һәм аның чикләрендә яшәгән көнчыгыш кыпчакларга турыдан-туры кагылышы бар.

Инде безгә тагы вакыйгалар агымына кайтып, 1229 елның Угәдәйне каһан итеп сайлаган корылтай карарларын тормышка ашыруга тукталу кирәк булыр. Ләкин аңарчы тагын бер тарихи мәгълүматны өйрәнергә кирәк. Сүз 1223 елны көнбатыш тарафта булып кайткан Субәдәй баһадурның 1224 елны Чыңгызхан исеменә язылган мөрәҗәгате турында бара. Атаклы яубашы, кыпчак җиренә яңа һөҗүм алдыннан меркит, найман, кереит, кыпчак (бу очракта – кимак) төркемнәреннән торган «бердәм армия» төзергә тәкъдим итә.Уйлап карасаң, алга таба күпсанлы көнбатыш кыпчакларын һәм башка халыкларны яулап алуда катнашу өчен «татар армиясе» төзү турында бара бит сүз! «Юань ши» әсәреннән күренгәнчә, Субәдәй бахадурның бу тәкъдимен Чыңгызхан раслаган. Ә бит бу төркемнәр барысы да Җучи Олысына кергәннәр. Димәк, күрсәтелгән хәрби контингент та аның кул астында булган булырга тиеш.

## Җучи олысының (Алтын Урданың) формалашып бетүе дәверендә татар факторының көчәюе

Мәкаләнең алдагы өлешеннән күренгәнчә, Бөек Монгол империясе оешкан һәм киңәйгән чорда дәүләт эчендә татарга мөнәсәбәтле этник төркемнәр мөһим роль уйнаганнар. Бу фактор бигрәк тә Җучи Олысы өчен хәлиткеч булып чыга, чөнки башта Еке Монгол Олысы эчендә аерым биләмә булып формалашкан шушы административ-сәяси берәмлек Урта Азияне яулап алган чорда үз чикләренә көнчыгыш кыпчакларны да, ягъни, татар төркемнәре җитәкчелегендә булган кимак һәм канглы берләшмәләрен дә ала. Бу процессның кайбер нюансларын карап үтү файдалы булыр, чөнки алардан тикшерелә торган төп проблеманы тирәнрәк аңлау мөмкинлеге килеп чыга.

Гарәп энциклопедисты ан Нувейри (1279-1333) язганча, Чыңгызхан Җучины гаскәр белән кыпчакларны буйсындыру өчен җибәргәндә, аның «җәйләве һәм кышлавы өчен Кыялык һәм Хорезм җирләреннән Саксин һәм Болгар чикләренә кадәр, аларның һөҗүмнәре вакытында атлары һәм [хәрби] төркемнәре барып җиткән иң ерак чикләренә кадәр» сузылган урыннарны билгели. Чыннан да 1223 елны «Саксин һәм Болгар» чикләренә кадәр Субәдәй һәм Җәбе җитәкчелегендәге гаскәрләр барып җитә, ләкин ул көнбатыштагы биләмәләр, кыпчаклар һәм руслар җиңелсә дә, яулап алынмыйча кала. Көнчыгыш кыпчаклар да әле бөтенләе белән буйсындырылып бетмәгән була.

Шуңа күрә 1229 елны («Тычкан елында») Бөек Монгол империясенең үзәгендә – «Бөек ставкада», корылтай җыела, анда Батый ханның туганнары да катнаша (ләкин ул үзе бармый). Шушы олуг җыенда Чыңгызхан карары нигезендә Угәдәй империя тәхетенә утыра. Элек бүлеп бирелгән биләмәләр яңадан раслана һәм ике яубаш – Кокошай (Кокетай) белән Субәдәй баһадур җитәкчелегендәге 30 меңлек гаскәрне «кыпчаклар җиренә һәм Саксин белән Болгарга» каршы җибәрү турында карар кабул ителә (Джувейни). Ләкин бу 1229/1230 елны башланган поход турында мәгълүмат аз сакланган, чөнки ул вакыйга бераз соңрак булган, 1235-1242 елгы гомумимперия гаскәрләрнең «көнбатыш илләренә» һөҗүме күләгәсендә кала. Әмма монголларның «Яшерен тарихында» нәкъ менә беренче 30 меңлек отрядның көнбатыш тарафка һөҗүме турында мондый юллар бар: «Субәдәй баһадур аңа Чыңгызхан яулап алырга кушкан халыклар һәм шәһәрләр ягыннан нык каршылыкка очрады». Ахрысы, бу яклар белән инде таныш булган Субәдәй баһадурга шушы һөҗүм вакытында Идел чикләренә чыгу йөкләнгән булган, ләкин монда ул тиз генә җиңеп чыга алмаган.

Күзгә ташланганы шул – 1229 елны атасының биләмәләрен яңадан раслаткан Батый ханның бу яуда катнашуы турында чыганакларда бер сүз дә юк. Ә бит соңгысы бик

сәер, чөнки Батый кулындагы Җучи Олысы нәкъ менә шул җирләр янында булган бит! Монда ике аңлатма бирергә мөмкин: 1) Батый биләмәсе эчендә баш күтәрүләр башланып, ул шуларны бастыру белән мәшгуль булган; 2) Үз биләмәсеннән Алтайны алып, Угэдэй биләмәсенә кушу уңаеннан ул, бәлки, империянең үзәк идарәсенә ризасызлык күрсәтү йөзеннән әйтелгән яуда катнашмагандыр. Шулай да без бу турыда төгәл генә белмибез.

Бер-берсенә бәйсез булган ике тарихи чыганак шушы 30 меңлек гаскәрнең сугыш хәрәкәте турында мәгълүмат бирәләр. Гарәп елъязмачысы Ибн Васил (XIII йөз) хиҗри белән 627 елны (1229/1230 ел) «татарлар (ягъни монголлар – *Д.И.*) һәм кыпчаклар арасында сугыш уты кабынды», – дип яза. Русларның «Лаврентьев елъязмасында» 1229/1230 елларга караган тулырак хәбәр күрәбез: «...Саксиннар һәм половецлар (ягъни кыпчаклар) Болгарга түбәннән (Иделнең түбән агымы ягыннан – *Д.И.*) татарлар алдыннан йөгереп күтәрелделәр һәм сакчы болгарлар Җаек елгасы янында татарлар тарафыннан кыйналып кайттылар». Күренә ки, 1229-1230 еллардагы монгол гаскәрләренең рейды беренче чиратта көнчыгыш кыпчакларга һәм болгарларга каршы юнәлтелгән була. Бәхеткә каршы, бу очракта чыганаклардагы «половецлар»/ «кыпчаклар» астында без хәзер кимаклар күз алдында тотылганны беләбез: сүз Бачман солтан исемле хөкемдар җитәкчелегендә булган илбары (алпарлы/олбурлик) кабиләсе кул астындагы берләшмә турында бара – аларның «Ак Түбә» исемле башкаласы хәзерге Оренбург шәһәре янында булганлыгы турында татарларда сакланган тарихи легендалардан билгеле.

Субэдэй баһадурның отряды кайбер уңышларга ирешә – 1231/1232 елларның кышында ул төркем, ахрысы, «Бөек шәһәр», ягъни Идел Болгарстаны башкаласы Биләргә кадәр килеп җитә, ләкин аны ала алмый һәм алга таба монгол гаскәренә өстәмә «ярдәм» кирәк була («Яшерен тарих»). Нәтиҗәдә, Угэдэй каһан аерым корылтай җыеп, 1235 елның язында «.. әле буйсындырылмаган, үзләренең күпсанлы булулары белән горурланучы Болгар, ас һәм Рус илләрен яулап алу турында карар чыгара». Бу – гомумимперия походы булып, аңа шушы җирләргә күрше яшәгән Батый да кушылган. Ахрысы, нәкъ менә аңа бөтен армия белән идарә итү вазифасы да йөкләнә, чөнки, Рәшидеддин язганча, «барысы да Батый тирәсенә җыелып, төньяк илләрне яулап алу эшенә керештеләр».

Бу яу турында тәфсилләп язу кирәк булмас, аның буенча мәгълүмат күп тапкырлар анализланды. Әмма шушы һөҗүм белән бәйле берничә фактка игътибар итү кирәк.

Монгол гаскәрләре 1235 елның язында Идел Болгарстанын буйсындыргач (аның башкаласы «Бөек шәһәрне» алганда, Джувейни күрсәткәнчә, 270 мең кеше үтерелә), андагы Баян һәм Җикү исемле ике «юлбашчы» буйсынуын белдерәләр һәм алар үз биләмәләренә кире кайтарылалар, ләкин аннан соң «яңадан баш күтәрәләр». Шуңа күрә, Субэдэй баһадурга аларны яңадан буйсындырырга туры килә (Рәшидеддин). Димәк, Идел буйларында 1235 ел дәвамында тыныч булмаган. Икенче хәбәр (ул болгарларны яңадан буйсындыру турындагы хәбәргә бәйле рәвештә бирелә) шул вакыйгалар барышында монголларның камап йөрүләре белән бәйле – монгол гаскәрләренең «Сул канатыннан» Мәнгу җитәкчелегендәге төркем «диңгезнең (Каспий турында сүз бара – *Д.М.*) ярларыннан» хәрәкәт итеп, анда «кыпчак халкыннан булган олбурлик кабиләсенең әмире» Бачманны һәм «ас кабиләсеннән» булган Качира-укуль исемле шәхесне әсирлеккә ала. Аннан соң, Рәшидеддин күрсәткәнчә, алар үтереләләр. Шундый ук хәбәр Джувейнида да бар. Ә менә «Юань ши» әсәрендә без бу вакыйгага кагылышлы кайбер детальләрне күрәбез. Андагы хәбәрдә, Угэдэй каһанның Субэдэй баһадурга «авангардта булып, Бачман белән сугышырга боеруы» турында әйтелә һәм танылган монгол гаскәриенең «армия башына куелуы» күрсәтелә. Димәк, Җаек елгасы буйларында һәм Иделнең түбән агымы тирәләрендә яшәгән бу кимак төркемнәре зур көч булганнар, югыйсә аларга каршы Субэдэй баһадур кебек күренекле яубашы җибәрелмәс иде.

Шушы уңайдан тагын бер рус елъязмасында элегрәк күренгән мәгълүматка игътибар итү кирәк. Сүз русларның 1184 елга караган «Болгар җиренә» һөҗүме турында бара. Алар «Бөек шәһәргә» – Биләргә якынлашканда, далада бер гаскәри берләшмә күреп,

аны болгарлар дип уйлыйлар, лəкин русларга алар арасыннан килеп «баш орган» 5 кеше бу хəрби берлəшмəнең «болгар князе җитəкчелегендə Болгарны яулап алу өчен килгəн йөмəк кыпчаклары» («Половцы Емяковы»), икəнлеген белдерəлəр. Руслар белəн килешү төзеп, бу кимак гаскəре болгарлар белəн сугышта катнаша. Моннан нинди нəтиҗə чыга соң? Минемчə, Җаек бассейнында яшəгəн кимакларның XII гасырда ук болгарлар белəн тыгыз мөнəсəбəттə булуларын күрсəтə бу. Ягъни, уйлап карасаң, монголларга кадəр үк татарлар кимаклар аркылы Болгар җирлəренə йогынты ясап ятканнар. Һəм бу яңа күренеш булмаган. Əйтик, Ибн əл Асир 1043/1044 елга караган мондый хəбəр бирə: шул елда 10000 «кибитка» саналган «динсез [мəҗүси] төркилəр» – ə алар – «Баласагун һəм Кашгар якларына» һөҗүм итеп торганнар – ислам дине кабул итəлəр. Ошбу тарихчы күрсəткəнчə, алар кышны Баласагун тарафларында үткəрсəлəр дə, җəй вакытында «болгар якларында» яшəгəннəр. Минем фикеремчə, соңгы очракта да сүз илбары/алпарлы кабилəсе турында бара, чөнки Джуджани мəгълүматлары буенча, нəкъ шушы кабилə ханнарының бабалары булган Абар хан (ул XI гасырда яшəгəн) 10000 «гаилə» өстеннəн хакимлек иткəн. Илбари кабилəсе җитəкчелегендə булган «кимак кыпчакларының» XII-XIII йөз чиклəрендə Җаек бассейнында яшəүлəре дə шул ук нəтиҗəне куəтли.

Хəзер безгə Җучи Олысы тарихының башлангыч чорын калдырып торып, анда Җучиның өченче улы булган Бəркə хан хакимлек иткəн 1254/1267 елларга килергə кирəк. Эш менə нəрсəдə: үлəренə күп тə калмастан, Батый хан Бəркəне элеккеге билəмəсеннəн (аны берəүлəр Кавказ алдында булган дип саныйлар, ə минем фикеремчə, ул Кавказ артында – төньяк Иранда булган) – Иделдəн көнчыгышка күчерə. Кайбер тарихи мəгълүматлар буенча, аның яңа билəмəсе Сыгнак тирəлəрендə, иске кимаклар яшəгəн җирлəрдə булган (Үтəмеш хаҗи). Джуджани, гомумəн, аның ислам динен Ходжентта өйрəнүен, мөселманча яшəгəнен күрсəтеп, əйтə: «...үсеп җиткəч (Бəркə 1206/1207 елларда туган – *Д.И.*)... [ул] кыпчак җиреннəн Бохара шəһəренə китə..., Җучи станында булган барлык мөселманнар аның гаскəренə билгелəнделəр». Алга таба күрсəтелгəн автор бу гаскəрнең 30 мең сугышчыдан торып, аларның «җомга намазларын» үтəүлəре һəм башка ислам йолаларын тотуларын яза. Гарəп елъязмачысы ад-Дзехаби (1348/1349 елны үлгəн) Бəркəнең Бохарага 1240 елларда барганлыгын һəм ул сəяхəт вакытында аның янында булган «күп əмирлəрнең» ислам динен кабул итүлəрен тасвирлый.

Кыскасы, шушы шəхес турында төрле версиялəр булса да, Бəркəнең элекке хорезмшаһлар билəмəсендə, төгəлрəге, аның төньяк-көнчыгыш өлешендə, инде ислам динен кабул итеп өлгергəн кимаклар, канглылар һəм алар белəн бəйле башка төркемнəр арасында яшəп, анда мөселманга əйлəнүе ачык. Аның белəн бергə янындагы «əмирлəре» дə ислам динен кабул иткəннəр, димəк, монда шактый киң исламлашу күзəтелгəн. Бу 30 меңлек мөселман төркемнəреннəн торган армия саны Батый хан карары белəн Бөек Монгол империясе тəхетенə Менгуны күтəрү өчен улы Сартакны анда озатып барган Бəркə янындагы 3 төмəннəн торган гаскəр санына туры килə, ахрысы, ул шул бер үк армия булган. Һəм менə шундый сорау туа: 1229/1230 елларда Субəдəй баһадур кул астындагы гаскəрнең саны да 30 мең булганлыктан, сүз шушы яубашның 1224 елны Чыңгызханга бирелгəн язмасы буенча канглы, кыпчак (кимак), найман һəм меркитлардан төзелгəн «татар» армиясе турында бармый микəн? Бу бик мөмкин, чөнки алар составында булган «көнчыгыш кыпчакларның» бер өлеше инде XI-XII гасырларда ук мөселманлашканнар.

Шушы фикерне куəтли торган ике дəлил китерəсе килə. Беренчесе – конграт кабилəсенең династик шəҗəрəсеннəн. Ул шəҗəрəдə башка чыганаклардан да билгеле булган Салжидай гургəн искə алына һəм аның «уйгур кабилəсеннəн» икəнлеге языла (Ю.Брегель). Чынлыкта исə ул шəхес Тукта хан һəм Үзбəк хан заманында яшəп, конграт кабилəсенең нойоны (бəге) булган. Ə менə аның Үтəмеш хаҗида «уйгурлардан» дип билгелəнүе монголларның, бу очракта конгратларның кимак-уйгур төркемнəре белəн катнашуын күрсəтə дип уйларга тулы нигез бар. Соңгысы исə, Бəркə Урта Азия якларында торган заманнарда күзəтелгəн булса кирəк. Юкка гына югарыда əйтелгəн шəҗəрəдə конгратлар белəн бергə аларга кушылып йөрүче күпсанлы «башка төркилəр»

дә искә алынмыйлардыр. Икенче мөһим мәгълүмат Әбелгази Баһадурханда бирелә. Ул Хива ханлыгына нигез салучы кабиләләр турында: «... [Ул] илнең башы татар нәселеннән булган уйгур һәм найманнар», – дип яза. Уйгурлар турында игътибарга лаек тагын бер факт Үтәмеш хаҗиның «Чыңгызнамә» әсәрендә сакланган. Анда әйтелгәнчә, Алтын Урда ханы Тукта үлгәч (1312 елны), ханның аталыгы, ягъни, аны яшьтән тәрбияләүчесе «уйгур» аймагыннан булган Бачиртук Буга, «кара кеше» була торып (хан нәселеннән, Чыңгызыйлардан түгел), үзен хан дип игълан итә һәм мәрхүм ханның хатыннарын алып, тәхеткә утыра. Чыганактан күренгәнчә, бу шәхескә мөнәсәбәтле «уйгур иле» ул вакытта «күпсанлы кабилә һәм ырулардан» торган. Бу дәвер өчен Чыңгызхан нәселеннән булмаучының тәхеткә утыруы гадәттән тыш күренеш, чөнки исән-сау Чыңгызыйлар тирә-якта җитәрлек булган. Шуңа күрә югарыда тасвирланган вакыйгага аерым аңлатма кирәк: ахрысы, монда без Идел буена Бәркән ханга ияреп килгән көнчыгыш кыпчаклар-кимаклар арасында сакланган һәм элеккеге кимак-уйгур-татар хөкемдарлары арасыннан чыккан, хан нәселеннән булган шәхеснең Җучи Олысында яңадан тәхетне кулга төшерүгә омтылышы белән очрашабыз. Ягъни элекке кимаклар дөньясындагы татар-уйгур тамырлы элита монголлар килгәнче булган сәяси вазгыятьне торгызырга тырышып караган. Әгәр дә без бу гипотезаны кабул итсәк, китерелгән факт алда сөйләнгәнннәрне тагы бер кат раслый.

Күрәсез, Алтын Урда эчендә XIII гасыр дәвамында «татар факторы» көчәюе өчен шартлар булган. Моның шулай икәнлеген Җучи Олысында ул дәвердә яшәгән «монгол-татарларның» кабилә составларын тикшереп карап та раслап була. Хәзер нәкъ шул мәсьәләгә күчү кирәк.

## Җучи Олысы / Алтын Урда дәүләтендә төп халыкның этник йөзе

Атаклы фарсы тарихчысы Рәшидеддин хезмәтеннән күренгәнчә, 1207 ел тирәсендә Чыңгызхан үз нәселеннән булганнарга «әмирләрне һәм гаскәрне», чынлыкта исә, биләмәләрне бүлеп бирә. Шул вакытта Җучига 4000 кешелек (берәр меңле 4 өлештән торган) гаскәр бирелеп, беренче меңлек сиджиуд (салжигыт) кабиләсе вәкилләреннән (башлыклары – Мунгэде нойон), икенчесе – кингит (кенегес) кабиләсе кешеләреннән (башларында – Кутан нойон), өченчесе һәм дүртенче меңлекләр – хушин (уйшин) кабиләсеннән булганнар (башларында Хушитай нойон һәм Байку күрсәтелгән, ләкин төгәлрәге: бу бер шәхес – Хушитай Байку нойон булыр). Шундый ук мәгълүмат «Яшерен тарих»та һәм Лубсан Данзанның «Алтан Тобчи» (XVII йөз) әсәрендә дә бар. Алардан күренгәнчә, Чыңгызхан үзенең якын туганнарына «биләмәләр» биргәндә, өлкән улы Җучига 9000 юрта (гаилә) бүлә һәм аның янына нойоннарны куя (исемнәре: Хунан, Мункеур һәм Кете). Ахрысы, шушы 9000 юрта/гаиләдән 4 берәр меңлек гаскәри берләшмәләрдән торган гаскәр җыелган. Җучиның беренче биләмәсе «монголлардан» торса да, уйшын кабиләсен электән монгол булган дип булмый – бу төркем һинд-арий тамырлы уйсунь берләшмәсенә барып тоташып, чынлыкта борынгы төрки дәвердә Алтай төркиләре тарафыннан ассимиляцияләнгән кабилә булган дип уйларга урын бар. Һәрхәлдә, Рәшидеддин хезмәтендә хушин (уйшын) кабиләсе чын монгол булган нирун тармагына карамый.

1207 елны, алда күрсәтелгәнчә, Җучи гаскәре «Урман халыкларын» җиңеп, Алтай-Саян буйларын һәм Иртыш елгасы бассейнына кадәр сузылган җирләрне Еке Монгол Олысына кушкач, Җучи биләмәсенә яңа төрки төркемнәр кушыла. Тарихта яхшы билгеле булган Минусин үзәнлегендә яшәгән кыргызлардан тыш алар арасында «Баргузин Токым» (Селенга елгасы янында) дип аталган төбәктә яшәүче баргут (боркыт), кори (хори), тумат, мингат, байаут төркемнәрен беренче булып атарга кирәк. Боларның кайберләре, мәсәлән, боркытлар, соңыннан монголларның конгырат кабиләсе белән туганлаша (кыз бирү – алу юлы белән), ләкин алар барысы да төрки булганнар (берсе бәхәсле, алга таба карагыз). Әйткән кори (хори), тумат, баргут (аларга мингат кабиләсен дә кушырга була) төркемнәре бер-берсе белән этник яктан туган булып, Тува җирләрендә яшәгән борынгы дубо (тума/туба) төркиләр төркеменә барып

тоташалар. Дөрес, монголлар дәверендә алар берникадәр дәрәҗәдә монголлашканнар, ләкин төркилекләрен җуймаганнар. Саналган кабиләләргә якын яшәгән байаут төркемен кайбер галимнәр монгол телле булган дип саныйлар (Б.Зориктуев). Ләкин бу – бәхәсле фикер, чөнки XIII йөз тарихчысы ан-Насави хезмәтеннән күренгәнчә, байаут кабиләсе йәмәкләрнең бер тармагы саналган. Димәк, бу төркем кимак-татарлар белән бәйле булган. Саналган төркемнәрдән тыш, Җучига буйсынган «Урман халыклары» арасында кыргызлардан бик ерак тормаган урасут (урсут), теленгит (теленгут), хуштеми (кешдем), хапканас, тубас, тухас, тоялес, тас (таз), бачжи төркемнәрен атарга кирәк. Хәзерге заман тарихчыларының фикеренчә, алар барысы да төрки булганнар. Юкка гына Рәшидеддин урасут, теленгут, хуштеми төркемнәрен башта «монголлар» дип, аннан соң «монголларга охшаш» дип атамый инде. Дәвам итеп, шуны да әйтергә кирәк: хапханасларның исеме хакаслар составындагы хапкас ыруы исеменә туры килә. Мондый мисалларны тагын да күбәйтергә мөмкин әле (Б.Зориктуев бу турыда язды инде). Әмма «Урман халыклары» арасында монгол телләләр (ойрят, бурят) һәм башка этник тамырлы төркемнәр дә булган. Мәсәлән, алар арасында саналган «шибер» төркеме угор тамырлы берләшмә булган дип уйларга нигез бар. Чөнки аларны болгарлар тарихыннан яхшы билгеле булган сувар/савирларның Себердә калган өлеше дип карарга мөмкин. Әйтергә кирәк, ул «халык» турында Себер татарларының тарихи хәтерендә әле дә легендар хәбәр бар – «сыпыр» халкын алар «вак гәүдәле, элекке заман халкы» дип саныйлар. Идел буе татарларында сакланган «ыбыр-чыбыр» сүзе дә шул этноним белән бәйле (тарихи чыганакларда Себер җирендә булган «Ибир-Сибир» төбәге атамасы да шул ук төшенчә) һәм аның беренче өлеше – «ыбыр», авар (обыр) этнонимын, икенче өлеше – «чыбыр» – күрсәтелгән «шибер» атамасын чагылдыра булса кирәк.

Әгәр дә без югарыда каралган мәгълүматны гомумиләштерсәк, нәтиҗә мондый булып чыга: 1207 елдагы яулап алулардан соң, тарихта яхшы билгеле кыргызлардан тыш Җучи Олысына күп кенә Алтай төркиләре килеп кушыла (араларында кимак-татар белән бәйлеләре дә булган), ә Җучиның биләмәләре көнбатышта Иртыш якларына килеп җитә, ягъни кимакларның борынгы җирләренә барып терәлә. Параллель рәвештә монголларның шул ук якларда яшәгән найман һәм меркитларны, ягъни борынгы татар этник тамырлы төркиләрне дә җиңеп, үз биләмәләренә кушуын да истә тотсак – ә аларның бер өлеше, һичшиксез, Җучи Олысына да кергән – татар этник аңы булган төркемнәрнең әле төп кимак җирләрен яулап алганчы ук сан ягыннан күбәя баруын күрәбез. Дөрес, Алтай – Саян буйлары 1219-1226 еллар арасында, ә бәлки 1229 елны, Бөек Монгол империясенең «Төп йортына», ягъни Үзәк биләмәсенә бирелә, ә бу исә Алтай төркемнәренең бер өлешенең Җучи Олысыннан алынуына китерә. Ләкин тарихи чыганаклардан инде бу вакыйга булганчы ук Алтай төркиләренең (найман һәм меркитларны да кертеп) шактый өлешен Җучи үз биләмәләренең башка төбәкләренә күчереп өлгергән дигән нәтиҗә ясарга була. Алда без моның шулай икәнлеген ачыграк күрсәтербез. Ләкин аңарчы безгә Җучи Олысының иң әүвәл шушы берләшмәнең этносәяси үзәген тәшкил иткән 4 мең сугышчыдан (9000 юрта/гаиләдән) торган төркеме мәсьәләсенә мөрәҗәгать итү кирәк. Алар чыннан да Җучи Олысы эчендә калганнармы соң? Мондый сорау урынлы, чөнки монголларның 1229-1230 елларда башланган Идел буйларына һөҗүме 1235-1242 еллар арасында булган гомумимперия масштабындагы «көнбатыш халыкларын» яулап алу походы белән алмашынып, анда элек Җучи Олысына кермәгән күп кенә башка төркемнәр дә катнашкан. Шуңа күрә, Җучи үлгәннән соң (1227 ел) Батый хан кул астында яшәгән биләмәнең дәүләт тотучы үзәген тәшкил иткән «монгол-татарларның» этник йөзен тагын бер кат барлап чыгу кирәк булыр.

Лубсан Данзан язганча, 1225 елны Чыңгызхан Җучины «кыпчаклар башлыгы» итеп билгеләгәч, инде бездә таныш Хукин нойонны (кингит/кенегес төркеме җитәкчесе) «биләмәнең көнбатыш яртысы» өчен җаваплы буларак «оросутлар һәм черкисутлар җирләре»н идарә итү өчен җибәрә. Шул вакытта аңа 8000 кеше дә бирелә. Күренә ки, башта меңбашы булган Хукин нойон хәзер темникка, ягъни 10000 сугышчы – төмән башында торучыга әйләнгән. Шул ук кулъязмада күрсәтелгәнчә, Хукин нойон тиешле

«урынга» барып җиткәч, аның артыннан Мунгэту баһадур (сиджутлар җитәкчесе) җибәрелгән. Бу хәрби берләшмәләрнең көнбатышка күчү вакыты төгәл билгеле түгел, әмма сүз 1225 елгы карарны үтәү турында бара. Дөрес, инде әйтелгәнчә, Чыңгызханның ул боерыгын үтәү шактый озакка сузыла. Китерелгән мәгълүматларны Рәшидеддин да раслый. Әйтик, аның хезмәтендә Мунгэде нойон турында ул «Батый дәверендә гаскәр белән идарә итте», – дип әйтелә, аннан соң ул чыганакта Тукта хан заманында Черкес исемле «өлкән әмирнең» аның нәселеннән булганлыгы күрсәтелә. Димәк, сиджут (салжигут) төркеме Җучи Олысында кала. Шул ук Рәшидеддин Батый ханның абыйсы Орда Олысында аның оныгы Кунджи (Куинджи) кул астында яшәгән Хуран исемле «билгеле бөек әмир» (монголча – нойон) турында аның Хукин (Кутан) нойон нәселеннән, кингит төркеменнән икәнлеген күрсәтә. Бу автор әйтүенчә, инде безгә таныш булган Хушидай Бәйку (уйшын төркеме башлыгы) «Батый гаскәренең уң канаты белән идарә иткән». Күренә ки, Җучига иң элек бирелгән хәрби берләшмә (кингит, сиджиут, уйшын кабиләләреннән) Батый хан биләмәсендә кала һәм хәрби яктан көчәйтелә – меңбашы булган Хукин нойонның 8000 кешелек гаскәр белән җитәкчелек итүе нәкъ менә шул турыда сөйли.

Әмма бу Җучи Олысында яшәгән «монгол-татарның» югарыда күрсәтелгән кабилә гаскәрләренең башка төркемнәре дә булган. Әйтик, 1236 елның көзендә Болгар җирләрен яулап алуда Батый белән бергә катнашкан энесе Шибан янында 10 000 кешелек авангардта барган гаскәр составындагы «әмир», яки «богатырь», «воевода» (рус чыганакларында) дип билгеләнгән Бурундай искә алына. Хәзер безгә билгеле – бу шәхес кыйат кабиләсе вәкилләреннән торган бер төмән (10 000) гаскәре белән, элек Шибан кул астында булган 30 меңлек гаскәргә китереп кушыла. «Таварихы гузида –йи Нусрат-намә» исемле хезмәттән күренгәнчә, соңгылары 3 төмәннән торып, конграт, боркыт һәм төмән кабиләләреннән төзелгән булганнар. Конгыратларның Җучи Олысында калуын Рәшидеддин хезмәтеннән ачык күреп була. Ул Тукта хан вакытында Әбугән нойон исемле шәхеснең 5 меңлек «конгырат гаскәре» башында торганлыгын да яза. Кыйат кабиләсе вәкилләреннән торган гаскәр, шул ук тарихчыдан күренгәнчә, Тукта хан заманында бер төмән тәшкил иткән. Боркытлар монда инде безгә таныш булган Алтай-Саян зонасында яшәгән баргут кабиләсеннән булса, төмән төркеме шунда ук утырган тама (тамат/туба) кабиләсе вәкилләре булса кирәк (ләкин аларның уйшын кабиләсе белән дә ниндидер борынгы бәйләнешләре бар). Шулай итеп, күрсәтелгән 4 төркемнең икесе монгол (кыйат – Чыңгызханның бабалары кабиләсе; конгырат – алар борынгыдан туганлашкан төркем), ә икесе – Алтай төркиләре (боркыт, төмән/тама/таман/тамйан).

Җучи Олысының төп халкының этник йөзен ачу өчен аның кабилә составын тикшергәндә, безгә XIII-XIV йөзләрдә Чыңгызыйларның хатыннары нинди кабиләләрдән булганлыгын да истә тотарга кирәк. Дөрес, бу мәгълүматларның бер кимчелеге бар: бердәм Бөек Монгол империясе яшәгәндә Чыңгызхан нәселеннән булучылар хатыннарны Төп йорттан да алып кайта алганнар. Шулай да күпчелек хатыннар Җучи Олысында яшәүче Чыңгызыйларга үз җирлегендәге кабиләләрдән китерелә. Әйтелгән принциптан чыгып, Рәшидеддин хезмәтен өйрәнгәч, инде кәтелгән конгырат, уйшын кабиләләреннән чыккан хатыннардан тыш, меркит, найман, татар (алчи-татар), кыпчак, кереит, тулас, огунан (онгут) кабиләләреннән (төрки-татарлар) һәм ойрат, сулдус, җаҗират (җурьят), аргунан, йисут (монголлар) төркемнәреннән килгән хатыннар да күренәләр. Бу мәгълүматның дөреслеген кайбер соңрак чорга караган чыганаклар аша тикшереп карап була. Әйтик, Батый ханның кече энесе Тукай Тимурга «вилайат-и ас һәм Мангышлак», шулай ук Хаҗи Тархан бирелгәндә (Батый хан боерыгы нигезендә), аңа тагын 4 төркемнән торган «илләр» («каучин» илләр) дә кушыла (Мәхмүд б.Вәли, XVII йөз). Менә алар: уйшын, минг, тархан, ойрат. Күрәсез, ойрат төркеме Җучи Олысына чыннан да кергән. Мондагы минг (мең) «Урман халыклары» арасында Җучи тарафыннан яулап алынган мингат төркеменә туры килә булса кирәк. Шулай итеп, бу фактлар «хатыннар базары» аша күзгә ташланган нәтиҗәне генә түгел, Алтай ягындагы монголларны (ойратлар) һәм төркиләрне Җучи олысының көнбатышына китерелүен ачыкларга да ярдәм итә. Моңа өстәп тагын

Җучиның бишенче улы булган Шибан кул астындагы моңарчы каралмаган XVI-XVII гасыр чоры чыганакларындагы төркемнәр турындагы мәгълүматны тикшерү дә кирәк. Әйтик, «Таварихы гузида-йи Нусрат-намә» (XVI йөз) әсәрендә Шибан ханга хезмәт иткән кошчы кабиләсе күренә. Безнең фикер буенча, бу – Алтай төбәгендәге коштеми (куштеми) кабиләсе. Ә Әбелгазый Баһадурхан үзенең «Шәҗәрәи төрек» китабында (XVII йөз) Батый хан тарафыннан Шибанга бүлеп бирелгән 4 төркемне күрсәтә: кошчы, найман, карлук (карлык) һәм бөйрек (буйрак).

Билгеле, бу очракта найманнарны Җучи Олысына XIII йөз башларында ук кергән төркемнәрдән дип карарга кирәк. Ә менә карлыклар һәм алар белән бәйле бөйрек төркеме Шибанның үзенә түгел, а аның варисларына XIV гасырда Үзбәк хан карары буенча бирелә (Үтәмеш хаҗи). Монда кызыгы шул – Рәшидеддин буенча карлыкларны (димәк, бөйрек төркемен дә) һәм кыпчакларны (бу очракта – кимакларны) уйгурларның бер төре дип карап булганга – ә бу фикер, инде күргәнебезчә, тарихи чыганаклар белән раслана – бу карлык компонентын да татарга мөнәсәбәтле төркем дип карап була. Һәм Әбелгазый Баһадурхан шушы нәтиҗәне раслаучы сүзләрне үзе үк әйтеп бирә. Хива ханлыгына нигез салган ике төркем турында – алар уйгур һәм найман илләре булган – күпне белгән тарихчы болай дип яза: «Илнең башы ... татар ыруыннан булган (игътибар! –*Д.И.*) уйгурлар һәм найманнар». Менә шул рәвешле татар үзаңы булган көнчыгыш кыпчаклар-кимаклар арасында югары катламны тәшкил иткән төркемнәр тагын бер тапкыр күренеп китәләр.

Шулай итеп, Алтын Урдага әйләнәчәк Җучи Олысының үзәген тәшкил иткән «халык», монголлардан (кыйат, конгырат, ойрат, суджигут/салджигут, сулдус, җаджират/җурят, йисут, аргунан) тыш күпсанлы төркиләрдән, беренче чиратта, татар тамырлы төркемнәрдән (алчи-татар, кыпчак-кимак, найман, меркит, онгут), аннан соң Алтай төркиләреннән (уйшын, кереит, тулас, мингат, кошчы) торган дигән нәтиҗә килеп чыга түгелме? Аны тагын да көчәйтү өчен безгә китерелгән мәгълүматка кайбер башкаларын да өстәргә кирәк. Алар бик үк күп түгел, төп фикерне бераз нигезлерәк кенә итәләр.

Чыганаклар тулы булмау сәбәпле, Җучи Олысында/Алтын Урдада яшәгән барлык кабиләләрнең төгәл исемлеген әлегә төзеп булмый. Дөрес, кайбер соң чорларга караган тарихи әсәрләрдә Батый ханга буйсынган «кыпчак гаскәренең», ягъни Алтын Урда биләмәләрендә яшәгән, билгеле һәм мөһим кабиләләрнең исемлекләре очрый. Мәсәлән, Ибн Вәлинең «Бахр ал-асрар» (XVII йөз) дип аталган хезмәтендә Батый хан гаскәрендәге 12 кабилә санап кителә: аргун, огуз, конгырат, кереит, барлас, минг, усун/уйшын, уйрат/ойрат, кошчы, найман, карлык, бөйрек. Бу без югарыда китерелгән, XIII-XIV йөзләргә караган чыганаклардан җыелган исемлектән (анда барлыгы 26 кабилә күренә) шактый ким. Шуның өстенә бу XVII йөздә язылган чыганакта кайбер кабилә исемнәре гомумиләштерүдән барлыкка китерелгәннәр. Әйтик, «огуз» атамасы. Чынлыкта бу кабилә исеме түгел, ә зур этник төркем – угызлар, ягъни халык атамасы. Әгәр дә ул кабилә исеменә әйләнгән икән, күрсәтелгән төркемне төрле угыз кабиләләреннән җыелган ясалма кабилә дип уйларга туры килә. Шулай ук барлас кабиләсе (Аксак Тимернең шәхси биләмәсе, чөнки ул шушы кабилә әмире булган) башта Алтын Урда җирләрендә булмыйча (барлас иле иң элек Чагадай Олысына караган була), Сәмәрканд якларында яшәп, Ибн Вәли исемлегенә Тимуридлар чоры варисы буларак кертелгән, ахрысы. Ә менә кайбер билгеле кабиләләр, шул исәптән, XV-XVI йөз татар ханлыклары өчен, XVII йөз исемлегендә юк. Мисал өчен без Үтәмеш хаҗи хезмәтендә (XVI йөз) күрсәтелгән барын (барин), җалаир, кенегес, канглы, хытай (кытай), кыпчак, кыйат, сиджут (салджигут), уйгур, ширин кабиләләрен атый алабыз. Шуның өстенә бу автор 4 кабиләне (ширин, барын, аргун, кыпчак) Туктамыш ханның «күптәнге, бабалары заманыннан калган илләре», – дип билгели.Чыннан да, бу кабиләләр, беренчесеннән башка, безгә инде танышлар. Ә ширин кабиләсе, минемчә, XIII йөздә, Бачман солтан дәверендә, Каспий диңгезе буйларында монголларга буйсындырылган төркиләшкән ас кабиләсенең дәвамы булган. Туктамыш хан Тука Тимур нәселеннән булганлыктан (соңгысының кул астындагы кабиләләрнең, исегезгә төшерәм – минг, ушун/уйшын, тархан, ойрат атамалы икәнлеге билгеле), ширин (чынлыкта – ас) һәм кыпчак (кимак,

бәлки, төгәлрәк, илбари кабиләседер; бу очракта «кыпчак» атамасы – гомумиләштерү нәтиҗәсе, ягъни, сүз җыелма төркем турында бара) төркемнәре Хорезм якларында яулап алу вакытларында буйсындырылган этник берләшмәләрдән оештырылганнар булып чыга. Күренә ки, кайбер чыгарылмалар булса да – ә аларны аңлату мөмкин – Батый хан биләмәсенең төп этник ядрәсен чамаларга була. Сүз, бәлки, чынлап та 12-14 этносәяси берәмлек (кабилә нигезле хәрби төркемнәр) турында барырга мөмкин.

Шушы нәтиҗәдән чыгып караганда, татарларда сакланган XVII йөз ахырларында язылган дип саналган «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәре игътибарны җәлеп итә, чөнки анда да кабиләләр исемлеге бар. Дөрес, кайбер очракта ул чыганакта кабилә үзе түгел, ә аның сәяси җитәкчесе – бәге аталган, ләкин алар артында нинди кабиләләр яшерелгәнлеген ачыклап була һәм мин ул эшне заманында башкарып чыккан идем инде. Нәтиҗә мондый. Барлыгы 15 кабилә күренә: кыйат, конгырат (I), уйшын, мең (минг), тамйан/төмән, кыпчак (I), җорматы, кереит, муйтен, буржан, боркыт, катай, кыпчак (II, ягъни, кимак), сальжут, тангаур (конгырат II). Бәхеткә каршы, соңгы вакытта «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәренең яңа бер версиясе табылып, андагы кабиләләр һәм бәкләр исемлеге алдында мондый сүзләр язылган булып чыкты: «Җанибәк хан заманында торган бәкләр». Әһәмиятлесе шул – бу дәверне билгеләүче язу эпик вакытны белдерсә дә, ягъни ул «борынгы заман, күптәнге вакытлар» мәгънәсендә булса да, соңгы исемлек бер ягы белән кызыклы – анда кабилә исемнәре ачыграк бирелгән, хәлбуки барысы да түгел. Менә ул исемлек: мең, уйшын, алчын (алчын-татар), ак мангыт, найман, сиджут, кыйат, шырын, аргын, барын, буркыт, найман, тама, җалаир, кыпчак, конгырат. Барысы 16 төркем-кабилә. Китерелгән ике исемлек арасында аерма зур булса да (8 берәмлеккә, ягъни яртылаш), аларның уртак нигезләре дә барлыгы күренә. Шуның өстенә, XIII-XIV йөз чыганаклары аркылы торгызылган Алтын Урда кабиләләренең исемлеге белән дә бу соңгы дәвер чыганаклары арасында охшашлык шактый. Димәк, аларда сүз бер үк этник нигез турында бара, ә вариацияләр, бәлки, Җучи Олысының/Алтын Урданың ике канатка бүленгәнлеге белән бәйледер – кайбер очракларда аерым кабиләләр бер генә канатка караганнар, ә башка очракларда бер үк кабилә ике өлешкә бүленгән булырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, Алтын Урданың төп халкының ике иң әһәмиятле этник тамырлы булуы көн кебек ачык: беренчесе – монголлар, икенчесе – төркиләр. Соңгылары исә күпчелекне тәшкил иткән татар этник тамырлы төркемнәрдән булганнар.

Нәтиҗә мондый: алга таба Бөек Монгол Олысы тарихын язганда шушы «татар-монгол» мәсьәләсенә ачыклык кертеп язу кирәк. Ә бу исә борынгы төрки чор белән монгол дәверенең бер-берсенә бик нык бәйле икәнлеген күрсәтәчәк. Шушы яңа карашны алга чыгару өчен чыганаклар бар, аларга фәкать тик башка, әле фәндә урнашмаган, концептуаль яссылыктан чыгып карау гына кирәк.

**Дамир ИСХАКОВ,**
*тарих фәннәре докторы*

# ЖУРНАЛЫБЫЗ ТУРЫНДА



## Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ:

– Журналның язмышы авыр булды, татар әдәбиятының да язмышы шулай иде. Әгәр ул хөр фикерләрне чыгара башласа, йә Мәскәүдән, йә Казаннан чукмар белән аның башын төеп тордылар. Аның хәтерен җимерделәр, әдипләребезне 37нче елларда бер кырсалар, сугыш елларында алар икенче мәртәбә чалгы астында калып харап булдылар. Ләкин журнал чыга килде, журнал яшәде, журнал ул хәтәр җилләрнең уртасыннан барган очкыч кебек давылларга-җилләргә бирешмәде. Бусы хак. Булды, әллә ниләр күрде безнең башлар. Ләкин без монда үзебезнең татарны зур хөрмәт белән искә алыйк. Журналны әдипләр генә түгел, журналны сәяси белгечләр генә түгел, журналны шагыйрьләр генә түгел, журналны татар яклады. Журналны татар ясады, татар рухсытты, татар яшәтте.

Менә мин хәтерлим, сугыш елларында журнал ике мең, өч мең тираж белән чыга иде. Уйга калып, кайвакытта күз алдына китерәм, кемнәр язылды икән, кемнәр алды икән ул журналны, нинди хисләр, нинди уйлар белән кулларына тоттылар икән алар аны. Ничә буын татар «Казан утлары» журналын үзләренең канатлары итеп яшәп килде, татарлыкларын арттырдылар, татарлыкларын расладылар, журналны яшәттеләр һәм үзләре дә яшәделәр.

Шушы уңайдан бер хәвефле уем белән уртаклашасы килә. Менә бүген журналга 70 ел. Әйдәгез әле, тагын бер 70 еллыкка сикереп уйлап карыйк, 60 еллыгына, 50 еллыгына, 30 еллыгына, 10 еллыгына. 10 елда буыннар алмашына, 10 елда буыннар үзгәрә, 20 елдан язучыларның әсәрләре ике процент кына кала. Менә күз алдына китереп карыйк. Бүгенге татар кем ул? Нинди ул? Без бит тынычландыру сүзләре генә әйтергә яратабыз. Имеш, татар йоклаган иде, менә хәзер, имеш, татар уянды. Нинди татар уяна? Карт татар уянамы, яшь татар уянамы? Нигездә татарлыгы аның канында калган, тамырларында ага торган өлкән буын татар уяна. Әле дин аны беркадәр саклап калган, әле ул элеккеге замандагы яхшы игътибарлы, мәрхәмәтле, шәфкатьле, изге татарларны күреп үскән. Ә хәзерге татар нәрсә күрә? Ул татар 10 елдан соң ничек булачак? Димәк, «Казан утлары» алдында бик күп бурычлар тора. Милли аңны үстерүдә ул бик зур эш башкарырга тиешле журнал. Ул әле шуны белергә тиеш: 20 елдан соң татарлар нинди булырга тиеш, 30 елдан соң нинди булырга тиеш – барсы турында кайгырту журнал өстендә. Чөнки без ваемсыз һәм гамьсез татарлар булмыйк инде. Дөнья безне нык өйрәтте бит. Без яратабыз юанырга һәм бер-беребезне юатырга, хәтта ипләп кенә шомартырга, алдашырга да. Ләкин милләт язмышы бервакытта да шомартуга мохтаҗ түгел һәм безнең алдагы мәсләгебез – еракка китеп карау. Шул ерактагы татарны күрә алсак, без татарны яшәтербез, һәм милләтнең дә эзе тарихта беркайчан да суынмас!

*1992*

# IV ХАЛЫКАРА МӘХМҮД КАШГАРИ ИСЕМЕНДӘГЕ ХИКӘЯЛӘР КОНКУРСЫ

Төркиянең Евразия Язучылар берлеге IV Халыкара Мәхмүд Кашгари исемендәге хикәяләр конкурсы игълан итә. Әсәрләр Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә тапшырыла. Соңгы тапшыру көне – 2016 елның 15 августы. Җиңүчеләрне игълан итү – 2016 елның 30 сентябре. Бүләкләү – 2016 елның октябрь-ноябрь айлары. Жюри Язучылар берлеге идарәсе тарафыннан билгеләнәчәк.

**Татарстан буенча бүләкләр:**

Беренче урын – 3 000 төрек лирасы.

Икенче урын – 1 500 төрек лирасы.

Өченче урын – 1 000 төрек лирасы.

**Конкурсның шартлары:**

1. Катнашучылар үзләренең эшләрен билгеләнгән адрес буенча алып килергә, почта яки электрон почта аша җибәрергә тиеш.
2. Хикәяләр башка конкурсларда җиңгән булырга тиеш түгел һәм моңа кадәр беркайда да бастырылмаган булырга тиеш.
3. Эш темасы иректе.
4. Конкурста төрле темага икедән артык эш катнаша алмый. Һәр эш 1 000 (бер меңнән) ким һәм 10 000 (ун меңнән) артык сүздән тормаска тиеш.
5. Конкурста катнашучы эшләрдә бары тик псевдоним гына кулланыла ала; әгәр псевдонимнан башка катнашучының шәхесен танытучы теләсә нинди билге табылса, эш конкурстан алына.
6. Катнашучы түбәндәгеләрне конвертка салып, псевдонимын язарга һәм аны эше белән бергә җибәрергә тиеш:

– шәхес таныклыгы;
– тулы адрес;
– биография;
– бер фотография.

7. Хикәя компьютерда 12ле шрифт белән басылган булырга һәм алты данәдә җибәрелергә тиеш. Призлы урынны алучы хикәя киләчәктә китап итеп бастырылачак, шуңа күрә дискка (CD) яздырылган электрон варианты да булырга тиеш.
8. Конкурста катнашучы хикәяләр кире кайтарылмый һәм автор үзенең авторлык хокукларына дәгъва кыла алмаячак.
9. Призлы урыннарны алган хикәяләрнең барлык хокукларына тулысынча Евразия Язучылар берлеге ия булачак.

**IV Халыкара Мәхмүд Кашгари исемендәге хикәяләр конкурсының Халыкара бәяләү комиссиясе:**

1. Азәрбайҗан – Анар.
2. Балкан илләре – Танәр Гүчлютүрк.
3. Гыйрак – М.Омер Казанжы.
4. Казакъстан – Дандай Ыскак.
5. Кыргызстан – Кыдырали Конкабаев.
6. Үзбәкстан – Таһир Каххар.
7. Төркия – Осман Чевиксой
8. Төньяк Кипр Төрек Җөмһүрияте – Исмаил Бозкурт.

**Халыкара бүләкләр:**

Беренче урын – 15 000 төрек лирасы.

Икенче урын – 10 000 төрек лирасы.

Өченче урын – 7 500 төрек лирасы.

Мактау бәяләмәсе – 2 500 төрек лирасы.

Халыкара бүләкләрне тапшыру тантанасы Казакъстанның Алматы шәһәрендә үткәреләчәк.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ XVIII КОРЫЛТАЕННАН КҮРЕНЕШЛӘР

*(«Казан» милли-мәдәни үзәге, 16 июнь, 2016 ел).*















**Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН**
*фотолары.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

**Быелгы бәйгенең башламнары былтыргы 12нче санда бирелгән иде, яңа укучылар өстәлгәнлектән, аларны кабатлап басабыз. Ярышта балалар да, яшьләр дә, өлкәннәр дә катнаша ала. Бу юлы алты җиңүче (бер – беренче, ике – икенче һәм өч өченче урыннар) билгеләнәчәк. Әҗере булыр. Күләм бер журнал битеннән артмасын иде.**

***

Бигрәк ваклана бу кеше дигәнең. Аңа акча кирәк, мал кирәк. Әйтерсең, дөнья шулардан гына тора. Әй, сез, Адәм балалары! Җир йөзендә мәхәббәт бар!

Берсендә шулай...

***

– Әни, мин күрше Сәлимәгә өйләнәм! – диде Дамир.

– Юк! Юк! Юк! – диде әнисе.

***

Ул дерт итеп уянып китте. «Онытканмын бит!»

***

Синме соң бу, Сания? Хәтерлисеңме, беренче, иң беренче тапкыр очрашуга барганда да, шушы көзге алдында озак кына басып торган идең бит...

***

Менә ничә көн инде Илсурның башында бер генә уй бөтерелә: калыргамы X сыйныфка, юкмы? Китсәң, БДИ бирүдән куркып киткән, диячәкләр. Калсаң...

***

Әлеге вакыйга инде онытыла да башлаган иде. Тик менә бүгенге хәл аны барсының да янәдән исенә төшерде.

***

Зәринә барсын да бер минут эчендә югалтты: сумкасын да, телефонын да, акчасын да... Һәм чит шәһәр уртасында япа-ялгызы басып калды.

***

«Син кайларда йөрисең икән?..» Бу җырны тыңлаганда, күзгә яшь килә... Яшь килә, ә син килмисең. Ике ел инде менә...

***

Арттагы партадан чәчемнән тарткан иде ул. Борылып, акаеплар караган идем үзенә... Чәч күптән кыскарды инде. Тик акыл гына кермәде шул һаман...

***

Чыгарылыш кичәсе безнең өчен кавышу кичәсе дә булды…

***

Кинәт кемдер күземне каплады. Шундый җылы, йомшак иде бу ике кул. Бик тә, бик тә тансык иде миңа мондый җылы игътибар. Тик кем соң бу?

***

Бу заман кызы түгелдер инде мин. Кулъяулык чиктем әле менә. Тик ничекләр итеп кулына тоттырыйм икән моны?

***

«Фәһим Габделәхәтович, минем белән калып шөгыльләнсәгез иде!» — менә нинди язу тоттырган бит XI б дан Назлыкаева… Кирәк булыр инде, әйе, кинәт «икеле»ләр ала башлады бит кызый.

***

Төбендә серле утлар янган кавыштырма казаны! Хыялга чумып, һәр кичне егермешәр, утызар кат урап чыгам бит мин аны… Тукта, тукта, каршыга кем килә ул?

***

— И, зәңгәр күк! Утыз яшемә җитеп тә, үземә пар таба алмадым бит җирдә! Ай кызын булса да төшер инде, ә? — шулай дип әйтүе булды, нәрсәгәдер сөртенеп, мәтәлепләр китте Гафур!

— Хәлең ничек, абзый? «Скорый» чакырыйммы? — Бик тә матур иде бу тавыш!

***

Кайчан кияүгә чыгасың дип теңкәгә тия башлагач, хәйләсен таптым бит: «Пенсиягә чыккач!» — дип җавап бирә башладым. Уйнап әйткәнем… утыз елдан соң чынга ашмасынмы!

***

«Привет! Сколько лет, сколько зим! Таныдыңмы?» Йокыдан уяныр-уянмас, күзләремне уа-уа, планшетымны табып алганда, әнә шундый хат килеп ирешкән иде. Юк, танымадым. Ашыга-кабалана хәбәр иясенең фотоларын барларга керештем. Булмас ла! Үзе микәнни? Үзгәргән…

***

«Элдеңме?!» — дип сүз башлады патрон. Аның исәнләшүе дә, таләбе дә, искәртүе дә, сөйләшүне дәвам итүнең төп шарты да — һәммәсе шул сүзгә сыеп беткән иде.

***

…Ир дигәне җай гына үз көненә яшәп, бернинди наз, ярату хисләрен тойдырмаганга илереп әйтте ул бу сүзләрне.

***

Бер елдан соң эзләп тапты ул Чыңгызын. Менә бергә булабыз, бәхетле тормыш корабыз дигәндә генә, язмыш аларны кабат аерды. Мәңгегә…

**Тагын өч башламны биредәге хикәячекләрнең башында күрерсез.**

## Язмыш сынавы

**Билгесезлек, мөгаен, иң авыр җәзадыр. Кайда ул? Ничек? Кем белән?Аны шушы сораулар гына борчыды.**

Алинә тагын күтәрелеп сәгатькә карады. Инде тугыз тулып килә. Ә Фәрит һаман юк. Кәрәзле телефоны да җавап бирми. Ул бит алтыда гел өйдә була торган иде. Ичмасам, иптәш егетләренең дә телефон номерлары юк. Ышана иде шул Алинә Фәритенә, артык нык ышана иде.

Вакыт соң булуга карамастан, Алинә Алсуга шалтыратырга булды. Ләкин Алсу да шатланырлык бер хәбәр дә әйтмәде. Бары тик: «Көт, үзе кайткач, барын да аңлатыр», – гына диде. Ә нәрсә аңлатырга тиеш соң Фәрите? Бу билгесезлектән тәмам гаҗиз булды Алинә. Арып, диванга барып ятты ул һәм хатирәләр йомгагын сүтә башлады.

Фәрит белән алар узган ел Яңа ел каршылаганда таныштылар. Алинә иптәш кызларына Яңа елны каршыларга килгән иде. Бик теләмичә генә килде ул Алсуларга. Чөнки бәйрәмдә барысы да парлы булырга тиеш иде. Алсу бик үтенеп сорагач, ул: «Барыгыз да парлы-парлы, мин генә моңлы-зарлы булыйммыни? – дип тә карады. Ләкин Алсу барыбер үзенекен итте, Алинәне күндерде.

Менә Яңа ел киче дә якынлашты. Алинә чыгарылыш кичәсендә кигән алсу ефәк күлмәген киде, чәченә күбәләкле бант куйды, иреннәренә беленер-беленмәс кенә иннек тидерде.

Алинә килеп кергәндә, Алсуларда бар да җыелган иде инде. Яшьләр, шау-гөр килеп, шешә тәгәрәтеп уйныйлар иде. Уртада кара бөдрә чәчле мөлаем гына бер егет басып тора. Ул, шешәне тәгәрәтеп җибәрде дә, кемдә тукталыр икән дип, сабыр гына көтә башлады. Менә шешә әйләнүдән туктады. Шулчак Марат: «Күпме теләсәң дә, болай туры китереп булмас иде. Кара әле, шешәнең башы Алинәгә караган түгелме соң?» – дип кычкырды. Барысы да әле яңа гына ишектән килеп кергән Алинәгә төбәлделәр. Марат, шатлыгыннан нишләргә белмәгән сабый баладай, тагын: «Фәрит, ычкындырма бәхет кошыңны, әнә ул, сине көтә», – диде.

Шулчак Фәрит белән Алинәнең күзләре очраштылар. Бу караашта аптырау да, серлелек тә, самимилек тә бар иде. Ләкин аларга озын-озак карашып торырга ирек бирмәделәр. Алсу тиз генә йөгереп килде дә Фәрит белән Алинәне таныштырды. Фәрит Алсуның туганнан-туган абыйсы икән. Әле яңа гына армиядән кайткан.

Бу Яңа ел төне Фәрит белән Алинә өчен кавышу төне дә булды. Шушы бәйрәмнән соң алар бер-берсеннән башка тора алмас булдылар. Фәрит көн саен Алинәне институттан каршы ала, тулай торакка озатып куя. Күпме сөйләшсәләр дә, сүзләре бетмәс сыман иде аларның.

Менә ямьле җәй дә җитте. Сабан туенда Фәрит белән Алинә, гөрләтеп, яшьлек туйларын бәйрәм иттеләр. Бу вакытта алардан да бәхетле кеше юктыр кебек иде бу дөньяда.

Җәйләр үтте, көз җитте. Көннәр бер-бер артлы үттеләр дә үттеләр.

Бүген Алинә институттан иртәрәк кайтты, соңгы парлары булмый, диделәр. Ул, җиң сызганып, бүлмәләрен җыештырды, кер юды. Аннары кыстыбый пешерергә уйлады. Фәрите бик ярата шул кыстыбыйны. Ә чәй эчкәндә үзенең сөенечле хәбәрен җиткерер, «тиздән әти булырсың, бәгърем», – дияр.

Бүлмә җыелган, кыстыбый өстәлдә, чәй әзер. Тик Фәрите генә һаман юк. Алинә күзен йомды һәм йокыга талды.

Ниндидер кыштырдаудан Алинә күзен ачты. Өстәл артында, күзләрен тутырып, аңа Фәрите карап утыра иде. Алинә, ничек итеп сикереп торганын, Фәритнең муенына барып сарылганын үзе дә сизмәде. Тик Фәрите бүген башка көннәрдәге кебек түгел иде: сикереп торып кочагына да алмады, колагына матур сүзләр дә пышылдамады. Бары: «Безгә сөйләшергә кирәк, Алинә!» – диде.

Алинә сак кына урындыкка утырды да Фәритенең күзенә бакты. Фәрит, сүзне ничек башларга белмичә, башта тамагын кырды, аннары, күзен читкә алды да,

акрын гына сөйли башлады: «Алинә, безгә аерылырга туры килер. Алисага әти кирәк. Мин баламның әтисез үсүен теләмим. Төмәндә хезмәт иткәндә, мин Марина белән танышкан идем. Бер-беребезне яраттык. Ләкин безнең бергә булуыбызга әти-әнием каршы килделәр. Шунлыктан Марина минем белән кайтырга теләмәде. Мин инде барысын да оныткан идем. Ләкин кызыбыз Алисаны күргәч, барысы да яңарды: аңа булган хисләрем дә, мәхәббәтем дә. Алинә, мине гафу итә алсаң, гафу ит. Син үзеңә тиңеңне табарсың, балаларыгыз да булыр. Ә мин китәм. Эзләмә мине, зинһар».

Фәрит, күз яшьләрен яшерергә теләп, тиз генә торып басты да ишеккә юнәлде.

Алинәнең аны туктатасы, «Китмә, безнең балабыз булачак!» – дип кычкырасы килде, ләкин теле билтәкләнде. Иреннәре генә: «Бәхетле бул, бәгърем!» – дип пышылдыйлар иде...

**Гөлзадә САФИНА,**
*Казандагы 96нчы гимназиянең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Соң иде инде

**Үләм! Нәкъ шундый җете салават күпере! Аны күргәч, миңа ни дип әйткәнен хәтерли микән Илсур?**

Илсур белән Кабан күле буенда очрашырга сүз биргән иде Айгөл. Кыз соңга калды, тик ул килгәндә егет кулларына кызыл роза тотып көтә иде инде. Айгөлне күргәч, егет аңа талпынды. Куллар кулга тоташты, иреннәр иренгә беректе. Яннарыннан елмаешып та, оялып та үткән халык төркеменә дә игътибар итмәделәр алар. Шулчак, каян килеп чыккандыр, нәкъ алар өстендә генә кара болыт чыкты да, коеп яварга да тотынды. Яшьләр сискәнеп, кая яшеренергә дә белмичә торганда, яуган яңгыр ничек башланган булса, шулай тиз тәмамланды да. Ялтырап кояш та чыкты. Айгөл елмаеп Илсурның чәчләрен сыпырды. Яңгыр чылаткан чәчләре кояшта елкылдыйлар иде.

– Кара әле, Илсур! Нинди салават күпере!

Айгөлнең сүзенә Илсур да борылып карады. Чыннан да, бик матур салават күпере күл өстенә салынган иде. Мондый хозурлыктан кем дә дулкынланыр, егет тә шашынып кызны үбә башлады.

Тыны кысылып:

– Айгөл, бәгърем, чык миңа кияүгә, – диде ул.

Кыз оялып аның күкрәгенә башын салды. Ул тынып калды.

– Җавапны соңрак бирсәм ярыймы?

Кыз әзер иде җавап бирергә, «әйе» дияргә күптән әзер иде. Әмма, нидер тыеп калды аны бүген. Илсурның да дулкынлануы юкка чыкты.

Кызны үзеннән сак кына этәрде дә:

– Кайтыйк инде, – диде.

Үпкәләде егет. Югыйсә, бер-берсен күптән яраталар. Димәк, Айгөл аны яратмаган. Ә үзе гел сөям, дия иде...

Илсур үз уйларына батты.

Салкын гына аерылыштылар. Икенче көнне кыз авылына кайтып китте. Ике-өч көннән, кире шәһәргә килгәч, аңлашырбыз, мин риза, диярмен, дип уйлады кыз. Телефоннан да сөйләшмәделәр алар.

Казанга килгәч, кыз егет янына йөгерергә теләде, тик иптәш кызы аны туктатты. Илсур өйләнгән! Кыз аңа җавап бирмәгәч, егеткә күптән гашыйк булып йөргән күрше кызына өйләнгән егет.

Ай, ашыктың, Илсур! Ашыктың! Ике-өч көн көтсәң!

Айгөл янды-көйде. Тик тормыш дәвам итте. Язмыштырмы, юллары бер дә

кисешмәде, очрашмадылар алар. Инде кыз утызга якынлаша. Һаман ялгыз ул. Ә Илсурның ике баласы бар. Ишетеп кенә белә кыз егет турында.

Шуннан бирле, нигәдер, салават күпере дә күзенә чалынмады. Ул көндәге кебек кояшлы яңгырның да булганы юк кебек.

Әмма менә бүген эштән чыкканда, Кабан күлен урарга уйлады кыз. Ни күрсен: нәкъ теге көндәге кебек яңгыр явып алды, кояш чыкты. Аннары теге көндәге кебек салават күпере! Шундый ук җете, матур!

Кыз елап җибәрде. Дәшми калуы үзен бәхетсез итүен аңлады. Тик соң инде, күптән соң иде!..

## Матур яулык, яшел күз...

**– Әгәр дә әбиләр кебек яулык бөркәнеп, төренеп йөри башлыйсың икән – мин сине ташлыйм! – диде Азат каты гына итеп. – Әнә, дөньяда ниләр бара. Сиңа да берәр сәбәп табып бәйләнсәләр? – Кыз икеләнеп, юк, икеләнеп түгел, уйланып калды...**

Алсу дингә кинәт килде. Беркөн иртән торды да, ниндидер тыелгысыз теләк белән, әбисеннән калган иске дини китапларны актарып, намаз укырга тотынды. Намаздан соң җиңеләеп, иркенәеп калган Алсу үзенә ният куйды: мөселман кануны буенча яшәргә! Бер-ике ай чынлап намазга өйрәнгәч, йөргән егете Азатка да бу турыда әйтергә уйлады. Азат белән бер ел элек дискотекада танышканнар иде алар. Егет җиңелрәк холыклы: уен-көлке ярата, тәмәкедән, аракы эчүдән дә тайчанмый. Киләчәктә бергә булу турында уйлана башладылар инде алар. Үзенә күрә «яратам!» дип йөри Азат. Атасыз үскән егет гаиләле булу теләге белән яна иде.

Беркөн кич Алсу Азат белән күрешергә матур итеп яулык ябынып, озын матур күлмәк киеп чыкты. Әле кайчан гына кино-концертларга йөргән, телефоннан җыр тыңлап йөргән Алсуны бу кыяфәттә күргәч, Азат телсез калды. Аннары үзен кулга алып, кызны тетеп ташлады. Дөньядагы исламга каршы мөнәсәбәтләр турында да, кеше алдында оят икәнлеген дә искәртте. Алсуны ток суккандай булды. Ел буе яратып, ышанып йөргән егеттән бу сүзләрне ишетү бик авыр иде аңа.

Кыз бер сүз әйтә алмыйча, борылып өенә кереп китте. Яулыгын тартып төшереп, идәнгә ташлыйсы килде. Әмма, ни гаҗәп, андый теләк тиз югалды. Ул үзен көзгедән озак күзәтте. Бик матур иде ул. Озак уйланды кыз. Иртән торганда, Азатка булган мәхәббәте күз яшьләре белән юылып сүрелгән иде инде. Ярый әле, өендә аның бу нияте белән килешәләр. Әтисе сабыр кеше, тыныч кына эшләп йөри, әнисе үзе дә дини китаплар укыштыра. Алсу дингә таба баруын дәвам итте. Азат күп тапкырлар очрашырга, аңлашырга талпынды да, кыз йөрәгендә аңа урын юк иде. Азатның да кызга карата мәхәббәте шуның кадәр генә булган, ахры, бүтән аны газапламады ул.

Тормыш дәвам итте. Кыз дин юлында булды. Тыныч кына язгы сессиясен япты. Кайбер кешеләр сәерсенеп карады, кайсысы елмаеп озатты.

Беркөнне Алсу кибеткә ипи-сөт алырга китте. Көн дә йөри торган кибет, нигәдер, бикле иде. Ерактарак урнашканына барырга булды. Керергә дип ишек ачканда, кинәт кенә берәүгә килеп бәрелде. Гафу үтенергә дип авыз ачкан кыз аптырап үзенә текәлгән егетне күрде. Егет пышылдап:

– Сез нинди гүзәл! – диде.

Бу егет үзе дә исламга якынаеп баручы, үзенә теләктәшлек белдереп яшәүче кыз эзләүче Илдар иде. Кызның сылу гәүдәсе, зур яшел күзләре әсир итте аны. Алсу исә күңелендә бөреләнгән хисне сизде, әмма киләчәктә шушы асыл егетнең тугры, акыллы хатыны буласын белми иде әле...

**Гөлшат ДӘҮЛӘТБАЕВА.**
*Арча районының Яңа Кырлай авылы*

# ХАТИРӘЛӘР

## Сары сандугач микән?

Камил Кәримовның үткән сандагы сандугачы, үрдәкләре уятты бу хатирәчекләремне.

Могҗиза түгел диген инде моны! Сандугач сайравын ерактан гына ишеткәләгән бар иде үзе. Ә монда дача бакчабызга килгәндә сандугач алмагачыбызда сайрап каршылады мине! Камил кебек сак кына якынаям моңа. Хәзер очып китә бит инде бу, барма, юньсез, тукта, дип үз-үземне сүгә-сүгә. Метр ярымлап калгач кына тукталдым... Юк, мине һич күрми-тоймый, шундый да илһамланып өздерепләр сайрый бит бу! Басып торам инде шулай әкияти ләззәт кичереп! Каян килә икән ошбу канатлы җан иясенә шундый гаҗәеп җыр, шундый тавыш, шундый илһам дип, һәм шунда...

Тукта әле, сандугачмы соң бу?! Сандугач соры булмый бит инде. «Кара карлыгач микән, сары сандугач микән...» дип җырлаганны ишетеп үскән кеше ләбаса мин! Шулай дидем дә үз-үземә, әкрен генә «Соры сандугач микән?» дип җырлап җибәрдем. Юк, «сары» дип җырлау күп рәхәтрәк икән бит, менә ни «редакцияләгән» икән җыр сүзләрен!.. Аннан, сандугач сайраганны аның соры түшкәенә карап тыңлаган татар ничә генә икән ул дип горурлык та кичереп алдым әле!

## Мөгезле дусларыбыз

Бәләкәй чакта иң якын дустым ел саен алышынып тора иде. Минем генә түгел, дүрт яшькә олы Рәшит абыемныкы да.

Кәҗәбез һәр елны ике бәти тапты. Ап-ак бәтиләр. Аның берсе – минеке, икенчесе абыемныкы була инде. И сөенүләребез шул чакта! «Тасмалыйбыз» үзләрен: муеннарына киң тасма куеп, аңа төрле төстәге тар тасмалар тезәбез. Бәләкәчләребез мич аралыгында яшиләр, әниләре имезергә кереп йөри. Аларның дәртләнеп имүләре әле дә күз алдымда... Гел аралыкта гына яшәмиләр инде, пыр тузып чабып та йөриләр. Үсә төшкәч, җилле генә сикерә дә башладылар. Әле урындыкка, әле караваткa, әле сәкегә сикереп менәләр. Гади генә дә сикермиләр, һавада кыланчык бер борылыш ясап алалар... Иркәлибез инде үз бәләкәчебезне, сыйпыйбыз, аркасыннан кагабыз, мөгез тирәләрен кашыйбыз. Ә кыш җитәрәк аларны суялар да, ашыйбыз инде үзләрен. Тамактан үтә тагын!.. Ләкин, еллар бер-бер артлы уза торса да, суйган чактагы үзәк өзгеч тавышлары хәтердән җуелмады. Тора-бара аларның мәгънәсе киңәйде дә әле: нигә адәм балалары тере җан ияләрен ашыйлар соң? Һәм, ниһаять, тамакны җиңдем: ит һәм балык ашамый башладым. Күңелгә рәхәтрәк булып китте. Һәм, шөкер, тән дә үпкәләми. Утыз ел шулай яшим менә.

## «Әчегән, төчегән...»

Бер елны кышны кичкән, ягъни бәтилектән узып барган кәҗә сатып алдылар безнекеләр. Соры төстәге бик кызык кәҗә иде бу, Рәшит абый аны ияртеп йөрергә дә чыгып киткәли иде. Бер тапкыр мине дә дәште. Бара инде бу янда эт кебек. Бераз алга, бераз янга да чапкалап куя. Авылны чыгуыбыз булды, уңга таба китте бу чабып бөтен көчкә минсиңайтим! 300-400 метрлап чапты бугай. Курыктым инде, качты бу, минәйтәм. Әмма Рәшит абыйның шунда: «Әчегән, төчегән, ипи бирәм, маһ, маһ!» – дип кычкыруы булды, ажгырып килеп тә җитте «этебез». Абыйның нигә алай дип кычкырганын ул чакта сорамаганмын, хәзер менә сорар кешем дә юк инде...

## Табигать мине кочып алды

1982 елны Идел башланган җирдән Казанга чаклы җәяү кайттым. Үзем эшләгән «Татарстан яшьләре»нең 35 көнлек җәяүле экспедициясе булды инде бу. Шунда ике тапкыр урманда адаштым. Беренчесендә тиз котылдым үзе: әтәч аваз салып, Ватан

сугышы каһарманы Лиза Чайкинаның туган авылы Руногa килеп чыктым. Икенчесе исә... кунакханәдә бик көчле яңгыр тавышын тыңлап йоклап китүдән башланган икән.

Урманга килеп кергәч, башта озак кына ләззәт кичереп бардым. Аннары юл сиздермичә генә түбәнгә төшә башлаган һәм яңгыр суы астында калып юкка да чыкты ул. Тагын адаштым! Шунда әтиемнең Рәсәй солдаты килеш Маньчжурия урманында адашкач (1905 елгы япон сугышы алдыннан бу, әти 1877 елгы иде, мин аның төпчек улы), агач башына менеп юл тапканы исемә төште. Мин дә иң биек каен башына менеп киттем. Чайкалып торган очына менеп җитсәм дә, агач башларыннан гайре берни дә күрмәдем. Әмма барудан туктамадым үзе. Су исә тирәнәйгәннән тирәнәеп, инде күкрәк турысына җитә язды. Табигатькәй әнә шулай кочып алды мине!

Берьялгызым ук түгел идем анысы: шәп хор сыман бердәм безелдәп, диаметры бер метр чамасы булган черки өере баш өстендәрәк озатып барды. Туктап, иелеп карта карый башлауга, болар минем башны уртада калдырдылар! Тураеп, ике кулны да селтәп җибәргәч, элекке «позициясенә» кайтты тагын үзе бу ач өер... Кайдадыр еракта берөзлексез торна кычкырды. Соңыннан әйттеләр: бу урманда кабан дуңгызлары һәм ким дигәндә бер (күргәннәр) аю да булган икән әле.

Маҗараны тулаем сөйләп тормыйм. Ул бик авыр да бетә ала иде бит. Ләкин инде караңгы төшеп килгәндә эт өргән тавыш ишеттем мин...

## Ниләр күрми үрдәк башлары

Камилнең «Кыр үрдәкләре артыннан» дигән этюдының дәвамын язу миңа насыйп булды. Казансуның Истанбул паркы турындагы өлешендә ай ярымлап бугай инде ун һәм унбер бәбкәле үрдәк гаиләләрен күргәлим. Камилнең сигез-тугыз еллар элек кылган теге игелегенең дәвамыдыр бу, бәлки? Бер тапкыр боларның яр буенда ятканнарын да күрдем әле. Тик әнкәләре гел муеннарын сузып ялт-йолт каранып тордылар инде. 10-15 метрда гына – җәяүлеләр, велосипедчылар юлы. Этләр дә үткәли моннан. Май урталарында күргән шаккатмалы хәл тиктомалдан гына булмаган инде ул. Сибгат Хәким исемле яр буе урамындагы ике зур йорт төзелешен калай койма уратып алган. Кыр үрдәге шул койма астыннан унлап бәләкәй баласын «ышыкка» алып кереп китте. Ярты сәгатьтән анда дөбер-шатыр эш башланасын каян белсен ди инде ул? Кардәшләрен Камил чыгарышкан Декабристлар урамы кебек киң булмаса да, машина юлы аша үткәннәр бит әле алар! Әнә ничекләр ут йотарга, баш ватарга һәм гайрәт күрсәтергә туры килә икән XXI гасыр әнкә үрдәкләренә!

## И, арысланкай!

Зоопаркка хатыным Дания белән өч ел элек бардык бугай. Күптән барган юк иде, балачакка кайткандай булдык. Һәм менә, карап йөри торгач, таш бина эченә килеп кердек. Монда да шул ук тимер рәшәткәләр икән. Берничә бүлемне карап үткәч, бөтен игътибарым арысланга юнәлде. Ята иде, һәм бик тә кәефсез ята кебек тоелды ул миңа. Күңелкәем әллә нишләп китте. «И, Арысланкай, – дип дәштем шунда эчтән генә. – Бик-бик авырдыр шул сиңа, гаять көчле һәм мәгърур затка, читлектә гомер кичерү!» Сүзгә-сүз хәтерләмим «әйткәннәремне», ләкин мәгънә нәкъ шундый иде. Шулай дип «әйтүем» булды, Арысланкай торып басты һәм миңа текәлде. Күпме шулай күзгә-күз карашып торганбыздыр, белмим, аннары без чыгып киттек. Тагын йөрдек читлекләр карап, ләкин моның тәме юк иде инде миңа. Янә теге бинага кердек. Һәм... без килеп керү белән Арыслан тагын торып басты. Югыйсә каршысында кешеләр дә бар иде инде. Янына килдем, күзгә-күз карашып тагын шактый гына басып тордык. «Хәлеңне аңлыйм, тик ярдәм итә алмыйм шул, киләчәк көннәрең әйбәтрәк булсын иде инде», – дип уйлап куйдым да, кайтып киттек. Юлда уйланып бардым: без, адәм затлары, Җирдә элек безгә кадәр дә яшәгән табигать балаларына, йә, ни бирдек соң?

**Рәфикъ ЮНЫС**

***Табигатьнең хикмәтле якларын күргән «мин»нәр күптер әле ул. Язмалар көтәбез!***



**Гамил АФЗАЛ**

## Неон яктылыгында

Ясалма көн өстә,
Ясалма йон өстә,
Ясалма сөт алда,
Ясалма дәрт канда.
Яңартылган никах,
Ясалма игътибар,
Ясалма соклану,
Ясалма аксымнар...

Ясап куйган бөер,
Тегеп куйган йөрәк.
Урлап алган бүләк,
Сорап алган хөрмәт,
Ясалма елмаю,
Ясалма ихтирам –
Ясалма шаккатып,
Исем китеп торам.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Шикле кеше

Театр директоры Шамил Закиров һәм артист Николай Дунаев белән Алабуга шәһәренә керәшеннәр бәйрәменә барырга чыккан идек. Бик һәйбәтләп директорның җете кызыл «Жигули»ена хозурланып утырдык та киттек.

Шәп кенә итеп барганда, 1552 елда Казан Кремлен шартлату планын төзегән немец Бутлер токымы – бөек химик Бутлеров һәйкәле янында безне милиция туктатты. Машинадан чыгарга боердылар.

Чыгып тезелдек. Горур атлап каршыбызга килгән милиционер алдында каушап калган Шамил, акланган сыманрак итеп:

– Менә бу – күренекле драматург Туфан Миңнуллин, монысы – күренекле артист Николай Дунаев, мин театр директоры булам, – диде.

Милиция өчебезне дә бөркетнекедәй үткен карашы белән тикшереп чыкты да, минем кулдагы дипломатка күрсәтеп:

– Ачыгыз, – дип боерды.

Ачып күрсәттем. Күрсәтмәс идең, кулында резина күсәк – муен тамырыңа менеп төшәргә дә күп сорамас. Кыяфәте шундый.

Минем дипломаттан һәм театр машинасыннан бомба тапмагач, безне җибәрделәр.

Менә уйлап язып утырам: ни галәмәт икән бу? Әллә минем кыяфәтем террорист кыяфәтенә тартым микән, әллә фамилиям шикләндерде микән, әллә надан милиционер «драматург» дигән сүзне ялгыш «демократ» дип аңлады микән?

Разил **ВӘЛИЕВ**

## Китү сәбәбе

1965 елда Казан университетына укырга кергәндә, абитуриент Разил Вәлиевне әдәбият галиме һәм университет доценты Гази Кашшаф әңгәмәгә чакырган. Әңгәмә вакытында булачак шәкертнең кылларын тарткалап, «шүрлегендә ни барын» чамалап карарга ниятләгән ахрысы.

«Нигә Казан университетына керергә булдың?» – дип сораган Гази Кашшаф. Разил аптырап тормаган, кистереп җавап биргән: «Чөнки монда Толстой укыган, Ленин укыган...» «Ярый, әйбәт, дөрес фикерлисең», – дип, Гази ага егетне мактап чыгарып җибәргән.

Икенче курстан соң, Разил, университетны ташлап, Мәскәүдәге Әдәбият институтына керергә ниятләгән. Документларын алырга рөхсәт сорап, Гази Кашшаф янына кергән. «Нәрсә, китәргә булдыңмыни? Моннан ике ел элек кызылавызланып «Толстой укыган, Ленин укыган» дип торган идең, нәрсә булды сиңа?» – дигән Гази ага. «Университетны Толстой да, Ленин да ташлап киткән...» – дип елмайган Разил. Гази Кашшаф кулын селтәгән дә Разилгә документларын бирергә кушкан.

## Фамилияң охшаш булса...

Республика китапханәсендә директор булып эшли башлагач, Разилгә еш кына, эше төшеп, обком секретаре Морзаһит Вәлиев янына йөрергә туры килә. Бу турыда Разилнең хатыны Алия белән бергә эшләгән кешеләр арасында шундый сүз була: «Обком секретаре Вәлиевне ишетеп беләбез. Синең ирең дә Вәлиев. Соңгы арада аның гел обкомга кереп барганын күрәләр икән. Ирең әллә обком секретаре булып эшлиме синең?» – дип сораганнар моннан. «Юк ла, ул бит китапханәдә эшли, 200 хатын-кыз арасында, республикада барлыгы 5 мең хатын-кыз китапханәче бар. Шуларның башлыгы ул. Обком секретаре – башка Вәлиев, минеке – бабком секретаре», – дигән Алия ханым.

## Бүген кая барасың?

Татарстанның халык депутаты булып сайлангач, Разил Вәлиевкә берьюлы Дәүләт Советында да, Милли китапханәдә дә эшләргә туры килә. Өйдән чыгып киткәндә, Алия ханым болай дип сорый икән: «Разил, син бүген иртән кая барасың: эшкәме, әллә Дәүләт Советынамы?»

Илдус **ГЫЙЛӘҖЕВ**

## Төшсә шигырь бәясе

Тукай фәкыйрь булмаган ул,
Санын милләт күтәргән!
Затлы кунакханәләрдә
Күп гомерен үткәргән.
Менә без ул – ыштансызлар –
Кагыйдәдән чыгарма:
Айлык пенсиям дә җитми
Бер кич кунып чыгарга...

## Рәхмәтле кошлар

Өйләре кырыенда мәһабәт өянке төбендәге эскәмиядә янәшә утырган мәлләре. Марсель Гали вакланган солы бөртекләрен кабы белән сибүгә, ботакта йокымсырап утырган күгәрченнәр, дәррәү очып төшеп, җим чүпләргә керешә.

– Ашатма шуларны! Күгәрчен дә булдымы кош! – ди җәмәгате Динә ханым.

– Борынгы заманнарда күгәрчен халкы зур абруй казанган. Король-хан-шаһ-солтаннарның почтальоны булып, алар ил белән ил арасында мөһим хәбәр йөрткәннәр, – ди Марсель Гали. – Мин аларны затлы бабалары өчен сыйлыйм...

– Син аларны ялкаулыкка өйрәтәсең. Нахлебниклар! – дип, Динә ханым һаман үзсүзләнә.

Ул арада, сибелгән җимне ялт иттергән кошлар, канатларын канәгать җилпеп, өянке ботакларына менеп кунаклыйлар.

Марсель Гали, шылтыраган кесә телефонын учына ала... Шул мәлдә өске ботактан нәкъ экранга турылап – ләчперт! Сыек солы коймагы секунд эчендә бөтен экранга җәелә. Динә ханым, борынын җыерып, читкәрәк тартыла:

– Әйттем ич, ашатма шуларны дип!

Марсель Гали, «авторы» кайсы микән, дип өскә күтәрелеп карый, әмма күгәрченнәрнең барысы да бертөрле-ипле тәртиптә утырганын күреп елмая:

– Сүз әйтмә, алар бит... рәхмәт белдереп, телефонга SMS җибәрделәр, – ди.

## Хәвефле ымлык...

– Әй, чәй кайнадымы? – дип кычкырыбрак дәшә Марсель Гали үз бүлмәсеннән. Кухня ягыннан Динә ханым шундый җавап бирә:

– «Әй!» – димә миңа! «Әй!» – дигәнгә, әнә, Сталинның хатыны үзенә-үзе аткан...

## Юлдашлар юмартлыгы

Өч язучы ерак бер районнан машинада кайтып килә. Юл йончыткан. Арыганнар.

Кама күперен чыккач кына салонда җанлану сизелә башлый, кәефләре күтәрелеп китә. Мөхәммәт Мирза учында җылынып беткән телефоныннан хатыны Рушаниянең номерын җыя:

– Күперне чыктык. Әйе, кайтып җитәргә күп калмады. Телефоннан тәмле ис килә, уха пешерәсең, ахрысы. Стерлядь янына судакларны салдыңмы? Алабугаларны онытма – балкондагы суыткычта...

Газинур Морат та, хатыны барлыгын капылт исенә төшереп, телефонын кабыза:

– Әлүү, күперне чыктык, Флүрә. Борай бәлеше дисеңме? Әйбәт! Борай бәлеше ханнар өстәлендә генә булган элек... Актаныш белән Азнакайларга бик тәтемәгән ризык...

Өченче булып Марсель Гали, телефоннан дәшеп, хатыны Динәне кузгаткан:

– Күперне чыгып җиттек. Син анда, фәнни эшләреңнән бүленеп, ашарга пешереп мәшәкатьләнә күрмә... Кайтышлый, минем әле ике өйгә кереп сыйланып чыгасым бар... Ухадыр, бәлештер ашап...

Юлдашларының кунакчыллыгына ышанган Марсель Гали ул көнне ач калган.

Сәхифәне **Марсель ГАЛИЕВ** әзерләде.

## ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ

Ульяновск өлкәсендәге Иске Кулаткы бистәсендә VII Бөтенроссия авыл Сабан туе үткәрелде. Бәйрәмгә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей Морозов килделәр. Башта алар «Гөлчәчәк» балалар бакчасында булды.

Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында бәйрәмне балалар бакчасында ачып җибәрүнең, йолалар белән кечкенәдән танышуның зур әһәмияткә ия булуын әйтте. «Сабантуй – татар халкының үзенә күрә бренды ул. Мин бу бәйрәмгә өлеш керткән һәрбер кешегә олы рәхмәтемне белдерәм», – диде ул. Сергей Морозов та әлеге матур бәйрәмне Ульяновск өлкәсендә үткәрү инициативасы белән чыккан өчен ТР Президенты Рөстәм Миңнехановка чиксез рәхмәтен ирештерде.

Киң колачлы бу Сабантуй милли бәйрәмебезгә хас булган барлык төсләр белән балкыды. Ярышлар, уеннар кызганнан-кызды. Һәркайда җыр-музыка яңгырап торды. Сабантуйның күрке булган көрәштә Мәләкәс егете, Универсиада чемпионы Сергей Павлик – абсолют батыр. Ул ТР Президенты бүләге – «Лада Гранта» автомобиленә лаек булды. Ат чабышында, шул исәптән арбалы атлар узышында беренче килгән Кирюшкино авылы фермеры Равил Яһудинга Ульяновск өлкәсе губернаторы бүләге – «УАЗ» машинасы тапшырылды.

Рөстәм Миңнеханов өлкәнең татар милли-мәдәни автономиясенә микроавтобус бүләк итте.

## АЛМАН ИЛЕНДӘ – ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов өч көнлек эш визиты белән Германиядә булды. Ул Дрезден шәһәрендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәдә катнашты. Әлеге чарага килгән тамашачыларны Г.Тукайның иҗаты белән таныштыру өчен зур мәдәни программа әзерләнгән иде. Германия-Россия мәдәнияте институты бинасының холында кунакларны китаплар һәм милли киемнәр кидерелгән курчаклар күргәзмәсе каршылады.

Р.Миңнеханов үзенең чыгышында Г.Тукайның татар әдәбиятында гына түгел, татар халкының күңелендә дә җуелмас эз калдыруын әйтте, чит илләрдә яшәүче татарларга Татарстан белән багланышларны, телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклаган өчен рәхмәт белдерде. Германия-Россия мәдәнияте институты директоры Вольфганг Шелике котлау сүзе белән чыкты.

## РУС ТЕЛЕ ҺӘМ ПУШКИН

Рус теле көне һәм А.С.Пушкинның тууына 217 ел тулу уңаеннан М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында зур бәйрәм булды. Анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. «Бу бәйрәмне Александр Сергеевич Пушкинның туган көнендә билгеләп үтүебез символик мәгънәгә ия. Рус теле – Пушкин, Толстой, Достоевский теле бүген дөньякүләм яңгырашка ия», – диде ул үзенең чыгышында. Р.Миңнеханов рус һәм татар телләренең, мәдәниятләренең өзелмәс рухи җепләр белән тоташкан булуын да искәртеп үтте.

Театрда үткәрелгән тантанага кадәр ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Казандагы Пушкин һәйкәленә чәчәкләр салдылар.

Ул көнне Р.Миңнеханов Татарстандагы Рус милли-мәдәни берләшмәсе әгъзалары белән дә очрашты.

## «НӘҮРҮЗ» ФОРУМЫ

Казанда IV «Нәүрүз» халыкара театраль белем бирү форумы узды. Ул ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның мөрәҗәгате белән ачылды. Ачылу тантанасында ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Эльвира Камалова, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссёры Фәрит Бикчәнтәев, театр белгече Нияз Игъламов, Германиядән кунак Юрий Альшик чыгыш ясады. Форумда 5 спектакль, 31 семинар һәм тренинглар тәкъдим ителде. Г.Камал театры «Хуҗа Насретдин», «Дон Жуан», «Минем исемем Кызыл» спектакльләрен күрсәтте. Венгрлар гадәти булмаган форматтагы «Вич божий» спектаклен алып килгән иде.

## ЯЗУЧЫЛАР КОРЫЛТАЕ

«Казан» милли-мәдәни үзәгендә Татарстан язучыларының XVIII корылтае булып узды. Корылтайны Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ ачып җибәрде. Әлеге җыенда Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров катнашты һәм чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында Язучы-

лар берлегенең республикада төп иҗтимагый оешмаларның берсе булуын һәм җәмгыятьнең үсешенә уңай өлеш кертүен әйтте. Корылтайда бер төркем язучыларга дәүләт бүләкләре, ТР Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатлары, ТР Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлегенең әдәби премияләре, ТР Мәдәният министрлыгының күкрәк билгеләре, Мактау грамоталары тапшырылды. Аларны ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин тапшырды. Татарстан Язучылар берлегенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турында доклад белән Берлек рәисе Рафис Корбанов чыкты. Ревизия комиссиясе докладын Фарсель Зыятдинов ясады. Докладлардан соң фикер алышуларда Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Әлмәт бүлеге җитәкчесе Рәфкать Шаһиев, язучылар Владимир Лавришко, Рифә Рахман, Айдар Хәлим, Тәлгат Галиуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Диләвәр Османов, Равил Рахмани, Вахит Имамов, Нәҗибә Сафина, Гәрәй Рәхим, Әхмәт Саттар, Рәдиф Сәгъди, Җәмилә Әхтәмова һ.б. чыгыш ясады.

Язучылар берлеге рәисенең хисап докладын, делегатларның чыгышларын һәм фикер алышуларын тыңлаганнан соң, резолюция кабул ителде.

Корылтайда Татарстан Язучылар берлегенең Уставына үзгәрешләр кертелде. Язучылар берлегенең рәисе һәм 27 кешедән торган идарә сайланды. Рәис вазифасына яшерен тавыш бирү юлы белән Данил Салихов тәгаенләнде.

Корылтайны Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Зиннур Мансуров алып бардылар.

Корылтайдан соң Данил Салиховны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул итте.

### УТЫРЫШ

XVIII корылтайдан соң Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең беренче утырышы булды. Аны берлек рәисе Данил Салихов алып барды.

Утырышта рәис урынбасарлары, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы, Әлмәт бүлекләре сәркатипләре, Берлеккә кабул итү коллегиясе, иҗат остаханәләре җитәкчеләре тәгаенләнде.

Язучылар берлеге рәисенең иҗат эшләре буенча урынбасары итеп – шагыйрь Рәмис Аймәт, оештыру эшләре буенча урынбасар итеп Расих Сабирҗанов билгеләнде. Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы, Әлмәт бүлекләрен элеккечә Факил Сафин, Рәфкать Шаһиевлар җитәкләячәк. Берлеккә кабул итү коллегиясе рәисе итеп Тәлгат Галиуллин, коллегия әгъзалары итеп Мөдәррис Вәлиев, Камил Кәримов, Рәмис Аймәт, Равил Рахмани, Луиза Янсуар, Илсөяр Иксанова, Әхәт Мушинский, Фирүзә Җамалетдинова расланды. Иҗат остаханәләрен Газинур Морат (шигърият), Рөстәм Галиуллин (проза), Рәдиф Сәгъди (драматургия), Ләбиб Лерон (балалар әдәбияты), Әхәт Мушинский (рус әдәбияты һәм әдәби тәрҗемә), Рифә Рахман (әдәби тәнкыйть) җитәкләячәк.

### ДРЕЗДЕНДА САБАНТУЙ

17 июнь көнне Алман иленең Дрезден каласындагы Германия-Россия мәдәнияте институты бакчасында үткән Сабан туенда 300гә якын милләттәшебез катнашты. Бәйрәмгә шулай ук Дания, Швеция, Финляндия, Франция, Чехия, Польшада яшәүче милләттәшләребез дә килгән иде… Бәйрәмдә катнашучыларга Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның котлау хатын «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Илфак Ибраһимов ирештерде. Көнозын дәвам иткән Сабантуй программасын Алман илендә милли оешмаларның җитәкчеләре булган Венера Вәгыйзова белән Бари Дианов үзләре үк алып та бардылар. Бәйрәмдә яшьләр, балалар күп иде, алар уеннарда, ярышларда актив катнаштылар. Сабантуйга махсус чакырылган артистларыбыз Фәридә -Алсу дуэты, музыкантлар Муса Маликов, Айдар Вәлиевләрнең чыгышлары ямь өстенә ямь булды. Киләсе ел Сабан туе Братислава шәһәрендә үтәчәк.

### ШАГЫЙРӘ ЮБИЛЕЕ

Узган атнада Чаллы каласының «Энергетик» мәдәният сараенда шагыйрә Рәзинә Мөхиярнең гомер бәйрәменә багышланган тантана узды. Р.Мөхиярне, уннан артык шигъри китап авторы булудан тыш, зыялыларыбыз филология фәннәре кандидаты, Чаллы педагогика университеты доценты буларак та яхшы белә. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Данил Салихов, «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире Вахит Имамов, Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Факил Сафин, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Айгөл Әхмәтгалиева, Чаллы педагогика университеты проректоры Дамир Гыйльманов, филология фәннәре докторы Әнвәр Шәрипов һәм башкалар котлады.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге, татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге казанышлары өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы әгъзасы Харисов Ренат Мәгъсүм улы Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

Татарстанның халык шагыйре Ренат Харисның юбилее Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Шагыйрь мәхәббәте» (авторлары – Резеда Ахиярова, Ренат Харис) операсы белән билгеләп үтелде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повести А.ЗАРИПОВА «Завещание», А.МУТАЛЛАПОВА «Плавающая тележка», Л.САБИРОВОЙ «Горсть гороха», Н.ХАРИСОВОЙ «Десять дней жаркого лета»: рассказы Р.МУХАМЕТШИНА: стихи Г.РАХИМА, Р.ИДИЯТУЛЛИНА, Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, Л.ВАЛИЕВОЙ, Г.КАРИМОВОЙ.*
*«100-страница»: Р.МУХАМЕТШИН. «Кто ты, татарин?»*
*«Литературная критика»: Н.ЮСУПОВА. «О сердцах мы ещё писать будем...»; А.МУБАРАКШИНА. «Родственные перья» о Тукае».*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.Рахман.*
*«В здоровом теле — здоровый дух». Беседа И.ИБРАГИМОВА с главным врачом 18-й городской больницы г.Казани Р.БАКИРОВЫМ.*
*«История»: Д.ИСХАКОВ. «Новый взгляд на этническую историю татар».*
*«Встречая юбилей»: Аяз Гилязов о нашем журнале.*
*«Белый парус»: рассказы Г.САФИНОЙ, Г.ДАУЛЕТБАЕВОЙ.*
*«Природа и я»: воспоминания Р.ЮНУСА.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Хлеба, хлеба»; Казань, озеро Кабан.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novels by A.ZARIPOV «Testament», A.MUTALLAPOV «The floating cart», L.SABIROVA «Handful of peas», N.HARISOVA «Ten days of hot summer»; stories by R.MUHAMETSHIN: poems by G.RAHIM, R.IDIYATULLIN, F.ZAMALETDINOVA, L.VALIEVA, G.KARIMOVA.*
*«100th page»: R.MUHAMETSHIN. «Who are you, the Tartar?»*
*«Literary Criticism»: N.YUSUPOVA. «Still we will write about hearts ...»; A.MUBARAKSHINA. «Related feathers« about Tukay».*
*«Tukay and Tatar literature»: section is conducted by R.Rahman.*
*«A sound mind in a sound body». Conversation of I.Ibrahimov with the chief physician of the 18th city hospital of Kazan R. BAKIROV.*
*«History»: D.ISKHAKOV. «A new view on ethnic history of the Tatars».*
*«Meeting anniversary»: Ayaz Gilyazov about our magazine.*
*«White Sail»: stories by G.SAFINA, G.DAULETBAEVA.*
*«Nature and Me»: memories by R.YUNUS.*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*From the photo archives of the magazine.*
*Diary of the social-cultural life.*
*On our covers: «Bread, bread»; Kazan, the lake Kaban.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Игеннәр, игеннәр...»

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казан, Кабан күле.